
# КАЗАН УТЛАРЫ

5. 1998



# Tatarstan Respublikasь Prezidentь
## UKAZЬ


### 1998 jьlda Tatarstan Respublikasьnьn Ƣ. Tuqaj isemendəge Dəwlət byləklərem biry turьnda



R. Minnullin



F. Bikcəntəjef



N. Dunajef



N. Ixsanova



Ə. Şakirof

Tatarstan Respublikasьnьn Ƣ. Tuqaj isemendəge Dəwlət byləge komitetь təqdimnəren qaraƣannan son, ***qarar birəm:***

1998 jьlda Tatarstan Respublikasьnьn Ƣ. Tuqaj isemendəge Dəwlət byləkləren tybəndəgelərgə birergə:

1. Şaƣir **Robert Məƣəllim ulь Minnullinƣa,** «Kyctənəc» digən balalar kitabь ɵcen («Məƣərif» nəşriatь, 1995 jьl);

2. T. Minnullin pjesasь bujьnca qujьlgan «Xuşьƣьz!» spektakle ɵcen Ƣ. Kamal isemendəge Tatar dəwlət akademia teatrьnьn içat tɵrkemenə:

spektaklne qujucь rezissjor **Fərit Rəfqət ulь Bikcəntəjefkə;**

Miləwşə, Nurislam, Ƣaliulla obrazlarьn içat itkən aktjorlar — **Nəçibə Ƣimaj qьzь Ixsanovaƣa, Nikolaj Ivanovic Dunajefqa, Əzhər Şəfiq ulь Şakirofqa.**

Tatarstan Respublikasь Prezidentь **M. Ş. ŞƏJMIEF.**

Qazan, Kreml'.
1998 jьl, 24 april.

# Казан утлары
# Qazan utlarь

1998

# 5

(907)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

**Татарстан хөкүмәте,**
**Татарстан Язучылар берлеге,**
**редакциянең хезмәт коллективы**

Баш мөхәррире
**Равил Фәйзуллин**

**Идарә:**
Гариф Ахунов, Харрас Әюпов, Нәҗип Бакиров, Хәлим Гайнуллин, Тәлгат Галиуллин, Миркасыйм Госманов, Аяз Гыйләҗев, Флүс Латыйфи (*баш мөхәррир урынбасары*), Салих Маннапов, Туфан Миңнуллин, Хатип Миңнегулов, Ринат Мөхәммәдиев, Нажар Нәҗми, Рашат Низамиев, Булат Солтанбәков, Ренат Харис, Розалина Шаһиева.

**Мөхәррирләр:**
Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Алмаз Гыймадиев, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Марс Шабаев.

**Гамәли хезмәткәрләр:**
Тәслимә Сибгатуллина, Гөлзадә Фәйзуллина, Лилия Гатауллина, Альбина Әхмәтова, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.

**Исәп-хисап бүлеге:**
Асия Рәхимова.

✉✉:
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎:
Баш мөхәррир — 49-36-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61, чәчмә әсәрләр, хатлар, тәнкыйть — 49-36-63, корректорлар — 49-36-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Роберт МИҢНУЛЛИН. Китеп барам көләч җәйдән. *Шигырьләр* ..... 5
Суфиян ПОВАРИСОВ. Күкнең җиденче катында. *Роман* ..... 12
Нур ӘХМӘДИЕВ. Чакматаш. *Шигырьләр* ..... 70
СӨЛӘЙМАН. Мәңгелек көй. *Шигырьләр* ..... 74
МӘГЪСҮМ ХУҖИН. Тар тыкрык сукмагы. *Хикәя* ..... 80

УКУЧЫЛАРЫБЫЗ ИҖАТЫ

Флюза МӘҮЛИКАЕВА, Афина ГОБӘЙДУЛЛИНА, Рәхимә ВӘЛИУЛЛИНА, Наил ЗИННӘТУЛЛИН, Даим ЯУШЕВ шигырьләре ..... 111
Нурулла ГАРИФ. Парчалар ..... 121

ПУБЛИЦИСТИКА

Марсель ЗАРИПОВ. "Кара май"ның калҗасы ..... 128

ӘДӘБИ МИРАС

Габделбари БАТТАЛ ТАЙМАС. Мин бер яктылык эзләгән идем ..... 144

МӨХӘММӘТ САДРИГА — 85 ЯШЬ

Рәдиф ГАТАШ. Бәхет турында җыр ..... 170
Мөхәммәт САДРИ. *Шигырьләр* ..... 171

ХАТИП ГОСМАННЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Рәшит ЯГЪФӘРОВ. Хатип ага ядкаре ..... 173

БУЛАТ СӨЛӘЙМАННЫҢ ТУУЫНА 60 ЕЛ

Ризван ХӘМИД. Каһарманнар затыннан иде ул ..... 176
Булат СӨЛӘЙМАН. Аучы өенә кире кайтмады ..... 177

СӘНГАТЬ

Рифат Фәттахов. Утырзая кебек... (Мәшһүр җырчы Рәшит Ваһаповның туына 90 ел) ..... 180
Истәлекләр ..... 182

КИТАП КҮЗӘТҮ

Әлфинур НӘҖИПОВА. Олы әдип "Кичү"е ..... 187
Латин имласында уку күнекмәләре. Шамил Маннапов. Сәнгать корбаннар сорый ..... 189
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 191

# В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

"Проза и поэзия": начало романа С. ПОВАРИСОВА "На седьмом небе", рассказ М. ХУЗИНА "Тропинка узкого переулка"; стихи Р. МИННУЛЛИНА, Н. АХМАДИЕВА, СУЛЕЙМАНА. "Творчество читателей: стихи Ф. МАВЛИКАЕВОЙ, А. ГУБАЙДУЛЛИНОЙ, Р. ВАЛИУЛЛИНОЙ, Н. ЗИННАТУЛЛИНА, Д. ЯУШЕВА, этюды Н. ГАРИФА.
"Публицистика": отрывок из книги М. ЗАРИПОВА, посвященной Татарской нефти людям нефтяного края.
"Литературное наследие": Г. БАТТАЛ ТАЙМАС. "Я искал красоту жизни".
"К 85 — летию М. САДРИ": статья Р. ГАТАША "Песнь о счастье" и стихи юбиляра.
"К 90-летию Х. ГУСМАНА" посвящена статья Р. ЯГЪФАРОВА. "К 60- летию Б. СУЛЕЙМАНА": статья Р. ХАМИДА "Родом из отважных" и стихи Б. СУЛЕЙМАНА.
"Искусство": статья Р. ФАТТАХОВА посвящена к 90-летию известного певца Р. ВАГАПОВА. Воспоминания об артисте И. ШАКИРОВА, М. МАГДИЕВА, Д. СИРАЗЕТДИНОВОЙ.
"Книжное обозрение": А. НАЗИПОВА рецензирует книгу Н. ФАТТАХА.
"Навыки чтения на основе латинской графики.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Шамаиль — работа художника Ф. ГИРФАНОВА; писатель ЗАУДАТ ДАРЗАМАН.

# IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and Poetry": S. POVARISOV'S novel "In the 7 th sky", M. KHUZIN'S story "THE PATH OF DISTRICT LANE"; the verses of R. MINNULLIN, N. AKHMADIEV, SULEYMAN.
"Creation of readers": the verses of F. MAVLIKAEVA, A. GUBAIDULLINA, R. VALEULLINA, N. ZINNATULLINA, D. YAKUSHEV, N. GARIPH'S etudes.
"Publicism": the fragment from M. ZARIPOV'S book olevoted to people of oil megion.
"Literary heritage": G. BATTAL TAIMAS "I WAS LOOKING FOR BEAUTY OF LIFE"
"Commemorating the 85 th Anniversary of M. Sadri": R. GATASH'S article "The song about happiness" and M. Sadri's verses
"Commemorating the 90 th Anniversary Kh. Gusman ": R. YAGAFAROV'S article.
"Commemorating the 60 th Anniversary B. Suleyman" R. KHAMID'S article "FROM BRAVES" and B. SULEUMAN'S verses.
"Art": R. FALLAKHOV'S article devoted to commemorating the 90 th anniversary R. VAGAPOV.
Remembrances about artist of I. SHAKIROV, M. MAGDIEV, G. CIRAZETDINOVA.
"Books survey": A. NAZIPOV'S review to the I. FATTAKH'S book
Skill of reading on the base of Latin script.
The diary of social and cultural life.
In our covers: shamail — F. GIRFANOV'S work; writer JAUDAT DARZAMAN.


★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-36-62 телефоны белән басмахәнәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итергә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 02.04.98 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108¹/₁₆.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 14095. Заказ Я-174
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2


© «Казан утлары», 1998 ел.

# ШИГЪРИЯТ



## Роберт Миңнуллин

### КИТЕП БАРАМ КӨЛӘЧ ҖӘЙДӘН

#### Үз иледә

Үз илеңдә яшәү бәхеттер ул —
Үләне дә аның бәрхеттер ул.

Бәхеттер ул үз көеңне көйләү,
Рәхәттер ул үз телеңдә сөйләү.

Гомер узды кеше көен көйләп,
Гомер узды башка телдә сөйләп.

Рәхәттер ул газиз үз өеңнең,
Рәхәттер ул газиз үз илеңнең

Капкаларын ачып керүләре,
Үз көнеңне үзең күрүләре!

Моңланабыз һаман чит телләрдә,
Күзләребез һаман чит илләрдә...

Үз илеңдә яшәү бәхеттер ул,
Тупсасы да аның тәхеттер ул.

#### Яшьлеген эзләүче шагыйрь

Йөргәндә Базы буенда,
Малай-шалай шикелле,
Җитмеш яшьлек Әхсән Баян
Ярдан суга сикерде.

Җитмәде суы тезгә дә...
Муеннан иде бит ул,
Үскәндә һәрчак шушында
Коенган иде бит ул.

Һаман агып бетә алмый,
Һаман ага Базы да.
Базы белән агып бара
Туган якның назы да.

Таллыклары да киселгән,
Ярлары да ишелгән...
Бу минутта ниләр генә
Уйлыйдыр ул эченнән?!

Эзләп китте ул аннары
Балачагы чишмәсен...
Чишмәсен дә тапмагачтын
Шагыйрь җаны нишләсен.

Күңелләре дә нечкәрде,
Күзләре дә дымланды.
Сагынды да уйланды ул,
Уйланды да моңланды.

Авылының сукмакларын
Шагыйрь озак таптады,
Тик ул малай чакларын да,
Яшьлеген дә тапмады.

Ә шагыйрьнең кодрәте зур! —
Шулай борын-борыннан...
Яшьлегенә кайту гына
Килми аның кулыннан.

## Төнге моңсулык

Бигрәк моңсу була икән
Көзнең алтыны да.
Калтырата иртә-кичен
Чыклы салкыны да.

Бигрәк моңсу көннәре дә,
Ямансу төне дә.
Айның аның эше беткән —
Чыкмый бер өне дә.

Айга нәрсә? Ул бит үзе
Моңлана да белми.
Мине генә моңландыра...
Булмагандай берни.

Бер тавышсыз-тынсыз гына
Йөзә дә ай йөзә —
Үзе өзгәләнмәсә дә
Үзәкләрне өзә.

## Күккә ашкан шагыйрь

*Башкортның илаһи шагыйре Рәшит Назаровка*

Илһамын Шагыйрь Ходайның
Үзеннән алган.
Ә шигырьләре... башкортның
Җаныннан тамган.

Ул — күңелдә мәңге кипмәс
Яшь булып калган.
Ул Бабичтан, Тукайдан да
Яшь булып калган.

Шигырьләрен, әйтерсең лә,
Аксакал язган.
Илаһи Шагыйрь буралмый
Акылдан язган.

Язса да язган ул шигырь,
Язган... эшләгән.
Ә аннары күккә ашкан!
Кире төшмәгән.

Ходай янында калган ул! —
Менә нишләгән.

* * *

Без күбебез озын кыш буена
Табаннарын имеп яткан аю.

Исәбебез — эшләмичә генә
Тәмле ашау һәм ничек тә баю.

Иң зур теләк — иртән баш төзәтү,
Ә төп һөнәр — урлашу һәм алдау.

Кода-кодагыйлык, хәрәмләшү
Һәм халтурщик дус-ишләрне данлау.

Булмаячагын да белгән килеш
Алтын, көмеш таулар вәгъдә итү.

Өч тиенлек талант булмаса да
Бөеклеккә, данга дәгъва итү.

Астагыга — гел кимсетеп карау,
Каргыш, тиргәш, ләгънәт — өстәгегә.

Битарафлык һәм игътибарсызлык
Башкаларның хәер эстәвенә.

Кешеләргә эшләгәннәребез —
Әшәкелек, хөсетлек һәм этлек.

Төшә-төшә, үзебез дә сизми,
Шушы көнгә менә төшеп беттек.

Рәхәт икән — телсез балык булу,
Әйбәт икән — мәхлук сарык булу.

Бөтен теләк — бушка рәхәт чигү...
Өстәвенә, бөек халык булу!

## Төнге кошлар

Ябалаклар чыккан төнге ауга —
Төннең карасына.
Эләктеләр алар машинаның
Якты фарасына.

Белми алар кая очарга да
Безнең якты уттан.
Уттан качкан кебек кача алар
Төнге яктылыктан.

Сез — төн кошы,
Сез — төн хуҗалары!
Юк сез көндезләрен.
Мин бит әле бала чагымда ук
Сезне күп эзләдем.

Сезнең ухылдаудан гел алына
Иде минем өнем.
Сез очасыз фәкать караңгыда,
Җанланасыз төнен...

Мин дә төнге ябалактыр, ахры,
Мин дә төнге коштыр.
Төннәр буе шигырь язган булам
Мин дә кыштыр-кыштыр.

Тормыш мәшәкате — көндезләрен...
Шулай көн дә менә.
Шагыйрь итеп тоям мин үземне
Фәкать төнлә генә.

## Ренат Харис шигырь укый

Ренат Харис шигырь укый
Шундый татлы иттереп,
Шундый ләззәтләнеп китеп,
Шашып, шартын китереп.

Укыганда ялкынланып
Битләренә ут каба.
Болай да зәңгәр күзләре
Күз алдында мутлана.

Һәрбер шигырь юлы саен
Кайнарлана каннары.
Хәйләкәр елмаеп, безгә
Карап ала аннары.

Укыганда тамагын да
Кырып-кырып алгалый...
Ренат Харис шигырь укый.
Укыганы — Кандалый.

Иң татлы урыннарында
Юри туктап алгалый.
Бу — бөтенләй башка Харис,
Бу — өр-яңа Кандалый.

Шигырьләрдәге ул кызлар! —
Йөзләре, имиләре...
Бер як читтә торсын икән
Шәрекънең Җәмиләре.

Ренат Харис шигырь укый.
Шагыйрь күңле алдамый...
Чыннан да бөек икән шул
Габделҗаббар Кандалый!

* * *

Әллә инде яшьлек кабатланмас,
Кире кайтмас гүзәл чор микән?
Искә төшкән саен бәгырьләрне,
Үзәкләрне өзәр җыр микән?

Күңелеңдә, яшь чактагы кебек,
Һаман сөю, һаман наз микән?
Миңа дигән кайнар тойгыларың
Бик күп микән, әллә аз микән?

Кара кашың һаман кыйгач микән,
Керфекләрең һаман ук микән?
Йөрәккәең, яшь чактагы кебек,
Һаман ялкын, һаман ут микән?

Чәчләрдәге аклык әллә инде
Картлык алып килгән кар микән?
Бу дөньяда бездән бәхетлерәк
Карт гашыйклар тагын бар микән?..

## Ярату

Яратам сине, кадерлем!
Син — иң якын кешемдер.
Сине нигә яратамдыр? —
Әйталмыйм, ни өчендер...

“Нигә яратасың?” — дисең.
Анысы нигә инде.
Гел бер сорау биреп минем
Җаныма тимә инде.

Синең өчен янып-көеп
Яшьлекләр үтте китте.
Сорама ник ратканны.
Яратам! Бетте китте...

## Чабам гомер атында

Әй чабам гомер атында! —
Тыеп булмый ул атны.
Малай чаклар, чаптар чаклар
Ул атны күп дулатты.

Шул чакларым кулын болгап
Кала минем артымда.
Кайчан ташлап калдырыр дип
Чабам гомер атында.

Ә гомер атым — иярсез,
Гомер атым — йөгәнсез...
Андый атның ниндилеген
Сез үзегез беләсез.

## Кайчагында...

Була авыр халәтләрем,
Сәгатьләрем, көннәрем.
Андый көннәрдә дөньяның
Тиргим әллә кемнәрен.

Андый чакта дөньясына
Килә бер төкерәсем,
Бөтенесен бетерәсем,
Аюдай үкерәсем...

Сиңа бар да дошман кебек,
Килеп тешләрләр кебек.
Тешләмәсәләр дә берәр
Этлек эшләрләр кебек.

Кайчагында кешедән дә,
Үзеңнән дә туясың.
Аптырагач, эчтән генә
Сүгенеп тә куясың.

Башны кара урманнарга
Килә алып качасы,
Килә кайчак шашкын булып,
Ташкын булып ташасы...

Түзә икән йөрәк — күпме
Янмасын, чукылмасын.
Чукынсын да дөньялары!
Юк әле, чукынмасын...

## Күзгә киттек, әйдә!

Күз алдында үзгәрә җәй —
Алыштыра төсен.
Чыга да кояш югала,
Көн дә явым-төшем.

Мондый түгел иде лә җәй
Әле кичә генә.
Күзгә таба авыша ул
Сиздермичә генә.

Үзгәрәм бугай үзем дә...
Күздән сагыш тама.
Китеп барам көләч җәйдән
Моңсу күзгә таба.

Килә тизрәк моңланасым,
Күздән моң аласым,
Моңсу күзләрнең эченә
Кереп югаласым...

Моңсулыкка китеп барам,
Тәгәлләнә җәй дә.
Кемнәр бара минем белән? —
Күзгә киттек, әйдә!



## Чәчмә әсәрләр



# Суфиян Поварисов

# КҮКНЕҢ ЖИДЕНЧЕ КАТЫНДА

РОМАН

## Үземнән — күңелемнән

*Фараз итәм: мин — җиләк бакчасында. Бик эре җиләкләр. Чыпчык башы зурлык. Кып-кызыл. Янып торалар. Һәрберсенең эчендә, әйтерсең, кояш бар. Күзем әле берсенә, әле икенчесенә йөгерә. Ә күңелем әйтә: сайланма — җый. Әмма ашыкмыйм. Кайсын өзәргә белми гаҗизләнәм.*

*Галимҗан Ибраһимов турында роман язарга булгач, нәкъ шундый гараиб-аптыраулы хәлдә калдым. Зур шәһрәт. Гаҗәеп киң даирә. Калебе-холкы кәбестә шикелле катлы: усал, кырыс, моңлы, тәкәббер, хисле, тойгылы, үзсүзле, башбирмәс, кешелекле, кечелекле, зиһенле, аңлы, көрәшчән, йөрәкле, туган җанлы, көчле рухлы, чирләшкә... — тагы да әллә ниндиләр, әллә нәрсәләр. Кайсы уңай? Кайсы кире? Бәгъзе берсе, кире як дип уйласаң, тышы ямьсез алманың эче тәмле булган кебек, уңай сыйфатка исәпләнә дә куя. Күпме сыйфат-фигыль-холык бер шәхес табигатендә!*

*Хезмәт — бәхет чишмәсе. Хезмәт зурлый адәм баласын. Хезмәткә мөнәсәбәттә кешенең рухи дөньясы, психологик халәте, күңел даирәсе, яшәү сәләте, ныклыгы шуларга охшаш әллә күпме эчке хосусияте ачыклана. Табиб, укытучы, нефть, колхоз рәисе, көтүче, төзүче, хәбәрче, очучы, фән кешесе... — кемнәр турында гына язылмый романнар. Язучы, нефтьче турында әсәр иҗат итә икән, ул бу фәнне шул һөнәр әһеленнән артыграк белергә тиеш. Галимҗан Ибраһимов — язучы, тарихчы, әдәбият галиме, публицист, методист, педагог, тел галиме, тәнкыйтьче, революционер... Һәммәсе диярлек — язучы каләмен бигүк санга сукмый торган «тәкәббер» һөнәрләр. Берсе буенча гына (әйтик, тел галиме) эш итү дә шактый кыен. Шулай булгач: «Ни пычагыма тотындың мондый четерекле эшкә?» — дип, чатнатып сорау бирүчеләрнең дә очравы мөмкин.*

*Мәсьәлә болай тора. 1957 ел. Татарстанның Актаныш районындагы Бурсак мәктәбе директорымын. Үшән генә алашамны иске читән арбага (тарантаска) җигеп, райүзәккә төштем (25 чакрым чамасы). Укытучылар өчен хезмәт хакы алырга. Китап кибетенә керсәм, үз күзләремә үзем ышанмый торам: Галимҗан Ибраһимов әсәрләре мәҗмугасы. Өч томлык. Алдым. Май азаклары иде шикелле. Бик матур кояшлы көн. Юлда — кайтканда — үшән-ялкау алашамны үз иркенә куеп, беренче томның сәхифәләрен актарам. «Яз башы» хикәясе. Оһ, бу нинди сихерле дөнья! Тел диңгезе! Ә ул диңгездә сүз гәүһәрләре! Ул гәүһәрләр йөрәккә, күңелгә шигъри моң булып тула. Әнә кайда*

---

Журнал варианты

*икән телнең тылсымлы көче, шигърияти ялкыны, эстетик ләззәте, зәвыклылык кодрәте!!!*

*Рәхмәт алашама: ашыкмый, пошмый, йокымсырап атлый бирә —халәтемне аңлый, күрәсең.*

*Язмыш җилләре мине бервакыт туган якларыма — Уфага китереп ташлады. «Кызыл таң» да эшләү. 1960елда Башкорт дәүләт университетында укыта башлау. Кандидатлык диссертациясе яклау. Докторлык диссертациясенә әзерләнә башлагач, Галимҗан Ибраһимовның тел диңгезенә чумып, анда аркылыга-буйга йөзә-йөзә, бервакыт төбенә үк төшеп, сүз энҗеләрен ныклап җыярга тотындым. Әдипнең туган авылы Солтанморатка да еш барам. Әнә нинди бай табигать бай күңелле киң даирәле, моңлы, хисле иткән икән кырыс холыклы Галимҗанны. Җиде буынын тикшердем бу нәсел-кавемнең. Җиде буын башында — Ибраһим хәзрәт. Галимҗанның әтисе Гыйрфан мулла: «Нәселебез чишмә башы Ибраһим пәйгамбәрдән», — дип әйтә торган булган.*

*Әнә шулай кереп киттем мин бу шан-шөһрәтле гаилә балалары дөньясына. Ихлас күңелем, тынгысызланган йөрәгем, бөтен вөҗүдем, кайнар хис-тойгым, әсәрләнгән уйларым белән. Ниндидер шайтан төшләремә керә-керә котырта башлады: «Яз, яз, яз, роман яз!» — ди. Моны якыннарыма сөйлим. Алар көлә. «Шәп, изге күңелле шайтан булган бу; язмасаң, барыбер йоклатмас, тынгылык бирмәс, яз», — диләр.*

*Бу хакта Уфада да, Казанда да күпләр әйтте. Янә эзләнү, уйлану, борчылулар башланды. Галимҗан Ибраһимовны, иҗатын, озак тыюлардан соң, яңадан халкыбызга кайтаручыларның берсе, язучының иҗаты һәм тормыш юлы турында докторлык диссертациясе яклаган академик Мансур Хәсәнов белән кат-кат фикер алышу, мәслихәтләшүләр булды. Аксакалыбыз Гомәр ага Бәширов бик күп файдалы киңәшләр әйтте.*

*Мин Галимҗан Ибраһимовның балалык һәм яшьлек еллары турында гына язарга булдым. Шуңа күрә роман «Яшьлек иртәсе» дип аталып, «Казан утлары»нда басылып та чыкты (1996, N 10, 11). Шуның белән язарга котырынган нәфесем басылды шикелле. Башкортстан җәмәгатьчелеге нык шатланды — миңа рәхмәт әйттеләр. Әдип туган Авыргазы районы үзәгендә. Аның авылы Солтанморатта «Яшьлек иртәсе» романы буенча китап уку конференцияләре булып үтте. РОНО оештырды аны. Башкортстандагы татар мәктәпләрендә укытырга кирәк, дигән уртак фикергә килենде. Моңа башка районнар да кушылып китте. «Башкортстан укытучысы» журналында әдәбият дәресләрендә романны ничегрәк өйрәнергә кирәклеге турында мәкалә дә язылды. Әмма котырынган нәфесемнең басылуы белән халык килешмәде. Романны дәвам итәргә, икенче кисәген язарга димләделәр.*

*Әйтүе җиңел ул. Ә менә язуы — кыен. Ул бит теләсә кем түгел — Галимҗан Ибраһимов! Кайсы яктан эләктереп алырга мәсьәләсенең мөгезен? Иҗат һәм тормыш бакчасындагы әлеге өлгергән эре-эре җиләкләрнең кайсын өзәргә? Мин аларны барыбер җыеп бетерә алмыйм бит. Калганнарын башкалар чүпләр. Икенче төрле әйтсәк, бу зур шәхес турында роман язучы янә табылыр әле.*

*Мәгълүм ки, әдәби әсәр үзәгендә — кеше образы. Мине, барыннан да элек, Галимҗан Ибраһимовның кешелеклек сыйфатлары кызыксындыра. Үзәк чылбырга куелды бу мәсьәлә. Документаль әсәрне сәнгать дәрәҗәсенә күтәрү бик кыен, әлбәттә. Чөнки анда хыял-фантазиягә чик куела. Бер үк нәрсә турында төрлечә сөйлиләр. Кайсы дөрес икәнлекне ачыклау да кыен. Шуңа күрә: «Нигә бу хакта гына язылган, ни өчен тегесе юк?» — дип әйтүчеләр дә булырга мөмкин.*

*Роман язуымны белгәч, төрле урыннан хатлар да килә. Урамда туктатып киңәшләшүчеләр дә табыла. Һәркемдә ярдәм итү теләге зурлыкны аңлап шатланам. Чынын әйтсәк, Галимҗан Ибраһимов турындагы роман Солтанморат халкы күңеленә ныклап язылган икән инде. Анда еш булам. Өйдән-өйгә кереп йөрим. Элек Галимҗан Ибраһимовларның күршесендә генә яшәгән Фәсәхәт абыстай (ул инде йөз яшьне түгәрәкләде) күпне сөйли. Яшьләр дә өлкәннәрдән ишетеп яхшы белә Галимҗан Ибраһимовны. Алар минем эшне нык җиңеләйтә. Шуңа күрә, форсаттан файдаланып, бөтен Солтанморат, Авыргазы халкына, матур, мәгънәле киңәш бирүчеләргә ихлас рәхмәтемне әйтәсем килә.*

АВТОР.

## Беренче бүлек

*Әллә тәкъдир, әллә язмыш, әллә ялгыш,*
*Ни котырта адәм баласын?*
*Алда томан, михнәт, кылыч күпер, дәҗҗал,*
*Беләме ул кая барасын?*

### I

1906 елның көзендә Гыйрфан мулла Оренбурдагы Вәли мулла мәдрәсәсеннән куылган, аның уйлавынча, җилгә каршы төкерә торган, үзсүзле улы Галимҗанны шушы Уфа шәһәреннән “Галия” мәдрәсәсенә китереп куйды. Троицк, Орск, Эстәрлетамактагы мәдрәсәләр хәзер Гыйрфан мулла өчен карга оясы кебек кенә тоела. “Галия” — гарәптән кергән сүз. Югары, бөек, өстен дигәнне аңлата. “Галия”, имеш, Казандагы “Мөхәммәдия”, Оренбурдагы “Хөсәения” мәдрәсәләреише генә булмаячак.

Тик — алтын сарай өмет иткәндә, алама куышка килеп кергән кебек булды бу. Баксаң, “Галия”нең әле бинасы да юк икән. Барысы да Алла кулында. Хәзергә шәкертләр Зариф мулланың мәчетендә генә укып йөрергә тиеш. Ул бәләкәй генә. Оренбурдагы Вәли мулланың кадими мәдрәсәсеннән һич тә артык җире юк икән. Әмма бер яманлыкның бер бер яхшысы була дигән кебек, мәдрәсә хакимияте башлыгы Зыя Камали җәнаблары икән. Ул инде каты куллы, алтын акыллы, тирән мәгълүматлы, дин вә фән дәрьясында балыктай йөзә торган остаз, имеш, шуңа күрә аны күрми, маңгайны маңгайга, йөрәкне йөрәккә куеп сөйләшми торып, кайтып китмәскә булды Гыйрфан мулла.

Тик синең ак юлыңа һаман шул кара елан сузылып ята. Атна чамасы вакыт үтеп китте. Тәкате корып бетте — очратып булмый алтын башлы остазны. Оятын олтырак итеп, фатирына да барды. Әмма өйдә юк иде. Ул әлеге дә баягы шул “Галия” мәдрәсәсен ачу, укыта башлау, шәкертләрне вакытлыча булса да яхшы урнаштыру эшләре белән ут йотып йөри икән.

Зыяэтдин әл-Камалины, ниһаять, Зариф мулла мәчетендә очратты ул. Алар ишек төбендә маңгайга-маңгай бәрелешә яздылар хәтта. Башта бер-берсенә сүзсез генә карашып тордылар. Зыя әфәнде уртача буйлы, юка-чандыр гәүдәле икән. Йөзен карлыгач канатыдай матур кара мыек бизи. “Әссәламегаләйкем!” — “Вәгаләйкем әссаләм!”не әйтешеп алгач, кул бирешеп күрешкәннән соң, үзен кыю тотарга тырышып, җайлап кына сөйләшергә тырышты Гыйрфан мулла.

Дөрес, сүзләр башта берекмәде. Тегеннән-моннан йолыккан саз мүге кебегрәк булды. Зыя әфәнде үзен: “Мин сезнең карамакта, күпме теләсәгез, шулкадәр сайрагыз”, — дигәндәй тотса да, аның кыяфәтендә ашыкканлык, башы-аягы белән авыр эшкә чумганлык, йөзендә борчылу, арыганлык, галәмәтләре дә сизелеп тора иде. Шулай да мөлаем бу йөз. Таныш булмаган кеше өчен анда кара күләгәнең әсәре дә юк. Уйчан күзләреннән җылы карашы да ягымлылык, сөйкемлелек, шәфкатьлелек тойгылары сибеп тора. Май чүлмәге тышыннан билгеле, дигәндәй, аның бөтен килеш-килбәтендә зыялылык нуры бар.

Әмма Гыйрфан мулла Галимҗан турында һаман әле өзеп кенә сүз башлый алмый торды. Бу, Зыя әфәнде кебек, шушы мәлдә әллә үзенең дә әдиплелек калыбы эчендә булырга тырышуыннанмы?

Зыя әфәндедән сизгер күңеле Гыйрфан мулланың ни өчендер хафалануын тиз аңлады. Шуңа сүз йөгәнен үз кулына алырга булды ул:

— Йомышыгыз бар шикелле? Икеләнмәгез. Әйтегез!

— Мин ни... Солтанморат авылыннан... Гыйрфан мулла... Ибраһимов...

— Димәк, теге Оренбурдагы Вәли мулла мәдрәсәсеннән куылган Галимҗан Ибраһимовның әтисе буласыз?

— Яман хәбәр тиз таралучан шул. Нинди усал җилләр китерде икән сезгә безнең тарафтан андый хәбәрне?

— Кичә улыгыз Галимҗан минем янда булып китте. Ул барысын да үзе сөйләп бирде. Эчендәге тышында икән.

— Алай... Безне капчыкта тота торган түгел шул. Хәер, андый гадәт нәселдән килә. Бу яктан ул үземә охшаган. Мин дә Ходай үзе шаһит, эчтәгене чир итеп сакларга яратмыйм.

Зыя әфәнденең ашыкканлыгын анлап, сүзне су урынына сузарга тырышмаган иде ул. Шулай да, бер ачылгач, аны тиз генә бикли алмый интекте. Яхшысын да, яманын да сөйләп бирде. Галимҗанның сүтелергә торган иң йомшак ягы — аның сәламәт булмавында. Дәхи дә... холкы мәсьәләсе. Кемдә юк ул? Куылган икән Вәли мулла мәдрәсәсеннән — бу бит уку-укыту эшләрен юлга салу, тәрәккыят өчен көрәшкәнлектән. Монда да көрәш мәйданы уртасына басарга мөмкин. Әмма китек-митек, тиле-миле яклары шәйләнә башласа, Ходайдан сабырлык сорап, улының уңай сыйфатларын да искә алып, аны, Оренбурдагы кебек, адәм мәсхәрәсе итеп, кумасыннар иде мәдрәсәдән. Һич югы Гыйрфан мулланың үзенә атап хат язсыннар. Ул, яшен ташыдай атылып, дәррәү килеп җитәчәк тә малаен акыл бизмәненә утыртып кайтып китәчәк. Моңа аның иманы камил!

— Борчылмагыз, Гыйрфан әфәнде, эш сәламәтлек-саулык мәсьәләсенә килеп терәлсә, аның өчен генә Галимҗан мәхдүмне укырга алмый калмабыз, ә инде мәдрәсәнең низам-интизамына яки эчке тәртипләренә буйсынмаса, безнең тарафтан бернинди дә хәерхаһ булмаячак, — диде Зыя Камали.

Шуннан аларның сүз чылбыры беразга өзелеп торды. Аны Гыйрфан мулла ялгап җибәрде:

— Сез, әлеге Вәли мулла кебек, куркыту юлына басасыгыз, Зыя әфәнде!

— Галимҗанның уйламый сөйләшә торган гадәте дә бар икән. Ул, мәдрәсәне карап чыккач, аның Вәли мулланыкыннан да котсызрак булуы турында әйтте. Димәк, улыгызның күңел зәвыгын канәгатьләндерерлек түгелбез.

Алар янә бераз сүзсез торды. Йөрәк түрендә мондый кара төер калдырып аерылышу кыен иде Гыйрфан муллага. Аның кичерешен сизде Зыя әфәнде. Ниндидер яңа сүз көтте. Булмагач, үзенә әйтергә туры килде. Көлкеле, серле, мәгънәле, уйландыргыч итебрәк хәтта:

— Гыйрфан әфәнде! Сез мәгълүм атлы, фикерле, акыллы кеше. Шуңа күрә сезнең белән теләсә нинди телдә сөйләшергә мөмкин дип уйлыйм. Менә нәрсә: вакыт казаны бик зур, Ходай Тәгалә һәммәбезне дә шунда салып кайната: аннан берәүләр гайрәтләнеп, икенчеләр акыллыланып, өченчеләр зәгыйфьләнеп чыга: димәк ки, кемнең кем булуы әле киләчәк кулында. Бер Алланың изге фатихасына өметләник. Иншаллаһ, күңелебез изгелектә булса, беребезне дә ким-хур итмәс!

## II

Гыйрфан мулла, уй-хис дәрьясына чумып, акрын гына атлады. Зыя әфәнде аның күңелендә таң яктысындай саф тойгы калдырды. Адәм баласының ташны тишеп үскән үлән булуы хәерледер. Тормыш ташын ярып чыгып өскә күтәрелгән бит бу!

Зыя Камали утыз-кырык чакрым чамасы ераклыктагы Келәш авылында дөньяга килгән. Ярлы кеше гаиләсендә. 1873 елның декабрь башында. Димәк ки, аңа хәзер утыз өч яшь икән инде. Берәү дә аны өф-өф итеп иркәләп, ефәккә төреп үстермәгән. "Ата белеге белән бала адәм

булмас, әгәр үзе белмәсә", — дигәне мең кат растыр, валлаһи. Ул бит үз юлын маңгае белән боз ярып тапкан. Уфадагы атаклы "Госмания" мәдрәсәсен тәмамлагач, "Җәмгыяте хәйрия" Мисырга укырга җибәрә бу гыйлем гәүһәрен. Әнә, кайда икән белеменең акыл тажы булу урыны. Каһирәнең Әл-Әзһар дарелфөнүнендә дә баета акыл казанын белем энҗеләре белән. Бәйрут, Истанбул мәдрәсәләреннән дә ала гыйлем-мәгърифәт нурын. Шуннан, күзен очкан кошның язын әйләнеп кайтканы кеби, Уфага әйләнеп кайтып, үзе укыган "Госмания" мәдрәсәсендә мөгаллимлек итә башлый. Урыс телен су урынына эчә, имеш. Дәхи дә гарәп, алман, француз, инглиз телләрендә иркен сөйләшә икән. Айга үрелгән — нурга күмелгән, ди бит. Әмма үреләә белергә кирәк. Бәгъзе тәрәү ахмак арысландай күккә сикергән була да, егылып төшеп, кабыргасын сындыра, башын яра. Мисалны әллә кайдан — Кафтау артыннан эзлисе юк. Улы Галимҗан шулай булды. Зыя Камали җәнаблары исә бөтенләй башка зат. Аның кечелекле, садә, түбәнчел булуы хәйран калдыра. Йөрәгенә кереп сөйләшә бит. Оренбурдагы кадим мәдрәсә хуҗасы Вәли мулла нинди иде? Борчак чүмәләседәй корсагын киереп, май урларга торган песинеке кебек соры күзләрен ямьсезләндереп, аягыннан ←ып ташлардай итеп, карап тора сиңа.

Әлбәттә, кояшта да таплар бар, дигәндәй, адәм баласы хатадан хали түгел. "Госмания" мәдрәсәсенең баш мөдәррисе Хәйрулла ахун белән борчак пешерә алмавы, нәтиҗәдә аны ташлап китүе, тәртәгә типкән тай шикелле кылануы Зыя Камалиның затлылыгын бизәми. Хәлбуки, моның бер хикмәте бардыр. Кешенең яхшысы да, яманы да сәбәпкә бәйләнгән. Кирәк булса, каты итеп әйтә дә белә бит. Димәк, сүзешә торган гадәте дә юк түгел. Ху-у-у-ш, бу тормышта сөешеп кенә, үбешеп кенә яшәп булмый, әлбәттә. Каты куллылык та кирәк. Усаллыкны да кире кагарга ярамый. Әмма ләкин акыллы усал булсын. Аңлармы Галимҗан шуны? Керешмәсме бу акыллы баш белән сүзешергә? Илаһым. Оренбурдагы хәл кабатланса, янә мәдрәсәдән кусалар, дөньяда яшәр рәтең калмаячак. Авылда болай да әрем телләләр күбәйде. Гыйрфан мулла, имештер, балаларына дөрес тәрбия бирмәгән. Шуңа күрә аларны бер мәдрәсәдә дә тотмыйлар, тегесе-монысы, фәлән-фәсмәтән.

### III

Габдрахман хаҗи дөньяны җиренә җиткереп күтәргә ярата. Ихатасы, кем әйтмешли, көлеп тора. Аяк астында энә зурлыгы да чүп булмас. Әгәр табыла икән, ул аңа чыраен сытып карап кына калмый, ә бәлки, иренмичә бөгелеп алып, чүп савытына китереп ташлый. Абзар-курасының төзеклеге дә бу дөньяның мәгънәле, иҗтиһатлы, хезмәт сөючән кеше кулында икәнлеген аңлата. Урам яклап, зәңгәргә буялган биек койма буена юкә агачлары утырткан ул. Төп-төз кәүсәсе адәм буе күтәрелгәч, ботаклары матур гына җәелеп, бөдрәләнеп, өскә таба акрын-акрын очлаеп үсеп киткәннәр. Сөбханалла! Күз тимәсен. Бөтенесе дә бертигез. Җәй көне алар бигрәк матур була. Балкып торалар. Чибәр кызлар кебек. Чәчәкләре — нәкъ менә шул сылу кызларның нәфис колакларында эленеп торган алтын алкалар. Шулар арасыннан күренгән зәңгәр коймалар зәңгәр күзле миһербанлы кешенең чакырып торуын хәтерләтә. Ихата якта, койма буйлап, алма агачлары тезелеп китә. Алар да тәртипсез кеше кебек таралып түгел. Җыйнак-нәфис булып үскәннәр.

Капканы кергәч, сул якта — ике катлы матур йорт. Тышкы күтәрмәсе сарыга буялган. Ялтырап тора. Аяк савытыңны салгач та әле, басарга уңайсызланып торасың. Өй эчендәге бүлмәләрдәге пөхтәлекне, зиннәтлелекне сөйләп торасы да юк. Аслы-өсле зур йорт эчендә санап беткесез бүлмә. Шуларның берсендә алмадай чибәр кызы Алмабикә яши. Илаһым! Нур өстенә — нур, ямь өстенә — ямь өстәүче. Янә бер-бер артлы үсеп

килгән өч улы бар. Ун-унике-ундүрт яшьләрдә шикелле. Олы улы Имаметдин Каһирәдә укый икән. Анын бүлмәсе — буш. "Галия" мәдрәсәсен салганчы, Галимҗанга шунда яшәп торырга куша Габдрахман хаҗи. Йөз сум акчаң булганчы, йөз дустың булсын, дигән алтын сүзләрнең кыйммәте шушы икән. Галимҗан өчен оҗмах бит бу! Оҗмах!! Тик, каһәрен, оҗмахның тәмугка әйләнү куркынычы бар. Чибәр кызлар күрсә, Галимҗанның каны кайнаша шикелле. Хәер, андый ярсыткыч кан яшь Гыйрфанның үзендә дә мул иде. Троицк мәдрәсәсендә хәлфә вазифасы башкарганда мөдәррис Җиһангирның чибәр кызы Хәсәнә канын кыздырмадымыни? Кыздырды. Кыздыру гынамы — женләндерде. Тетрәндерде. Хыялга сабыштырды. Ләкин бит, бәгъзе бер йомшак җаннар кебек, илаһи мәхәббәт алдында җебеп-мәлҗерәп калмады. Мөгезеннән тотты мәхәббәтнең. Яратуын иң әүвәл кызның үзенә чатнатып әйтте, аннан әтисенә җиткерде. Әллә ул — кыю-кырыслыгы һәм дә ки усаллыгы белән даны чыккан Гыйрфан — тимерне кызуында сугарга кирәклекне белмиме? Белә. Сукты. Өйләнде дә туган авылы Солтанморатка алып кайтты да китте үлеп гашыйк булган Хәсәнәсен. Ходайга шөкер, ялгышмады. Акыллы атын, ахмак хатынын мактар, ди. Әйтсеннәр. Урынлы мактау бу. Кулыннан килмәгәне юк. Ашны телеңне йотарлык итеп пешерә. Чигү чигә. Тегү тегә. Балалар укыта. Тәүлегенә өч-дүрт сәгать кенә йоклаган чаклары күп була. Шул бәләкәй генә кубәләктәй җанда дөньяга сыймастай зур көч-куәт бар. Ирне ир иткән дә хатын, хур иткән дә хатын, ди. Аллага шөкер, хур итмәде, ир итте аның Хәсәнәсе.

Ярый, монысы шулай булды, ди. Иллә мәгәр Галимҗан гаилә коруда андый югарылыкка күтәрелә алмас кебек. Ахмаклык эшләп ташлаудан бөтенләй курыкмый. Иртәгә сәфәр чыгасы көнне теге Хөрмәтулла кызы Мәдинә белән урман буендагы үлән арасында кочаклашып, үбешеп ятканнар бит. Кеше күрмәс дигәннәрдер инде. Һм, күрмәс сиңа. Урман — колак, дала — күз, ди. Күрү генә түгел, сүзләренә кадәр ишетеп торган теге Мөбахис мәзин малае Бәкерҗан. Кочып, яшеренеп күзәткән иблис җан. Хәер, яшеренеп күзәтсә бармыни? Әле кояш та баемаган чакта, ягъни көн күзендә, икесе бергә урам буйлап үткәннәр бит. Өйләнешмәгән егет белән кызга шундый иркенлек килешәме? Тарихта, ата-бабаларның ата-бабаларында булмаган хәл бит бу.

Ничек кенә булмасын, Галимҗанның бу җәннәттәй куышта калуы бәхет! Габдрахман хаҗига вакытында үзенең дә файдасы аз тимәде. Кыешкы мәдрәсәсендә бергә укыдылар. Габдрахман сабакны авыр үзләштерә иде. Шулай да тырыша иде ул. Гыйрфан аны тәртипле, инсафлы, акыллы булганы өчен яратты. Матди яктан да ярдәм итте.

Габдрахман хаҗи яшь чакта карап туйгысыз чибәр егет иде: ул сөлектәй матур гәүдә, ул балкып торган мөлаем ак йөз, ул серле зәңгәр күзләр... Кырык яшьтә нык бирешге. Хәзер инде берникадәр бөкрәеп калды. Ябыкты. Чандыр кешегә әверелде. Эчкә баткан күзләрдә элеккеге матур зәңгәрлек сизелми. Аларга тормыш авырлыгы сөреме сарылган. Как сөяккә калган биттәге җыерчыкларда да фани дөнья мәшәкате күләгәсе биешә. Әмма эчендәге асылташ, күңелендәге гәүһәр, йөрәгендәге кешелеклелек энҗеләре хәзергә ару гына сакланган. Юмартлыгы да Ходайга шөкер. Акыллының кадере әдәп белән, байлыкның кадере юмартлык белән, ди бит. Юмарт кеше баючан. Ходай Тәгалә монысын да искә ала, күрәсең. Борынгы ата-бабаларыбыз: "Азны аяган күптән коры калыр", — дип тә әйткән. Монысы сараннар турында. Габдрахман хаҗи боларны белеп эш итәдер. Галимҗанга бер бүлмә тәкъдим итүе — монын ачык мисалы.

Ләкин дә... Галимҗан ул алмадай матур кызга артык нык кызыгып китмәсме? Алмага корт булып төшмәсме?

Ул кайтып кергәндә, ихатада Галимҗан Габдрахман хаҗи белән сөйләшеп тора иде.

— Әткәй, Алмачуарны ашаттым, эчердем, җигимме? — дип

каршылады аны Галимҗан. Бу сүзләр әтисенең, ниһаять, инде кайтып китәргә тиешлеген аңлату җәһәтеннән әйтелде.

Галимҗанның сүзенә Габдрахман хаҗи каршы төште:

— Нинди ат җигү?.. Кичкә табан? Иртәгә дә көн бар лабаса...

Гыйрфан мулла икеләнмәслек итеп әйтте:

— Юк, юк, Габдрахман кордаш, хәзер үк китәм, җигә башла атны, Галимҗан улым.

— Алайса чәйләп алыйк инде, — дип, өйгә кереп китте Габдрахман хаҗи.

Атны алар икәүләп җиктеләр. Ата кеше Зыя Камали янында булуы, аның белән матур гына әңгәмәләшеп алуы турында сөйләде. Әмма Галимҗанга бу ошамады.

— Әткәй, бала түгелмен бит, нигә минем өчен шул тиклем ут йотып йөрисең, — дип, үпкә белдерде ул.

Ата кеше, гәрчә улы төсен бозса да, йөрәгендә кайнаганнарын әйтми калмады. Хөрмәтулла кызы белән булган "ахмаклыгын" да, Оренбурда мәдрәсәдән куылуын да. Габдрахман хаҗи кызы алдында үзен әдәпле тотарга тиешлекне дә, яңа мәдрәсәдә тәртипле булырга кирәклекне дә туглады. Бабалары Ибраһим исеменең җиде буыннан килүен янә бер мәртәбә телгә алды.

Галимҗан тел кайтармады. Карт кешенең күнелендә ни — телендә шул икәнлекне аңлый ул. Яшь кешенең җиле үзе белән йөргәнлекне дә белә. Әтисенең болай да янган йөрәгенә сүз уты салуда бер фәтва да юк. "Ярар, әткәй", "соң, аңладым бит инде", "йөзегезгә моннан ары кара якмам" кебек сүзләр әйтү белән генә канәгатьләнде.

* * *

Галимҗан чәй эчәргә кермәде. Ул Алмачуар белән сөйләште:

— Их, Алмачуар! Син миңа караганда бәхетлерәк! Ни өченме? Чөнки син туган авылыбыз Солтанморатка кайтып китәсең. Сагынганыңны, үзең әйтмәсәң дә, белеп-сизеп торам. Ябыгып киттең. Күзләрең моңсуланды. Миңа да бик боегып карыйсың. Аңлыйм инде, аңлыйм: аерылышуны авыр кичерәсең. Әллә миңа җиңелме? Ә?! Сагыну хисе миндә дә бик көчле. Синеке ише генә дә түгел әле. Әмма сагыну, Алмачуаркаем, матур күңелле затлар өчен хас. Таш йөрәкләр сагына белми. Өйдән чыгып киткәнгә нибары бер атна. Ә мин, йомшак җан, үлеп сагындым да инде. Әнкәйне, Шакирҗан абзыйны, энем Габделхәкимне, зәңгәр чишмәне, Кондызлы күлне, Исәнбикә болынын... — барын, барын сагынып хыялланам. Тиздән аерылышабыз. Мин әле сине сагынып та саргаячакмын.

Галимҗан Алмачуарның муеныннан кысып-кысып кочаклап сөйде, аның маңгаен, моңсу күзләрен үпте, бармаклары белән ефәк ялларын тарап чыкты.

Бакча эчендә Алмабикә йөри икән. Ул, көмеш тавышлар чыгарып, кычкырып көлеп җибәрде:

— Галимҗан абый! Сез Алмачуарга нык гашыйк икәнсез. Ә менә берәр кызны шулай назлап сөйгәнегез булдымы?

— Яшьлек үзенекен итә, Алмабикә, авылда яраткан кызым Мәдинә — Акчәчкә калды.

— Шул арада сагынып та өлгердегезме?

— Сабырлык — сары алтын, диләр дә бит...

— Сабыр итә алмыйсызмы?

— Юк шул.

— Ә мин сезне кырысрак холыклы кеше дип уйлый идем. Эчегездә әллә нинди ялкын бар икән.

— Шул ялкын канны кайната, Алмабикә!

— Янып көлгә әйләнә күрмәгез, тагы.

Алар икесе дә көлеп җибәрде. Галимҗан, Алмабикәне якыннан

күрү теләге белән, бакча якка күз ташлады. Ләкин күрә алмады. Чөнки ул куаклар арасында иде.

Бераздан Галимҗаннын әтисе белән Габдрахман хаҗи чыкты. Гыйрфан мулла, җайлап менеп утыргач, дилбегәне кулына алып:

— Әйдә, малкай, әйдә, унган, — дип, юлга кузгалды. Тегеләр аны озатып калды.

## IV

Алмабикәнең исеме җисеменә нык туры килә. Пешкән алмадай чибәр кыз. Зифа буй. Калку күкрәк. Нечкә бил. Зәңгәр күзләр. Кыйгач кара кашлар. Килешле борын. Елкылдап торган кара чәч. Ак йөз. Сөйләшкәндә бит очындагы алсулыгы янә куера төшә. Елмайганда, көлгәндә исә ул кызарып пешкән алманы хәтерләтә. Ул энҗе тешләрен күрсәтеп, елмаерга ярата. Гаиләдә бердәнбер кыз булгангадыр, бәлки, анарда иркәлек төсмере дә бар. Вакыт-вакыт көязлек чаткылары да сирпелеп китә. Адымнары инсафлы, гаҗәп ипле, тигез аның. Гәүдәсенең аз гына бөгелеп-сыгылып торуы аяк атламнарына күчә. Бөтенесе бергә аның йөрешендә оста шагыйрь шигырендәге вәзен вә кафия ярашуын тудыра кебек иде...

Гомәр Хайям, Әбелкайсым Фирдәүси, Кол Гали, Байрон, Пушкин, Лермонтов кебек нәфис сүз сәнгате осталарының шигырьләрен йотлыгып-йотлыгып, кайнар йөрәк хисе, күңел ярсуы, аң-акыл бөеклеге белән укымаса, мондый чагыштыруны Галимҗан куллана алмас иде шикелле. Шигырьдәге вәзен-кафияне кеше йөрәгенең тибешенә дә тиңләргә мөмкиндер. Шигърият — матурлык. Шигърият — хис-тойгы. Шигърият — аң. Шигърият кафиясе — йөрәк тибеше кафиясе. Галимҗанның үз йөрәк тибеше — Алмабикә йөрәге тибеше. Аларның икесе арасындагы күңел кафиясе. Ничек кенә булмасын, кыз гаҗәп сөйкемле, мәхәббәт күленә манып алган кебек иде.

— Кызлары фәрештәгә биргесез, Алланың рәхмәте, тфү-тфү, күз тимәсен, Ходай яман күзләрдән сакласын: ә син берәр ахмаклык эшләп ташлый күрмә тагы, аң бул, — дип әйткән иде әтисе бер сөйләшкәндә.

— Соң, әткәй, кәҗә кәбестәгә тими торырмы? — дигән иде Галимҗан.

— Һи, дуңгыз малай, тапкан әйтер сүз, ата сакалы белән уйнамыйлар, — дип, аның аркасына җиңелчә генә сугып алды әтисе.

Күңеле бик ачылып китсә, гаҗәп шатлыклы мизгелләрдә, хәтта бераз мактанырак та, аның әтисе әнисенең яшь, чибәр, җегәрле вакытларын сөйләргә ярата. Аны ул зур ләззәт, күтәренке рух, ниндидер бер самими хис-тойгы белән сөйли. Баксаң, Алмабикәнең бөтен булмышы, — төсе-бите, килеш-килбәте, чибәрлеге, аш-суны оста әзерләве, тагын да әллә нинди серле яклары, — әнисенең яшь чагындагы кебек икән...

Галимҗан башта әтисенең вәгазенә тугрылыклы булды. Алмабикәгә күңелен кымырҗытмаска тырышты. Ләкин җиткән егетнең күзе нишләп инде чибәр кызга төшми калсын, ди. Аның йөрәге таш түгел лә. Күңеле дә бозга катырып куелмаган. Дәхи дә шунысы мәгълүм: адәм баласын әллә күпме ахмаклыклардан тыярга мөмкин, әмма аны матурлыкка карап соклanудан мәхрүм итеп булмый. Күзе барыбер төште: бүлмәдән бүлмәгә чыкканда да, ихатада йөргәндә дә, аш мәҗлесендә дә... Ә беркөн алар капка төбендә йөзгә-йөз, күзгә-күз очраштылар. Алмабикәнең гимназиягә китеп барышы иде. Капкадан урамга килеп чыкса, Галимҗан белән бәрелешә язды хәтта. Башта алар, авызга су капкан кешеләрдәй, тын гына торды. Икесенең дә сөйләшәсе килә иде, әлбәттә. Ләкин ни-нәрсә турында?

Алмабикә йөзен яшерми. Гимназисткага килешми ич ул. Бу — бер. Икенчедән, урыс-япон сугышы, 1905 елгы инкыйлаб җилләре, егерменче гасыр башында азатлык өчен башланган көрәш дулкыны, тигезлек турында яңгыраган даими сүзләр, тагын да әллә ниләр... хатын-кыз йөзендәге тартыну-оялу пәрдәсен акрынлап ача килә, ача килә иде.

Ничек кенә булмасын, татар кызының бар булмышында, бөтен вөҗүдендә, елмаю, сөйләшү, көлү, атлап китү, нәзакәтле мөгамәләсендә әдәпле-лек нуры бөркелеп тора. Андый унай-асыл сыйфатлар Алмабикә кыяфәте-нең дә һәр күзәнәгенә мөселман каны тамчылары белән нәкышләнгән. Галимҗанга аның моңа чаклы тутырып караганы юк иде әле. Шулай да анда-санда, сирәк-мирәк күзе төшкәләде. Әтисенә охшаганлыгын аңлап алды. Киң маңгайлы, каты карашлы, елкылдап торган кара чәчле, ниндидер яшерен сергә бай кара күзләр.

Әле кайчан гына шәкертләргә чәч үстерергә рөхсәт ителми иде. Галимҗан бу канун-низамга үз ноктасын куеп өлгергән. Озын кара чәчләре җилкәсенә кадәр җиткән. Киеме дә шәкертләрнекечә түгел. Кызыл күлмәк-нең сул як якасы кайтарылып төшкән. Билен бармак юанлыгы ефәк билбау белән буган да аның чуклы очларын уң якка асылындырып куйган. Күксел яңа чалбар. Аякта — штиблет. Кулында — калын китаплар. Аның бөтен торышы, үз-үзен тотышы: “Мин бу фани дөньяда ирекле шәхес, мәдрәсә кысаларында бикләнеп саргаячак кемсә түгелмен, күңелем иреккә, галәм киңлекләренә ашкына”, — дип әйтә кебек. Берничә көннән “Галия”дә уку башланачак. Ул үзен һаман шулай иркен дөнья кошы итеп тотарга тырышырмы? Әллә, ел фасылына карап төсен үзгәрткән шушы табигатьнең үзе кебек, мәдрәсә чапаны эченә кереп төренерме? Алай итмәс, бәлки? Кеше иманына кызыгып яшь торган егеткә һич тә охшамаган бу.

Шундый уй-хис кичерде Алмабикә. Ныклап танышу, күңел җепләрен бәйләү җәһәтеннән үзе үк сүз башлады:

— Сез инде, Галимҗан әфәнде, гыйлем-мәгърифәт дөньясына кереп чумарга да өлгергәнсез, дини китаплармы? — дип сорады.

— Төрлесе бар, Алмабикә туташ. Дин белән Оренбурда да миебезне күп череттек. Анысын кирәк кадәр дәрәҗәдә үзләштердек шикелле. Хәзер инде, йомыркасын тишеп чыккан кош баласы кебек, киң җиһан кочагына йөз тоту хәерлерәк булыр.

— Максатыгыз изге вә бөек икән. Хак Тәгалә күп көч, ярдәм бирсен берүк.

Галимҗан шаяртуга күчте:

— Арпа-көрпә аш булмый, надан кеше баш булмый, ди бит.

— Нинди баш турында сүз алып барасыз?

— Фән башы...

— Сез күпкә омтыласыз бугай?

Галимҗан һаман шаяртыбрак сөйләшү ягын каерды:

— Абына-абына Бохарага җитәрсең, янылыша-янылыша гыйлемгә дәгъва итәрсең, — дип сөйләшкән картәтием Нурмөхәммәт Имамның әтисе Әхмәт ахун.

— Әтиегезнең телгә осталыгын сизгән идем. Сез дә шулай икән. Бу нидән килә?

Сөйләшүнең рәсмилеккә тартылуын аңлап, Галимҗан җавапны тагын да шаян сүз белән бирергә булды:

— Күңел — йөгерек, тел — батыр, — диләр лә ул. — Әти мине яратып бетерми. Йөгерек күңелле булгангадыр, бәлки. Ә тел батырлыгын Ходай кызганмаган.

— Күңелегез йөгерек булмаса, уку башланмас борын, шул кадәр күп китаплар күтәреп йөрмәс идегез.

— Менә монысы — Тургеневның “Отцы и дети” әсәре. Ата белән бала ызгышы гомерлектер ул. Ә бусы — Пушкин әсәрләре. Шуннан — Гете, Байрон, “Йосыф китабы”, Хафиз, Фирдәүси, Гаяз Исхакый...

— Күп укыган — күп белгән, — диләр бит. Шулаймы, Галимҗан мәхдүм?

— Күпне белгән — тиз картайган, — дигәне дә бар, Алмабикә туташ.

Алар көлешеп аерылыштылар.

## V

Зыя Камалиның тиз арада өч катлы “Галия” мәдрәсәсен салдыра алуына күпләр шикләнгән иде. Әмма Зыя әфәнде, үзенекен-үз итеп, бер ел эчендә өч катлы зур мәдрәсә салдырды. Беренче катында ашханә. Икенчесендә тору-яшәү урыннары. Өченчесендә — уку-укыту бүлмәләре.

Гыйрфан мулла, юк йомышын бар итеп, Уфага килеп йөрде. Килгән саен Габдрахман хаҗиларга тукталды. Ана Галимҗан өстеннән күзәтчелек итү кирәк иде. Әмма Галимҗан —Габдрахман хаҗиның оҗмахтай дөньясында озак тормады, шәһәр читендә бер бүлмә алып яши башлады. Моның сәбәпләрен ул төрлечә аңлатты. Әтисе, әнисе аның нәсел тамырын нык тотучы, аннан кәүсә үстерүче, ботаклар җибәртүче, яфраклар ярдыртучы асыл зат булуын теләи. Моның өчен, кем әйтмешли, биленне биштән буып, уртынны чәйни-чәйни, тешеңне кысып, даими укырга кирәк. Шуңа күрә ул — Галимҗан — ялгыз торнадай аерым яшәүне мәгъкуль күрә.

Әтисе Гыйрфан мулла моңа ышанды. Улының ата сүзен тотып яшәвенә шатланып куйды. 1907 елның көзендә “Галия”гә Галимҗанны янә үзе китереп куйды.

... Солтанмораттан көне буе килгәч, атын тугарып, гәрчә инде соң булса да, җан түзмәгәнлектән, тынгысыз Гыйрфан мулла, Галимҗанны ияртеп, яңа мәдрәсәне карарга китте. Мәдрәсәнең эчке күркәмлеген карап чыкканда шәфәкъ вакыты канат җәйгән, уттай янган кызыл кояш офыкка килеп кунаклаган иде инде.

— Уфа — биек тау башында. Бәс, шулай икән, башның маңгае да булырга тиеш, Галимҗан улым, менә бу урын — маңгай; бу мәдрәсә — маңгай уртасындагы миң; гыйлем йорты булгач, ул миңне, Ходайның рәхмәте, Мөбарәк тәсбихнең бер төймәсе дип атау лязим.

Гыйрфан мулла шулай сөйләнде. Аның күңеле гадәттән тыш шат, күтәренке иде. Шуннан ул бер ел эчендә мондый әкияти йортны салдырырга көче житкән Зыя әфәнде Камалины мактауга күчте:

— Хосусан, чын мәгънәсендә дин әһеле икән бу Зыя Камали җәнабләры; инсаниятчылык мәсгудияте, шәригать канунлары, иман шарты өчен җанын фида кылучы гали зат булмышын бөек рухы белән “һә” дигәнче исбатлады да куйды; моңа инде, Галимҗан улым, Аллаһы Тәгалә үзе ярдәмгә килде; дәхи дә... изге эшкә гарше көрсидән, ягъни мәсәлән, күк тәхетеннән һәрдаим шәфкатьлелек нуры сибелеп торыр; ул каралыкны каплый, аклыкны аклый; менә бит мәсьәләнең җимеше кайда...

Галимҗан, билгеле, әтисенең өйдә чакта да, юлда килгәндә дә, әле менә монда да миеңә сеңдерим, дип, төрттереп сөйләвен аңлый. Аның бөтен теләге — балаларын инсафлы, мәртәбәле, кешелекле итү инде. Шуларны уйлап, Галимҗан әтисенең сүзенә су кушмаска, тыңлап торырга гына булды. Ә бит аны тыңлавы күңелле. Әллә нинди гыйбрәтләр сөйли ул. Әле дә менә “Галия” мәдрәсәсен Уфа тау башы маңгаеның уртасында торган миң дип атады. Атасының тел байлыгы аның зиһененә, күңел сандыгына бала чактан ук салына килгән иде. Әнисенең бишек җыры, күз гәүһәре, урынлы үгет-нәсихәте — барысы, һәммәсе йөрәк төпкеленә энҗе-мәрҗән бөртекләре булып җыелган.

Алар икесе дә баеп барган кояшка караш ташлады. Чыннан да, бик матур күренеш иде бу. Тау башыннан аска кырт кына таш дивар төшеп китә. Аннан — аста Агыйдел сузылып ага. Елга аръягында — урманлык. Аннан соң әллә ни биек булмаган тау күтәрелә. Кояш нәкъ шул тәбәнәк тау түбәсенә төшеп терәлде. Аның кызгылт нурлары әле агач башларында, Агыйдел дулкыннарында уйнаклап, “Галия” мәдрәсәсен дә балкытып тора. Ул — Кояш — әйтерсең, әнә шул Күк тәхетендәге илаһи шифалы нурларны әле бөтен мөселманнарның дини мәккәсе булачак “Мәдрәсәи Галия диния” өстенә махсус сибә.

Менә Кояш, бөтен җиһанга хәерле төн теләп, таулар артына яшеренде. Офык кып-кызыл уттай янып калды.

Чү! Кинәт кенә пароходның моңлы тавышы ишетелде. Ул түбәнгә табан йөзә икән. Шактый зур пароход шикелле. Казанга хәтле барадыр әле, бәлки. Әтисе "Галия"не мактый. "Их шул пароход белән хәзер үк Казанга китсәң иде. Анда — дәредфөнүн! Әнә кайда чын гыйлем-фән оясы!" — дип уйлады Галимҗан.

## VI

... Яз!

Ул саф-садә күңелле, ярсу йөрәкле, шаян табигатьле көләч кыз сыман балкып килде. Март аенда быел акман-токман бураны, бәгъзе бер еллардагыча, ярлыларның бәләкәй өйләрен күмеп китәрлек дәрәҗәдә котырына алмады. Ара-тирә, анда-санда, вакыт-вакыт булып торган кыюсыз бураннар, кар ашый торган җылымса җилләр йомшак кешенең бер дә юкка ыңгырашуын гына хәтерләтеп торды. Апрельнең уннарында Язбикә бөтен тирә-якка йөрәк ялкынын чәчеп елмайды. Аның күз нурлары җылы агым булып сибелделәр. Аннан Язбикә, Кояшның җылы-назлы, шифалы-сихри нурлары белән иркәләнгән хәлдә, матурлыкка галибанә мәдхия укып, җиңү тантанасы шатлыгыннан бәхет-сәгадәт яшьләре түгә башлады. Ул гәүһәр яшьләр җир өстенә шифалы ләйсән яңгыр булып түгелде. Ләйсән яңгыр җир өстен һәммә пычрак-чачраклардан арындырды. Җир өсте әбелхәят суы — мәңгелек тереклек суы белән юылган кебек сафланып калды.

Тормыш бер көйләнсә, ул инде таш нигез белән салынган нык йорт кебек. Ныгыды шикелле бу йорт. Шакирҗан менә дигән мөдәррис. Габделхәкимнең зиһене чамалырак анысы. Әмма ләкин, кара эшкә тотынса, кулында ут уйната. Аның күңеле җир кендегенә береккән. Әйдә, икмәк үстерсен. Бөек һөнәр ул —игенче һөнәре. Димәк, бу яктан аның күңеле тыныч. Инде Галимҗанга килсәк, ул да акрынлап, акыл чанасына утырып алды бугай.

Быел да ул алтын хәрефләр белән язылган шәһадәтнамә алып кайтып, өстәлгә җәеп куйды. Әтисе, укасы коела күрмәсен берүк дигән саклык белән кулына алып, аңа озак кына мөкиббәнә карап торгач:

— Бәрәкаллаһ, бәрәкаллаһ! Сөбханаллаһ, сөбханаллаһ! Карачы, әнкәсе, бу текә маңгайның шәһадәтнамәсе гел югары бәһа белән зиннәтләнгән бит, менә терәкә, чирттеме борынына чуар көпшәләрнең! — дип шатланды да Галимҗанның биленнән бик каты кысып кочаклап, көрәш мәйданындагы батыр кебек, аны күкрәге өстендә тотып торды. Галимҗанның билен, әйтерсең, утлы тимер кыршау китереп кысты.

— Әти! Әти! Әткәй! Җибәр, бөтен гәүдәмне он-талкан итәсең бит! — дип чәбәләнде Галимҗан. Сүзгә әнисе Хәсәнә абыстай да кушылды:

— Әткәсе, йә житәр, әллә сабантуйдагы көрәшче кебек ыргытып бәрмәкче буласыңмы аны, сиңа ышаныч юк, — дип өзгәләнде.

Ата кешедә андый уй бөтенләй юк иде. Хәләл җефете әйткәч, ул, дәртләнеп китеп, Галимҗанны чыннан да караватка китереп салды. Бу, билгеле, әтисенең җисмәни көче сезнең ише юеш борыннарны бишкә бөкләрлек әле дип мактану өчен иде. Әмма аның шатлыктан исереп шаяру икәнлеген һәркем аңлап торды. Галимҗан бик ябыккан иде. Җитен көлтәсе шикелле булып калган. Как сөяк. Көчле беләк уратып алса, бу как сөяк, чыннан да, таралып төшәр сыман. Хәсәнә абыстай шуннан куркып, коты очып торды. Ләкин берни дә булмады Галимҗанга. Чөнки аны әтисе йомшак түшәккә китереп салды. Галимҗан шундук сикереп тә торып, әтисен кочаклап алды да:

— Әткәй, нык картайганчы, син шулай да сабантуй көрәшендә бу албасты көчеңне бер күрсәтеп ал әле! — дип көлде.

Көлүгә Хәсәнә абыстай да, Шакирҗан да, Габделхәким дә кушылды. Өй эчендә шаяру, шатлык дулкыннары чайкалып торды. Шәһадәтнамәне

ана кеше дә, Шакиржан да, Габделхәким дә кат-кат тотып, әйләндерә-әйләндерә карый-карый куаныштылар.

* * *

Тәһарәт алып, барысы да ахшам намазы укыгач, беренче каттагы түгәрәк өстәл янына жайлаштылар. Аш табынында сүз әлләни куермады.

Алар сүзсез генә ашады. Дөрес, вакыт-вакыт кирәкле сүзләр чыкмый калмый иде. Хәсәнә абыстай да:

— Ашагыз, җитешегез, рәхим итегез, — дип, кыставын белде.

Ата кеше, остабикәсенең күңелен күтәреп:

— Ай-һай ла, сумсасы, сумсасы, авызда эреп тора, — дип, мактап куя иде.

Шундый ук сүз балалардан да ишетелә:

— Их, әнкәйнең бәлеше...

— Ә коймагы...

Сүзне ата кеше җөпләп куя:

— Тәмле аш пешерә белү хатын-кызның иң асыл сыйфаты ул, ба-балар! Әниегез, әнә, шул югарылыкка ия!

Тәмле аштан соң, мул табынга фатиха кылып, барысы да берьюлы амин тотты. Шуннан соң ата кеше янә бер хосусиятле тәкъдим ясады:

— Балалар! Бүген барыбыз да мәчеткә ясту намазына бергәләп барабыз. Бу — Галимҗанның алтын хәрефләр белән язылган бәһале шәһадәтнамә алып кайту дәрәҗәсе өчен!

Икенче көнне Галимҗан, иртәнге чәйдән соң, йөрештереп кайтырга булды. Ул ел да шулай итә. Сагыну хисен иң әүвәл әтисе, әнисе, абыйсы Шакиржан, энесе Габделхәким белән күрешү баса. Башта ул әле җәннәттән һич тә ким бизәлмәгән өй эченә дә карап туя алмый. Ике катның да тәрәзәләрендә кәрәз кебек челтәр пәрдәләр. Тәрәзә төпләрендә — тамчы гөле, сөмбел, рәйхан, бадъян, канәфер, ахшамсафа гөлләре. Аларны әнисе өф-өф итеп, тәрбияләп, иркәләп үстерә. Шуларга күз нурларын җәлләми түгә, йөрәк җылысын бирә, яз көне үзләрендә үстерү өчен аларның ботакларын сорап килүчеләр дә күп була. Әнисе һич тә саранланмый. Кызганмый. Шатлана гына. Тик ул биргән ботаклар бәгъзе берәүләрнең гөл чүлмәген нигәдер үз итми. Йә утырту белән үк шинә, йә бер елдан соң корый, йә чәчәк ата алмый изалана.

— Хәсәнә абыстай, барын да син өйрәткәнчә эшләдем: күмердәй кап-кара балчыкка утырттым, яктылыкта гына тотам, суын да вакытында сибәм, менә үсмиләр генә бит, — дип, әрнеп килә кайсыберләре.

Әнисе елмаеп куя:

— И!.. Гөл бит ул кеше кебек: аның җаны бар — шуны аңларга кирәк, — ди.

Су сипкәндә, йә булмаса, авырттырмыйм дигән сыман, иплән-назлап кына яфракларын сөрткәндә, ул алар белән сөйләшә дә:

— И йөрәккәем, гүзәлкәем, бигрәкләр дә сылусың, акыллысың шул, былтыр да алсу-зәңгәр-кызыл-көрән чәчәккә күмелгән идең, быел да, җәренгә дә бу сыйфатыңны саклый күр берүк... — кебек сүзләр әйтә-әйтә, сөя аларны. Гөлләргә дә үз балаларына биргән йомшак-ләтыйф тәрбиясен кызганмый. Күрәсең, ул әйткәнчә, гөлләрнең чыннан да җаны бардыр, тик сөйләшергә телләре генә юк. Гәрчә үзләре сөйләмәсә дә, кеше әйткәнне аңлыйлар. Табигать йөрәге белән адәм баласы йөрәгенең Аллаһу Тәгалә биргән күренмәс серле-иманлы җепләр белән бәйләнүе шушыдыр инде. Янә бер гыйбрәтле хәле бар бит әле аның. Бервакыт әтисе, әнисе Уфага кунакка китә. Пар ат җигеп. Туйга. Бик якын бер дусларына. Туй — туй инде. Атна чамасы торалар. Өйдә чыбык очы тиешле ераграк туган Хәлимә түти кала. Рәйхан гөленең яфраклары күзгә күренеп саргая. Нишләргә дә белми Хәлимә түти — өзгәләнә, көяләнә, кыенсына. Кунаклар кайткач:

— Суын да син өйрәткәнчә сиптем, яфракларын да иплəп кенә, назлап кына сөртеп тордым, Хәсәнә абыстайгынам, балам кебек тәрбияләдем, ә ул, сарыга сабышкан кеше төсле, әллә нишләде дә куйды, — дип борчылды Хәлимә түти.

— Һич тә үзеңне-үзең бимаза кылма, Хәлимәттәй, сагыну кешене дә, гөлне дә, бөтен тереклекне саргайта. Мине сагыну сарыга сабыштырган аны, — дип юатты Хәсәнә абыстай.

Әнисе гөлләргә янә шәфкатьле күз нурларын сибә, аларны сөю хисенең ләззәтлелеген әзһәр итүче сүзләр әйтә, күңел даирәсендәге сафлык тулы мәхәббәт тойгылары белән яшәүгә илһам бирә. Рәйхан гөле яфракларына яңадан яшел төс керә. Чәчәкләре элеккегә караганда да матуррак булып балкый.

Гөлләргә карап, шул хис-тойгыларын кичерде Галимҗан. Нәкъ әнисенә охшап, алар белән серләшеп-сөйләшеп тә алды:

— Их, гөлләр, гөлләр, сез әниемне нык яратасыз, ә менә минем йөрәгемдә нинди каһәрле ут дөрләү турында аслан гамегездә юк. Хәер, мине берәү дә аңламый: әти, әни дә, якын дуслар да, туганнар да, хәтта "Галия" мәдрәсәсе башлыгы зур фикер иясе өлкән мөдәррис Зыя әфәнде Камали да аңламый мине...

Гөлләр аңа шундыйрак җавап бирде кебек:

— Үзен зур тоткан түрәнең соңы хур булыр. Галимҗан абзыйкай, син, үзең дә шәйләмирәк, тәкәбберләнәсең шикелле.

Өй эчендә — икенче катта — Галимҗан әле берүзе генә иде. Әтисе иртәдән бирле ихатада, абзар-курада төрле вак-төяк эш белән мәшгуль. Әнисе аскы каттагы аш-су бүлмәсендә мәш килә. Шакирҗан белән Габделхәким дә әтисе янында кайнаша. Алар әле абзар тазарта. Галимҗан хәзергә кунак сыйфатында булгач, һәммәсе дә аның ял итүен тели.

Өске каттан аскы катка төште дә Галимҗан аш бүлмәсендә мәш килеп йөрүче әнисенә дәште:

— Әнкәй, мин тирә-юньне урaштырып кайтыйм әле.

Хәсәнә абыйстай кулын ак сөлге белән сөртә-сөртә чыкты. Кичә аның йөзе аксыл-саргылт иде шикелле. Бүген әле бит очлары пешкән алмадай кызарып тора. Йөзендә шатлык нуры балкый. Бу — мичтә янган уттан төшкән кызыллык кына түгел, улы Галимҗанның мәртәбәле шәһадәтнамә белән кайту куанычыннан кабынган йөрәк уты тәэсире дә иде.

— Озак йөрмә, улым, көндезгелеккә аш әзерлим бит, кешеләр килер.

— Әнкәй, нигә шулай мәшәкатьләнәсең инде: мин кайттыммы — мәҗлес оештырасың.

— Алар чакырмасаң да килә, балакаем, хөрмәтләп, сине күрергә.

Хәсәнә абыстай Галимҗанның гадәтен яхшы белә: кайтканының икенче көнендә үк табигать кочагына чыгып китә, нык сагыну басылганчы шунда йөри ул, аннан, әлхәмделилля, кендек әбисе Хәмдия абыстайга хәер биреп кайта. Шуларны уйлап:

— Әллә кая китеп олакма әле, балакаем, кендек әбиеңә хәер бир дә әйләнеп кайт, табигатькә иртәгә чыгарсың. Әле башланмаган җәй бар, — дип, шкафка барды да аннан бер көмеш акча алып килеп, Галимҗанның кулына тоттырды.

— Хәерлек кенә үземдә дә бар иде, әнкәй!

— Бар янына бар сыя, барлыктан күңел дә, тамак та туя; юк янына юкны куйсаң, бәндә ачтан харап була, балакаем!

— Рәхмәт, әнкәй! Озакламам. Әйе, Актүтине үзем дә сагындым, барып кайтыйм әле.

Әтисе ишегалдын себерештереп йөри иде. Аның эш куллы икәнлеген кыяфәте, киеме, бөтен бәдәнен горур тотуы ук күрсәтеп тора. Әле ул кыска бишмәт өстеннән киндер алъяпкыч киеп алган. Киҗеле ыштаннан. Башында — мескен бүрек. Аягында — кәлүш. Чатнап торган крәстиән сыны үзендә. Башта ул сүз башлады:

— Кая киттең соң әле? Бүгенгә ял итәргә кирәк иде.

— Кендекәйгә хәер биреп кайтам.

— Бу изге эшкә кем хәерһаһ бирмәс. Рәхмәт, улым! Бик муафыйк уй белән йөрисең икән. Адәм баласының ике иңендә ике фәрештә. Сул яктагысы — яманыңны, уң яктагысы яхшыңны язып бара. Бер хәер бирсәң, яхшылык фәрештәсе ак бизмәненә мең савап бөртеге салып куя. Шулай бөртекләп җыела бу фани дөньяда ахирәткә алып барачак изгелек гәүһәрләре. Гаделлек, юмартлык, тугрылык, шәфкатьлелек бизи адәм баласын. Ә инде икейөзлелек, тәкәбберлек, үч алу, хәмер эчү, зина кылу, гайбәт сату, ялган сөйләү, саранлык, үч тоту кебек начар гадәтләр бәндәләрне харап итә. Андыйларга оҗмах ишеге ябык инде ул.

Мондый фәлсәфәгә кереп китсәң — чумасың. Әтисенең андыйларны әйтергә теле кычытып кына тора. Әле менә үзеннән-үзе җае чыкты. Хәзер инде аны туктатырмын димә. Иң яхшысы — китеп котылу.

— Әткәй! Дөрес әйтәсең. Мин бик ашыгам. Кайткач, сүзне дәвам итәрбез әле.

— Һы, итәрбез. Син бит бер сүзенә бер бозаулы сыер сорыйсың. Әткәй мәрхүм әйтер иде: акыл — казна, күңел — йозак, тел — ачкыч. Акылың казна синең. Әмма күңелең йозаклы. Ача торган түгел.

— Соң, әткәй, акыллы тыңлар, ахмак сөйләр, дигәне дә бар бит әле аның.

— Акыллы сөйләмәс, надан сөйләтмәс, дигәнен дә беләм. Янә әткәй мәрхүм әйтер иде: боланның — мөгезе, галимнең — сүзе, филнең — теше, останың эше кыйммәт, дип. Әллә-ләл, сүзгә оста иде картәтиең, әллә-ләл!

— Син үзең дә бит, әткәй, бик матур сайрыйсың.

— Минем дә сине тыңлыйсым килә ләбаса. Ярый, сүз белән юл бүлүне дә килештерми шәригать. Бар инде алайса, Хәмдия абыстайга сәлам әйт. Аның әле аяклары авыртып тора иде. Шулай да, ашка чакырып кайт үзен. Көндезгелеккә. Әгәр атлый алмаса, Алмачуарны җигеп алып килермен. Әйт шуны. Җиткер сүзләремне аңа. Бар. Хәерле юл!

Галимҗан киткәч, бөтен эшен онытып, күңелен уй дөньясында йөздерде ата кеше. Улының игә килүе, инсафлылык саклап сөйләшүе, ниһаять, бу фани дөнья хәятенең буразнасына дөрес кереп китүе нык шатландырды аны.

* * *

Әтисе аны сүзгә саран булуда гаепли. Сүз бик кадерле нәрсә ул. Казакъ халкының бөек акыл иясе Абай әйткән бит: "Сүзнең эче — алтын, тышы — көмеш", — дигән. Алтын бәрабәренә торырлык булса гына әйт сүзеңне кешегә. Шулай да, тыңларга күбрәк ярата Галимҗан. Чөнки мондый мәлдә сөйләгән кемсәнең аң-акылы да, күңел даирәсе дә, хис-тойгысы колы булу хосусияте дә, хәтта кешелекле булу-булмау сыйфаты да ачыклана. Оренбурдагы Вәли мулланың кадим мәдрәсәсендә сүз көрәштерү күп очракта якалашуга, мендәр белән тәпәләшүгә барып җитә иде. "Галия"дә дә бәхәс күп, әмма ул шактый югары дәрәҗәдә була. Яхшы баш куйсаң, илне төзер, яманнан баш куйсаң, илне бозар, ди. Шуңа күрә бәхәс күп очракта "патшаны бәреп төшерүгә" барып җитә. Милләт язмышы өчен ачыну өстенлек ала. Вәли мулла мәдрәсәсендә дә, "Галия"дә дә йомгаклау сүзе Галимҗанга бирелә. Менә кайчан кирәк була Абайның: "Сүзнең эче — алтын, тышы — көмеш", — дигәне. Алтын сүз әйтү өчен алтын акыл кирәк. Монда инде кеше сөйләгәннең гәүһәрен генә җыеп, соңра шуларга үз алтыныңны кушу лязем. Әмма анда да: "Аз сүз — алтын, күп сүз — болтун", — дигәнне онытмаска кирәк.

Бусы бер булсын, ди. Хәзер аның башында мең төрле уй давылы кайный. Фатих Әмирхан Казанда "Әльислах" газетасында аның "Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы" исемле хикәясен бастырды. Аны ул Кавказда чакта җәй көне нугай балаларын укытканда язган иде. Бу хикәя

басылып чыккач, "Галия" шәкертләре туздырылган кырмыска оясы урынына кайнашты. Газета кулдан-кулга йөри. "Галимҗан язучы икән ләбаса", "Нигә шуны моңа чаклы әйтмәде икән", "Әллә кешенекен урлап бастырганмы?", "Менә астыртын шайтан!" кебек сүзләр дулкыны чайкалды. Бу хикәя әле өйрәнчек кенә. Галимҗан үзе аны яратып бетермәде. Чөнки сәнгатьчә эшләнеше аксый. Хәзер инде башта әллә күпме яна хикәяләр йөри. Аларны кәгазьгә төшерергә кирәк. Ни-нәрсә тамар каләм очыннан ак кәгазьгә: гәүһәрме, кырлыкмы? Бусы — үзе бер зур уй дулкыны. Икенчесе шул: Кавказга нугай балаларын укытырга барды, ә кулында берни юк — китап, каләм, дәфтәр һәм башкасы. Башына төшсә, башмакчы булырсың, ди. Башка килгән авырлыкны җинеп чыгарга кирәк. Нугай картлары, өлкәннәр, башкармалар белән киңәшләшеп, уртак тел табып, шәһәргә барып кайтып, тиз генә дәфтәр, каләм кебекләре юнәтелде. Ә ничек укытырга? Нинди методик алымнар белән? Шайтаным белсен боларын. Шулай да укытты. Аваз-хәрефтән башлады. Хисапка өйрәтте. Белем чишмәсенең башы нидә икәнлекне төшендерде. Чишмә инде ул ага-ага инешкә әверелә. Аннан елга хасил була. Бәләкәй елга олы елгага коя. Олы елга диңгез куенына барып сыена. Аваз-хәрефен өйрәтеп, язу сукмагына төшереп куйгач, гыйлемнең олы юлына үзләре чыгар. Моңа аның иманы камил. Әмма ләкин грамматиканы язарга кирәк. Гарәп телендәге сарыф (морфология), нәхү (синтаксис) белән бала укытып булмый. Аны Галимҗан Ибраһимов язарга тиеш. Моның өчен "Галия" мәдрәсәсе мәгълүматы җитми. Казанга барып дарелфөнүнгә, ягъни университетка укырга керергә кирәк...

Ул күп укый. Көнчыгыш әдәбияты. Көнбатыш Европа әдәбияты. Дөнья әдәбияты. Шулар белән чагыштырганда татарныкы әле Кояш тирәсендәге күләгә кебек кенә. Казандагы атаклы дарелфөнүндә тирән белем алгач, әнә шул күләгәне юк итеп, татар мәдәниятен дә кояшның үзенә китереп кушарга кирәк. Хәлбуки, моның өчен әлеге күләгәләрне тәнкыйть уты белән көйдерү мотлак. Шунсыз күләгә таралмый ул. Димәк ки, аек карашлы тәнкыйтьче булырга. Бусы — янә бер елга...

Шундый уй-хисләр давылында тирбәлә-тирбәлә килеп җитте ул кендек әбисе капкасы янына.

* * *

Актүтигә икеләтә бурычлы Галимҗан. Иң әүвәл якты дөнья күзен күрсәтүче җиңел куллы кендек әбисе булганы өчен дә, үзен үлем тырнагыннан алып калучы табибә була белгәне өчен дә.

Бәләкәй чакта Галимҗан, салкын яңгыр астында калып, үпкә чире эләктерә. Хәлсезләнә. Телдән кала. Хәрәкәтсез ята. Әтисе хәтта ясин чыга. Менә шунда Актүти дип даны чыккан Хәмдия абыстай чирнең имен табып, оста табибә була. Чувашлардан көмешкә, дуңгыз мае барып ала да шулар белән Галимҗанның бөтен әгъзаларын камыр булу дәрәҗәсенә җиткереп сылый. Тик моны Галимҗанның әтисенә дә, әнисенә дә әйтми. Чөнки алар дуңгыз мае, көмешкә белән дәвалауга каршы булачак. Гыйрфан мулла улын ничек сәламәтләндерүе турында кат-кат ялынып сорагач кына, серне ача Актүти.

... Ихатадагы үләннәр арасыннан тар сукмак китә. Галимҗан, авыз эченнән бисмилласын әйтеп, шул сукмактан бераз атлады да янә туктап калды. Бу язгы үләннәрдән авыл халкы гына тоя торган әйтеп тә, язып та аңлата алмаслык тәмле хуш-ис килә. Яз исе! Авыл халкы моңы исе!!! Шәһәрдә бу юк. Сатып алырга да табып булмый. Анда таш, таш, таш. Бәлки, үз авылыныкы булганга тәмле-татлыдыр бу әрем исләре, алабута исләре, кычыткан исләре. Яшел хуш-ис! Яшел үлән исе аңкыткан тәмле һаваны янә бер мәртәбә күкрәк киереп сулады да акрын гына атлап, сезне калдырып менә бу базга керү бер дә килешми бит әле, дигән кыяфәт белән, ишек янына барды Галимҗан.

Бәй, баксана, иске-москы тактадан әштер-өштер рәтләштереп куйган ишектән җилләр искән. Монысын да якканмы кендекәй? Өйалды болай таза-чиста күренә. Җир идән булса да, чырайны сытып карарлык түгел. Акрын гына өй ишеген какты Галимҗан. Аннан:

— Керегез, — дигән тавыш ишетелде. Әмма ул бер дә Актүти тавышына охшамаган. Әллә нинди нечкә, нәзакәтле, моңлы, яшь тавыш иде.

Ачып керсә, ни күзе белән күрсен: сәкедә, аякларын асылындырып, Мәдинә-Акчәчкә моңаеп утыра. Бу көтелмәгән күрешү икесен дә авыр хәлгә китереп тераде. Алар бер-берсенә гаҗизанә карашып, катып калдылар. Карашларда аптырау да, гаҗәпләнү дә, әсәрләнү дә, хәтта гасабиләнү дә бар иде. Галимҗан: "И Мәдинәм — Акчәчкәм, беренче мәхәббәтем, сине бер күрү өчен зар-интизар булып йөри идем бит, Ходай Тәгалә безнең йөрәкләрне аңлый икән, менә ул үзе китереп кавыштырды", — дип уйлады. Мәдинә-Акчәчкә исә: "Их, Галимҗан абыкаем, харап булдык бит, ирем бик көнчел, бу очрашуны ишетсә, колак итемне чәйнәп кенә калмас, каеш камчысы белән ярыр, имгәтеп бетерүдән дә курыкмас, аның иманы юк", — кебек сүзләрне әйтәсе килде. Әмма яшьлек мәхәббәте, беренче мәхәббәте алдында аның да теле йозаклы иде. Кыскасы, күңелләр бу мөкатдәс мизгелдә мәхәббәт чылбыры белән богауланды. Мәдинә-Акчәчкә, йөземне күрмә дигәндәй, башын түбән иде. Шулай да ул бераздан башын күтәреп, мәэюс карашы белән өздереп бер карап алды. Бу караштa йөрәк уты да, күңел кайнарлыгы да, хис-тойгылар давылы да бар иде. Галимҗан аптырап калды. Аңа шушы минуттагы хикмәт үлчәвен кулга алырга иде. Мәдинә-Акчәчкә болай матур гына киенгән. Зәңгәрсу сатин күлмәк. Ак алъяпкыч. Артка чөеп бәйләгән ак яулык. Аркасына яткан ике толым. Аякларында читек. Кыскасы, аннан бай хатыны исе аңкып тора. Кергәндә өй эче караңгы иде әле. Чөнки бердән-бер карындык тәрәзә көн яктысын да урлый. Һаман шул элеккечә җир идән. Түрдә — сәке. Дөрес, өй эче болай пөхтә, нурлы, ямьле генә. Сул якта бәләкәй өй эчен чамалап салган кечкенә мич. Ул, кайбер ярлыларныкы кебек, алалытиләле түгел. Яхшылап агартылган. Тәрәзә кашагасына сөлге-тастымал эленгән. Бер чөйдә намазлык асылынып тора. Бераздан соң Галимҗанның тышта калган күзе дә әйләнеп кайтты. Өй эче һаман яктыра бара. Шулай да базны хәтерләтә бу ызба. Караңгы базда үсеп утырган гөл-чәчәккә охшатты Галимҗан Мәдинәне.

— Мәдинә-Акчәчкә! Син нишләп монда? — диде Галимҗан, ниһаять.

— Минем әти белән Актүтинең туган балалары икәнлеген беләсез ич, Галимҗан абый! Менә, хәер китергән идем.

— Без бит икебез беркөнне туган. Нигә мине һаман шулай элеккечә "абый" дисең әле?

— Әллә инде. Шулай гадәтләнелгән бит. Сезне зурлап, хөрмәтләп әйтүем. Сез бит алданрак туган. Шуңа күрә Актүти "абый" дияргә кушкание. Теге вакытта ук.

— Болай әйтүең мине шатландыра гына, Мәдинә-Акчәчкә!

— Куй, Галимҗан абый, ташлагыз, зинһар, шул "акчәчкә" дигән сүзегезне. Мин бит бу хакта теге вакытта да әйткән идем. Хәзер бу шаяртуыгыз бөтенләй килешми. Шуны онытмагыз, мин — ир хатыны.

— Син минем өчен барыбер "Мәдинә-Акчәчкә". Мәңге шулай булып калачак та.

— Ир хатыны алдында төчеләнү гөнаһ түгелме?

— Мәхәббәт барлык гөнаһлардан өстен тора.

— Мин андый матур сүзләрнең мәгънәсен аңламыйм.

— Мәхәббәт артык аңлашуларга мохтаҗ түгел.

— Сез инде андый купшы сүзләрне икенче берәүгә әйтегез.

— Син бераз юашланып калгансың шикелле. Болан баласы кебексең. Элек, әтиеңә охшап, каты сөйләшә торган гадәтең бар иде.

— Авыр сүз кирәкме, Галимҗан абый? Аны суган базарыннан сатып аласы түгел лә инде.

— Әйт кылчыклысын. Күңелем тынсын.

— Бакча карачкысыдай алдымда көмерәеп торма, мәхәббәт козгыны, бар кит, сыпыр, үкчәңне күтәр, ирем ифрат көнчел, бергә булганны ишетсә, икебезнең дә кабыргаларны санаячак, иманы юк аның.

— Димәк, яратып бармадың?

— Яратыр җире бармы соң аның?!

— Ә нигә бардың?

— Хәлле кеше булганга.

— Тамак тәмугка кертә шул.

— Димәк ки, бәхетле була алмадың?

— Ә сез үзегез бәхетлеме, Галимҗан абый?

— Әллә инде. Ул хакта уйланганым да юк.

— Әтиең беркөн әйткәние: “Иман белән гыйлем кешене бәхетле итә”, — дигәние. Сездә икесе дә бар бит инде, Галимҗан абый! Шулай булгач, сез бик бәхетледер.

— Рәхмәт, Мәдинә-Акчәчкә! “Галия” мәдрәсәсенең башлыгы Зыя әфәнде Камали әйткән иде бервакыт: “Бәхеткә ирешү өчен тугрылык белән гомер итәргә кирәк”, — дигән иде.

— Иманыгыз тугрыдыр бит?

— Мин шәхси бәхет турында сөйләмим, Мәдинә-Акчәчкә! Бөтен халык, ил бәхетле булмаса, син дә, мин дә бәхетсез дигән сүз. Инкыйлаб булып алды. Әмма халыкка бәхетнең чите дә тәтемәде. Алда зур инкыйлаб булачак. Патшаны бәреп төшергәч кенә киләчәк зур бәхет!

— Уй, куегыз, Галимҗан абый, авызыгыздан җил алсын мондый сүзләрне, тәүбә итегез, кан коюю илгә үләттән башка берни дә бирми. Кытлыклы елларны болай да аз кичермәдек.

— Башлыкка баш оралар, үсенсә, үз башын оралар, Мәдинә-Акчәчкә!

— Мин андыйларны аңламыйм, Галимҗан абый! Куй, тирәнгә кермик. Гөнаһлы булырбыз. Безнең каксыган күңелне агартып булмас барыбер.

Мәдинә, торып, чыгарга әзерләнде. Галимҗан:

— Ашыкма әле, Мәдинә-Акчәчкә, без бередә икәү генә, сиңа әйтәсе сүзләрем күп, Актүти кайтканчы сөйләшик, — дип, аның кулларыннан алды.

Нәкъ шул вакыт ярсыган үгез кыяфәте белән Мәдинәнең ире Илһаметдин килеп керде. Килеп тә керде, кәшәкә зурлыгы йодрыгы белән Галимҗанны сугып та җибәрде. Аннары Мәдинәнең чәч толымыннан урап тотып, өстерәп дигәндәй, җилтерәтеп алып чыгып та китте.

Галимҗан аврткан уң як күз төбен тотып карады. Ул сызлый иде. Әллә шешеп тә чыкканмы? Димәк, Илһаметдин истәлеккә бүләк-самак та калдырган. Менә сиңа балалык дусты. Бергә шар суккан, балыкка йөргән, бишташлы уйнаган дус.

Кайда югалды бу Актүти? Ник кайтмый? Инде көтеп торырга да ярамас. Алай, дисәң, шешкән күз төбе белән чыгып китүе дә кыен бит әле. Кендекәй кайтса, бер әмәлен табар, бәлки. Аның шешне суыра торган әллә нинди үлән-яфраклары да бар бит. Юк, кайтып китмәскә, көтәргә кирәк, дип уйлады ул.

Шул уйлары очына өйалдындагы аяк тавышы килеп ялганды. Бераздан, акрын гына нидер көйли-көйли, сөйләнә-сөйләнә, Хәмдия абыстай* кайтып керде.

— И-и-и!.. Кунак бар икән ләбаса, менә син агай, озак көттердемме үзеңне?.. Бәй, Галимҗан улым, кадерлем минем, син түгелме соң бу? Танымыйча да торам. Күз тышта калган бит; җәзгы җактылык, ызбага кергәндә, күз нурын алып кала торгание, бөген дә шулай итте, калебем, — дип сөйләнә-сөйләнә Галимҗанны кысып-кысып бер сөеп алды. Аннары һаман сүзләрен дәвам итте:

*Солтанморатта мулла остазбикәләрен генә түгел, мәртәбәле карчыкларны да, хөрмәтләп, абыстай дип йөртәләр.

— Балаларым бик ишле шул авылда, бик ишле, җездән артып китте, Аллага шөкер, бик баймын, бик бәхетлемен: аларның һәммәсе, мына синең шәйле, гелән генә килеп торалар, Ходайның рәхмәте яугыры үзләренә! "Актүти", "Хәмдия абыстай". "Кендек әби", "Кендекәй", дип, тагын әллә матур сүзләр әйтеп, җөрәгемне җылытып, күңелемне күтәреп китәләр, күгәрченкәйләрем! Менә терәкә! Әле менә теге Алпавыт урамындагы Сафура шалкандай сылу малай тапты. Җәнә дә бер бәхет борынлады, Ходайның рәхмәте! Дөнҗага жаңа кеше килү ата-ана өчен генә түгел, барча илгә зур бәхет ул, балакаем, син инде, шәт, аның шылай икәнлегән аңлыйсындыр.

Хәмдия абыстай картайган, бирешә төшкән иде. Хәят гарасаты аның башын идереп, аз гына бөкерәйтеп тә куйган. Шулай да кара шадраларыннан элеккечә ак нур бөркелеп тора. Ап-ак ситсы күлмәк, алга төшереп бәйләгән ак яулык, йөрәгенә сары май булып ятучы йомшак, мәгънәле сүзләр, мөлаем караш.

Сөйләшәсе килсә дә, Галимҗан сүзне хәзер җилем урынына сузмаска булды. Яңасын башласаң, Актүти сине сүзләр диңгезенә төшерә дә батыра ул. Аннан аны ерып чыга алмыйсың. Шуны уйлап, уң як чалбар кесәсеннән һаман әле ботын кытыклап торган көмешне алды, Актүтигә сузды:

— Хәер китергән идем, Кендекәй!

— Бәй, бәй, син бит аны киткәндә бирә торганиең.

— Мин озакламый китәм.

— Кай якларга сәфәр тотасың тагы да?

— Казакъ балаларын укыту ниятем.

— Бә-ә-ә-й, әле нугай, әле казакъ?..

— Шулай туры килә.

— Ни генә әйтием суң, күз нурым, ни генә әйтием. Мине олылаган өчен Аллаһу Тәгалә үзеңне мең өлеш зурласын, фәрештәләр җөргән җулыңа гөл сипсен, балакаем, бәхетле бул, бөркеткәем минем! Сиңа фатихам дөнҗа зурлыгы!

Алар, сәке йөзлегенә утырып, дога кылдылар. Шуннан ары Галимҗан, күз төбендәге Илһаметдин мөһерен дә күрсәтми, тиз генә кайтып китмәкче булган иде, әмма Кендекәйнең сөйкемле карашы ул кара тамганы шәйләп тә алды. Моңа Галимҗан үзе дә гаепле. Чөнки ул, һич тә аны-моны уйлап тормыйча, баш бармагы белән Илһаметдин "бүләк" итеп киткән шешне сыпырыштырып алды. Фани дөнья аны шактый какшатса да, Актүтинең күзләре әле һич тә бөркетнекеннән ким түгел икән.

— Бәй, бәй, Галимҗан улым, күңел тулпарым минем, нишләде күз төбең, җөрәккәем, әллә җыгылдыңмы? — дип борчылды.

Галимҗан алдашырга яратмый иде. Бар булган хәлне, — Мәдинәнең монда булуын, ихлас күңелдән сөйләшүне, шуннан ире Илһаметдин килеп зилзилә куптаруны, хатынының чәч толымыннан тотып, өстерәп алып чыгып китүне, артык уратмый-чуратмый сөйләде дә бирде. Актүти хафага төште:

— Илаһым... Ул Нәҗметдин бай баласы Илһаметдин бикләр дә әшәке булып чыкты бит, хәзер дөнҗа куптарыр инде, Мәдинәкәемне хараплар гына итеп ташламаса жарар иде инде, имансыз бит ул, имансыз... теге җәшел җылан белән дуслашып алган икән юньсез!

— Шешне тиз генә бетерә торган берәр шифаң юкмы, Кендекәй, болай урамга чыгу әллә ничек бит әле, әткәй- әнкәй алдында да оят, әллә ни уйлаулары бар. Болай да мин аларны гел генә хафага салып яшим.

— Алай үкенә белгәч жарый инде, җөрәгем, димәк ки, синең эчеңдә асылташ бар. Ана, асылташны сакларга тырыш, күгәртмә, каралама, шунда булырсың кеше. Дуамаллыгың да җук түгел бит синең, жаныкаем, ата-ана фатихасы белән җәшәргә тырыш, менә шул, — дип сөйләнә-сөйләнә чыгып китте дә ниндидер яфраклар алып керде. Казаныннан чүмеч белән җылы су алып, шуны бер тустаган сымаграк нәрсәкәйгә салды да, әлеге үләннәр гөлләмәсен җебетте. Аннары аларны бер бәләкәй генә чүпрәккә төреп, Галимҗанга китереп тоттырды:

— Кырыктан артык шифалы үлән, чәчкә жафрагы мында, җитмеш төрле имгә җарарлык, җылы көе тотып кына утыр, хәзер суырып шешенне. Иллә мәгәр кайтмый тор, мин озакламам, Алла боерса, — дип, һаман шулай сөйләнә-сөйләнә, тәтелди-тәтелди чыгып китте.

Актүти кайтмый да кайтмый. Ялгыз утыру кыен булса да, хатирәләр дулкынына кереп чуму аның төшенке күңелен бераз күтәреп җибәрде. Иң тәүге кат Галимҗан бирегә 1899 елның көзендә, унике яшьлек чагында, Оренбург мәдрәсәсенә китү алдыннан килгән иде. Анда да әнисенең әйтүе буенча хәер китерде. Ләкин аны сәкедә ирәеп-җәелеп аракы эчеп утыручы бер шәрә, йонлы күкрәк каршылады. Актүти белән туганнан туган балалары икән үзе. Күрше чуваш авылында ишек ясаган өчен көмешкә биргәннәр. Актүтинең өйдә юклыгын шәйләп, хатыны, балалары белмәсен өчен, шуны эчәргә монда килгән икән. Култык астына йодрык зурлыгы гына гармунын кыстырырга да онытмаган.

— Мин ат карагы, — диде ул маңгай астыннан гына карап.

Бераздан Актүти кайтып керде. Эчеп утырганы өчен ару гына тетмәсен тетеп алды. Аннан хатыны Мәликә түти килеп керде. Ул да эчеп утырганы өчен төлле генә сүзләр чәпәде. Ат урлауны ул төшендә күргән икән. Шуннан, авыз тутырып, шаярып, үзен "ат карагымын", дип сөйләп йөри башлаган. Уеннан уймак чыга, дигәндәй, халык аны, чыннан да, ат карагы дип кабул итә. Мөбахис мәзиннең кара сарыгы югалгач, бәлане аңа ягалар. Моңа чаклы да гаеп-гораәбсе шактый күп булган икән шул. "Хөрмәтулла"дан "Хөрмәй"гә, аннан "Хәрти", "Хөрти"гә әйләнгән. "Хөрти" дигәнен ямьанлык тамгасы сыйфатында сылап куйганнар. Бераздан аларның кызлары Мәдинә килеп керә. Аларга, имеш, бер кеше килгән. Ул әтисен таптыра. Мәликә түти белән кызы Мәдинә бер тамчы судай охшашлар. Икесе дә чибәрләр. Ә инде Хөрмәтулла абзый — боларның киресе. Ямьсез. Котсыз. Маймыл диярсең. Нишләп ана барды икән Мәликә түти? Бәлки, ир-егетлек куәте, гайрәте, гаярьлеге тарткандыр, дигән сөземтә ясады ахырда Галимҗан.

Тора-бара һәммәсенең йөрәк капкачы ачылып китте. Ул йөрәкләрдән өй эченә моң түгелде. Кендекәй рөхсәте белән, акрын вә салмак кына, башта Хөрмәтулла абзый гармун уйнап җырлады. Аннан аңа Мәликә түти кушылды. Алар бик сак, тавышны чама белән генә чыгарып, башка өйләргә ишетелмәслек итеп кенә җырлыйлар. Монда тавыш түгел, моң агыла. Кем белә: аларны шул моң кавыштыргандыр, бәлки. Аннан Кендекәй Мәдинәгә җырларга кушты. Озак ялындырды Мәдинә. Дөресрәге — кыенсынды. Әтисе, әнисе әйткәч кенә ризалашты. Ике җыр җырлады Мәдинә. Шуның берсе аеруча нык уелып калды Галимҗан күңелендә:

Кара күзләр түзем була
Кайгылар күргәндә дә;
Кара күзем, иркә гөлем,
Онытмам үлгәндә дә.

Бу җырны Галимҗан үзенә алды. Аның да күзләре кара ич. Тик кайгылар килгәндә — алар булгалап кына тора — ул әле һич тә түземле була алмый, утка баскан песидәй үрле-кырлы килә. "Кара күзем, иркә гөлем, онытмам үлгәндә дә", — дигәне аның күңелен ифрат дәрәҗәдә нык тетрәндерде. Шунда кабынды бугай Галимҗан йөрәгендә тәүге, серле, сихри мәхәббәт чаткысы. Җырлаганда Мәдинәнең аксыл йөзендә алсулык төсе балкый. Бит очындагы сизелер-сизелмәс сипкелләре җемелдәп-җемелдәп куя. Алар үзләре бер исем табуы, атавы кыен булган ниндидер тылсымлы чәчәкне хәтерләтә. Әнә шунда килгән иде Галимҗанның башына аны "Мәдинә-Акчәчкә" дип атау уе.

Ләкин бу гаилә өстендә кара болытлар һаман куерып торды. Хөрмәтулла абзыйны, Мөбахис мәзиннең югалган кара сарыгын урлауда нахакка гаепләп, башта бик каты тукмап, аннан ат койрыгына бәйләп, бөтен урамнан сөйрәтеп йөрттеләр. Соңыннан сарык табылды. Әмма кеше

имгәнеп калды. Мөбахис мәзиннең аты югалгач, янә Хөрмәтулла абзыйны гаепләп, аны тереләй килеш күмәләр. Бу гарьлекне күтәрә алмаган Мәликә түти, кулына күсәк күтәреп барып, Мөбахис мәзиннең тәрәзәләрен кыра. Аны Нәҗметдин байның таш келәтенә ябалар. Шунда ул акылдан шашып үлә. Күзләре кара булса, Мәдинә-Акчәчкә бу кайгыга түзәр иде микән? Әмма ул түзә алмый шул. Акылын югалта. Шөкер, акылы кире кайта. Тик бәхет дигәне аннан һаман әле ерак йөри икән. Нишләтер аны Илһаметдин? Галимҗанның күз төбендәге шеше тиз бетәр. Ә менә Мәдинә-Акчәчкә йөрәгендәге яралар төзәлерме?

Шундый тирән һәм киң уйлар дингезендә йөзеп йөргәндә, сискәндереп, оялдында аяк тавышы ишетелде. Һаман шулай сөйләнә-сөйләнә кайтып керде Актүти.

— Бездән өч өй аша гына Зифабану бәбәйгә авырып киткәние. Әле шуның янына барып килдем. Бик акыллы кемсә. Нык җаратам үзен. Бүген төнлә куна барырга кирәк булыр. Вакыты җитә, шәт. Ә үзең ничек соң? Күзең?

— Авыртуы басылды, Кендекәй!

— Шылай булмыйча сун. Кая, карыйк әле.

Галимҗан теге ул биргән чүпрәкне күз төбендә һаман тотып тора иде әле. Хәмдия абыстай аны Галимҗан кулыннан тартып алды да, авырттырмаслык итеп, шешнең тирә-ягыннан бармагы белән баскалап карады.

— Мына күрерсең, Аллаһы боерса, иртәгә чаклы эзе дә калмас. Кендекәй әйткәние диярсең, хәзер мин сиңә ул шифа үләннәрнең җаңасын төреп биреп җибәрәм, шылай мин өйрәткәнчә, кайткач та, төнлә дә эшләрсең, — дип сөйләнә-сөйләнә, янә өйалдына чыгып китте дә теге үләннәрнең яңасын алып кереп, икенче бер чүпрәккә төреп бирде...

## VII

Галимҗан кайтып кергәндә, аскы катта аш табыны әзерләнеп беткән иде инде. Дус-иш, туган-тумача, кардәш-ыру, күрше-күлән... Һәммәсе мәш килә.

Солтанморат халкы, кем әйтмешли, кәбестә шикелле катлы-катлы. Башкортлар үзе бер урам хасил итә. Алар төньяктагы тау сыртына тезелеп утырган. Алатыр мишәрләре авылның урта урамнары буенча йорт сала-сала сузылган. Янә дә типтәрләр, татарлар төрле урынга килеп җайлашкан. Татар-мишәрләрнең — үз шивәсе, башкортларның — үз теле, типтәрләрнең — тагын үзенчәлекле сөйләме. Холык-фигыльләрендә, тормыш итү үзенчәлекләрендә, эш-хезмәткә булган мөнәсәбәтләрендә дә аерма бар. Җан исәбе алу вакытларында татар, мишәр, типтәр аерым милләт булып языла. Оренбурда да, "Галия" мәдрәсәсендә укыганда да Галимҗан аларның килеп чыгу тарихын төбе-тамырыннан өйрәнде. Анынча, татар, мишәр, типтәр — бер тамырдан үсеп чыккан зур тарихи кәүсә ул. Киләчәктә, шөбһә юк, алар бер милләт булып каралачак.

Тирә-якта мари, мордва, урыс, алман — тагы да әллә кемнәр яши. Шулар арасыннан иң күбесе — чувашлар. Галимҗанның әтисе әллә кемнәр белән дуслашып бетә. Ә инде дуслыкка хилаф итүне жене сөйми. Билгеле, дуслык җепләренең төйнәлеп китүе сәбәпсез булмый. Башкорт Котлызаман аңа, ат чабыштыру жене кагылганлыгын искә алып, чабыш атыннан туган Алмачуар колынын бүләк итә. Ул да килгән хәләл җефете Көнсылуын җитәкләп. Чуваш Әптерәйнең бик тере, елгыр улы Әләксәй бер елны Алмачуарга атланып чабышка барган иде. Беренчелекне алды бу ут бөрчәсе. Аларның ихлас дуслыгы, ничек кенә сәер тоелмасын, сабан туендагы ат чабыштыру хосусиятенә бәйләнгән. Әптерәй дә килгән Кәтринәсен ияртеп. Тагы да әллә кемнәр.

Димәк, мондый мәҗлеснең чишмә башы әллә кайчангы дуслык тойгылары бөеклеге белән аңлатыла. Бала ата шәһрәте яктылыгында

яши. Әтисен хөрмәт итмәсәләр, Галимҗан, ихтимал, алар өчен тишекле бер тиен генә торыр иде. Ата мәртәбәсе күтәрә баланы. Бүгенге кунаклар аеруча шат күренә иде.

Галимҗанның бер күзен ниндидер чүпрәк белән каплап кайтып керүе генә берникадәр сәерсендерде аларны. Иң әүвәл әнисе хафаланып сорады:

— Ни булды, балакаем? Нишләде күзең? Әллә агачка-мазарга төртелдеңме? Егылдыңмы әллә?

Бу сорауларны көткән иде Галимҗан. Ничек итеп җавап бирү турында әллә ниләр уйлый-уйлый баш ватты ул. Ә менә әнисе авыр җаваптан коткарды да куйды. Хәзер инде йә "егылдым", йә "агачка төртелдем" дип кенә җавап бирәсе. Соңгысын сайлады Галимҗан. Аннан соң әнисе — Хәсәнә абыстай — өске катка алып менеп китте дә йомшак мамыкка хушбуй сибеп, шуның белән әлеге шешенең тирә-ягын сыпыргалады. Тагы да ниндидер кара-коңгырт сыекча сөртеп, акрынлап-акрынлап, шеш тирәсен аның битенә охшатып калдырды да:

— Хәзер инде көзгегә кара, — диде.

Караса, ул кадәр куркыныч нәрсә күрмәде. Әнкәйнең дә, икенче әнкәй — Актүтинең дә күңелләре дә, куллары да сихәтле-шифалы икән, дип уйлады ул. Шулай да мәҗлес өстәленә утырудан баш тартты. Кеше алдында уңайсызланды. Әмма әнисе чарага куймады:

— Юк, юк, улым, алай килешми, алар бит сине котларга килгән, яраңа игътибар да итмәсләр әле, менә күрерсең, —диде.

Галимҗан андый мәҗлесләрнең уртасында булырга үзе дә ярата. Халык күпне күрә, күпне белә, күпне хәтерли. "Әткәй әйткән иде", "Картәти шулай дигән иде", "Бабакай болай дигән иде", "Ерак бабай әйткәнчә" кебек сүзләрне куллана-куллана сүз көрәштерергә керешәләр. Чал тарихтагы хәл-вакыйгалар яшь күңелнең ак сәхифәләренә языла бара. Күңелгә генә язылып калмый, кәгазьгә дә төшкәли. Әнә бит, "Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы" исемле беренче хикәясе Казанда басылып чыкты. "Гыйшык корбаннары", "Яшьләр хәятыннан бер ләүхә", "Яз башы", "Дингездә", "Йөз ел элек", Сөю-сәгадәт", "Уты сүнгән җәһәннәм" кебек хикәяләр — әлегә зиһене дөньясында. Аларны кәгазьгә төшерергә генә кирәк. Ни нәрсә түгелер ак кәгазьгә каләм очыннан: сүз-акыл вә хис-тойгы җәүһәрләреме, коры шапырынулармы? Гаяз Исхакый әфәнде Оренбурда "Хөсәения" мәдрәсәсендә шәкертләр белән очрашкан чакта әйткән иде: "Язучы өчен бөркет күзе, сандугач колагы кирәк", — дигән иде бит. "Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы" хикәясендә әле сүзләр һич тә былбыл булып сайрамый. Алар әле, Галимҗанның үз фикер йөртүенчә, йә чикерткә булып чәрелди, йә каргадай каркылдый, йә саескан шикелле такылдый? Әнә бит Толстой җәнаблары, Пушкин хәзрәтләре, Тургенев, Лермонтов, Достоевский... — тагы да шундый бөек-ләрнең әсәрләрендә һәр сүз ниндидер бер зур идеяне нәкышләү җәһәтен-нән файдаланыла. Гаяз әфәнде Исхакый җәнаблары да сүзләрдән чәчәк гөлләмәсе ясый белә. Гаяз әфәнде Оренбурда "Халык арасында кайнарга, аларның кайгысын да, шатлыгын да уртаклаша белергә, йөрәк тибешләрен, күңел әрнешләрен анларга кирәк", — дигән иде. Бик яшьли танылган бу каләм иясенә Галимҗанның хөрмәте аеруча зур иде шул. Ул әсәр тукымасында сүзләрне, ай-һай, җай гына кәрәзли белә. Әнә, шулай оста булсаң иде!

Әле табын янына утырышмаганнар иде. Тынлыкны чәчрәнләп торган башкорт хатыны Көнсылу бозды. Яшьрәк вакытта, чегән кызларыдай, талчыбыктай нәфис гәүдәсен уйнаклатып, бер басасы урынга биш басып тора иде ул. Аның күмердәй кап-кара күзләре әллә нинди сихри-серле ялкын сибә. Җырлаганда дала моңнары чыңлый. Көлгәндә чишмә чылтыраулары ишетелә. Хәзер инде ул — сигез бала анасы. Әмма яшьлек дәрте һаман әле тормыш мәшәкатьләренең кара давылына күмелеп калмаган. Һаман шулай чая караш. Гәүдә уйнатып алу. Кымырҗып тору.

— И Гәлимйән, йөрәккәйем, битерәк ябыкканһын бит, карга күтәреп китерлек булганһын. Һы-һы, укыузы энә менән козок казыу тип белмәй әйтмәйзәр шул. Кешене тәмам коро таякка калдыра бит ул, көл итә, бөтөрә, — дип тәтелдәде ул.

Ирек куйсаң, Көнсылуның сүзләре сәгатьләр буена сузылырга мөмкин. Аны ире Котлызаман туктатты:

— Һин тузга язмаганды һөйләмә әле, Көнһылыу, кешенең гәйрәтенә кагылма. Һөйәк булһа, башкорт әйтмешләй, ит куна ул бервакыт. Шәкерт ул язын хәлһез һарыкка окшап калһа, йәй буйы көс йыйып, көзөн айыу менән көрәшерлек пәһлеүәнгә әүерелә.

Котлызаманның сүзеннән җинелчә генә көлешеп алдылар.

Чуваш Әптерәй, ат дагалаганда бака ботын кыстырган дигәндәй, бүген дә шул гадәтен күрсәтте.

— Син, Көнсылу, кара кашым, карлугачым, Галимҗанны карга күтәреп китәрлек тисен, пез... Кәтринә пелән мин... пу сүз пелән гүпчи килешә алмыйпыс. Ни үчүн килешә алмыйпыс сун, ә? Кәзер әтәм. Ашыктырмакыс. Пер бакыт мине карга төгел, пөркет күтәреп карады. Тәки пирешмәнем пит, әй. Потарладым да ташладым пөркетте. Шуннан икенче көнне, ихатага чуксам, ун пөркет көтеп тора мине. И пәрешәпес, и көрәшәпес. Тукысын сузып салдым. Пересе кенә калды. И сурай пу миннән: "Әллә син чувашмы?" — ти. Мин әйтәм: "Никә улай сурайсың?" Пу әйтә: "Чуваш пулмасаң, пу кәдәр көчле пулмас иден", — ти. Шул сүзләре өчен пынысына тимәдем. Кайдан килгән, шунда очыруп еппәрдем. Бына шулай ул.

Кунаклар рәхәтләнеп бер көлешеп алды. Ниһаять, Хәсәнә абыстайның табынга рәхим итергә дигән әмере булды.

## VIII

Галимҗан, өч-дүрт көн тору белән, казакълар арасына китмәкче иде. Мөгаллимлек кылырга. Шулай да әнисе аны һаман-һаман китмәскә үгетләде. Күз төбендәге шешнең "егылудан"да, "төртелүдән"дә түгел икәнлеген ана күңеле сизенде.

— Улым, моңарчы яхшысын да, яманын да әниеңнән яшермәдең, алдашма, дөресен әйт: минем алда да, Ходай каршында да гөнаһлы булып калма — күз төбеңдәге кара төер кем "бүләге" ул? — дип сорады ул, кайту шатлыгыннан оештырылган мәҗлестән соң ук.

Галимҗан елмаеп куйды. Ул, әлбәттә, бу хакта әнисе сорамаса да әйткән булыр иде.

Нәҗметдин бай малае Илһаметдин белән булган кара вакыйганы әнисенә түкми-чәчми сөйләп бирде. Мондый чакта Хәсәнә абыстай, гәрчә чәйнәүгеч аналар сыман теле белән талкып-талкып алмаса да, җитди бер нәтиҗә — сөземтә ясамый калмый. Бу юлы да шулай итте:

— Дөнья, улым, шуңа корылган: син берәүне кыйнасаң, ул да сине кыйный, син кемгәдер авыр сүз әйтсәң, ул да сиңа авыр сүз әйтә: син аны рәнҗетсәң, ул да сине рәнҗетә. Борынгылар: "Бер алдыңа, бер артыңа карап яшә", — дип белми әйтмәгән.

— Минем, әнкәй берәүне дә кыйнаганым юк.

— Телең белән дәме?

— Анысы бар.

— Авыр сүз дә әйтмисеңме?

— Кешесенә карата.

— Рәнҗетмисең дәме?

— Кирәк булганда.

— Менә шул-шул. Ир хатыны белән аулакта очрашу кеше рәнҗетүгә кермидер шул.

— Әнкәй, син дә бу юлы мине аңламадың.

— Моны аңларга фәрештә булу кирәктер шул.

— Мин бит аны теләмәдем. Үзеннән-үзе шулай килеп чыкты.

— Сәбәпнең сәнәге күп чатлы, балам, аңа алданма. Үзең мөхәррир-язучы булырга җыенасың...

Шуның белән аларның сүзләре киселде. Галимҗан, кысып кочаклап, әнисен үбеп алды. Хәсәнә абыстай да җавапсыз калмады. Бәләкәй чагындагыча куенына сыенган Галимҗанның чәчләреннән сыйпап, улының аркасыннан сөя-сөя иркәләде.

* * *

Яз көләч кыз елмаюын хәтерләтеп, балкып торды. Иртән кызарып кояш чыга, әле яңгыр явып үтә, әле җылы җилләр исә. Кичен кояш таулар артына яшеренә. Солтанморат халкы, тормыш җебенең очын-очка ялгый-ялгый, алдагы көннәрдә киләчәк зур бәхеткә өмет баглап, үз җае белән яши бирә.

Көннәрдән бер көнне, өйлә намазыннан соң, ишегалдында ялгыз гына йөргәндә Галимҗанның күзе капка башындагы сыерчык оясына төште. Менә бервакыт ата сыерчык кырдан кайтып төште дә оясының түбәсенә кунды. Авызында ашамлык-корт иде. Бераз торгач, ояга кереп китте дә ул, озакламый, янә әйләнеп чыкты. Авызындагы ашамлык-корт юк иде инде. Галимҗан шуны аңлады: ана сыерчык хәзер бала чыгарырга утырган — аңа инде йомыркаларын калдырып китәргә ярамый. Суына. Димәк, аны тукландырып тору вазифасы тулысы белән ата сыерчыкка "йөкләтелгән".

"Ата кеше", тагы да оя түбәсенә кунып, озак кына моңаеп утырды. Нигә күңелсезләнә? Нигә сайрамый? Ни уйлый икән? Әллә парлап очу мәлләрен сагынганмы? Басуда сөеклесен тукландыра торган азык юкмы? Табу кыенлашканмы? Хәзер инде кайсы тарафка очарга белми мазасызланамы?

Чү! Уф! Ни булды? Нәрсәдер килеп тиде дә сыерчык әйләнеп тә төште. Күз ачып күз йомган арада эшләнде бу. Йөгереп барып, Галимҗан сыерчыкны кулына алды. Аның башыннан кан ага иде. Әллә берәрсе таш атканмы? Кем? Ни өчен? Бу бит бернинди әхлак кысаларына сыя торган хәл түгел. Галимҗан, ялт итеп, ян капкадан урамга чыкты. Ун яшьләр чамасындагы бер малай уң якка, икенчесе сул якка таба йөгерә. Димәк, ташны шуларның берсе аткан. Кайсысы артыннан йөгерергә? Галимҗан унга җилдергәнен сайлады. Әмма тота алмады. Каядыр кереп качты юньсез. Ә кулдагы сыерчык чәбәләнә, үрсәләнә, үлем белән яшәү арасында өзгәләнә. Нишләтергә? Кая куярга моны? Ничек дәваларга?

Шулай уйланып торганда, әнисе килеп чыкты. Улы кулындагы сыерчыкны күреп, аптырап калды ул. Галимҗан булган хәлне тиз-тиз генә сөйләп бирде. Хәсәнә абыстай исә бөтенләй гаҗиз калды.

— Бу, балакаем, бүген генә түгел, моңа чаклы да булгалаштырды. Бала-чага теге ни... нәрсә диләр соң әле... рәгәт... рәгәт... әйе... рәгаткә дигән нәмәрсәкәй ясый икән... Шуннан аталар... беркөн дә ишегалдына бәләкәй генә таш килеп төште. Мәгәр анда сыерчыкка тимәгән иде. Теге... Мөбахис мәзин малайлары шаяра икән.

— Бу шаяру гына түгел, әнкәй! Мөбахис мәзин белән әти арасында кара елан йөри. Димәк, ул балаларын да котырта.

Сыерчык аның кулында җан бирде. Галимҗан бакчага кереп бер әрекмән өзеп алды, сыерчыкны шуның өстенә куйды да китеп барды. Хәсәнә абыстай аның һәр хәрәкәтен күзәтеп торды. Галимҗанның авыр кичерешен аңлау кыен түгел иде. Йөзе күм-күк булды. Иреннәре дерелди. "Һәй, кешеләр, бер-берегез белән ызгышуыгыз җитмәгән, инде хәзер яшәвебезгә ямь, ләззәт, матурлык биреп торучы гүзәл җан ияләренә дә газраил булып ябырыласызмы?!.." — дип кычкырасы килде аның...

Гыйрфан мулла, Шакирҗан белән Габделхәкимне ияртеп, иртүк печәнлекләрне карап кайтырга киткән иде.

— Әтиең кайткач мәслихәтләшербез, балам, бу сыерчыкны кая кую турында, — диде Хәсәнә абыстай.

— Борчылма, әнкәй, бар, эшенне кара, үзем бер җаен уйлап тапкач, сиңа әйтермен, — дип җавап бирде Галимҗан.

Абзар эчендә бер остаханә бар. Ата кеше балаларын бәләкәй чакта ук пычкы белән утын кисәргә, янә бераз үсә төшкәч, аларны балта белән ярырга өйрәтә. Бусы инде "хезмәт тәрбиясе" дип атала. Остаханәдә зур балта, бәләкәй балта, зур пычкы, бәләкәй пычкы, тишкеч, өтерге, келәшә, кыскыч... — тагы да әллә нинди кораллар бар. Алар белән ничек эш итәргә ата кеше улларын башта үзе өйрәтә. Тора-бара остаханәне үзләре иркенә тапшыра. Шунда тегесен ясап, монысын әтмәлләп, кулларын канатып бетерәләр. Бу кадәрәсенә ачуланмый ата кеше. Көлеп кенә куя. Без — шалкандай сигез малай, җиләктәй дүрт кыз, димәк ки, җәмгысы унике бала мыжылдашып үстек; әти карт — Нурмөхәммәт имам — әлләләл усал иде; бәй, шулай булмаса, ул унике җан иясен ничек итеп тормыш бураэнасына төшереп җибәрәсең, дип уйлый. Шуңа күрә балаларына:

— Әти карт безне шулай өйрәтте, әти карт безне болай өйрәтте, — дип, үз фәһемен бирә башлый.

Галимҗан остаханәдә, шул сыерчык оясы зурлыгында итеп, тактадан бер әрҗә ясап алды. Әрҗә төбенә йомшак чүпрәк җәеп, сыерчыкны шунда куйды да әнисен чакырды. Әнисе килгәч, бу газиз, гөнаһсыз, сылу җан иясен аңа күрсәтеп, әрҗәне кадаклап куйды. Аннан бакчага кереп китте. Әнисе дә аннан калмады. Бакчаның түрге өлешенә барып җиткәч:

— Әнкәй, мин бу оҗмах кошын менә монда — чәчәкләр арасында кабер казып җирлим, — диде.

— Ярый, улым, бик мәслихәт, бик дөрес эшлисең, — дип, улының аркасыннан сөеп китте Хәсәнә абыстай.

— Әнкәй! Мин хәзер кырга китәм. Ана сыерчык бала чыгарырга утырган. Аңа, суынмас өчен, йомыркаларын калдырып китәргә ярамый. Корт җыеп алып кайтам да оясы янына капка түбәсенә куям. Шунда чыгып ашар.

Хәсәнә абыстай яулык очы белән шатлыктан чыккан яшь бөртекләрен сөртеп куйды. Ниндидер зур, кыйммәтле, кадерле сүз әйтәсе килде аның. Шулай да сүзне озакка сузмады.

— И балакаем, бу кадәр дә йомшак, нечкә күңелле, олы йөрәкле булырсың икән, — дип куанды ул.

## IX

Кичен, ахшам намазыннан соң, алар җыйнаулашып чәй эчте. Чәй табыны ризык-нигъмәткә мул булган шикелле, күңел күкләре дә шатлык-куаныч хисенә, рухи юанычка бай иде. Берничә көннән Галимҗан казакълар арасына китәчәк. Шуңа күрә барысы тарафыннан да аңа кадер-хөрмәт зур.

Ләкин бу яктылыкка кинәт кара таракан килеп төште. Инде чәй табынын җыештырып, ястү намазын көткән арада Нәҗметдин бай малае Илһаметдин ярсып килеп керде. Өй эченә аракы исе аңкып җәелде. Бу имансызның ниндидер хәвеф-хәтәр куптарырга йөргәнлеген дә һәркем чамалап алган иде инде. Ул шулай булды да.

— Мин хатыным Мәдинәне үтердем! — дип кычкырды ул. Шуннан, кибәк ашап күбенгән сыер шикелле, үз сүзләрендә үзе тыгылып калды. Бу мизгелдә аның бөтен бәдәнендә, йөзендә ахмаклыгы өчен йомшару, үкенү, хатынын кызгану кадәрәсе дә бераз сиземләнеп калды. Мәгәр ул озакка бармады. Аз гына йомшарган йөз янә ерткычлык тойгысы белән катыланды. Ә инде: "Хатыным Мәдинәне үтердем", — дигән тетрәндергеч сүзләр башкаларны һуштан яздырды.

— Мин үтермәдем аны, Гыйрфан бабай, Хәсәнә абыстай, дип дәвам итте бу зобани, — аны сезнең "асыл сөяк" улыгыз Галимҗан үтерде.

"Асыл сөяк" түгел ул — сарык тиресенә төренгән бүре. "Галия" мәдрәсәсенә киткәнче Галимҗанның Кондызлы күл буенда Мәдинә белән уйнаш иткәнлеген әллә мин белмәдемме? Белдем. Галимҗан өчен Мәдинәнең акылдан язуы хакында бөтен авыл халкы сөйли. Ярый, Мәдинә элекке хәленә кайтты. Алдым мин аны хатынлыкка. Бер төнне, йокы аралаш, Мәдинә мине "Галимҗан" дип кочаклады. Аңа да түздем. Бу минем тарафтан кешелеклелек күрсәтү түгел идемени? Ә? Эндәшмисез?! Ярый, монысы үтеп китте. Мәдинә — ир хатыны. Ә нигә алар һаман аулакта очраша?! Ә?! Эндәшмисез?!

Илһаметдин битеннән аккан тирне уң кулы белән сыпырып алды. Битенә кан буялды. Моның Мәдинә каны икәнлеген аңлау кыен түгел иде. Шул канлы бармаклардан йодрык төйнәлде. Бу йодрык Галимҗанның ике күзенә бер-бер артлы тондыру өчен иде. Эшнең болай зурга китүен шәйләп алган Гыйрфан мулла тизрәк арага керү җаен карады. Мөмкин кадәр сабыр булырга тырышып, сүз башлады:

— Илһаметдин улым, син бит тегенди-мондый, беткән, юлдан чыккан, акылсыз кеше түгел идең. Сокланып карап торырлык имән кәүсәседәй гәүдәң бар, Ходайга шөкер, көч-куәтең ташып тора, Аллаһы Тәгалә үзенә тел ачкычы да биргән. Мондый авыр мәсьәләне йодрык белән дә, акырып-бакырып та хәл итеп булмый. Әйдә, яхшылап кына аңлашыйк әле: кайда, нинди аулак урында очрашкан соң Галимҗан Мәдинә белән — минем шуны беләсем килә?

Илһаметдин аз гына түземлек-сабырлык игенә керде. Шулай да үзен газамәтле-өстен тотарга кирәклекне онытмады. Гыйрфан мулланың йомшак әйтеп, катыга утырырга маташуын да чамалап алды ул. Шуңа күрә үз туксанын туксан итәргә тырышты:

— Һм, кайда, имеш. Хәмдия карт шайтаннарда. Җитмәсә, "Актүти" дип йөрткән булалар. Битендә кара пәрдә, эчендә кара елан бит ул хәшәрәт карчыкның. Кендекәй, янәсе. Нигә очраштыра ул Мәдинә белән Галимҗанны үз өендә? Очраштыра да, юк эшне бар итеп, үзе каядыр, китеп бара, убырлы карчык. Өсләренә барып чыктым бит! Мин, Галимҗан, кулымдагы Мәдинә канын синең йөзенә буйыйм дип килгән идем. Ләкин әле ул фикердән кире кайттым. Әйдә, үземдә калсын Мәдинә каны. Менә бу чукмардай йодрыгым белән ике күзеңә җибәрү дә иде исәп. Бу уемнан да кире кайттым. Чөнки Мәдинә каны белән синең каныңны кушасым килми. Әмма шуны бел, кара елан, мин исән чакта бу фани дөньяда сиңа якты көн булмаячак. Мин бу хакта "Галия"гә язачакмын!

Илһаметдин ничек ярсып килеп кергән булса, шул дәрәҗәдә котырынып чыгып та китте. Өй эчен авыр тынлык басты. Һәммә гаилә әгъзасы телсез калды. Кемнендер нindидер сүз әйтүе хәзер тозы таман ашка янә учлап-учлап тоз салу кебек кенә булырга мөмкин. Галимҗан өчен бу минутлар аеруча авыр иде. Мәдинә белән тамчы да гөнаһы юк лабаса. Моны әнисе аңлый, әлбәттә. Илһаметдин сүзенең нахак икәнлеген дә белә. Әле ананың кызганучан, миһербанлы күз карашы ук әйтеп тора. Әмма әтисе аңа әлегә сарыкка караган бүре күзе белән карый. Менә хәзер чәйнәп ыргытырга җитешеп тора. Шакирҗан — битараф. Аның карашы әллә дөрес, әллә ялган дигәнне аңлата. Габделхәким: "Минем өчен арба ватылса — утын, үгез үлсә — ит", — кебегрәк кыяфәт күрсәтә. Галимҗан исә озак кына сыны катып торды. Аннан, селәүсендәй җитез хәрәкәт ясап, чыгып йөгерде. Аның Мәдинәне күрәсе килде: чыннан да, үтергәнме аны Илһаметдин, әллә ялганлый гынамы? Бусы — бер. Икенчесе — Илһаметдин белән аңлашу нияте... Алдында бу хакта сүз куертуны кирәк санамады. Хәер, ул вакытта мөмкин дә түгел иде. Чөнки ярсыган Илһаметдинга нindидер сүз әйтүнең дөрләп янган утка май өстәү икәнлеген яхшы аңлады ул. Их, Илһаметдин, Илһаметдин! Әйбәт кенә егет идең ләбаса! Нишләп болай җенләндең соң әле син?... Кыскасы, аңлашырга кирәк. Авылдан болай кара гайбәт төяп чыгып китү килешми ләбаса!

Галимҗанга берәү дә сүз катмады. Артыннан әнисе йөгереп чыкты:

— Балам, Галимҗаным, кая болай шашынасың әле? Күрәчәгең җилкетмидер бит! — дип өзгәләнде. Ләкин Галимҗан бу юлы әнисен тыңламады.

### X

Нәҗметдин бай вак-төяк белән сату итә: тарак, кашык, савыт-саба, камыт-дуга, күлмәк-ыштан... Шулар белән ул якын-тирәдәге Эстәрле, Уфа, Оренбур калаларына гына түгел, җаен туры китереп, хәтта Казанга да барып чыга. Тиен өстенә тиен өстәлә, акмаса да тама, кебегрәк "иман" белән яши. Фырт киенеп, билгеле бер газамәт белән йөрүе, кыяфәт-калебе аны бай кеше итеп күрсәтә. Дөрес, соңгы вакытта яшел елан белән дуслашып китүе турында урам хәбәрләре йөри. Яшел елан Илһаметдинны да ару гына чаккан икән, дигән хәбәрне дә урам авызлар тиз таратты. Шулай инде: авыл халкының күзе күпне күрә, колагы күпне ишетә — аннан бернәрсәне дә яшереп булмый.

Ә инде Мәдинә белән Галимҗан хакында ул көнне гайбәт таралуга Хәмдия абыстайның күршесе Хәмәтдин карт гаепле. Монысы аның икенче мәртәбә шулай кеше муенына нахак камыты кидерүе. Беренче бәла 1899 елда — ягъни Галимҗан Оренбурга укырга китәргә әзерләнеп йөргәндә булган иде. Мөбахис мәзиннең кара сарыгы югалгач, нәкъ шул көнне, гөнаһ шомлыгына, Хәмәтдиннең юньсез борынына ит исе килеп бәрелә. Әһә, "ат карагы" күршесе Хөрти генә чәлдергән Мөбахис мәзин сарыгын. Рәхәтләнә, дуңгыз, авызын чәпелдәтеп сарык ите ашап утыра... Оятсыз! Ә Хәмәтдин шул ит шулпасыннан чыккан тәмле ис белән тукланып тилереп йөрсен, имеш. Гаделлекме бу? Йөгерә Хәмәтдин авыл старостасы Тәхлис янына.

Тик ихатада Хөртине гаепләрлек әйбер-шаһит табылмый. Бик эзли торгач читән буенда иске бер сарык кабыргасы табып алалар. Староста ул "һайт" дигәндә "тайт" итеп торучы унлап кара надан мужикны алып килә дә Хөртинең измәсен издерә. Ләкин "сарык урлавын" әйтми Хөрти. Шуннан хәле тәмам беткәнче тагын изәләр бу мескенне. Анда да әйтмәгәч, ат койрыгына тагып, урам буйлап йөртәләр-йөртәләр дә Нәҗметдин байның таш келәтенә китереп ябалар. Шул вакытта нинди зур йөрәклелек, кешелеклелек күрсәтә Нәҗметдин бай малае Илһаметдин. Әтисе яшереп куйган ачкычны табып, алар, — Илһаметдин, Галимҗан, Апуш, — җиде төн уртасында келәтне ачып керәләр. Тик Хөрти качарга ризалашмый. Качса, хатынына, балаларына, хәтта коткаручыларга да авырлык киләчәк. Шулай итеп, бөтен нахак бәлане үз өстенә алып, күрәләтә үлемгә бара. Малайлар Хөртинең сарык урлавына аслан ышанмый. Гәрчә тәүлекләр буе эзләп тапмасалар да, яңадан бөтен чокыр-чакырны, урман буйларын кыдырып йөриләр. Тәки табалар сарыкны! Бу вакытта Хөртигә урам хөкеме — халык хөкеме ясала, тереләй кабергә күмәргә, дигән мөһер сугалар Хөртинең маңгаена. Нәкъ шул чакта алып килеп җиткерәләр малайлар кара сарыкны хөкем мәйданына. Староста Тәхлис тә, Нәҗметдин бай да авыр хәлдә кала. Янә шул ачыклана: Хөрти Әпсәләм авылында берәүгә ишек ясаган икән — итне шуңа биргәннәр. Моны икенче төр шаһитлар — Хөрти яклылар исбат итә. Хәзер Хөрти староста Тәхлисне дә, Мөбахис мәзинне дә судка бирә ала. Тик Хөрти аннан баш тарта. Карга күзен карга чукымый дигән "хакыйкатькә" таяна. Күп чәбәләнсәң, үзеңнең хәбесханәгә яки төрмәгә килеп эләгүең бар.

Бу юлы да гайбәт башы Хәмәтдиндә. Ул абыстайларга Мәдинәнең, соңрак Галимҗанның кереп киткәнлеген күреп кала. Әһә, менә кайда икән зур гөнаһ кылу урыны — кендекәй Хәмдияләрдә. Аның шулай туры килүен әйт син: ни күзе белән күрсен — урамда Илһаметдин йөри.

Сөйләп биргәч, Илһаметдинның күзләре чәркәдәй булды. Яңак мускуллары биешеп алды. Бизгәк тоткан кешедәй калтыранырга кереште. Аннан йодрыгы төйнәлде. Шул төйнәлгән йодрыгы белән кереп китте кыласы гөнаһларына.

Актүтидән өстерәп алып чыгып киткәч, урамда хатынына тимәде Илһаметдин. Ә инде кайтып кергәч, шундук изәргә тотынды. Әнисе өйдә юк иде. Әтисе эчке бүлмәдә улының: “Уйнашчы, фәхишә, Гыйрфан мулла малае Галимҗан белән зина кылырга тотындыңмы, тирес бит, себерке!” — кебек әллә нинди җирәнгеч сүзләр әйтә-әйтә кыйнаганын ишетеп торды. Башта ул улын бу ахмаклыктан тыярга уйлаган иде. Ә инде “уйнашчы”, “фәхишә”, себерке”, кебек сүзләрне ишеткәч, килененең гөнаһ өстендә тотылуын фараз итте. Өйдә, акылга утыртсын, тәүбә иттерсен, хатын-кызның нәфесе белә́к буе була, чәч төбенә шайтан коткысы оялаучан, каккалап тормасын, азып-тузып китүе көн кебек ачык, дип уйлап утырды Нәҗметдин бай. Ул үзе дә салмыш иде. Шулай да бераздан акылга килде. Үтереп ташламасын тагы, бәладән баш-аяк дип, алгы бүлмәгә чыкса, кан эчендә яткан Мәдинәне күрде.

— Син артыгын кыланма әле, кемнән ишеттең, нахакка котырынмыйсыңмы? — дип улын туктатты.

— Кеше сүзенә ышанырга ахмакмыни мин, әткәй?! Үз күзем белән күрдем. Гөнаһ өстендә тоттым. Бар бит әле теге Хәмдия дигән карт бия, кендек әбисе, шунда икесе генә аулакта... өсләренә барып кердем. Үбешеп торалары.

— Ничек белдең анда икәнлекләрен?

— Хәмәтдин абзый әйтте.

— Димәк, шаһитларың бар?

— Өчәү булды инде. Хәмәтдин абзыйдан башка да. Судка бирәм мин ул Гыйрфан карт малае Галимҗанны. Мәдрәсәдән кудыртам. Һм, сарык тиресе ябынган бүре!

Бераздан әнисе Гыйззелбанат биләмнән кайтып керде. Урам хәбәрчеләре килененең кайда, ничек, кем белән “зина кылуын” җиткергәннәр иде инде.

Мәдинә үлмәгән иде әле. Авызыннан кан төкереп:

— Мин... Галимҗан абый белән... — дип әйтергә көч тапты. Шуннан “бер гөнаһ та кылмадым” дип өстәмәкче иде, монысына көче җитмәде.

“Галимҗан” дигән сүз ишетелгәч, Илһаметдиннең җене тагын да ныграк котырды. Ул, ерткычланып китеп, Мәдинәне янә таптап ташламакчы булды. Ләкин бу юлы аңа әтисе дә, әнисе дә ирек бирмәде — кеше болай да үлем чигенә җиткән бит инде.

Мәдинәне, бик авырлык белән күтәреп алып, эчке бүлмәдәге караватка җайлап салдылар...

* * *

Галимҗан килеп кергәндә, Нәҗметдин бай, Гыйззелбанат байбичә, уллары Илһаметдин алгы бүлмәдә ни хакындадыр гәпләшәләр иде. Алар Галимҗан күренүгә үк күзләрен кан баскан Илһаметдинне тынычландырырга ашыктылар. Шәригать шулай куша: мәет өстендә тавыш чыгарырга ярамый гына түгел, кычкырып еларга да рөхсәт ителми мөселман кешегә. Галимҗан ашыкмый гына, җайлап-җайлап, тегеләрнең миенә тәмам сеңдерерлек итеп, бар булганын сөйләп бирде. Беренче мәртәбә Актүтиләрдә уникe яшьлек чагында очрашулары, мәрхүм әтисе Хөрмәтулла абзыйның гармун уйнавы, мәрхүмә Мәликә түтинең, Мәдинәнең җырлавы, шундагы моңның самими-садә булуы, йөрәкләрне тетрәндерүе турында әйтте. Әтиәнисенең фаҗигале үлеменнән соң, Мәдинәнең җенеләеп китүен дә телгә алды. Кондызлы күл буенда булган хәлне Мөбахис мәзин малае Бәкерҗан, гайбәтче алама хатын-кызларга охшап, мең өлеш арттырып, күпертеп сөйләп йөргән... Галимҗанның монда бер гаебе дә юк. Ә инде өенә хәтле озатып куйган икән — ни гөнаһы бар аның? Шунда акылга җенеләйгән кызның ялгызын калдырып китсә... әнә кайда булыр иде намуссызлык... Шуларны сөйләп бирде Галимҗан. Акрын, ашыкмый, ярсымый сөйләде. Янә шуны әйтте ул. Әгәр Мәдинәгә өйләнсә, аны

барыбер бәхетле итә алмас иде. Чөнки Галимҗанның тормыш учагы әле сүнеп пыскыган көл-күмерне хәтерләтә. Кайчан дөрләр ул? Билгесез. Ана әле укырга, укырга кирәк. Казанга барып, дарелфөнүнгә керергә. Өйләнү мәсьәләсе әле аның хәбәрендә дә юк. Мәдинәне соңгы юлга пычрак гайбәткә төреп озатмыйк. Ни генә күрмәде ул бала, ни генә күрмәде аның әтисе, әнисе. Күпме пычрак-чачрак чәчтеләр алар өстенә. Барысы да ялган булып чыкты бит.

Аңлады булса кирәк, Галимҗанның ихлас сүзләрен Нәҗметдин бай тәсдыйклап куйды:

— Дөрес әйтәсең, Галимҗан улым, зур гөнаһ эшләдек, моның соңы ни белән бетәр, Ходаем! Яхшы кеше авызыннан яман сүз чыкмый бит ул, һәйбәт әйттең, күзебезне ачтың, ләкин соң инде, Мәдинә моны ишетми. — Ул Илһаметдингә ачулы карап алды. Их, син, хөрәсән капчыгы, камыр батыр, хатын үтерүче ерткыч, дигәнне аңлата иде аның карашы.

Шуннан иртәгә сәфәр чыгачагын әйтеп, Галимҗан Мәдинә белән хушлашырга рөхсәт сорады. Аның теләгенә каршы килмәделәр.

— Хуш, Мәдинә, тыныч йокла, синең халык алдында да, ирең алдында да бер гөнаһың да юк! Гөнаһсыз кешеләр оҗмах кошы була, оҗмахта яшәсен җаның, — диде дә Галимҗан янә алгы бүлмәгә чыкты.

Мәсьәләнең асылын ныклап аңлады булса кирәк Илһаметдин. Галимҗанны кочаклап, кычкырып үкерергә-еларга кереште:

— Тукма син, Галимҗан, мин юньсезне, кеше үтерүчене! Бар, әйт старостага, кулга алсыннар, утыртсыннар мине! Хәзер авылда кеше күзенә күренеп йөрер чамам калмады! Нәләт миңа, нәләт, ләгънәт!.. Oh!..

Галимҗан кайтып китте. Ә көн һаман матур иде. Бөтен җирдә язгы манзара тантана итә. Тик кешеләр күңелендә боз, боз, боз! Былтыр бер яшь килен, муенына таш бәйләп, Авыргазы елгасына ташланган иде. Каенанасының җәберләвенә чыдый алмаган. Соң, вакытында ул карт каенана үзе дә килен булгандыр лабаса. Нигә онытты икән шуны?

Күпме ислах-яңалык күтәрде егерменче йөз башы: "Җир мәсьәләсе", "Хатын-кыз мәсьәләсе", "Азатлык мәсьәләсе"... Ә бит кайнар йөрәкле, көчле рухлы, көрәшчән табигатьле татар хатын-кызлары болгар чорында ук дошман ябырылса, ирләре белән бер сафта көрәшкә күтәрелгән. Ире һәлак булса, аны хатыны алыштырган... Их, язарга иде әнә шулар хакында! Гел болай булмаячак бит бу. Бирелер азатлык татар хатын-кызларына бервакыт. Бирерләр. Тик хәзергесе бик фаҗигале. Мәдинә-Акчәчкә кебек меңнәр әрәм була. Меңнәр. Миллионнар.

Шундый уйлар давылында кайтып керде Галимҗан. Ул Нәҗметдин байларда булган хәлнең барын да түкми-чәчми сөйләп бирде. Ләкин ата кешенең күңел бозы моңа аз гына да эремәде. Чөнки өй эчендәге Мәдинәгә бәйләнешле булган ут өстенә икенче бер ут килеп өстәлгән иде. Мәсьәләнең очы һаман шул капчыкта саклап булмаган "без очы"на килеп бәйләнә. Төртеп чыккан капчыкны без очы. Мөбахис мәзин малае Бәкерҗан Галимҗан белән бергә "Галия"дә укыган бер шәкерт-мәхдүмне күргән. "Галимҗан, "Коръән Алладанмы, түгелме?" дигән бер хезмәт язган икән. Моның өчен аны мәдрәсәдән сөргәннәр". Бу чәнечкеле хәбәрне Мөбахис мәзин малае Бәкерҗан, авыз тутырып, бөтен авылга чәчеп йөргән. Ул хәбәр, мең төрле арттыру-күпертүләр белән сырланып, Гыйрфан мулла өенең дә тәрәзәсен ватып керә. Имештер, Галимҗан Алланың юклыгы, Коръәннең Аллада түгел икәне турында язган, тегесе-монысы, фәлән-фәсмәтән.

Авылда Гайшәбикә исемле янә бер кендек әбисе бар. Ул Галимҗаннардан әллә ни ерак тормый. Шулай булуга карамастан, Гыйрфан мулла кендек әбисен аннан ике мәртәбә ераклыкта торган җирдән китертә. Хәмдия абыстайны чакыра. Чөнки яратмыйлар Гайшәбикәне. Гайбәтче, усал, комсыз булганы өчен. Шуңа күрә ул Гыйрфан муллаларга сырт йөнын кабартып йөри. Билгеле, моны ул тыштан сиздерми. Ә инде, җае туры килсә, итәккә ут төртергә генә тора. Бу очракта да юха елан була

белә. Әле дә, Галимҗан юктан файдаланып кереп, бик авыр кайгы кичергән атлы булып, "Галия" мәдрәсәсеннән куылу хәбәрен сөйләп чыгып китте. Шулай итеп, өй эченә яңа кайгы аждаһадай килеп керде.

Гыйрфан мулла тузынмаска, сабыр итәргә, Галимҗанга котырынып ташланмаска тырышкан иде. Чөнки бакырынуның да тишекле бер тиен чаклы да файдасы юк. Акыру ягымлы булса, ишәктән кадерле хайван булмас иде, дигән әнә бер йомры баш. Троицкида хәлфә булып торганда Хәсәнәнең әтисе Заһретдин мөдәррис әйткән иде бервакыт: "Комы юк — су булмас, Ходае юк — ил булмас, якасы юк — тун булмас, кануны юк — йорт булмас", — дигән иде. Кануны бетте шикелле бу йортның? Ни бу? Картаю кәсафәтеме югыйсә? Аның сүзләрен бакыр бер тиен урынына да күрмиләр. Күпме тырышты "Галия"не тәмамлатыр өчен. Ярый, Оренбурдагы Вәли мулланың черегән мәдрәсәсеннән куылсын да, ди. Бу бит — ягъни дә мәсәлән, "Галия" мәдрәсәсе бөтен тирә-якта дан тота. Татар, башкорт, казакъ, кыргыз, төрекмән, үзбәк... — кем балалары гына укымый анда?

— Димәк, синенчә, Алла юк булып чыга? Коръән Алладан түгел инде, ә? — дип каршылады Галимҗанны әтисе.

Галимҗан шундук "Галия"дәге кара хәбәрнең Солтанморатка да аякланып килеп җиткүен аңлап алды. Моны төшендереп торуның хаҗәте юклыгын да белә ул. Чөнки, ни генә әйтмә, аның сүзенә хәзер барыбер ышанмаячаклар. Әле генә Мәдинә язмышы тетрәндерсә, инде килеп, Коръән, Алла мәсьәләсе энәсен тырпайтып килеп чыкты. Галимҗан нык арыган, йончыган иде. Ул фәкать шуны гына әйтә алды:

— Әткәй! Бер Алланың барлыгына ышанам мин. Син үзең Троицк мәдрәсәсендә дин тарихын укыткансың. Кайдан килеп чыккан соң ул Коръән?

— Коръән сүрәләрен Аллаһы Тәгалә Мөхәммәт пәйгамбәрнең колагына әйтеп торган.

— Мөхәммәт пәйгамбәр язып барганмы?

— Язмаса, Коръән булыр идемени?

— Мөхәммәд пәйгамбәр яза белмәгән бит ул, әткәй!

— Җитте! Оятсыз! Хәзер пәйгамбәрләрдән дә көлә башладыңмы?

— Әткәй!..

— Әйтмә шул сүзеңне миңа моннан ары. Мин сиңа ата түгел. Мин синнән баш тартам.

Ата кеше сыны белән катты. Галимҗанның да хәле шуннан ким түгел. Хәсәнә абыстай телсез. Шакирҗан белән Габделхәким дә ни диярге белмичә аптырап калдылар.

Галимҗанга әтисен, әнисен тынычландырырлык сүзләр әйтергә кирәк иде. Әмма хакыйкать камытыннан барыбер ычкынмаячак ул. Чөнки күз буярга тырышу, ялганлык чанасына утыру, төлкедәй койрык болгап маташу корымы аның намусына аз гына да буялмаган әле.

— Миннән баш тартып дөрес эшлисең, әткәй! — диде ул моңсу һәм йомшак итеп, шул ук вакытта газамәтле-тыныч тавыш белән. — Чөнки бүгенге хәят сулышы, ислах-яңалык өчен көрәш, алга куйган максат табигыйлеге таләп итә моны. Инде хәзер сезнең белән бер табактан аш ашый алмаячагымны үзем дә аңлыйм. Күпме генә бәддога кылсагыз да, мин сездән беркайчан да баш тартмаячакмын. Алла, Ата, Ана, туганнарым — минем өчен иң газиз төшенчәләр. Шулай да сез, әткәй, әнкәй, улыгызның холык-фигылен һаман аңлап бетермисез. Мин куыла торган кемсә түгелмен. Оренбурдагы Вәли мулланың кадим мәдрәсәсеннән үзем киткәнлекне беләсез. "Галия"дән дә кумадылар. Әгәр Зыя әфәнде Камали моны эшләсә, башка шәкертләр дә миңа ияречәкләр иде. Әйе, "Коръән Алладанмы, түгелме?" дигән хезмәтне яздым. Ышаныгыз, әткәй, әнкәй, аның бер генә урынында да Аллага тел тидерелми. Әмма мәдрәсә хакимияте, аңа иганә бирүче тышкы дөнья әһелләре мине аңламады. Хәзер инде мин "Галия"гә кире әйләнеп кайтмаячакмын. Казакълар арасында мөгаллимлек

кылып, акча туплап, шуннан Казанга китәчәкмен. Университетта укырга.

Шулай да бу сүзләр эретмәде ата кешенең күңел бозын. Ул һаман үзенекен туглады:

— Ә менә ни өчен Коръәннең Алладанмы, түгелме икәнлеген син тикшерергә, син язарга тиеш?

— Чөнки аны миннән гайре кеше яза алмый.

— Ә нигә кирәк ул сиңа?

— Соң, әткәй, янә кабатлап әйтәм: син үзең дә Троицк мәдрәсәсендә дин тарихы укыткансың бит.

— Укыттым. Әмма ләкин Аллага тел тидермәдем.

— Соң, әткәй, мин дә Аллага тел тидермәдем бит!

— Эндәшмә миңа бүтән. Иблис вәсвәсәсенә бирелгәнсең. Менә шул гына Тьфу!..

Бу сөйләшүнең барыбер тозсыз булачагын тәмам аңлагач, Галимҗан, кырт борылып, икенче катка менеп китте дә киемнәрен салып ыргытып, уң як дивар янындагы үз караватына барып ауды.

## XI

Гыйрфан мулла белән Хәсәнә абыстай аскы катта йоклыйлар. Гыйрфан мулла үзе йоклаган атлы булып ята. Эчендәге ут давылын остабикәсенә сиздермәскә тырыша. Ара-тирә гырлап та куйган була. Остабикәсенең дә йөрәге үзенекеннән ким янмаганлыкны тоя ул. Аның йоклап китүен тели. Ата кеше әле үзен бала тәрбияли алмауда гаепли. "Баланы сәкедә аркылы ятканда тыңлата алмасаң, буй яткач, тыңлатырмын димә", — дигәнне хәтеренә төшерде. Моны аның әтисе — Нурмөхәммәт имам кабатларга ярата иде. Аңа әйтсә дә ярый. Чөнки унике бала тәрбияләп үстерде: дүрт кыз, сигез ир бала. Әтисе нәсел-нәсәп чылбырын да еш кына санап күрсәтә иде: Локман улы — Ибраһим, Ибраһим улы — Хисаметдин, Хиса-метдин улы — Әхмәт, Әхмәт улы — Нурмөхәмәт, Нурмөхәмәт улы — Гыйрфан, Гыйрфан улы — Галимҗан. Димәк ки, Галимҗан җиденче буын. Ә буыннар үзәгендә алтын көүсә. Көүсә ботаклары дөнья шаулаткан. Берсе — мулла, икенчесе — хәзрәт, өченчесе — имам, дүртенчесе — ахун... Менә шушы алтын көүсәне янә ныгытып җибәрү өмете төшкән иде Галимҗаны җилкәсенә. Ә ул... инде ике мәдрәсәдән куылды. Хәзер Казанга дарелфөнүндә укырга бара, имеш. Һм, телеңне аркылы тешләп йөрмәсәң, аннан да сөрмәсләр димени? Башлары буш тубал түгелдер бит инде аңдагыларның?

* * *

Өске катта — ике карават. Аның берсендә — Шакирҗан, икенчесендә Габделхәким йоклый. Галимҗан кайткач, сул яктагысында — киңрәгендә — Шакирҗан белән Габделхәким бергә ята башлады. Бүген дә шулай җайлаштылар. Башта Шакирҗанның азрак гәпләшеп алуда иде исәбе. Тик, киселгән икмәкне ябыштырып булмаган кебек, сүзләр сүзгә әллә ни берекмәде. Чөнки сөйләнәсе сөйләнелгән, чәйнисе сүзләр чәйнәлгән, аңлашасы аңлашылган инде. Шакирҗанның:

— Димәк, Казан каласына каерасың? — дигән соравына да:

— Әйе, — дип кенә җавап бирде Галимҗан.

Габделхәкимнең:

— Их, зурдыр ул Казан, күрәсе иде, — дип уфтануына да:

— Күрерсең әле, башың яшь, — дип кенә куйды.

Габделхәким унөч яшьтә инде хәзер. Аның үз мәсләге, үз буразнасы бар. Кая барып бәрелергә белмәгән кигәвен урынына пырылдап йөрми. Сулаган йонга ябышкан тигәнәкне суырып алу никадәр авыр булса, кендеге җиргә берекккән Габделхәкимне дә туган туфрагыннан куптару җиңел

түгел. Янә шунысы бар: "Һайт" дигәнгә "тайт" итеп тора, кушкан эшкә йөрәксенеп йөгерә. Һәр нәрсәне жиренә житкереп башкарырга ярата. Әйткән иде әлеге сыерчыкка басудан корт ташу мәсьәләсен, әллә нинди калай савыт ясап, шуны чүмәкәй тутырып алып кайта да капка төбәсенә куя.

— Әнә, шәкерт абый (ул Галимжанны шулай дип атый), таләбең үтәлде, — дип шатландырырга да онытмый.

Энесенең шундый чос, үткер, житез булуы Галимжанны нык куандыра. Сыерчык турында ул бүген дә әйтми калмады.

— Габделхәким энем, сыерчыкны тукландыру синең жаваплылыкта кала.

Габделхәкимнең, Галимжан абыйсы кебек, шаяртыбрак сөйләшә торган гадәте дә бар.

— Ярар, шәкерт абзыкай, таләпнамәнне алдык, хәтер сандыгына салдык, — дип куйды.

Озакламый алар "әвен базары"на китте, Галимжан гына йоклый алмады. Уйлар, гәрәбә шикелле бер-бер артлы тезелеп, башка һаман килә тора, килә тора, килә тора. Менә Мәдинә-Акчәчкәнең унике яшьлек чагы. Анын жыры. Моңы. Әтисе болай дип жырлаган иде:

Зәңгәр чишмәкәйнең суын эчтем, Суын эчтем йөрәк янганга; Кайгырмагыз, дуслар, кайгырмагыз Гомеркәйләр бик аз калганга.

Димәк, фажигале үлемен анын күңеле шул чакта ук сизенгән. Мәдинә-Акчәчкә үлеме. Илһаметдиннын ерткычлыгы. Хәмәтдин карт, нахак бәла тагып, Хөрмәтулла абзыйнын башына житте. Кызы Мәдинәнең үтерелүенә дә ул сәбәпче. Әгәр Илһаметдингә Актүтиләрдә аларнын көтелмәгән очрашуын барып әйтмәсә, Мәдинә бүген дөнья балкытып, көлә-көлә эшләп йөрер иде әле. Әләкләгән өчен, билгеле, Хәмәтдин картка азрак ризыкфәләң, йә хәмер тамызалар. Димәк, тамак өчен кеше башын ашый. Ничек курыкмый гөнаһтан? Нишләп намус корты кимерми анын йөрәген? "Галия"дәге Хисмәт шәкерт анын Коръән турында язганын урламаса, шуны мәдрәсәне тотучы тышкы хәкимияткә илтеп бирмәсә, бу күңелсез хәлләр килеп чыкмас иде. Ә бит Хисмәт шәкерт күп вакыт намазга тәһарәтсез бара. Яшереп тәмәке тартканын, хәмер эчкәнен күргәннәр. Гыйш-гәшрәткә хирыс бәндә икәнен дә барлык шәкерт белә. Адәм баласы бер-берсен ашый. Нигә болай бу? Зыя әфәнде Камали бервакыт, әхлак-тәрбия турында сүз чыккач, Акмулланын бер шигырен әйткән иде:

Иң әүвәл пакьләү кирәк эчнең керен, Эчтә тулып ятмасын сасык эрен. Аһ, дәрига! Эч тазарсын, эч тазарсын, — Булмаса, файда бирмәс коры белем!..

Димәк, иман белән гыйлем берлеге кирәк. Ә ул күпләрдә юк. Бик күпләрдә. Яктылык югарыдан, бөек аң — Күк тәхетеннән төшә икән, нигә ул иң әүвәл ил башында торган зур түрәләрнең миендәге кара уйларын агартмый. Патшасы нинди — иле шундый, дигән әйтем бар. Акыллы хөкемдарда халык тыныч яшәр, дип тә әйтәләр. Кеше — закон өчен түгел, закон — кеше өчен, дигәне бигрәк урынлы. Нинди кешеләр өчен закон? Нигә кеше башы ашаучы староста Тәхлис, Мөбахис мәзин, Нәжметдин бай, аларның уллары Бәкержан, Илһаметдин кебекләргә закон юк? Ә?! Дөнья мондый ялганга корылса, халык нишләр? Бервакыт бөтен ил ялган ялгашына утырып бетмәсме? Аллага, дингә ышану гына житми бит. Шәригать кушканны үтәү зарур. Коръән турында язганда әнә шуларны аңлатмакчы иде Галимжан. Аңламадылар аны. Акны корымга буярга маташучылар күп икән.

Уйлар! Уйлар!! Уйлар!!! Беренче әтәч кычкырды. Икенче. Өченче. Ул йоклый алмады.

## XII

Чулпан танга мөкиббанә сөеп-яратып эндәште:

— И таң! Матур таң! Гүзәл таң!! Нурлы таң!!! Мин Аллаһу Тәгалә

тарафыннан сине уятырга тәгаенләп куелган Гарьше көрсидәге якты йолдызларның берсе. Моңарчы бу бинаһия киң вә зур галәм йөзендә ин бәхетле гаилә корган гөнаһсыз, саф күңелле, шәфкатьле ата-ана кеби тату, гыйффәтле мәхәббәт белән яшәдек, ә син бүген якты-нурлы сүзенә колак салмас булдың: һаман уянмыйсың, йоклыйсың да йоклыйсың — нәкъ бишектәге сабый бала сыман.

Матур таң, нурлы таң, гыйззәтле таң җавап бирде:

— Инсаният, Адәм балалары безгә карата бихисап күп җыр чыгарды. Менә шуларның берсе:

Таң — таң ата, чулпан калка, Чулпан — таңның көзгесе; Чулпан таңнарның көзгесе, Сагынуларым билгесе.

Монда бит иң әүвәл минем уянуым, аннан соң гына синең калкуың турында сүз бара. Син — минем нурларымның җемелдек энҗеләрен берәм-берәм җыеп, шуларны көзге хәленә китереп, җир йөзенә яктылык бүләк итүче илаһи сыйфатлы сын. Сагыну хисләрен бәндәләр бер-берсенә синең аша житкерә.

Чулпан-сылу Таң җавабы белән ризалашмады. Ул болай диде:

— Җир балалары бик акыллы, моңлы, уйчан; алар бит мине Таңны уятучы дип хис итә. Менә бит ничек җырлый ул тагы да:

Таң-таң ата, Чулпан калка, Чулпан таңны уята; Таң сызылып аткан чакта Җирсетә дә, елата.

Чулпан таңны уята, дигәннәр бит. Димәк, мин сине уятучы йә ата, йә ана булып чыгам. Ә син — бала хөкемендә.

— Син, Чулпан-сылу, мин-минлек чире белән авырый башлагансың. Шуңа күрә җырның үзеңне данлый торган урынын гына сайладың. Ә бит беренче юлындагысы, ягъни, "таң — таң ата, Чулпан калка" дигәне сине икенче урынга куя: башта —Таң, аннан — Чулпан.

— Ни өчен җир балалары сызылып таң атканда җирсеп елый соң ул? Нигә елатасың кешеләрне?

— Без алар күңеленә чиксез матурлык-гыйззәтлелек бирәбез. Матурлыкның йомшата торган гадәте дә бар.

— "Без " дидең. Кемнәр кирә моңа тагы да?

— Син дә, мин дә.

— Димәк, икебез бер үк вакытта барлыкка киләбез?

— Инде, иншаллаһ, төшенә башладың шикелле.

— Без икебез зур кодрәт иясе булып чыгабыз.

— Син матурлыкны һаман үзеңә генә кайтарып калдырмакчысың. Без бит вакыт мизгелләрен белдерүче генә. Кояш бабайны кая куясың? Аның бер тамчы алсу нуры да безне күздән гаип итә ала бит.

— Бу киң галәмдә Кояш үзе дә бер йолдыз гына. Кояштан әллә күпмегә зур йолдызлар бар. Бик еракта булганга гына алар бәләкәй күренә.

— Анысы шулай. Ләкин без бит әле чиксез галәм киңлекләре белән түгел, Җир үлчәме белән фикер йөртәбез. Тик безгә ачуланышырга, бер-беребезне түбәнсетергә, һич кирәкмәгәнгә тәкәбберләнергә ярамый. Чөнки безнең уңай сыйфатларыбыз да, кире якларыбыз да Җир балаларына тәэсир итеп тора. Күрмисеңмени аларның ызгышканын? Үтереш. Кан коеш. Гөнаһ. Вәхшилек. Наданлык. Тагы да әллә нәрсәләр... Аларда әле — яхшылык белән яманлык көрәше. Хәзергә әле яхшылык өстенлек ала. Яманлык җинсә, Адәм балалары бөтенләй бетүгә таба йөз тотачак. Әнә бит аларда нинди куркыныч яклар бар.

— Ә хәзер нигә халыкны һаман уятмавың турында әйт.

— Аз гына көт. Аннан үзең үк аңларсың...

Әллә төш булды бу? Әллә өн? Әллә төш белән өн арасында буталган уйлар дулкыны агышы? Галимҗан аны аңлап бетерә алмады. Хыялга сабышамы әллә ул? Нигә бөтен галәмне башына сыйдырырга маташа? Җен-пәри котыртуымы бу?

Тукта! Ни-нәрсә дәберди? Әйтерсең, мең-миллион дию пәрие

чыелдаша. Күктә, гүя, өй зурлыгы ташлар бер-берсенә бәрелешеп шартлый. Нинди дәҗҗал анда? Бөтен дөньяны авыр караңгылык басты. Аһ, имәнеч көчле шартлау. Караңгылыкны яктылык еланнары кискәләргә тотынды. Бер ут шары нәкъ тәрәзә төбенә килеп шартлады — яктылык өй эченә бөркелде. Тавышы колакларны тондырырлык булды. Хәзер инде Чулпанның якты таңны уята алмавын аңлавы кыен түгел. Аларның икесе дә куе-кара болыт пәрдәсе артында хәзер. Ыжгыра-ыжгыра яшенле яңгыр килә. Нәрсә шартлады тәрәзә төбендә? Яшен шайтанны сукты шикелле.

Галимҗан, шайтан тырнагына эләкмим дигәндәй, ялт сикереп торды да киенеп тә алды. Биштәрләп аркага аса торган юл капчыгына берничә китабын салгач, беренче катка төште ул. Әтисе таһарәт алырга чыгып киткән икән. Әнисе иртәнге намазга әзерләнә иде. Галимҗанны күргәч, аптырап калды.

— Әнкәй, мин китәм.
— Кая китәсең?
— Сәфәремне беләсең ич инде, әнкәй!
— Соң бит әле... һич югында берәр атна торыр идең?..
— Юл кешесенең юлда булуы яхшы.
— Нигә аны кичтән әйтмәдең?
— Сине борчыйсым килмәде.
— Юлга дүшәмбе көн чыгу хәерле.
— Бөтенесе дә Алла көне, әнкәй!
— Әтиең ни әйтер?
— Ул фатихасын бирмәячәк.
— Болай булгач, мин дә бирмим.
— Алайса, фатиханы Ходайдан сорармын.
— Таба ашы да пешермәдем бит әле.
— Ярты икмәгеңне кызганмассың шәт, әнкәй!

Аш бүлмәсенә кереп китте дә Галимҗан, аннан-моннан битен юган-дай итеп, сөртенеп алгач, өстәлдә торган бер бодай икмәген пычак белән урталай кисеп, шуның яртысын юл биштәренә салды.

— Балам! Галимҗаным! Акыллым! Күрмисеңмени? Ишетмисеңмени? Күк күкрәп, яшенле яңгыр килә бит!

Галимҗан шаяртуга күчте:

— Яңгыр булмаячак, әнкәй! Ике аяклы шайтаннар кыбайде дөньяда. Бүгенге яшен шул шайтаннарны куркытып йөри. Хәзер... карап керим әле менә.

Тышка чыкты да әйләнеп тә керде Галимҗан:

— Фикерем дөрес, әнкәй: яңгыр булмаячак — болытлар башка якка китте. Шайтаннар артыннан.
— И... һаман шаяртып маташа бит әле.
— Юлга елап чыкмыйлар, әнкәй!
— Күрәселәрең җилкетәме әллә сине?
— Дәрвиш матур тормыш өмет итми, әнкәй!
— Балам! Иртәгә китәрсең, булмаса, ә?!

Галимҗан бер йомры салкын су эчте дә, әнисенең ике бит очыннан үбеп, юл капчыгын аркасына аскан килеш, чыгып та йөгерде. Әтисе аны күреп калды. Килеп кергәч, аның беренче соравы шул булды:

— Кая китте теге кире беткән нәмәкәй шул хәерче капчыгын күтәреп?
— Китте. Улыбыз китте!
— Кая китте? — дип сорыйм лабаса.
— Дәрвиш кая китмәс. Казакълар арасына.
— Нигә кичтән әйтмәгән?
— Аның җиле үзе белән.
— Җаяүмени? Кеше ни әйтер?
— Ат җигеп бирерләр. Озатыр иде Габделхәким олы юлга хәтле.
— Әле дә соң түгел.

Ата кеше өске каттан күзләрен уа-уа төшкән Шакирҗан белән Габделхәкимгә җикеренде:

— Бер аягыгызны атлаганчы, икенчесен эт ашый, пошмас җаннар, йокы чүлмәкләре! Галимҗан җәяү китеп барган бит, җигегез җирән кашканы, җәһәт кыланыгыз, куып җитеп, кире алып кайтыгыз, дүшәмбе көн озатырбыз. "Әткәй кушты", дисәгез, тынламый калмас.

Тегеләр "ә" дигәнче җирән кашканы ишегалдындагы тарантаска җигеп алгач, Габделхәким:

— Мин үзем генә, олы абзыкай, атка авыр булыр, бар, кер, — дип, дилбегәне үз кулына алды да, тарантаска менеп тә утырды.

Шакирҗан, зур капканы ачып, аны озатып калды.

* * *

Ата-ана, баласы күпме генә рәнҗетмәсен, ул аңа барыбер бәддога кылмый, ә бәлки бәхет тели. Гыйрфан мулла, остабикәсе алдында ачу тәкәбберлеге күрсәтсә дә, намаздан соң дога кылганда, Галимҗанга барыбер хәерле сәфәр теләде. Хәсәнә абыстайны инде әйтәсе дә юк. "И бер Аллам! Галимҗан бәгырькәемә юл газаплары күрсәтмә, аны үз канат астыңа ал, юлларына ак җәймә җәй, яман күзләрдән, бәла-казалардан үзең сакла", — кебек сүзләрне кат-кат, кат-кат әйтте.

Әлеге күк күкрәп, яшен яшьнәп, кара болытлар белән ажгырып килгән яңгыр каядыр китеп барган иде. Тик ул вакытлы гына булган икән. Таралган болытлар, яңадан оешу өчен бер-берсенә күз кысышып, янә куерып алдылар да, зур кайгыга дучар булган кешедәй үксеп-үксеп, яшь түгәргә керештеләр. Ата кеше иң элек Шакирҗанга бәрелде:

— Ник бармадың син? Нигә энеңне берүзен генә җибәрдең? Әллә Габделхәкимне тыңлар дип беләсеңме шуны?

— Галимҗан мин әйткәнгә кире кайтыр дисеңме?

— Син бит аңа ага кеше.

— Аның өчен ата кеше сүзе дә сукыр бер тиен.

— Җитәр!

Аннан остабикәсенә бәйләнде ул:

— Нигә җибәрдең? Яңгыр килгәнне күргәнсеңдер бит?

— Минем көч җитәрлектер шул аңа.

— Нигә йөгереп килеп әйтмәдең миңа?

— Намаз вакытында тавыш чыгудан курыктым.

— Их, сез!..

Тышта яңгыр чиләкләп коя. Хәсәнә абыстай өчен яңгыр бөртекләре калай түбәдә, җир өстендә биешми, ә бәлки аның йөрәгенә утлы энә булып кадала. Галимҗанны бәләкәй чакта Нәгыймә апасына, Шакирҗан абыйсына ияртеп җиләккә җибәргән иде ул. Иртән көн гәрчә аяз, чуак булса да, бераздан чатнатып-дөбердәтеп күк күкрәде, уйнаклап-чәчрәнләп яшен яшьнәде, коеп-ишеп яңгыр яварга тотынды. Болар лычма су була. Шакирҗан белән Нәгыймәнең сәламәтлеге хәзергә Ходайга шөкер. Андыймондый җил-давылга, гарасатка, зилзиләгә бирешә торган түгел. Ә Галимҗан, ни гаҗәп, бәләкәйдән үк чирләшкә булды. Бала-чага аны, хәтта, "чирле чәүкә" дип йөртә иде. Менә алар тагын да коймa яңгырга эләкте. Аһ, Ходайның шомлыгы, боз яварга керешә түгелме? Калай түбәгә, гүя, чүкеч белән сугып торалар. Ярый ла әйләнеп кайтсалар. Габделхәким нык бәдәнле бала. Ул бирешмәс. Галимҗан тагын да аяктан егылачак. И раббым! Бала кайгысы ачы да, авыр да, коточкыч та икән. Әгәр Галимҗан әйләнеп кайтмаса, һаман шулай киреләнсә, бөтенләй бетәчәк бит бу бала, бетәчәк. Уф, Алла!

— Гыйрфан! Әллә ат менеп үзең чабасыңмы? Әллә артларыннан куып җитәсеңме? Бу явымда, бу пычракта, бу шомлы көндә әллә кая китә алмаганнардыр әле. Син бит ат өстендә оста җилдерәсең.

Гыйрфан мулла уйланып калды. Аңлый ул остабикәсенең кичерешен.

Тирән аңлый. Йөрәге, күңеле белән. Галимҗан язмышы аны дәхи дә изәчәк, саулыгын мең кәррә кимерәчәк. Әйе, ул дөрес әйтә: барырга кирәк — юлда ул-бу булса, гомерлек кайгы бит.

Гыйрфан мулла өстенә чапанын киеп алды да тышка чыкты. Мәчеткә, ашка барганда кия торган бу гөнаһсыз чапан, әйтерсең, аны юлда бәла-казадан саклаячак иде. Ә яңгыр һаман шулай чиләкләп коя да коя. Болдырга остабикәсе дә чыкты.

"Мулла, әллә азрак сабыр итәсеңме, бигрәк каты ява бит, үзеңнең харап булуың бар", — дип әйтәсе килде аның. Ләкин үзсүзле улы Галимҗан кебек, ата кешенең дә аның йомшак, ягымлы сүзләренә колак салмаячагын аңлый ул. Өчәүләп әйләнеп кайтсалар — мунча ягарлар. Коймак белән кайнар чәй дә эчкәч, үзәккә үткән бөтен салкын тир белән тышка чыгып агар, иншалла...

Гыйрфан мулла, абзардан Алмачуарны йөгәнләп алып чыкты да, атланып алып, остабикәсе ачкан капкадан үтү белән, томырылып чабып китте.

Шулай да тилелек каны кайнап торган яшь чактагы шикелле, Алмачуарга артык йөрәксенергә дә ирек бирмәде ул. Бераз җилдергәч, аңына килеп, чамасыз шашынырга кирәкмәгәнне аңлату өчен, бушаган йөгәнне ныграк тартып куйды. Юл пычрак, атың таеп китеп, әллә кая тәкмәчләп барып төшүең бар. Бәй, монысы ни тагы, Ходайның хикмәте, авылдан чыгып бераз чапкач, боз яварга тотынды. Бик эре ләбаса бу, шайтан алгыры, тавык күкәе чамалы. Ярый әле башына бүрек кигән иде. Шулай итмәсәң, башыңның тишелеп бетүе бар. Хәзер инде, мәмрәйгән мәмәй авыз урынына, йокымсырап барырга ярамый. Боз, бәлки, шушы урында гына явадыр. Аны тизрәк үтеп китәргә кирәк. Чапты ул. Нык чапты. Яшь чактагыча. Җенләнеп. Эчтән генә: "И Кадир! Афәтеңнән сакла! И бер Аллам! Бәндәләргә хафаңны салма! — кебек сүзләр әйтте. Ниһаять, боз япмасы артта калды. Тик... аның алдында икенче бер тетрәндергеч моназәрә пәйда булды. Бу коточкыч койма яңгырда тарантас җиккән нинди кемсә чаптырып килә тагы? Бәй, бу аларның җирән кашкасы лабаса.

Менә ярсыган атлар, сөзешергә торган үгезләрдәй, бер-берсенә каршы килеп тукталдылар. Тик тарантаста Габделхәким берүзе генә иде.

— Шәкерт абыең кайда? — дип кычкырды ата кеше.

— Ул, юл капчыгын алып, үзе генә китеп барды.

— Җәяүмени?

— Әйе.

— Нишләп алай?

— Мине кызганды.

— Ни өчен?..

— Бик күшектең. Салкын тияр. Чирләрсең. Бар. Борыл да чап. Әйт әнкәйгә — мунча яксын, — диде.

— Син тыңладыңмы?

— Ә нишлисең. Ул да манма су булды. Теше тешкә тими. Җылыныр өчен миңа җәяү атларга кирәк, диде дә капчыгын аркасына асып, китеп тә барды.

— Бар, югал күз алдымнан, "ә" дигәнче кайтып җит, су комагы булгансың бит, — диде дә ата кеше, Алмачуарны уң якка каерды, Габделхәким выжлап үтеп киткәч, янә алга таба томырылды. Ә яңгыр, үч иткәндәй, һаман коя да коя. Әйтерсең, күк гөмбәзе тишелде. Һәй, бала, бала! Алар өчен ата-ана кадере шушы яңгыр тамчысы бәясенә дә тормый микәнни соң?

Галимҗан әллә ни ерак китә алмаган иде. Аны күргәч, ата кеше атының йөгәнен янә тартып, акрын гына юыртуга күчте. Бераздан атлатып кына бара башлады. Галимҗанның исерек кеше кыяфәтендә кылдый-былдый атлап баруын күрү аның йөрәген парә-парә телгәләде. Нишләргә? Ни дип сүз башларга? Ничек итеп аны акыл мөгезенә китереп утыртырга? Илаһым! Кая илтеп олактырыр аны бу кырыслыгы? Нинди сазларга ки-

тереп батырыр? Кайсы гөнаһ ояларына алып барып тезләндерер?

Аның артыннан барырга ярамый хәзер. Ул, бәлки, борылып та карамаячак. Кыеклатып чабып үтәргә дә юлын бүләргә. Шулай итте дә ата кеше.

Менә алар бер-берсенә карашып калды. Ата кеше — ат өстендә. Ярсыган Алмачуарны көчкә тыеп тора. Бая Габделхәкимне "су комагы" дисә, шул ук сүзләрне Галимҗанга карата да әйтергә мөмкин. Беткән бала. Лычма су. Салкыннан аны өстендәге җиләне генә коткарып кала алмаячак. Аягына штиблет кигән булган да бит. Аның да эче тулы су икәнлек сизелеп тора. Аркасына биштәрләп аскан юл капчыгы эчендә дә җылылык бирә торган бер нәстәкәй дә юк. Галимҗан башын тотып алгач, әлеге бозның җен суккандай аны да ару гына түпәләвен аңлап алды ата кеше. Дөрес, Габделхәкимнекедәй, аның тешләре салкыннан дерелдәп тормый. Чөнки бу пычрак юлдан авыр атлау аны нык тирләткәндер. Димәк, эче дә су, тышы да су. Атлап барганда ул әле синс авыр хәлдән коткарып калырга мөмкин. Ә туктагач? Җен суккан кешедәй калтырана башлаячак! Әгәр егылып китсә? Сеңәчәк бит ул шунда үзенең "чирле чебеш" икәнлеген белмичә. Нигә Алып батырдай кыланып йөрергә инде? Нигә тәртәне зиректән каерырга?

Сүзне ата кеше башлады:

— Галимҗан улым! Әниең дә бик борчыла. Мине ул җибәрде. Беткәнсең бит. Әйдә, сикереп мен минем артка. "Ә" дигәнче кайтып җитәрбез. Әниең мунча ягар...

Галимҗан итагатьле булырга тырышты:

— Рәхмәт, әткәй, язмышым өчен борчылуыңа. Ләкин бит үзең: "Маңгаең белән боз ярып булса да алга бар", — дия идең.

— Ергансың инде. Маңгаеңны боз тишеп бетергән. Күреп торам.

— Мин — дәрвиш. Дәрвиш җылы почмак эзләми.

— Дәрвиш тә кеше.

— Әткәй! Зинһар, юлыма каршы төшмә. Мин барыбер кире борылмаячакмын.

— Ата-ана фатихасын алмасаң, бәхетсез булырсың бит, улым!

— Миңа, әткәй, сез өмет иткән бәхет кенә җитми.

— Олы бәхет кирәкме? Бөтен кеше өченме? Их, улым, улым!

Ә яңгыр һаман коя да коя. Болай карышып торуның бер фәтвасы да юклыкны икесе дә нык аңлый. Галимҗанның көчкә басып торуын күрү ата өчен бигрәк тә авыр. Менә-менә егылып китәр кебек ул. Гәрчә үзен нык итеп күрсәтергә тырышса да, җеп эзәрлек тә хәле калмаганлыкны сизү кыен түгел. Ата кеше дә шактый нык йомшарды. Каты куллылыкны онытып, ялыну-ялвару юлына басты:

— Улым! Йола вә әдәп бар! Сәфәргә болай чыкмыйлар. Халык ни әйтер? Ә?!

Галимҗан аны тынычландырырга тырышты:

— Әткәй! Сәфәр чыкканда укый торган доганы да беләм. "Бисмиллаһи вә амәнәтү билләһи вә игътасамту билләһи вә тәвәккәлтү галләһ вә лә хәүлә лә куәтә илләһил-галиил-газыйм... "Аллаһы тәгаләнең исеме белән бу сәфәрне башлыйм, ышандым Аллаһы тәгаләгә, тотындым Аллаһы тәгаләгә, тапшырдым Аллаһы тәгаләгә, аның әмереннән башка көч җитмәс һәм аннан да куәтлерәк көч булмас, барлык эшләр Аллаһы тәгаләнең ярдәме белән генә ирешер, и Аллаһы тәгалә, дөреслектә мин бары тик сиңа гына сыенам, сәфәремнең мәшәкатьләреннән, кайтуның катылыгыннан өй җәмәгатенең явыз итеп каравыннан..."

Гыйрфан мулла тәмам гаҗиз булды. Менә кемдә баш, менә кемдә зиһен, менә кемдә мәртәбәлек, дип аптырады ул. Өйдә, тыныч вакытта булса бер хәл. Шундый авыр мизгелдә чәтрәнләп тора бит.

Янә чатырдатып күк күкрәде. Алардан әллә ни ерак булмаган бер ялгыз каенны чатнатып яшен сукты. Яшен ташы боларның арасыннан ажгырып үтеп китте дә кайдадыр барып челпәрәмә килде. Ул бер шайтанны

куып йөри шикелле. Галимҗан әтисенең юл бирмәсен белгәч, читләтеп үтү җаен карады. Шулай да юлсыз җирдән мондый пычракта атлау кыен икән. Су. Баткаклык. Ләм. Аягы таеп китеп, чалкан барды да төште ул. Ата кеше атыннан сикереп төшеп, Галимҗанга торырга ярдәм итте. Ә үзе һаман бер үк сүзләрне кабатлады:

— Әйдә, балам, кайтыйк, карачы: ләмдә аунаган чучка кебек булдың бит. Алдагы авыл әле җиде-сигез чакрым чамасы. Ярый, мең бәла белән үттең дә, ди, ул араны — кешегә бу килеш керә алмыйсың бит инде.

Галимҗан уйланып торды-торды да:

— Фатиханда бул, әткәй! — дип китеп барды.

* * *

Төштән соң, табигатьне нурга күмеп, яктырып кояш чыкты. Икенде намазы җитәр алдыннан җирләделәр Мәдинәне. Аның җидесен үткәргәч, Илһаметдин кулга алынды.

## Икенче бүлек

*Юллар илтә безне усал язмышларга,*
*Алданмагыз, и бәндәләр, юкка- барга.*
*Чәчсәң, бәхет орлыклары үсми калмас,*
*Канатларың авырлыктан бер дә талмас.*

### I

Галимҗан җәй буе казакъ балаларын укытты. Хәер... укытып кына йөрмәде, ә бәлки үгез җигеп, хуҗа кушкан әллә нинди кара эшләр майтарды. Беренче шөгыль — акча өчен. Икенчесе — белем савытын тутыру максатына бәйле. Күрше авылда бер учитель бар икән. Шуннан урыс телен өйрәнмәк булды. Тик әҗере шактый кыйммәт булып чыкты. Бер дәрес өчен бер көн буе этләнергә кирәк. Үгез җигеп йә сабан сөрдерә, чирәм күтәртә, йә чүп түктерә, йә әллә ниләр ташыта. Үгезе, ой дәүмәллеге булса да, ыңгырашып кына тарта. Ишәктән дә кире үзе. Сукканга да ыжламый. Таңда башланган эш кичке эңгер-меңгер белән ялгана. Теленне аркылы тешләп, уртыңны чәйнәп түзәсең. Бу кадәресе инде — алар тарафыннан мыскыл итү. Түбәнсетү. Кешелеклелек сыйфатыннан көлү. Нишлисең — ризалашмый чараң юк. Казан университетына керү өчен акча гына түгел, белем дә кирәк. Урыс телен белмәсәң, шәһадәтнамә алу өчен имтихан тотып булмый.

Җәй буе үгез белән булган көрәш, тир түгү, бил бөгү, бимазалану, казакъ балаларын укыту бушка китмәде, билгеле. Аз гына кесә калынайды. Белем савыты тулыланды. Үткән җәй Нугай балаларын укыткан тәҗрибәгә бу һөнәрнең яңадан-яңа серле ысуллары өстәлде. Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз, ди. Ә мөгаллимлек эше гаҗәп кызык икән. Әйтик, егерме бала — егерме ачылмаган бөре. Син ачасың бу бөреләрне. Бересен генә ачалмасаң да, төн йокың кача. Димәк, син —булдыксыз. Җебегән. Сәләтсез. Ләкин Галимҗан андый түбәнлеккә төшмәде. Казакъ халкы алдында — йөзе ак, күңеле саф.

Җәйләүдә күңел ачу мизгелләре дә була. Җыр. Моң. Думбра уйнау. Казакъ кызларының ачык йөзе, дала шаулатып көлүләре, егетләр белән бергә ат чабыштырулары... — барысы да күңел төбенә җуелмас матур хатирә булып сеңә. Каһәр суккан үгезгә дә рәнҗеше юк Галимҗанның. Үгез телен белү дә үзенчә бер һөнәрдер әле. Ул теләсә нинди изрәгән авызга баш бирми икән ләбаса. Башта тыңламый диңкетте ул Галимҗанны,

елар чиккә җиткергән чаклары була. Бер киреләнсә киреләнә икән, әй, үгез халкы. Койрыгына ут төрт, кабыргаларын без белән чәнечкәлә, маңгаена чүкеч белән тондыр — барыбер сине санга сукмый: юкка этләнәсең, энекәем, синең ише маңка малайларны күп күргәнем бар, дигәндәй, сыртын кабартып, ачуынны мең өлеш кайнатып тик тора. Шуннан Галимҗан үзен үгез урынына куеп карады. Үзенең дә кирелеге үгезнекеннән ким түгел ич. Нахакка сугып карасын берәү. Кыерсытсын. Түбәнсетсен. Ул аңа аслан баш бирмәячәк. Гадел булсын. Тиешен әйтсен. Яхшылап. Бу — икенче. Үгез дә шулай икән. Беркөн, үгез киреләнгәч, чукынып катсана дигән кыяфәт белән, буразна буена сузылып ятты ул. Дала. Тын. Ул бер үзе. Кояш уттай кыздыра. Әллә нинди күңелсез уйларга бирелеп, моңаеп ята торгач, кычкырып җырлап җибәрде ул. Бәй, Ходайның рәхмәте, моң ару гына чыга лабаса. Әллә далада булганга шулаймы? Галимҗан моң ярата. Башкалар җырын ул йөрәге белән тыңлый. Әмма кеше алдында кычкырып җырлаганы юк. Чөнки яхшы чыгуына ышанып бетми. Ул бит эштә дә, укуда да шулай. Өстен булсын. Мөмтазлык күрсәтсен. Җиңелеп калмасын!

Озак кына җырлап ялыккач, сикереп торып, үгезе янына барды ул. Берникадәр шаяртып, аз гына чынлык хисе дә кушып, гәрчә үгезнең тыңлавына ышанмаса да, аны иркәләргә, сөяргә керешге. Шуның белән, әйтерсең, Алмачуарны сагыну тойгысын баса.

— Йә инде, үгез иптәшкәй, ачуланышмыйк. Казакъ күгенең кайнар кояшы белән ант итеп әйтәм: валлаһи, моннан соң сукмам үзеңә, — дип аның кабыргаларын сыпыргалады, маңгаеннан сөйгән булды. Бәй, менә хикмәт, үгезең, җайлап кына, әллә кайчан шулай кирәк иде, маңка малай, дигәндәй, кузгалып китмәсенме.

Шуннан соң Галимҗан, сабан тоткасына ябышкан килеш, буразнадан җырлап бара торган булды. Үгез аның моңнары белән тәэсирләнеп, үз хис-тойгыларына күмелеп, атлый бирә. Галимҗан алдында йозаклы зур дөнья сере ачылып киткәндәй тоелды. Үгез дә, адәм баласы сыман, җырмоң, җылы сүз ярата икән ләбаса. Бер яхшы сүз мең күңелнең ярасын төзәтә, ди. Җылы сүз үгезнең дә үҗәтлеген ала икән ләбаса!

Бу вакыйгалар, искән дала җиле кебек, үтеп китте инде. Алар сагынып сөйләргә генә калды. Шау-гөр килеп торган эссе җәйләү буйлары көзен сүрәнләнә төште. Казакълар кышлакка күчте. Галимҗан җиде юл чатында торып калды... Шуларның берсен сайла. Язмышың әнә шунда. Дөрес аяк бастың — бәхетеңне таптың дигән сүз. Салуласаң, бәхетеңнән колак кагасың. Моның өчен әлеге "җиде үлчәп бер кис" дигәне хакында ныклап уйланырга кирәк. Җиде генә түгел, йөз-мең мәртәбәгә уйлап та кисеп булмый бәгъзе бервакыт. Кем уйлаган саннар эчендә дә шундый тирән мәгънә бардыр дип. Әлеге: "Сүз эчендә энҗе бар", — дигән мәкаль турында кат-кат уйланды Галимҗан. Мәгәр кызык һәм серле икән бу тел. Ходай кушып, җиде юлның берсенә дөрес басып, Казан университетына барып керә алса, инде менә шушы телләргә тылсымнарның да тамырын өйрәнер иде бит ул. Әмма университетка бару мәсьәләсен җиде генә түгел, йөз-мең кат уйлап та, кисә алмыйча иза чигә әле ул. Инде кисәм дип күңел кайчысын алса, кулына шайтан китерә дә суга.

— Адәм шайтаны Алла шайтанына караганда да яманрак, —дигән иде бер казакъ карты. Аны ике шайтан да котыртты. Болай диде Алла шайтаны:

— И бәндәчеккенәм, бәләкәй чакта әллә тавык мие күп эчтеңме, башың бер дә эшләми бит: кесәңдәге тиеннәрең бер айлык кына лабаса, Казан сине чыраен сытып, кара йөз белән каршылаячак. Белем тубалың да яртылаш кына бит әле. Кит син шахтага, төш җир астына, әнә кайда байлык, кәйлә тотарга кулың гына карышмасын, чапкан саен көмешләр ялтырап чыгып торачак...

Кеше шайтаны да ару гына тәтелдәде:

— Урал бабаң итәгендә Миас дигән бәләкәй генә кала булыр, әллә

кайда олагып йөрмә, кит шунда гына; анда Җиз эретү заводы бар. Кесәң юка күренә, тапкан акчаң анда гына сыймас, берәр капчык кебегрәк нәмәстәкәй рәтләп ал, — диде. Хәзергә әле ул бер ел эшләргә кирәк дигән шайтан коткысына бирелде.

Галимҗанны язмыш җилләре бөтереп алды. Бөтереп тә алды, әйләндереп-тулгандырып, Миас шәһәренең Җиз эретү заводы капкасы төбенә китереп тә бастырды. Башта ул, яшәү мәсләген югалткан кешедәй, нишләргә дә белмичә, аптырап тик торды. Аяк асты пычрак иде. Яңгыр, күрәсең, бу тирәдә чиләкләп койган. Шулай да әле ул артык шашынмый, сибәләп кенә тора. Әмма салкын җиле ач иблистәй котырына. Аның кайсы яктан искәнен дә белер хәл юк. Әле уң колакка китереп суга, әле сулына тондыра, әле битеңә чәпи, әле бөтен гәүдәңне уратып алып, пычракка сузып салмак була. Теге коткы салучы шайтаннар аның артыннан өерләре белән ияреп килгәннәрме әллә? Шулар шаяртамы? Ныклыгын сыныйлармы? Син бәләкәй чакта сумса, бәлеш, коймак ашап, каз боты кимереп үстең, әниеңнең җылы кочагында иркәләнеп кинәндең. Тормыш бер елмайса, йөз мәртәбә теш ыржайта ул, егеткәй, менә хәзер этлән инде, диләрме?

Шулай уйланып торганда, аның янына өстенә кәҗән, аякларына итек, башына картуз кигән илле яшьләр чамасы бер агай килеп чыкты.

— Пәчәмү эздис ыстаиш, холытны бит, пәйдүм туда, новинки нәверне, работы искаеш ышту ли? — дип, аны эчке якка алып кереп китте.

Урыс телен вата-җимерә сөйләшүеннән аның мөселман кешесе икәнлеген аңлау кыен түгел иде. Шуңа күрә, эчкә кергәч, ныклап танышып, эш эзләп килеп чыгуын сөйләп бирде Галимҗан. Мәгәр кем икәнлеген әйтмәде. Абзый кеше дә бу хакта төпченеп тормады. Беткәнмени менә шушылай бәләкәй юл капчыгы тотып, эш эзләп йөрүче берәдәкләр. Алар дөнья тулы. Берәүгә, әйтик, йорт юнәтергә кирәк — чыгып китә ул мескен зур өмет белән. Икенчесенең ат аласы килә. Ул да кала ягын каера. Урыс-Япун сугышыннан кайтканнар да шәһәр урамнарына тозлы су сибелгәнлеккә алдана. Инкыйлаб давылы эчендә кайнаганнар да рабочий булып китә. Мәдрәсәдән куылган шәкертләр дә килә бирегә. Шулай итеп, зимагурлар гаскәре, яңгырдан соң үрчегән гөмбәдәй, һаман ишәя бара. Бу мескен егет тә шундый гөмбәләрнең берседер инде, дип уйлап алды абзый кеше.

Галимҗанның өстендәге киеменнән мәдрәсәдә сеңгән шәкерт исе килмидер инде хәзер. Аларны казакъ далаларындагы эссе кояш нурлары әллә кайчан киптереп бетергәндер. Бәгъзе бервакыт анда дала җиле дә нык котыра. Аягыннан егып салыр дәрәҗәдә тилерә. Киемнәренә сеңгән шәкерт исен шул шашкын җилләр дә аз каккаламагандыр. Әмма абзый кеше, Галимҗанның киеме буенча фикер йөртеп, аның мәдрәсә комагы икәнлеген барыбер чамаламый калмады. Ярлы-ябагай мескен авылдагы бакча карачкысына охшап килә. Аягында чабата булыр. Өстендәге теткәләнеп беткән киндер күлмәге, киндер ыштаны да аның авыл хәерчесе кайгысын төяп килүе турында кычкырып сөйләп тора. Бәгъзе берсе теткәләнгән шул киндер күлмәк өстеннән иске бишмәт киеп алган була. Монысы үзен берникадәр фырт тота. Ул, янәсе, кырлык арасындагы бодай. Ләкин бишмәтенең йә ямавы, йә ертыгы бу фыртыкайның да асыл заттан түгеллеген исбат итә. Ә абзыйның алдында торган егетнең аягында әле, шактый дөнья күргәнлеге сизелсә дә, ботинка. Өстендәге кояш ашаган җиләнендә дә зыялылык төсе бөтенләй үк китеп бетмәгән. Башындагы картузы астыннан ишелеп чыгып торган чем-кара чәчләре дә фәкыйрьлек базында аунамаганлыкны раслый. Авыл "йолкышлары" әле чәч үстерми. Ә моныкы, Ходайның хикмәте, ат койрыгын хәтерләтеп, җилкәсенә төшеп тора. Маңгае текә, кара күзләр чая карый... "Нинди усал язмыш тырнагына эләккән икән соң бу тәти егет?" — дип уйлады да абзый кеше, үзен ныклап таныту өчен уң кулын сузды:

— Мин Нурислам абзаң булырмын, туганым, Җиз эретү завытында бригадирмын...

— Мине Галимҗан дип белерсез, Нурислам абзый. Сезнең белән танышуыма бик шатмын. Әле менә кем белән сөйләшергә, кая барырга белми аптырап тора идем.

— Аптырама. Ходай язмаган эш булмас.

— Ходайга ышанып килдем дә инде менә.

— Анысы шәп. Әмма ләкин кешеләргә дә таяну кирәк.

— Мине үз бригадаңа алсаң иде, Нурислам абзый, ә?

— Анда бик авыр бит, туганкай!

— Эшнең майлы бутка түгеллеген беләбез анысы.

— Менә монысы егетләрчә булды!

— Йөзегезгә кызыллык китермәм.

— Әйдә, алайса, кердек хуҗа янына.

Коридордан үтеп, уң якка борылгач, икенче ишек хуҗаныкы икән. Нурислам абзый үзен бик кыю тота. Уртача буйлы ул. Ябык кына. Хәрәкәтчән. Сарык тәкәседәй тып-тын басып барды да ишекне бик каты дөбердәтеп алды. Эчтән: "Можно!" — дигән салмак тавыш ишетелгәч, Галимҗанның җиңеннән килеп тотты. Монысы, әйдә, бәхетең бар икән, хуҗа үзендә, кеше юкта тизрәк кереп чыгыйк, дигәнне аңлата иде.

Аларны өстәл артында ишелеп утырган мичкәдәй юан урыс каршы алды. Аның симезлеген язып та, сөйләп тә аңлатырлык түгел. Муены бөтенләй юк диярлек. Ике бит очыннан йодрык зурлыгы симез йомарлак бүртеп чыккан. Бу кешенең күзләрен дә май каплаган хәтта. "Их, теге ушән үгезне җиктереп чирәм күтәрттерсәң икән бу ит бүкәненнән. Эссе кояшта мае буразнага эреп агар иде мәгәр. Алай гына да түгел, үзен сабан үгезе урынына җигәргә була бит моның..."

Шундый уй йөгереп узды Галимҗанның башыннан.

Нурислам агай әле үз йомышы белән килгән икән. Хуҗа вакытсыз йөрүенең сәбәбен сорагач, баягы кебек урыс телен корыган агач урынына сындыра-сындыра, кулларын болгый-болгый, тәтелләргә тотынды:

— Вот вит, Ычтапан Никулаеч, эта... — медеплавильный завут... так вит... Руда грузим вагонеткам... так вит. Патум... мед идет в одну сторону, ышлак идет чәпчим другай сторона... Руда очин тижелый... ышлак туже тижелый... а лошат худой, худой... сила не хватает...

Хуҗа, күрәсең, Нурислам абзыйның рус телен болай вата-җимерә сөйләвенә күнгән инде. Шуңа күрә ул чыраен сытмый, йөзен жыермый, аз гына да көлемсерәми тыңлап, аның фикер жебе очын тиз тотып алды да:

— Кормить надо лошадей, — дип куйды.

Нурислам абзый үзенекен аңлатты:

— Ызнам, Ычтапан Никулаеч, кормит нады, ну вит, курма ниту вит, курма...

— Ладно, — диде дә хуҗа, бер кәгазьгә нидер язып куйды. Монысы хәл ителергә тиешлекне аңлатты. Аннан соң Нурислам Галимҗанны тәкъдим итте:

— Вот... пришул новый челавик... Работа надо... ыздоровый... Сила мнуга... Мая бригада один челавик надо... — Работат будет как бык...

Монысына хуҗа бик тиз генә җавап бирмәде. Май баскан күзләрен чекрәйтеп, озак кына Галимҗанга карап торды. Соңгы вакытта менә шушындый шәләй-вәләй йөрүчеләр күбәеп китте. Аларның эшләре чыпчык тезеннән, ә телләре беләк буе. Сигез сәгать кенә эшләп, күп акча күрәп алмакчылар. Баракта яшәргә дә риза түгелләр. Алтын сарай кирәк үзләренә.

Нурислам абзый хуҗаның икеләнүен, сырланып маташуын тиз аңлап алды. Кара фикерен тамырландырганчы, аны ашыктырырга, тимерне кызуында сугарга булды:

— Он хорош парин... Сила мнуга... Если я сказал... правильна сказал... нам надо... вот такие орлы...

Бу юлы хуҗа, алаптай авызын аз гына ерып, елмайгандай итте дә алагаем бер төчкереп куйды. Бу исә ике арада үсә башлаган боз тавын эретеп җибәргәндәй тоелды. Нурислам:

— Бутте ыздоровый... — дигәч, хуҗа янә йомшый төште. Әмма сүз әйтергә ашыкмады. Галимҗан исә арага яхшы мөнәсәбәт җебе тартылганлыкны аңлады. Моның сәбәбе нидәндер — Галимҗан өчен әле ул караңгы. Эшләгән атны тукмамыйлар. Нурислам абзый, бәлки, хезмәте белән абруй казангандыр. Хуҗа кеше тәлинкә тотучыны да нык ярата. Бригадирның шундый гадәте дә бардыр, бәлки. Дөнья бу...

— Ладно, пусть работает, — диде хуҗа.

Шул сүзләрне ишетү белән Нурислам абзый, яна танышы өчен бәхетне чыннан да якасыннан эләктергәндәй шатланып, ишектән ялт чыгып китте. Галимҗан аңа иярде.

## II

Завод ихатасыннан чыккач, капка төбендә аз гына туктап торды Нурислам абзый. Кая куйыйм икән соң сине, туганкай, дигәндәй, Галимҗанга карап куйды. Кунагының язмышы өчен абзыйның борчылуы, хәстәрлек күрергә тырышуы, өзгәләнүе сизелеп тора. Галимҗан шатланып та куйды хәтта. Кая гына бармасын, — нугайлар арасына, казакъ далаларына, — мөселман кардәшләрдән яхшы кешеләр ярдәм кулын суза, ихлас күңел белән каршы ала. Менә генә чокырга төшеп китәм дигәндә, алар сине тартып чыгара. Бар ул шәфкатьле бәндәләр. Бар! Бар!! Бар!!! Аның шушы мөкатдәс уйларын раслагандай, Нурислам абзый янә бер шатлык тәкъдим итте:

— Хәзер җәһәт кенә баракка барыйк, туганкаем, Сабирабикә җингән бик ачык күңелле кеше, яхшы каршы алыр, ә миңа эшчеләрем янына ашыгырга кирәк. Кич тагын да очрашырбыз әле, — дип, аны җилтерәтеп алып та китте. Үзе бик җәһәт, җиңел, тиз атлый Нурислам абзый. Ут борчасыдай кылана. Гәрчә салкын җил җилеккә үтәрдәй котырынып иссә дә, яңгыр һаман шулай борчак сипкәндәй сибәләп торса да, артта калмаска тырышып, тек-тек атлый торгач, эче җылынып китте Галимҗанның. Аягында итек булгач, һич куркып атламый абзый кеше. Пычракчачракка да кереп китә, күлләвекнең дә күзенә басып үтә, тайгак җирдән дә курыкмый. Аның бу кыланышы да ошады Галимҗанга. Ут чәчрәтердәй итеп баса җир күкрәгенә. Ашкынып-ашкынып атлый. Галимҗан аннан үрнәк алырга тырышты. Тик, каһәр төшкере, тертелде бер урында. Бер сөзәк җиргә Нурислам абзый кебегрәк чатылдатып басыйм дисә, аягы таеп та китте, суга барып та батты. Ярый әле егылмады. Куллары, бөтен бәдәне белән әллә нинди хәрәкәтләр ясап, тигезлек сакларга тырышып, бу бәладән котылып калды. Чучка урынына сузылып ятсаң пычрак суга, ходаем, адәм көлкесенә калуыңны көт тә тор. Ботинкалар эченә тулган су да ул кадәр эчне пошырмый. Эч җылынгач, салкын тимәс әле.

Нурислам абзый күрде моны. Шулай да бер сүз дә әйтмәде. "Их!" — диде дә кулын селекте. Пычракка куркып бассаң, ул сине сузып салырга гына тора, дигәнне аңлата иде аның бу ишарәсе.

Алар шактый озак атлады. Ике чакрым чамасы булды шикелле. Бу араны үтәргә күнеккән кешегә әллә ни авыр тоелмыйдыр ул. Һәр тайгакка шүрләп баскан Галимҗан өчен исә зур газапка әйләнде бу.

Менә алар шәһәр читендәге бер барак янына килеп туктадылар. Нурислам абзый беркавым вакыт әле Галимҗанга, әле баракка карап торды да:

— Менә шушы инде ул, туганкаем, без яшәгән оя, бохар ташыннан өелмәгән, такта-токтадан әтмәлләнгән, бармак белән төртсәң, ишелеп төшәргә тора, — диде. Аз гына сүзсез торгач, Галимҗанның күңелен күтәрергә теләгәндәй, янә әйтеп куйды: — Әйдә, борчылма, мең алтын ташың булганчы, бер акыллы башың булсын, — дияр иде әти мәрхүм.

Баракның тышкы күренеше чыннан да котсыз иде. Яртысына кадәр

балчыктан өелгән нигез янә такта белән әйләндереп алынган. Авылда мондый нигез көзен кыш көне өй жылы булсын өченгә салына. Салкын кыш үтеп, жылы яз килгәч, ул нигезне алып ташлыйлар. Шулай итмәсән, жиләтмәсән, өй астан чери. Бирелдәге нигез вакытлыча булырга охшамый. Ул бүселеп чыккан. Такталарын алсаң, ишелеп төшәргә тора. Такталары да инде аның, ташка үлчим, череп, күгәреп беткән. Бәлки, баракның нигезе бүселгәндер дә икенчесен дивары жимерелеп төшмәс өчен чәпәгәннәрдер. Жиргә тәмам сеңгән инде бу барак. Түбәсендәге такталары да ярчаланып, каерылып, телгәләнеп беткән. Ул ашын ашаган, яшен яшәгән йөз яшьлек картны хәтерләтеп тора.

Ишекне ачып керсәләр, аларны караңгы баз каршы алды. Коридорның идәне жир икән. Ул да баткакланып беткән. Якты төшсенгәдер инде, Нурислам абзый иске тактадан ясалган ишекне ачып, аны шунда торган бер тимер белән терәтеп куйды. Коридордан бераз баргач, уң яктагы бер такта ишекне ачып, эчкә үттеләр.

Аларны Нурислам абзыйның үзе кебек ачык йөзле, кырык яшьләр чамалы бер ханым каршы алды. Нурислам абзый исә, нык ашыкканлыгын белдереп, шуны гына әйтте:

-- Сабирабикәм, менә кунак, чәенне куй, якты чыраенны кызганма, мин ашыгам, — диде дә чыгып та китте.

Галимжан ни дип әйтергә дә белми аптырап калды. Аңа кыен да, уңайсыз да, күңелсез дә иде. Дөрес, алдында елмаебрак торган ханым аның суынган күңеленә бераз жылы өргәндәй тоелды. Ул чибәр түгел кебек. Гажәп, нәкъ Нурислам абзыйныкыдай, бит очларында, борынында сизелер-сизелмәс сипкелләр жемелди. Яңаклары берникадәр эчкә баткан. Сары кашлары да аны әллә ни бизәми. Өстендәге шактый дөнья күргән ситсы күлмәге дә дан түгел. Шулай да, мөлаем карашы аны сөйкемле итеп күрсәтә.

— Сез уңайсызланмагыз... кем... исемегезне дә белмим бит әле...

— Мине "Галимжан", диләр.

— Галимжан энем...Үз өегездәге кебек булыгыз. Нурислам абзыегыз теләсә кемгә егылып төшми ул. Күңеленә ошагансыздыр. Әйдә, үтегез әле, үт...

— Минем өчен борчылмагыз, Сабирабикә апай!

— И — "бикә"сен әйтмәгез. Мине "Сабира", диләр.

— Ә Нурислам агай...

— И... аның... "Бикә"не үзе генә жилемләде бит ул. Кәефе килгәндә әйтә инде шунда. Телгә беткән ул абзыегыз. И... менә тинтәк. Үзем дә шул тел бистәсемен. Кеше суыктан килгән. Һаман сөйләнәм дә сөйләнәм. Хәзер... чәй куеп жибәрим әле... Ә сез... Өстегезне салыгыз... Аягыгыз да нык чыланган түгелме? Ботинкаларыгызны нитеп... менә бу башмакны киеп торыгыз әле...

Сабира түти аңа юкәдән үрелгән тирән, зур башмак китереп бирде. Ботинкаларын салгач, оекларының лычма су икәнлеген күреп, аптырап калды Галимжан. Юлда, Нурислам абзый артыннан колындай теркелдәп йөгергәндә, боларны ул искә алмаган иде. Башмакның төбе киез икән әле. Аякларга рәхәт жылылык иңгәндәй булды. Өстендәге жиләнен дә, башындагы картузны да салып чөйгә элгәч, Галимжан барак эче белән таныша башлады. Бер бүлмәдә егермеләп койка. Кайсыберләре тактадан ясалган. Тимер карават та бар. Алары да бүлмәгә һич тә ямь бирми. Тутыгып беткәннәр. Урыннары юньләп жыештырылмаган. Берсендә ертыкмыртык мендәр аунап ята. Икенчесендә йә иске солдат шинеле, йә кырык ямаулы сырма. Оренбурдагы Вәли мулла мәдрәсәсендә дә бүлмәләр шулай зур иде бит. Ләкин анда аларны чаршаулык белән бүлгәләп булса да куялар иде: ике кешелек, өч кешелек, дүрт кешелек, биш-алты кешелек... Монда да шулай итәргә мөмкин түгел микәнни?

Шулай уйланып торганда, уң як почмакта бала елап жибәрде. Бәй, монысы ничек була инде тагы? Анда почмак чаршау белән бүленгән

икән. Шуннан Сабира түти килеп чыкты да мәсьәләне аңлатып та бирде. Боларның ике баласы бар икән. Берсенә — биш яшь. Анысы әле авылда, ди. Ә монысы — бер айлык кына. Сабира түти шуңа күрә хәзергә эшләми икән әле. Шулай итеп, ике балалы бер гаиләне почмакка китереп кысрыклаганнар да аларны чаршаулык белән бүлеп куйганнар. Менә сиңа Урал бабай хыялындагы җир җәннәте. Стеналарына акбур бөтенләй тимәгән бугай. Тәрәзәләрендәге, башка урыннардагы тишек-мошыкларга төрле иске-москы чүпрәкләр тыгылган. Түбә сайгагының әллә ничә урыныннан тамчы тама. Әлбәттә, яхшы хуҗа мондыйга малын да япмас. Ә адәм баласы түзә. Чыдый. Сабыр итә. Кайгысын эченә йота. Тышка чыгармаска тырыша. Әгәр бу авырлыкны утка әйләндерсә, аның бит дөрләп януы бар.

Чәйдән соң Сабира түти:

— Мин хәзер әйләнеп кайтырмын, гөлкәем, кибеткә генә барып киләм, — дип чыгып китте.

Галимҗан бер сүз дә әйтмәде. "Ярый" дигәнне ул "ым" кагып кына аңлатты. Ә инде Сабира түтинең күңелен фәкать бер уй борчый иде: кунак килгән — сый юк. Анысын-монысын юнәтештерер, бәлки.

## III

Галимҗанның җаны тыныч түгел иде. Тышка чыкса, кара-кучкыл болытлар эченә яшеренгән көзге моңсулык ыңгырашуы каршы ала. Хәзер яңгыр ишелеп яумый. Җил дә аяктан егардай кылтаеп-котырынып исми. Шулай да табигать тыныч түгел. Болытлар көйсез бала белән бер. Һаман әле азлап булса да яшь сыга да тора. Җил агачлардагы соңгы хәлсез яфракларны алып ыргыта. Болытлардан түгелгән яшь кайгылы кешенең сыкрануын хәтерләтә. Бу күренешләр куркыныч та, моңсу да.

Кичкә таба яңгыр бөтенләй туктады. Җил дә тынды. Ә болытлар, ачуланышкан егет белән кыз сыман, бер-берсеннән аерылышып китә. Ләкин бу да озакка бармый. Сагынуга чыдаша алмагандай, ашыга-ашыга килеп кавышалар да, кочакларына керешеп, бер бөтенгә әвереләләр. Шуннан, яңа дәрт белән янадан куерып алып, риваятьтәге тулпар аттай ялларын болгый-болгый, җир өстенә ашыгалар. Түбән үк төшеп, канат очлары белән шәһәр өстен сыпырып-сыпырып үтәләр. Аннан, ныклап укмашып, болай да җиргә сеңгән бараклар өстенә каплану җаен чамалыйлар. Шулай тилерә табигать. Әллә кешеләрне куркыта, әллә шул шаярудан кызык таба. Әллә Кыш бабай килеп җиткәнче көз бер шашынып калырга уйлыймы.

Эшчеләр эңгер-меңгердә кайтыр кебек иде. Юк. Күз бәйләнде. Алар юк. Бөтен дөньяга тартылды караңгылык пәрдәсе. Хәзер инде күмердәй кара караңгылык. Күзгә төртсәләр дә күренмәслек.

Галимҗан эчкә керде. Монда да шомлы караңгылык. Сабира түти үз почмагында әш-мәш килә. Баракның урта бер җирендәрәк торган өстәл өстендә сукыр лампа яна. Аның саран яктысы тирә-якка бик аз төшә.

— Әллә азрак ашап аласызмы, Галимҗан энем? — дип, Сабира түти чаршау эченнән башын күрсәтте.

Галимҗан кулын күкрәгенә куйды:

— Юк, юк, Сабира түти, тамагым тук, Нурислам абзый кайтсын әле.

— И... Көн дә шулай инде менә. Уникешәр сәгать эшлиләр. Аларны көтсәң...

Нәкъ шулвакыт коридорда шау-шу ишетелде. Егермеләп эшче берьюлы кайтып керде. Алар нидер хакында сөйләшеп кайтканнар, күрәсең. Көлешү, бер-берсен төрткәләшү, хәтта чамасызрак сүз ычкындыру һаман дәвам итте. Ә инде җыенысын уптым-илаһи алганда, алар яңа гына таш капчыктан ычкынган кешеләрне хәтерләтә. Аякларында әллә ниләр: берсенекендә чабата, икенчесендә кәлүш, өченчесендә башы бака авызыдай ачылган иске итек. Өсләрендә дә шулай: ертык-мыртык фуфайка, кырык

ямаулы сырма, әллә кайчан мунчала итеп кулланырдай бишмәт. Мәгәр тавышлары таш ярырлык, күнелләре күтәренке, сөйләшүләре каты. Әйтерсең, авыр эштән түгел, ниндидер күнел ачу мәҗлесеннән кайтып киләләр. Сөйләшү-көлешүләреннән аларның "зәмзәм суы" белән җылынып алганлыкларын чамалау кыен түгел. Ә инде ертык-мыртык киемнәр йә һәркемнең үз "оясына", йә почмакка очты. Шулар белән бер үк мәлдә өстәл өстенә берничә шешә килеп кунаклады, алар янына суган, кыяр, сарымсак, икмәк, тозлы балык таратып ташланды. Бу өстәл янына почмакта торган икенчесен китереп куштылар. Хәзер инде боларның эчәргә җин сызганып кайтканлыгын ахмак та аңларлык иде.

Галимҗан, эшчеләр ыгы-зыгысына кысылмаска тырышып, бер як читтә — караңгырак урында басып тик торды. Хәзергә аны берәү дә күрмәде шикелле. Тик Нурислам абзый гына:

— Хәзер... — дип, аның аркасына йомшак кына кагылып алды да чаршау эченә кереп чыкты. Күз ачып йомган арада бөтенесе дә әзер булды. Өстәл өстендә яньчелеп беткән калай кружка, китек чынаяк, шешәне яртылаш кисеп ясалган стакан пәйда булды. Һәркем үз хәзинәсендә барын китереп куйды. Өстәл буйлап ике яктан өчәр бүкән утырттылар. Сул як стена буенда махсус калын такталары бар икән. Шуларны алып килделәр дә, бүкәннәр өстенә куеп, сандугач балаларыдай тезелешеп тә утырдылар. Әлбәттә, шаярышу да, тарткалашу да булып алды. Чөнки һәркемнең урын алып каласы килә. Уңайлырагын көчлесе, елгыры яулап ала. Йомшагraклары йә басып кала, йә өстәл янындагы караватка җайлаша. Бу мәшәкатьләр эшләнеп беткәч, Нурислам абзый, ниһаять, һаман әле бер як карангылыкта атасы тарафыннан кыерсытылган баладай басып торган Галимҗан янына килде:

— Әйдә, Галимҗан туганым, табын янына уз, нигә болай боек торасың, үз өеңдәге кебек бул!

— Нурислам абзый, мин аракы эчмим бит. Шушында гына басып торыйм әле.

— Ярамый. Бала-чага түгел бит син.

— Килешми. Чит кешеләр... яше, карты бар, дигәндәй...

— Соң, туганкай, шулар белән иртәгә эш башлаячаксың бит.

— Эштә сынатмам.

— Анысында шигем юк. Иллә мәгәр безнең рабочи гаиләсенә бүген үк керүең хәерле...

Соңгы сүзләрен әйткәч, телиме-юкмы, беләгеннән кысып тотып, җилтерәтеп алып китте дә өстәл башына китереп бастырды Галимҗанны. Башта Нурислам абзый сүзне ничек башларга белми аптырабрак торды. Шулай да ул озакка сузылмады.

— Туганнарым, — диде ул, — бездә бүген ике шатлык: беренчесе — палучка алу, икенчесе — кунак килү.

Бөтенесе дә Галимҗанга карап катты. "Син кем, исемең кем синең, нинди тәти егетсең, кайсы иләрдән, нинди язмышлар белән килеп чыктың монда?" — дигәнне аңлата иде аларның сынаулы карашлары. Ә инде Нурислам абзый:

— Ул бүген генә кунак, иртәгә таңнан безнең белән эш башлаячак, — дигәч, бөтенесенең дә күзләре шакмак булды. Чөнки Галимҗан алар алдында чыннан да тәти егет иде. Яратып кия торган кызыл күлмәгенең якасы, гәрчә кояшта шактый уңган булса да, ул кадәр үк иске булмаган пинжәге эченнән күренеп тора. Ә чем-кара озын чәчләр соң? Матур гына итеп шоп-шома таралып, җилкәсенә хәтле үк төшкән. Кара тут чибәр йөз. Кыскасы, аксөякләр нәселе исе аңкып тора бу чибәр егеттән.

Мондый капшаулы карашларның хикмәтен тиз сизде Нурислам абзый. Эшчеләр арасында төрлесе бар: әрем теләсе, чәнечкелесе, тупаслары — алар, һич уйламый, әллә ни әйтеп ташларга мөмкин. Шуна күрә күзләрен Галимҗаннан ераклаштырып, аларны аракы савытларына юнәлтергә ашыкты. Хәтта җырлап та җибәрде:

И дускаем, сиңа әйтәм:
Эч төпләрен күргәнче;
Эчсәң төпләрен күргәнче,
Дус булырбыз үлгәнче.

Мәҗлес җанланып китте. Тиз-тиз генә чәкештерешеп алдылар да төбенә хәтле түңкәреп тә куйдылар. Мәгәр Галимҗан эчмәде. Аны кыстап та маташмады Нурислам. Чөнки әле бая гына "мин эчмим" дигән сүзләрне бик ихлас, кыстый күрмәгез берүк, дигәнне аңлатып әйткән иде. Бик шәп. Эчмәсен. Күпме яшь егетләр бозыла шушы агулы еланнан.

Янә берәрне төшергәч, ниндидер йомыш табып булса кирәк, Нурислам үз "бүлмәсенә" — Сабира янына кереп китте. Шунда берсе — җирән мыеклы, яньчек борынлы, озын гына ябык кеше Галимҗанга килеп бәйләнде.

— Почему наша гост ни пиют, а? Значит он наш рабучий бырат ни лубит. Ыкту ни хошет — заставим, ыкту ни ызнает — научим! — ул, Галимҗанның аракылы кружкасын алып, аның кулына тоттырды.

Галимҗанга кыен иде. Ни әйтергә дә белми аптырап торды да бераздан гына телгә килде:

— Туганнар!.. Гафу итегез. Мин эчмим. Бу һич тә сезне хөрмәт итмәүдән түгел.

Галимҗанның ихлас күңелдән ялварып әйткәнлеген аңладылар шикелле. Үзара чыш-пыш сөйләшү китте. Кемдер кычкырып җибәрде:

— Кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырлыйсың, брат!

Аннан төрлечә шаяртып алдылар:

— Мәгәр зимагур арбасына бик ышанма, парин!

— Коргаксыган бит ул.

— Төбе тишек, диң...

— Хи-хи-хи...

Агайларның берсе, чувашлардан булса кирәк, кечкенә буйлы, шактый өлкән яшьтәгесе — Галимҗанны яклады:

— Син, мыек, Сәрпәреттин курдаш, никә кешене көчлисең әле, әчпәй икән, эчпәсен, әле пит ул песнең керүек позылмаган...

Аның сүзләрен ябык йөзле бер кара татар егете җөпләде:

— Чуваш абзый дөрес әйтә. Аракы икмәк түгел. Сез мине дә шулай өйрәттегез.

Мәҗлес беразга тын торды. Әмма ул озакка бармады. Янә үзара сүз көрәштерү, бәхәсләшү китте. Җирән мыекның җиңелеп каласы килмәде, күрәсең. Галимҗанның аракылы кружкасын кулына алды да берничә иптәшенә ым какты. Бу ым: "Монда килегез", дигәнне аңлата иде. Ике таза гына егет килеп, Галимҗанның кулларын артка каерып тоттылар. Берсе, яңагыннан кысып, авызын яптырмый торды. Ә җирән мыек, шул уңайдан файдаланып, Галимҗанның авызына аракы койды.

Бу эш тәмамлангач, мәҗлес, бертавыштан диярлек, шаркылдап көлеп җибәрде. Тавышка Нурислам атылып килеп җитте. Мәсьәләнең мөгезе нидә икәнлекне аңлады ул —Галимҗанны көчләп эчергәннәр. Үзе биредә булса, моңа ирек куймас иде.

— Синең эш бу, Сәрвәретдин, нигә ахмакланасыз? — дип, ачу белдерде Нурислам.

— Ярый, башлык, ачуланма пүчтәк өчен, тайны җигеп, кешене тукмап өйрәтәләр, пунимаеш, зимагур тек зимагур...

Галимҗан сүзсез генә торды. Эчергәндә чәбәләнмәде ул. Моның мәгънәсе булмаячагын аңлады. Оренбурдагы Вәли мулла мәдрәсәсендә беренче көнне, карт шәкертләр җан-фәрман килеп, тун җиненнән йолдыз каратмакчы булганнар иде. Карасаң, җиңнән салкын су коялар. Шуннан алар мәзәк таба. Рәхәтләнеп бер көлешеп алалар. И бу наданлык! И бу җаһиллек! Күңел ачу өчен юкмыни соң башка берәр хасият? Мәдрәсәдә унар ел бәсәреп ятып, кыршылып-сусәргән шәкертләр шулай юньсез кылана. Галимҗан алданмады ул вакытта. Бер як читтә яшеренеп торды. Бераздан

инде ачып карасалар, аның коп-коры икәнен күреп, гарьлектән җир тишегенә керердәй булдылар. Шуннан Галимҗан аларга Плутон, Анторес кебек кояштан әллә ничә мәртәбә зур йолдызлар булу турында сөйләп, мәдрәсәгә буш тубал белән килмәвен сиздереп алды. Тора-бара шәкертләр тажы булу дәрәҗәсенә күтәрелде.

Шәкертләр "гаскәре" билгеле инде ул. Ә менә эшчеләрдән моны көтмәгән иде. Кайда да наданлык икән. Томаналык. Каешланган кара халык. Әйтерсең, бөтен Русия мәет кайгысыннан кара күлмәк кигән мескен бәндәгә әверелгән... Бераздан Нурислам, янә чаршау эченә кереп китеп, бер таба коймак күтәреп чыкты да аны табын уртасына китереп утыртты. Моны дәррәү кул чабып каршы алдылар. Мона чаклы кыяр, суган, балык капкалап утырсалар, хәзер инде болар хаятендә бик сирәк очрый торган тәмле нәстәкәй бизи табынны. Галимҗанга бәйләнешле тамаша бөтенләй онытылды. Һәммәсенең күзе коймакка карап чекрәйде. Әллә күпме шатлыклы тавышлар яңгырады:

— Ну, маладис, Нурислам абзый!

— Моны күрмәгәнгә биш былтыр.

— Зимагур ашы түгел ич бу.

— Мин ашамыйм. Майлы аш эчемә килешми.

Көлешеп алгач, кырык күз янә табадагы коймак өстенә төбәлде. Тик үрелеп алырга берәү дә җөрьәт итмәде. Нурислам аз гына сөйләп алырга булды:

— Сабирабикәм кунак хөрмәтенә тырышкан. Мин аңлыйм, туганнар, сезгә кимендә биш таба коймак кирәк. — Бераз уйланып торгач, ул шаяртып алуга күчте. — Бер кабымны икегә бүләек, беребез өчен беребез үләек, дип сөйләшәбез. Ә хәзер болай диик: бер коймакны икегә бүләек. Сабирабикәмә рәхмәт әйтеп, күңелен күрәек.

Көлешеп, хәтта кул чабып алдылар.

— Мең яшәсен Сабирабикә апа!

— Безгә анабыз кебек бит ул!

— Бәхетле син, Нурислам агай!

Нурисламның яхшы башлык та, кешелекле булуын да янә бер мәртәбә ныклап аңлады Галимҗан. Башкалар аның авызына гына карап тора. Аннан алда коймакка да үрелмиләр хәтта.

Берара Мыек сүз башлады:

— Дуңгыз корсакны бәреп төшереп, завут мөгезенә Нурислам агайны менгереп атландыргач, вәт, әй, мин сиңа әйтим, ашаячакбыз ул вакыт майлы коймакны, алаптай авызыбызны чәпелдәтеп, хи-хи-хи...

Аның сүзен көлкегә алдылар. Һәркем үзенекен ярды:

— Әйттем бит инде безнең эчкә майлы аш килешми дип...

— Иң әүвәл бәрәңге ашарга өйрәнергә кирәк...

— Кара икмәк тә карынны ерта әле...

Көтмәгәндә бәхәс купты. Кара-каршы сөйләшү китте:

— Зур калаларда, әнә, мәсәлән, Мәскәүдә, Казанда, Уфада сигез сәгать эш өчен көрәшәләр, ди...

— Ә без унике-унөчәр сәгать эшләнәбез...

— Шулай эшләп тә әҗере тамак ялгарлык кына...

— Сигез сәгатькә калса, шуның яртысын гына алачакбыз бит.

— Ашадың, ди, пычагымны майлы коймак...

— Юк-барга штраф түләтеп кисәләр акчаны...

— Кан эчеп туясы юк ул дуңгызкорсак бирәннең...

Сүз, бәхәс шактый озакка сузылды. Галимҗан тыңлап кына торды. Фикер әйтергә ашыкмады. "Дуңгызкорсак" дигәне әлеге үз күзе белән күргән завод хуҗасы икәнлекне аңлады ул. Шуны алып ташлап, Нурислам кебек уңган кешене куйсаң, барлык эш майлы табада шуган коймак кебек китә, янәсе. Әнә, зур бәхетне ничек өмет итәләр. Алай булмаганны Галимҗан белә. Шулай да аңлатырга ашыкмады, әмма сүзгә катышмый калуны да килештермәде.

— Завод хуҗаларын алыштыру белән генә тормыш үзгәрми. Сез әйткән дуңгызкорсаклар артында тагын да калынрак тиреле аждаһакорсаклар бар.

Мыек сорау бирде:

— Анысы кем, "аждаһакорсак" тигәнең?

— Патша.

— Аны нишләтергә?

— Бәреп төшерергә!

Эшчеләр өчен бу сүз яңа түгел. Беренче революциянең җиңелү сәбәпләрен алар белә. Завод хуҗасын алыштыру белән генә бәхет тәтемәгән кебек, патшаны алып ташлап кына дөнья рәтләнмәячәкне дә аңлап баралар. Мыек тагы да сорап куйды:

— Аждаһакорсак патша урынына диюкорсак патша утырса, ни булыр? Майлы коймак ашап кына яшәячәкбезме?

— Властька эшче-крестьян киләчәк.

— Бәй, ягъни мәсәлән, мин барып утырдым, ди, ул патша тәхетенә. Укый белмим. Яза алмыйм. Олы агач кашык белән майлы ботка ашап утыруын килештерер идем инде анысы...

— Ну, әйтте!

Бу бәхәснең шактый озакка сузылачагын аңлаган Нурислам сүзне тизрәк йому чарасын күрде:

— Туганнар, житте, мәҗлеснең ямен җибәрмик, патшага тел тидерү яхшы шөгыль түгел, — диде дә бушаган зур табаны алып, үз почмагына кереп китте. Нәкъ шул вакыт коридорда ниндидер дау купты. Сугыш башланды. Барысы да, ут чыкканда чаң кагу ишеткән кешеләрдәй, ишеккә ташланды. Өстәл янында ике чуваш белән йөзләреннән әле сабыйлык шәүләсе дә китмәгән өч егет һәм Галимҗан гына калды. Яу тавышын ишетеп булса кирәк, чаршау эченнән Нурислам да атылып килеп чыкты. Бер Галимҗанга, бер тегеләргә карап, әле коридордагы кычкырышка колак салып:

— Башланды... — диде.

Галимҗан сорарга мәҗбүр булды:

— Нәрсә башланды, Нурислам абзый?

— Нәрсә булсын — "пәри туе".

Ул, шул "пәри туе" эченә ыргылырга теләптер инде, ишеккә таба атылды. Ләкин аны чувашларның берсе килеп тотты:

— Нурислам туган, пу пәри туе пер пүген генә төгел пит инте, үсең пеләсең, чокыу кирәкми, үзгәләп ташлаулары бар, алар пит пик яман сукыша...

Нурислам тыңлады чувашны. Дөрес әйтәсең дигәнне аңлатып, аның аркасыннан кагып куйды да кулын селекте. Шуннан Галимҗанга "пәри туе" дигән сүзләрнең хикмәтен аңлатырга керешге. Коридорның сул ягындагы ишекне күргән иде Галимҗан. Әнә шул ишекне ачып керсәң, сине шушындый ук кыр зурлыгы шыксыз бүлмә каршы ала, имеш. Анда да мондагыдай эшчеләр яши икән. Получка алган көнне алар да хәмер йотып ләззәтләнә. Зимагурның йөрәге һәрвакыт ярсу була. Аракы исә ярсулыкны мең өлеш котыртып, җенләндереп җибәрә.

## IV

Казакъ шагыйре Абайның: "Сүзнең эче — алтын, тышы — көмеш", — дигәнен янә бер мәртәбә искә алды Галимҗан. Абайның җырлары, шигырьләре казакъ халкының күңеленә сеңгән, йөрәгенә сары май булып яткан. Алар далада да, җәйләү күкләрендә дә яңгырый. Галимҗанның күңел даирәсенә дә моң-сагыш булып күчте. Алар бик күп:

Йөрәгенне биләп алыр
Яхшы җыр һәм моңлы көй;

Күнелгә төрле уй салыр,
Җырны сөйсәң, миндәй сөй!..

Якты җитмәс кара күнелем ачылса да,
Күктәге ай белән Кояш чагылса да,
Бу дөньяда миңа мондый бүтән яр юк,
Сиңа миннән артык ярлар табылса да.

Алтын бәрабәренә торырдай матур сүз баштагы томанны тарата, миенә акыл оеткысы сала, күнеленә гүзәл зәвык бирә. Эчендә алтын түгел, зәккум* булганнары да бар. Биредә күбрәк эчендә зәккум җимеше булган сүз белән сөйләшәләр. Алар тамыр җепселләрен өзә, йөрәккә кара төер сала, канынны боза. Боларның бер-берсенә булган атамалары да шул дәрәҗәдә. Иван исемле урыс егетенә "шакал" дип эндәшәләр. Чувашның берсе — мәет козгыны. Икенчесе — ала карга. Татар егете Сәрвәр — "зобани". Тагы да әллә нинди атамалар бар: кыл койрык, чыпчык баш, буаз сыер, карга борын... Нурисламныкы гына юк. Аны "башлык" дип кенә йөртәләр. Шушы исемне югары тотканлыгы эш өстендә һәрдаим сизелеп тора. Ә инде Галимҗанга Зобани-Сәрвәр "аждаһакорсак" дигән берәгәйле кушаматны китереп сылады. Галимҗан табында патшаны шулай мыскыллаган иде. Ул үзенә әйләнеп кайтты. Сәрвәретдин аны, әйтергә җиңелрәк булсын дип, кыскартып та җибәрде. "Аҗкорсак" булып калды Галимҗан.

... Беренче көнне эш иртәнге сәгать җидедә үк башланды. Дөрес, торуы бик авырга туры килде. Кичәге сугыш. Аннан соң юньләп йокламау. Таң алдыннан гына бераз керфек кагып алу. Торганда да, юлда эшкә барганда да үзләре аракыны сүктеләр. Дөнья бутаучы, илне ярлыландыручы, кешене эт көненә калдыручы бер зәккум бар: ул да булса — аракы, имеш. Бу яктан караганда, аракы шайтаннан да яман, янәсе. Адәм баласының шуны аңлау дәрәҗәсенә күтәрелүе шәп, билгеле. Ә бит, уйлап карасаң, һич тә аракы гаепле түгел. Куй син аны шүрлегеңдәге иң мәртәбәле урынга менгезеп. Әгәр алмасаң, шунда мең ел буе мөлдерәп утыра бит ул, бахыр. Һич тими ул аракы кешегә. Ә кеше хаслаша аракыга. Менә моны аңлау дәрәҗәсенә кайчан күтәрелер адәм баласы? Зимагурларның эчкәнлеге мәгълүм инде. Моны ишетеп белә иде Галимҗан. Хәзер үз күзе белән күрде. Күрде генә түгел, үзен дә чөмерергә мәҗбүр иттеләр. Хәзер аның каны зимагур канына катышып акты.

Ә инде сугыш бер дә юктан купкан икән. Имештер, бер татар егете урыска "Иван" дип дәшкән. Чынында исә исеме Иван икән ләбаса. Ә аңа Иван Федорович дип әйтергә кирәк булган. Урыс халкы үзенә татарның тәлинкә тотуын һәрвакыт тели. Әмма татар үз тәлинкәсенә урыс төкерегә төшүне һич тә хуп күрми. Шулай итеп, "Иван" дигән сүз милли мәсьәлә күгенә күтәрелә. Шуннан китә сугыш. Эчкән кеше аны-моны аслан уйлап тормый бит...

... Эш башта сүлпән барды. Чөнки Галимҗандагы авырлыкны барысы да кичерә иче. Кичә сугышның каты булуы ярасы тәндә генә түгел, йөрәкләрдә дә калыр әле. Маңгае тишелгән, кулы каерылган, борыны җимерелгәннәр дә бар. Бүреләр арасына эләккән сарыктай тойды Галимҗан үзен. Кемнәр чанасына утырды ул? Бу чана аны нинди упкында төшереп калдырыр?..

Сүлпән башланган эш бик тиз кызып китте. Ат җигелгән вагонеткалар килеп кенә тора. Вагонеткаларда — руда. Шуларны завод амбарына бушатып торырга кирәк. Руда бик авыр. Аның укмашканнарын кул белән, вакларын көрәк белән бушатасың. Берничә кеше бүлешеп эшлиләр икән. Галимҗан Сәрвәретдин белән туры килде. Бер укмашкан руда кулыннан төшеп киткән иде, теге:..

*Зәккум — җәһәннәмдәге агулы агач, җимеше үтергеч ачы, зәһәр, имеш.

— И син, ажкорсак, йоклап киттеңме әллә, пунимаешь, — дип бакырды. Тора-бара ул, “ажкорсак”тан “ачкорсак”ка әйләнде. Башкалар да аңа шулай дип эндәшә башлады. Җизен эретеп алгач, өелеп-өелеп шлак ага икән. Ат булмаганда аларын бер тәгәрмәчле кул арбасы — тачка белән ташыйлар. Бүген, гөнаһ шомлыгына каршы, нәкъ шундый көн туры килде. Бер урында тар гына такта аша үтәләр. Аз гына йомшаклык күрсәттең, арттагы кешенең тачка тәгәрмәче, зәһәрле еландай, үкчәңне кимерергә тотына. Шуңа күрә син, кара тиргә батып, үкчәңне өтеп алудан курка-курка, тиеңне аркылы тешләгән хәлдә, җан-фәрманга атлыйсың. Артыңнан Сәрвәретдин туры килсә, юри ахмактай кылана:

— Һай, син, ачкорсак, тачка тәгәрмәче үкчәңне җимерә бит хәзер, — дип мыскыл итә. Аны юкка гына “зобани” дип атамаганнар икән. Газап фәрештәсе бит ул зобани. Тәмуг утын дөрләтеп торучы.

Галимҗан бирешмәскә тырыша. Вакыт-вакыт бөтен тәне изелә, ике күзеннән утлар чәчрәп чыккандай тоела. Ә башта тик бер уй кайнаша — түзәргә. Шулай да сынатты ул үзен. Бер барганда “зобани” “ачкорсак”ны әйтеп кычкырып җибәргәч, башы әйләнеп, ачуы табан астына җитте; кинәт өзелгән скрипка кылы шикелле, нерв җепселләре шартлагандай тоелды; кулыннан тачка тоткычлары ычкынып китеп, үзе пычракка барып капланды. Аны күтәреп алдылар. Әле тегендә, әле монда эш оештырып, арт ягына ут терткән кешедәй чабулап йөргән Нурислам моны күреп, йөгереп килде. Ул “зобани”ның мыскыллы сүзләрен ишетеп йөргән иде. Егылу бәласен шуннан күрде.

— Телеңне тыясыңмы, юкмы, Сәрвәретдин, әгәр бик озынайтсаң, кисеп алырга да күп сорамабыз, — дип, йодрык күрсәтте ул. Бераз ярсып торгач, янә өстәп куйды. — Үзең кем идең, беренче көннәрдә әллә шулай интекмәдеңме?

Сәрвәр эндәшмәде. Бераз йомшый төште. Галимҗан исә Нурисламның матур күңелле генә түгел, каты куллы икәнлеген дә аңлап алды.

Авыр хезмәткә багышланган бер көн әнә шулай үтеп китте. Галимҗан нык арыды. Җеп өзәрлек тә хәле калмады аның. Монда килгәненә үкенеп тә куйды. “Казакъ кызы” романын язасы бар. “Яз башы”, “Сөю-сәгадәт”, “Дингездә” исемле хикәяләр йөри башта. “Татар хатыны ниләр күрми?” повесте дә тынгы бирми. Кайчан язасың аларны? Кайда? Ни өчен килде бирегә? Фәкать акча эшләргәме? Әмма акча эшченең ертык кесәсендә озак тормый икән шул. Урысларны күргәч, шатланып куйган иде ул. Янәсе, алардан урысчага өйрәнә. Ләкин урыс дигәне монда үз телен дә юньләп белми икән бит. Сүгенергә шәпләр, әлбәттә. Әйтерсең, шуның өчен генә махсус уку йорты бетереп чыкканнар. Аларның шакшы сүзеннән баш әйләнә, җан телгәләнә.

* * *

Аларны кичәге салкын, караңгы, котсыз барак каршы алды. Зимагурлар кичә җиң сызганып эчсәләр, бүген баш төзәтер өчен янә “ак башлар”ны кыстырып кайттылар.

Галимҗан Башлыктан сорарга мәҗбүр булды:

— Нурислам абзый, сез нигә болай җыйнаулашып эчүгә юл куясыз соң?

— Минем кул астында алар бик шашына алмый иделәр. Кичә әллә нигә шәйләмирәк калдым. Берәмләп, кайдадыр эчсәләр, аларның тиз арада юлдан язулары бар.

— Эчүне бөтенләй тыеп булмыйммы?

— Ул кире генә тәэсир итәчәк. Бик авыр язмышлы кешеләр бар монда, туганкай! Язмыш шаяра адәм балалары белән. Без, күрәсең, язмыш алдында көчсез әле.

## V

"Без язмыш алдында көчсез әле..."

Нурислам абзыйның бу сүзләре нык уйланырга мәҗбүр итте Галимҗанны. Нәрсә ул язмыш? "Язмыштан узмыш юк", диләр. Язмыш, имеш, галәмнәр раббысы тарафыннан индерелә. Ул синең маңгаеңа ана карынында чакта ук сугылып куелган икән. Кеше язмышының йолдызларга бәйле булуы турында әйтәләр.

Йолдызлар! Алар бит куе караңгылыкта бигрәк тә якты була. Һәммәсе сиңа мөкиббән яратып, сөеп, иркәләп карый төсле. Кайсысы синеке? Менә шуны беләсе иде. Анысы нурын сиңа артыграк та сибәдер әле. Шул нурлар индерәме йөрәгенә язмыш төшен? Бу төш эчендә янә гәүһәр бармы? Гәүһәр бөтен бәдәнеңә яшәү мәгънәсе булып кәрәзләнәме? Нигә йолдыз караңгылыкта яктырак яна? Кара тормышта да бәндәнең йөзе ак булуын телиме? Эчеңдә йөретмә, аны башкаларга йоктыруың бар, дип әйтәме? Әгәр йолдыз адәм балаларына карата шундый хәерхаһта икән, кайдан вә ничек барлыкка килә соң ул аларның кара эчләре? Йолдыз бит кара нур сипми. Әллә теге тәненә, җанына кәрәзләнгән ак гәүһәр илаһилыгын саклый белмиме бәгъзе берәү? Тора-бара ул карага әвереләме?

Язмыш ул бөтен тән күзәнәкләренә, йөрәгенә, рухыңа сеңгән. Шуларның җәмгысы тора-бара маңгайга күчеп бетәдер, бәлки. Чөнки маңгайга карап та кемнең кем икәнлеге билгеләнә бит. Әтисе Гыйрфан мулла Галимҗан тугач беренче күрүдә үк әйткән иҗ: "Әһә, киң вә текә маңгайлы, иншаллаһ, башлы, зиһенле булыр", — дигән. Бәгъзе бервакыт горурлык катыш мөкиббәнлек белән: "Таш маңгаем", — дип сөя иде бит. Монысы, билгеле, балдай татлы бала чагында. Үсә килә арага боз төшәлде. Ул боз акрынлап зурая барып, хәзер инде тау булып өелде. "Галия"дән киткәч, берәр авылда йә мулла, йә мөәзин булып торырга өндәде. Маңгаена, бәлки, шулай язылгандыр, ләкин моңа ризалашмаячак анын таш маңгае. Моны аңламады инде карт ата күңеле. Троицк мәдрәсәсендә үзе атаклы мөдәррис булган бит. Дан тоткан. Галимҗан бәләкәй чакта да заманына күрә гаҗәп алдынгы карашлы иде. Кешеләрне укырга өндәде. Акыллы башларның: "Кытайга барып булса да гыйлем ал", —дигәнен әйтергә ярата иде. Ә үзе баш-аягы белән җир эшенә чумды. Ярый, монысы — шәп. Оста игенче әһеле була алу үзе зур бөеклек! Бу хакта да борынгы бабакайлар күп әйткән. Ләкин Галимҗанны аңламавы шәп түгел. Ул инде "таш маңгай", "текә маңгай" кебекләрне беркайчан да әйтмәячәк. Аныңча, зур маңгайда хәзер язмыш гәүһәре түгел, язмыш кырлыгы тырпаеп тора. "Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы" дигән хикәясен укыгач, отыры котырынып китте ул. "Үзеңне фаш итәсең, җебегән", — дип җенләнде. Хәзер инде аннан бөтенләй баш тартты. Бер ел эчендә атасына алты хат язды. Галимҗанга әлеге боз тавын эретергә кирәк иде. Эремәде боз тавы — һаман зурая гына барды. Безне капчыкта саклап булмау галәмәтенең бер хикмәте шушыдыр инде. Ялчы хезмәтен үтәгән олы колаклар Галимҗанның кара эш белән шөгыльләнүен Солтанморат халкына житкергән. Авылда урамавызлар күп була. Колактан-колакка чыш-пыш сүзләр әйтелә, тел очларыннан ул чыш-пыш гайбәт галәмәте булып чәчри дә Гыйрфан мулланың да өй түренә менеп кунаклый. Акылыннан шаша Гыйрфан мулла. Үрле-кырлы килә. Башы җәпкә бәрелгән кемсә шикелле үрсәләнә. "Зиһене буенча фикер йөреткәндә, пәйгамбәр дәрәҗәсенә күтәрерлек мөмтазы бар иде лабаса! Әгәр алай ук түгел икән, булсын пәйгамбәрнең хәлифәсе. Ягъни дә мәсәлән, пәйгамбәрнең рухын таратсын. Юк! Юк! Булмады. Таш маңгай түгел ул — чүпрәк маңгай. Менә кем!"

Хәләл җефете Хәсәнә абыстайга бу хакта мең кәррә әйтте. Галимҗанның да, әнисенең дә тетмәсен тетте. Ахыр чиктә Галимҗанның "бозылып китү" сәбәбен остабикәсенең йомшак табигатьле булуына китереп япсарды. Ул, имеш, артык иркәләгән аны.

Хәсәнә абыстай ир белән хатынның бала өчен тарткалашуын яхшы белә. Баланың бер гаебе чыкса, ир — хатынын, хатын ирне гаепли. Бу — элек-электән килгән бер гадәт. Мондый чакта тел кайтармый Хәсәнә абыстай. Сабыр төбе — сары алтын, дигән иманына тугрылыклы булып кала. Шулай да Галимҗанга йөрәк әрнүләрен белдергән хатны язмый калмады ул.

*"И улым, Галимҗаным, күз нурым, йөрәк парәм, әтиең бик тузына, соңгы вакытта чамадан ашып китте бөтенләй, синең өчен мине битәрли, күземне дә ачырмый. Мин бик гаҗизмен, сөеклем, бик аптыраштамын. Ни кылырга да белмим хәзер. Бу чынмы? Син кара эштәме? Зимагурлар белән аракы эчеп, тәмәке тартып йөрисеңме? Шундый хәбәрләр килде бит монда. Бөтен авыл халкы "аh" итте. Яхшыдан яман туган, дип сүгәләр үзеңне..."*

Бу хатны укыгач, озак уйланды Галимҗан. Ничек итеп җавап язарга? Акыллы, эшчән, җегәрле, шәфкатьле әнисен нинди сүзләр белән юатырга? Алдашыргамы? Алдашу — гөнаһның иң зурысы, диләр бит. Алдашу гөнаh кына түгел, кешелексезлек тә. Алдашу, ахыр чиктә, адәм баласын хаинлек сазлыгына китереп батыра. Галимҗан фәкать дөресен язарга булды. "Ак"мы, "кара"мы — эшнең гаебе юк. Оренбурдагы Вәли мулла мәдрәсәсендә бүлмәдәше Шәhит Әхмәдиев әйткәнчә, ул бит урлашып түгел, хәләл көче белән таба акчаны. Моның өчен аны гаепләргә берәүнең дә хакы юк.

Әлбәттә, "кара эш" дигәне ифрат авыр икән. Дөрес, ул әле шушы яшенәчә дә "ак кул", "ак сөяк" булып яшәмәде. Мәдрәсәдә бит уку язгы кыр эшләре башланганчы ук бетә. Һаман шулай китап тузаны эчеп тынчу бүлмәләрдә бурсып ятмасыннар — кайтып, әти-әниләренә хезмәт итсеннәр. Ә инде уку кыр эшләре беткәч башлана. Галимҗан hәр җәйдә бу форсаттан тулы файдаланырга тырышты. Аның ике файдасы бар. Беренчесе — ата-анага ярдәм итү. Икенчесе — җисмәни яктан hаман ныгый бару. Шуларга бәйле рәвештә рухи дөньяң да байый. Билгеле, крәстиән эше дә җиңел түгел. Язгы чәчү, урак өсте вакытларында әтисе күз йомарга да ирек бирми. Кара таңнан күз бәйләгәнгә чаклы эшләтә. Шулай да анда рәхәт. Таң җилләре иркәли сине. Иртәнге кояш нурлары тула куеныңа. Яз көне яшь үләннәрдән, чәчәкләрдән, уҗымнардан килгән тәмле ис белән хозурланасың. Җәй көне колач җәеп печән чабуларда да үзенчә бер хезмәт шигърияте бар. Көзге эшләрне әйтәсе дә юк. Урак уру, көлтә бәйләү, кибән кую... Бу мәлдә инде син иген исенә исереп йөрисең. Янә шунысы бар. Бик арып китсәң, тотасың да җиргә ятып ауныйсың. Җир-ана сине шәфкатьле куллары белән иркәләп сыпыргач, бөтен алҗыганың бетә дә китә. Син әле кичен йә күлдә, йә елгада коену бәхетенә ирешәсең. Су бөтен арыганыңны үзендә алып кала. Кулалмаш эшләү дигәне дә бар бит әле аның. Башта береннекен бетерәсең, аннан — икенченнекен. Күмәк эш көнләшеп эшләтә. Анда инде, җан кисәгем, адәм ыстырамы буласы, сынатасы килми. Анда уен-көлке дә җитәрлек була. Җырлап та җибәрәләр. Ә кичен күңел ачу үзе бер бәйрәмгә әйләнә. Монда инде тәкә ите белән сыйлану, әйрән эчү, кымыз эчүләр сагынып сөйләргә генә кала. Төнлә болында ат карау, учак ягып, чикмәнле бәрәңге пешереп ашау, кырын ятып, әкият сөйләүләр. Син инде бар булмышың белән табигать баласына әвереләсең.

Табигать баласы! Табигать баласы!! Бәй, шундый хикәя язганда ничек булыр икән, ә?

Уйлар! Уйлар!! Уйлар!!! Кайчак алар шулкадәр күбәя, ә кәгазьгә төшерергә вакыт юк. Башта Галимҗан мондагы авыр эшне күтәрә алмас кебек иде. Кайбер көнне үндүртәр сәгать эшләтәләр. Син инде телеңне аркылы тешләп, аягыңны көчкә сөйрәп кайтасың. Тәнең изелгән була. Ул менә-менә таралып төшәр кебек. Яңакларың эчкә бата. Күз төпләреңә кадәр сызлый. Башта гына шулай авыр булыр, күнеккәч җиңеләер әле, дип уйлады Галимҗан. Ләкин ул ялгышты. Эшче мескен эчәргә мәҗбүр

була. Аракы арыганны бетерә кебек. Ләкин ул вакытлыча. Иртән тән янадан каткан була. Башың чатнап авырта. Эш башлагач инде янадан язылып китәсең. Нурислам Галимҗанның сөяккә калып ябыкканын, авыр тын алганлыгын, бетеп барганлыгын сизеп йөри.

— Башта шулайрак була инде, тора-бара күнегерсең әле, — дип юатып та карый. Сүзнең тәэсире көчле, әлбәттә. Ләкин ул да авыруны вакытлыча баскан дару кебек кенә. Галимҗан тагын да нык ютәлли башлады. Бала чакта ук алынган үпкә чире янадан баш калкыта. Урал бабай, әллә кешеләр бозыла башлауга үчләшеп, үз тирәсендәге кышны быел бигрәк суык итте. Карны ифрат мул бирде. Кая карама — кар тавы. Коточкыч япма бураннар, җилекләргә үтеп искән салкын җилләр телә бәгырьне. Бәгъзе бер көнне бары да тына: җил дә исми, буран да шашынмый. Әмма коры суык өтә жаныңны. Шәйләми барсаң — бит очларын туңа, шундый салкын көннәрнең берсендә Галимҗанны юлда ютәле тотты. Бер төркем иптәшләре аны калдырып китте. Озак ютәлләде ул. Аннан кан төкерде. Менә шул кан аны баракташ дусларыннан да аерды. Арттан Сәрвәретдин килә икән. Ап-ак кар өстендә Галимҗан калдырган кан-төкрекне күреп, хәйран кала ул. Аның авызы тишек иләк белән бер. Сүз тота торган түгел.

— Әйтәм буылып-буылып ютәлли, чихут икән ләбаса бу "ачкорсак", понимаешь, — дип, әле берсенең, әле икенчесенең колагына пышылдады. Шуннан Галимҗанның "ачкорсак" кушаматы янына "чихут" дигәнен дә сылап куйдылар. Беренчесе аны гарьләндерми. Чөнки корсакның ачлыгы — тормыш хакыйкате. Ачлык, туйганчы ашамау — илгә килгән уртак кайгы. Бергәләп күтәргән кайгы ул кадәр авыр булмый. Ә "чихут" кушаматы — куркыныч. Әллә ничә тапкыр бәхетсезлек китерде бит инде ул аңа. Оренбурдагы "Хөсәения" мәдрәсәсендә табиб алдында буылып ютәлләп кан косты. Абыйсы Шакирҗан үтте. Ә Галимҗанны, "чихут", дип, алмадылар. 1906 елда Уфадагы "Галия" мәдрәсәсенә килгәч, әтисенең яшьлек дусты Габдрахман хажи йортының бер зур, якты, җылы бүлмәсендә хан малаедай ирәеп кенә яшәргә тиеш иде. Бүлмәсе әле аның мулла баласымын дип һаваланып йөрмәгән Галимҗан өчен ул кадәр зур хаҗәт тә булмасын, ди. Бүлмә аша гына яшәгән алмадай чибәр Алмабикә — аның өчен иң кыйммәте. Сүз дә кирәкми. Күз карашлары аңлатты гашыйклыкның җитдилеген. Сәгатьләр буе сөйләшеп тә сүзләре бетми иде. Әлеге дә баягы шул каһәр төшкән бума ютәл харап итте эшне. Беркөн пар күгәрчендәй матур гына гөрләшеп-сөйләшеп утырганда котырды имансыз ютәле. Аптырагач, йөгереп тышка чыгып китте Галимҗан. Шуннан соң үзгәрде карашы Алмабикәнең. Моңа чаклы куенына атылып керергә әзер тора кебек иде. Ә шул хәлдән соң салкынайды да куйды элекке кайнар карашы. Дөрес, Алмабикә аны сиздермәскә тырышты. Һаман шулай Галимҗан абый, дип, өтәләнеп тора иде. Әмма бу сүзләр, элекке кебек, йөрәктән алып әйтелми иде шул инде. Кайнар мөнәсәбәткә салкын тын өрде шайтан. Моны әтисенә, әнисенә дә житкерде шикелле. Элек бер генә тәмле аштан да калдырмыйлар иде аны. Хәзер анысы да сирәгәйде. Тора-бара бөтенләй бетте. Болай да сизгер күңелле Галимҗанга аларның элекке җылы карашларына салкын кырау төшкәнлекне аңлау кыен түгел иде. Ул аннан китәргә мәҗбүр булды. Шәһәр читендәрәк сиксән яшьлек бер әби яши икән. Үзе дә кәкшәнләп беткән, өе дә җиргә иңгән. Әби сөйләвенчә, заманында ул ару гына йорт булган. Ике бүлмәле. Ире Гутман заводында авария вакытында үлгән. Кырык яшьтә. Балалары икәү генә булган. Кызын — тиф, улын бизгәк чире алып киткән мәңгелек дөньясына. Әби үзен-үзе кул эшләре белән шөгыльләнеп караган. Вак-төяк белән дә сату итә икән. Хәзер, билгеле, алардан да ваз кичкән. Бер бүлмәсе әле зур гына. Аңа өч кеше керткән. Берсе — бәләкәй. Анысында кеше бөтенләй тормый икән. Әби аны әллә нинди иске-москы әйберләре, кием-салым, аягы-фәләне сынган өстәл, урындык, караватъ, тагы да әллә нәрсәләр белән тутырган. Галимҗанга аерым бүлмә

кирәк. Ул инде әллә кайлардан эзләп, әллә күпме фатирлар тапты. Ләкин яхшылары бик кыйммәт. Әби күп сорамады. Чөнки аның бүлмә дип әйтерлек җире дә юк иде инде. Бик тар ул. Караваг, өстәл куйсаң, йөрер урын да калмас кебек.

— Бик чибәр егет күренәсен, синең өчен бер дә муафыйк түгел бит әле бу, улым, әллә икенче бер җирдән эзләп карыйсыңмы сон? — дип сөйләнгән иде әби, Галимҗан кулын гына селекте.

— Бүлмә минем кесәмә тап-таман, әбекәем, — дип шаяртты ул.

Галимҗан эшкә керешге. Ишегалдында янә бер тавык кетәге зурлык кына сарай кебек нәмәстәкәй бар икән. Артык әйберләрне шунда ташыды. Кайберләрен өйалдындагы почмакка да урнаштырды. Агач караватның ике аягы да сынык булып чыкты. Аяклар урынына ике бүкән китереп куйды. Өстәлнең дә бер аягы бөтенләй юк, икенчесе зәгыйфь икән. Аны рәтләп тә батты кара тиргә. Әтисенең остаханәсендә Шакирҗан абыйсы белән дә, бәгъзе бервакыт үзе генә дә нидер әтмәлләп маташа иде ул. Бер җәйдә бәләкәй чүкеч, балта, пычкы тотып өйрәнгән кул менә кайчан кирәк булды. Рәхмәт яусын атасына. Өйрәткән. Әби исә Галимҗанның эшенә, хәрәкәтенә сокланып бетә алмады.

— И генәм лә, зур гына ызба иде лә бу, тора-бара ул да картайды, тарайды, бөрешге, бөкрәйгән карчыкка охшап калды. Ызба да, месткенкәем, кеше шикелле икән. Үземне әйтәм әле, ифратлар гына да зифа буйлы, чибәр, көр идем, чүктем хәзер, беттем, карга күтәреп алып китәрлек булып калдым, — дип сөйләнеп йөрде.

Көннәрдән бер көнне Алмабикә килеп керде шунда. Озак карашып торды алар. Галимҗанны бер нәрсә гаҗәпләндерде. Ни булды? Нигә килгән? Нәрсә кирәк ана? Алмабикәнең дә сораулары күп иде. Шундый затлы, бай нәселдән килгән чибәр егет нишләп әле мондый карга оясында яшәп ята? Авыру өстенә авыру алмасын бу? Нигә шәкертләр белән бергә тормый? Әллә кеше яратмыймы? Төрле сораулы карашлар ташланып, сүз башларга җай тапмыйча ык-мык килеп торганнан соң, бермәлдә, ниһаять, икесенең дә телләре ачылды:

— Сез мин килгәнгә гаҗәпсенәсез инде, шулай бит, Галимҗан абый?

— Яшермим.

— Әти сезне эзләп табарга кушты.

— Димәк, күңелегез белән килмәдегез, Алмабикә?

— Алай ук түгел, Галимҗан абый. Мин сезне сагынам.

— Монысы өчен рәхмәт, Алмабикә!

— Күпме серләр алыштык.

— Ә мине ничек таптыгыз соң?

— Мин "Галия"дә булдым. Кайда торганлыгыгызны шәриктәшләрегез әйтте.

— Бирегә алар да килеп йөри. Дус булганнары, әлбәттә.

— Сез нигә бу кадәр дә алама бүлмәдә яшисез, Галимҗан абый?

— Мине бай тормыш кызыксындырмый, Алмабикә.

— Димәк, иҗат корбанына ныклап әверелдегез?

— Анысы да бар. Шәкертләр арасында укып та, язып та булмый. Анда даими рәвештә шау-шу, бәхәс, хәтта якалашу да була.

— Ә нигә бездән киттегез?

— Сезне мәшәкатьлисем килмәде.

— Сезнең әтиегез минем әтигә күп изгелекләр кылган.

— Шуның рәхмәте өчен миңа матур тормыш тәкъдим итәсезме?

— Бәйрәм ашы кара-каршы, диләр бит.

— Ә менә мин сезне ничек бәйрәм иттерим икән соң әле?

— Сезне күрү минем өчен үзе зур бәйрәм!

— Аһ, бу сүзләр йөрәк маемны эретеп җибәрде.

— Эреп ага күрмәсен, Галимҗан абый, сак булыгыз.

Алар көлешеп алды. Сөйләшү тора-бара шаян сүзләр катнашлыгында

дәвам итте. Галимҗан өстәлдә таралып яткан китапларын рәтләштергәләгәндәй итте, кунак барда җыйнакланырга кирәк, янәсе. Шуннан ул кунак кызына утырырга кәкшәнләп торган урындык тәкъдим итте. Үзе һаман көлеп сөйләште:

— Авырлыгыңны бик салырга тырышма инде, Алмабикә җаным, бу утыргычның таралып төшүе бар.

— Һай, Галимҗан абый, тарала башласа, кочагыңа алырсың.

— Синең ише пешкән алманы кочаклаудан баш тарткан егетнең эчендә җаны булмас.

Алар "сез"дән "син"гә күчкәнлекләрен сизми дә калдылар. "Син" алмашлыгы хис-тойгылар якынлыгына ялкын өстәп җибәрде. Алмабикә утыргычка утыргандай итте дә "аһ" дип кычкырып куйды. Егылып китә, янәсе. Бу мизгел Алмабикәнең Галимҗан кочагына сыенуга сәбәпче булды. Галимҗан аны егылып китүдән саклый, имеш. Алмабикә әлеге кочакка атылу турында әйткән вәгъдәсен үти, янәсе. Форсаттан файдаланып, алар нык кына кысышып алды. Хәтта кайнар иреннәр бер-берсенә якынлашты. Шулай да үбешү булмады. Кыз бала җаныңны кыздырыр, ди. Җаны кызды Галимҗанның. Алмабикә аңа караганда да кызу иде. Кыз кызуы — куз кызуы, диләр. Кызлар күңеле — кызган казан, дигәне дә бар. Кызның күңел казанында ялкын кайнаганны боз йөрәк тә сизәрлек. Энә очында бии торган чагы бөтенләй үк үтеп китмәгән шул әле Алмабикәнең. Тик Галимҗанның аны биетәсе килми. Сабырлык кирәк. Аңа өйләнергә ерак әле. Казан университетында укыйсы бар әле аның. Кыз күңеле белән уйнау — зур гөнаһ. Нигә ярсу мизгелдән усал файдаланырга? Кыз күңелендәге кайнар кузны суыту яхшырак булмасмы? Галимҗан сүзне хис-тойгылардан ераккарак алып китәргә тырышты. Китаплар дөньясына алып кереп китте кызның күңелен. Тик Алмабикәнең шашкын йөрәгендә "китап" сүзләре өчен аз гына да урын юк иде. Шуңа күрә аларның сөйләшүенә "ык-мык" ымлыгы, "ул-бу" алмашлыгы килеп кысыла башлады. Ахыр чиктә сүзнең яме китте. Кыз килүенең максатын әтисе йомышына япсарды. Аның әйтүенчә, бер фикерләшеп утырганда, Галимҗан Коръәнне татарчага әйләндерүдә шактый мөмтазлык күрсәткән. Тагын да киңәшләре бар икән. Сөйләшү өчен үз янына чакырган. Чынмы, түгелме — бу кадәресе аңа караңгы әле. Кыз авызында — кызыл тел, диләр бит. Кызыл тел ни сайрамас?..

... Шулай да барды Галимҗан Габдрахман хаҗиларга. Габдрахман хаҗи "Нәрсә ул Коръән?" дигән сорауга җавап эзли икән. Җавабын тапкан. Тик татарчага дөрес тәрҗемә иткәнме, юкмы — шуңа икеләнеп иза чигә икән. Галимҗан аны тиз аңлатты: "Коръән илаһи диннәрнең иң соңгысы булган мөселманнарның — ислам диненең бәхетле китабыдыр. Коръән һәр кабилә яки бер милләткә генә түгел, ә бәлки бөтен кешелек дөньясына мөрәҗәгать итә. Коръәндә әйтелгәнчә, ислам дине (мөселманлык) кешелек белән бергә туган дин ул. Аллаһының бар иткәне — дин тойгысы. Барлык кешеләр дә Аллаһы Тәгалә тарафыннан бу тойгы белән бар ителгәннәр".

Габдрахман хаҗи үтә гаҗиз булып:

— Бәрәкаллаһ, пәйгамбәрләр башы бар икән ләбаса үзендә, — дип, Галимҗанның зиһененә шаккатты.

Аннан соң Коръәннең халыкка ни рәвешле индерелүе турында сорашты Габдрахман хаҗи. Бу очракта да гарәпчәсен укып тормады Галимҗан. Татарчасын әйтеп салды: "Аллаһы Тәгалә хәзрәтләре фәрештәләрнең олугларыннан Җабраил галәйһиссәлам аша әмерләрен һәм сүзләрен пәйгамбәребезгә белдерде. Димәк, Коръән пәйгамбәребезнең Җабраил ярдәме белән Аллаһы тәгаләдән алган әмерләре һәм илһамларыдыр".

Шушы сөйләшүдән соң Габдрахман хаҗи Галимҗанның әтисе Гыйрфан муллага хат язды. Улының ифрат дәрәҗәдә мәгълүматлы, зиһенле, бәһаләп бетергесез акыллы булуы турында хәбәр итте. Ә инде Галимҗанның: "Коръән Алладанмы, түгелме?" дигән хезмәткә тотынуы нәкъ менә

шушы мәсьәләләрне ачыклау өчен иде. Чөнки Коръәннең кайдан килеп чыгуын, кем тарафыннан язылуын, аның теле нинди икәнлеген шактый белемле кешеләр дә ярып кына әйтә алмый. Ул, үзенчә, мөкатдәс эш башкарырга тырышты. Әмма моның өчен аны "Галия" мәдрәсәсеннән кудылар.

Хәзер инде ул Урал бабай канатының бер кауные булган Миас каласында яшәп ята.

## VI

Галимҗан барактан китәргә мәҗбүр булды. Эшчеләр, билгеле, гади, эчкерсез, киң күңелле, олы йөрәкле халык. Беркөнне эчеп сугышсалар, икенче көнне татулашып алалар. Кинә тоту, ачу саклау, керле күңеллелек юк аларда. Әлбәттә, бармаклар да тигез булмаган кебек, һәркемнең үзенә генә хас холык-фигыле бар. Кушаматлары да шуңа җайлаштырып сайланган. Әнә бит, Сәрвәретдин теләсә кемгә әтәчләнергә ярата. "Зобани" дигән кушаматны аңа шуның өчен сагыз урынына сылаганнар. Кыска буйлы, җирән урыс егете Иван бервакыт — яз көне — ашханә тирәсеннән сөяк-саяк җыеп йөри икән. "Зимагур белән тавык тибенеп тамак туйдыра", дип тә сөйләнәләр. "Шакал" дигән кушамат аңа шуннан соң чәпәлгән. Чепек күзле чуваш Степанга җеназа вакытында буталып йөргәне өчен ябыштырыла "Мәет козгыны" дигән атама. "Ала карга" дигәне аңгыралылык белән бәйле. "Күлмәк тишек, бүрек тишек, ыштан белән дүрт тишек", дип көлдерергә ярата Сәхи. Шуннан аны "Төпсез ыштан" дип йөретә башладылар. Бервакыт Шәйхине котырган эт талаган. "Хәерче" дигән мөһерне аның маңгаена шуннан соң сугалар.

Алар бер-берсенә күп очракта әнә шул кушаматлары буенча эндәшә. Әмма үпкәләш юк. Чөнки андый "койрык" һәрберсендә бар. Ул йә тескә-биткә, йә буйга, йә эчке дөньяга, йә холык-фигыленә карап бирелгән. Галимҗан "Аждаһакорсак", "ажкорсак" дигәннәрен авыр кичерде. Шулар "ачкорсак"ка әйләнгәч — рәнҗү бетте. Карын — ач. Бу — чын. Чынга — хөкем юк. Туйганчы ашап, кикереп йөрер идең — кесәңдә сырт җилләре уйнаячак. Ә менә "чихут" тамгасы Галимҗанның күңелен нык китте. Дөрес, аны аңа бер мәртәбә "Зобани" гына әйтте. Моны белгәч, аның кикригенә нык сукты Нурислам.

— Тагын бер ишетсәм, сузып салып, каеш белән җыйнаулашып каезлыйбыз үзеңне, Сәрвәретдин! — диде.

Галимҗан барыбер сизде кайберәүләрнең бу чиреннән шикләнүен. Моның өчен генә дә китмәде ул барактан. Эшчеләр даими эчә. Тарталар. Барак эчендәге төтен, кем әйтмешли, балта элеп куярлык була. Сүгенү, ыңгырашу, пычрак телләр яралый йөрәкне. Әшәке сүзләр бизгәге, акрынлап, Галимҗанның үзенә дә йокты. Ачуын китереп, җенен кузгатсалар, "Зобани" кебекләрнең ипи шүрлегенә берәгәйле сүз белән менеп төшә. Аерым фатирга кучүнең икенче хикмәте дә бар: иҗат итәргә кирәк. "Казакъ кызы" романы күңел сәхифәләренә һаман языла бара. Шуны кәгазьгә төшерергә кирәк. Ә вакыт юк. Урын да юк.

Фатир табу тәҗрибәсе анда көчле хәзер. Ул зур, биек, чибәр йортларны сайламас. Алар Галимҗан өчен тыштан ялтыраган, эчтән калтыраган кеше кебек. Шәһәр читендә бер балчык йорт елмаеп каршы алды аны. Эченә керсә, ни күзе белән күрсен, Нәгыймә әбигә охшаган сиксән яшьләр чамасы бер карчык моңаеп утыра. Күрешү, исәнләшү, танышу әллә ни күп вакыт алмады. Галимҗан, сүзләрне җилем урынына сузмастан, иң кирәген генә ярып салды — ул фатир эзли. Уфадагысы — Нәгыймә булса, монысы — Нина икән. Карт марҗадан күпне өмет итү килешмәс. Шулай да урысча сайрашу өчен телен һаман чарлаячак әле. Аерым бүлмәсе бар. Нәкъ Нәгыймә әбинеке кебек иңе. Җиткән. Баштан ашкан.

Мәгәр шәп әби булып чыкты бу карт марҗа. Нәгыймә әбинекенә

караганда ярты гына хак сорады. Шулай да Галимҗан кыш буе берни дә язалмады диярлек. Авыр эш аны һаман яньчеде, изде, корытты. Үпкәсен чир кимерде. Озын, салкын, буранлы кышлар үтеп, җылы яз килгәндә инде ул бик нык ябыккан, балык сөяге кебек булып калган иде.

Бушка үткән бу кыш өчен Галимҗанның җаны өзгәләнде. Ул үзен мәсләксез яшәүдә гаепләп маташты. Казакъ даласыннан туп-туры Казанга китәргә кирәк булган. Анда Фатыйх Әмирхан, Габдулла Тукай, Галиәсгар Камал кебек әдәбият йолдызлары калыкты. Нигә шул йолдызлар нуры эчендә кайнашмаска? Дөрес, ул йолдызларның нуры Урал буе шәһәрләрен дә яктырта. Әлбәттә, Казанда көчле көрәш бара. Аның беренче хикәясе басылган "Әльислах"ны яптылар. Хәзер "Йолдыз" балкымакта. Ул мөмкин кадәр барысын да таба, укый. Хәзер инде әдәбиятны сәнгать бизмәненә салып үлчәү кадәресе дә нык кызыксындыра аны. Бизмәннең бер ягында — зәвыклы әсәрләр, икенче ягында — пешмәгән икмәкне хәтерләтә торган чеп-чи нәрсәкәйләр. Үлчәгәндә кайсысы авыр тартыр? Әлбәттә, хәзергә әле — сүрән икмәкләр. Ә тәнкыйтьчеләр ул икмәкнең йөзе килсен өчен мичне кызу якмый. Татар прозасы унтугызынчы гасырның икенче яртысында ныклап тамырланды. Хәзер инде кәүсәсе бар. Кәүсә ботаклар җибәрде. Әмма ул ботаклар һаман әле ныклап яфрак яра алмады. Поэзиянын тамыры — бик еракта. Кол Галинең 1233 елда иҗат ителгән "Кыйссаи Йосыф" поэмасыннан ук килә. Ләкин сигез гасыр буена шигърият бакчасындагы чүп үләннәрне утаучы юк. Һаман әле халык кына түгел, хәтта галимнәр, зыялылар, мәгълүматлы кешеләр үзләре дә аңламаган гарәп-фарсы, борынгы төрки тел сүзләрен күп куллана. Ул сүзләр поэзия тукымасына чакырылмаган әрсез кунактай килеп кереп җайлашалар. Алар туган телне, әсәр канвасындагы зәвыкны ямьсезли. Күп нәрсә борчый Галимҗанны. Бик күп. Хәзер инде аны Казанга бару уе алгысыта. Быелгы яз да, матур кыз сыйфатына кереп, аның колагына пышылдады:

— И Галимҗан! Күп михнәт чигеп, авыр кайгы күрдең, ләкин бирешмәдең; чын ир-егет әнә шулай була; хәзер инде рәхәт-бәхет күлендә йөз. Кил Казанга — мин сине шунда көтәм!

Бу — казакъ кызы Карлыгач-Сылу иде. Аның күз алдында казакъ халкы тормышындагы низаглар, интригалар дулкыны чайкалды! Карлыгач-Сылу шул дулкыннар эчендә йөзә, шаяра, көлә. Бермизгел ул, тораташтай катып калып, булачак кәләше Калтайга йодрык күрсәтә. Бәллүдә чакта ук Карлыгач-Сылуның колагын Калтайдан тешләтәләр. Калтай кәрлә буйлы, шадра йөзле, сүз тәме белмәүче мәнсез малай булып үсә. Карлыгач-Сылу аның куенына керүне тәмуг утында януга тиңли. Аһ, илаһи мәхәббәт! Ләйлә-Мәҗнүн, Таһир-Зөһрә, Йосыф-Зөләйхалар бар ич! Нишләп соң әле бөтен дала моңын үзендә туплаган, сихерле кара күзләре белән йөрәгенә үтеп керә белгән, энҗе тешләре арасыннан сүз гәүһәре сибә алган Карлыгач-Сылу калку түшләренә маймылдай үрелүдән башканы белмәгән Калтайның сасы тынын иснәп яшәргә тиеш? Юк, мөмкин түгел бу! Бу романын укысалар, Җир йөзендәге барлык милләтләр: "Аһ, Карлыгач-Сылу... син иҗтиһатлы, син бөек, син ирек кошы, син акыл иясе", — диячәкләр. Карлыгач-Сылулар бит бер казакъ халкы тормышында гына түгел, татар, башкорт, үзбәк, уйгыр, әзербайҗан, төрекмән... халыкларында да бар. Хәзергә Галимҗанны казакъ кызы Карлыгач-Сылу язмышы борчый. Чөнки бу кыз белән ул күзгә-күз очрашты. Аның сихерле, серле, тылсымлы карашлары белән ләззәтләнде. Ул әле унбиш яшьтә генә иде. Галимҗаннан укырга-язарга өйрәнде. Аһ, ул чая карашлар! Аһ, ул аның сөеп каравы! Аһ, аның акыл җитмәс дәрәҗәдә елмаюы! Менә шушы инде Карлыгач-Сылу. Менә шушы инде дала матурлыгын, дала мәгънәсен аңлаучы кыз. Менә шул кызның тылсымлы көчен, йөрәк-гәүһәрен, гүзәллек алиһәлегең тасвирларга кирәк аңа "Казакъ кызы" романында. Димәк ки, Казанга буш кул белән түгел, "Казакъ кызы" исемле роман күтәреп барырга кирәк. Сал өстәлгә. Шаккатсыннар. Исе-акыллары китсен. Чәчләре үрә торсын.

Шуңа күрә Галимҗан, романын тәмамламый торып, Казанга кузгал-

маска булды. Җәй буе утырды. Җәйге җылы җилләр көзге салкын җилләр белән аралашты. Ә роман һаман тәмамланмады әле. Шулай да ул барыбер китәргә булды. Тик... аның ак юлына янә кара елан сузылып ятты. Елдан артык тиенләп җыйган акчасын жуликлар урлады. Ул янә бер ел кара эштә эшләргә мәҗбүр булды. Шул ниятен әйтер өчен ул Нурислам абыйсы янына баракка барды.

## VII

Аның күңеле бик тә төшенке иде. Ә эшчеләрнеке, киресенчә, гаҗәп күтәренке. Алар эчеп күңел ача. Шул аракы күпләрнең гомерен өзде, гаиләсен таркатып, балаларын фаҗига сазлыгына батырды, тормыш юлына көл сипте. Галимҗан өч изге максатның мөгезеннән алды. "Тартмаска, эчмәскә, хатын-кыз белән чуалмаска. Ул бу максатның мөгезен каты тотты. Андыйлар бер Галимҗан гына түгел. Бер-ике ел эчендә йә колынлык, йә бәләкәй өйлек акча эшләп, күлмәкнең эчке ягында теккән кесәгә яшерелгән акчасын даими рәвештә билгеле бер нәзакәтлелек белән сыйпый-сыйпый, әҗәл даруыннан да ныграк саклаган хәлдә, тизрәк авылына сыпыра ул. Шуны эшләмәсә, әлеге тәнне өзлексез кытыклап торган акча аяклана башлый. Бер аякка бастымы ул акча, канатлы тулпарга әверелеп, оча да китә. Ку син хәзер тулпар артыннан. Булмый. Аслан булмый. Үлсәң дә. Зимагур тормышы — аждаһа теле белән бер. Ялмап, суырып алса — аннан ычкынырмын димә. Шуннан ул әллә нинди җырлар дөньясына кереп бата:

Зимагурлар җәйгә чыкса,
Ун кадак ит — бер ашка;
Зимагурлар кышка керсә,
Он табалмый умачка.

Зимагурның аягында
Аршын ярым чабата,
Киндерәсен урый-урый,
Караңгы төн таң ата.

И зимагур, кайт иленә,
Илеңдә иген игәрсең;
Ыстаканыңны ат итеп,
Бутылкаңны җигәрсең...

Шуларны җырлап, шаркылдап бер көлеп җибәрә бахыркайлар. Хәзер инде ул үзен ата зимагур дип хис итә. Аның өчен — диңгез тубыктан. Бар акча бүген эчәргә — ул капрал. Юк акча — ул кикриге шиңгән әтәч. Бер ел үтә. Ике. Өч. Дүрт. Биш... Зимагур агуы йоккан мескен мәңгелек фаҗигага дучар була. Андыйлар Нурислам абзый яшәгән баракта да бар. Әле менә шулар каршы алды Галимҗанны. Күңелләре күтәренке. Әйтерсең, 1812 елгы Ватан сугышында Парижны алган солдатлар. Ачның күзе — икмәктә, ялангачның — бишмәттә, ди. Боларның уе икмәктә дә, бишмәттә дә түгел — аракыда. Аракы вакыт-вакыт ачлыкны да, бишмәтне дә оныттыра.

Галимҗанны алар аягүрә басып каршы алды. Аңа хәзер хөрмәт зур. "Аждаһакорсак", "аҗкорсак", "ачкорсак", "чихут" кебек күңелсез сүзләр хәзер балык куыгы урынына шартлады. Аны "пәйгамбәр" дип йөртә башладылар. Аның пәйгамбәрлек галәмәте бәхәс вакытында калкып чыга. Аннан соң аның язучы икәнлеген дә белеп алдылар. Мөхәррире Фатих Әмирхан булган "Әльислах" газетасында басылган "Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы" исемле хикәясе бервакыт Нурислам кулына килеп эләгә. Уфага килгәч, бер танышы табып бирә. Миаска кайткач, Нурислам аны ял көннәрендә, кичләрен, азлап-азлап, боларга укып күрсәтә. Шуннан


башлана Галимҗанга быелтыргы күз белән түгел, ә бәлки киләчәккә булган өмет күзе белән карау. Ә инде Нурислам абыйсы болай укымышлы кеше икән. Авыл мәдрәсәсен тәмамлаган. Тик кайдадыр йә мулла, йә мәзин чапаны кию кызыксындырмый аны. Аптырагач, эшче чанасына утырырга мәҗбүр була. "Без язмыш алдында көчсез әле" дигән сүзләре аның тирән мәгънәгә ия. Аны теләсә кем әйтә алмый. Бу хакта тирән уйланганнар гына төпле фикер йөртә ала. Язмыш алдында көчсезлек мәсьәләсен Галимҗан үзе дә хәл итә алмый. Бер ел кара эштә үткәрде гомерен. Нәрсә бу? Язмышмы? Ялгышмы? Алда — әллә ничә биек тау. Барысының да башына менеп житеп булырмы? Ай-һай! Бу да язмышмы? Ярый ла язмыш җиле, котырынып исеп, балык җәтмәседәй урап алып, таулар түбәсенә мендереп ташласа. Ай-һай-һай, көт син аны, андый бәхет кызыл кар яуганда да булмаячак. Балык — тирән җирне, кеше яхшы җирне эзли, ди. Эзләп тә табып булмый бит әле аны. Алда күпме өмет, хыял, менәсе таулар... Син шуның өчен чәнчелердәй булып тир түгәсең. Бер байгош ел буе тиенләп җыйган акчаңны чәлдерә. Кая керде бу акча? Кем кесәсен баетты? Кемнең эчен жылындырды? Кичә кибеттән әнисенә яулык, күлмәклек сатып алмакчы иде. Аны интегеп яши дип уйламасыннар, янәсе. Башта авылга кайтып, аннан соң гына Казанга китү иде исәбе. Күлмәклекне дә, яулыкны да ошатмады барыбер. Икенче җирдән алырмын әле дип, акчасын тышкы кесәсенә салды. Кайткач караса, акчадан җилләр искән. Хәзер инде буш кул белән авылга кайтып булмый. Казанга бару турындагы кайнар хыял да салкын бозга әйләнде. Янә бер ел кара эшче хезмәтен башкарудан башка чара юк.

Шундый уйлар белән килеп керде Галимҗан эшче дуслары янына. Аягүрә басып каршы алсалар да, эчү табынына чакырсалар да, ул берсенә дә ризалашмады. Ым кагып чакырды да Нурислам агасын, булган хәлне сөйләп, янә бер ел эшләячәген әйтте.

— Ярый, Галимҗан туган, үзең беләсең: бүген получка көне, салмыш баштан берни дә әйтеп булмый, иртәнге уй кичкесеннән яхшырак, ди, иртәгә килерсең, хәл итәрбез, — диде башлык.

— Рәхмәт, Нурислам абзый! — дип, маржа хуҗабикә Нина Андреевна янына кайтып китте Галимҗан.

*Дәвамы киләсе санда*



# ШИГЪРИЯТ



## Нур Әхмәдиев

### Чакматаш

Язмышларны язган чакта әллә
Фәрештәләр нидер бутаган:
Әле уңга, әле сулга китәм,
Ә теләгем — бару уртадан.

Борчулары бик аз тоелгандай
Кайгы кылә, кылә ишелеп.
(Кайгыныммы, әллә шатлыкныммы
Күбрәк күрә икән кешелек?)
Назлар өмет итәм — шелтә алам.
Яңгыр көткән башка таш ява.
Әкрен генә гомер узып бара,
Күзәнәкләр тәндә картая.

Ә барыбер көлә-көлә яшим,
Ни килсә дә минем башыма.
Рәхмәт, язмыш,
Синең сынаулардан
Әверелдем чакма ташына.

### Замана

Заманалар — үзгә:
Нәрсә булыр — көзгә?
Бездән сәлам сезгә!..

Ташка үлчим заманасы:
Алданасы да гел алданасы;
Бүгенгедән киләчәккә
Шушы җанның ялганасы...

## Эри карлар

Эри кар, эри сак кына,
Безнең гомерләр сыман.
Мин эремим,
мин бөгелмим,
Мин бары шартлап сынам.

Чабып барганда авармын
Йөрәккәем ярылып.
Үкенмәм, аз яшәмәдем
Сылуыма яр булып.

Эри кар, эри сак кына,
Сагышка сала-сала.
Әллә нинди яз булды бу —
Йөрәктән тотып ала.

## Кичке авыл

Офык читләрендә ак болыт,
Ак болыттан иңә яктылык.
Алсу буяуларга буялып,
Баеп бара кояш оялып.

Көтү кайта, көтү ашыга,
Өреп чыга этләр каршыга.
Аттан төште арган көтүче,
Урамнарда — җылы сөт исе.

## Гаҗәпләнмәгез

Җилгәрде еллар җилләрдә,
Кибәкләр кайдан калсын!
Хакым бар: инде юлымда
Сандугачлар елмайсын.

Иләде язмыш, иләде,
Ул да кеше димәде.
Ничә тапкыр төзәлде дә
Яраларым чиләнде.

Тишелеп беткән йөрәгем
Тартыла тегермәндә,
Гаҗәпләнмәгез, егылсам,
Ашыгып йөгергәндә.

## Изге чишмә

*(риваятькә нәреп)*

Болгар илендә таулар да дала,
Биләр янында бар Мәрҗән кала.

Тырышмал Хуҗа — шәһәр хакиме,
Сыенган аңа карты, ятиме.

Унике кызы булган Хуҗаның,
Нәркәсе йөрткән гүзәллек данын.

Нәркәсне сөйгән Иштирәк батыр,
Гашыйк егеткәй — арыслан тотыр.

Унике кыз да, барып Биләргә,
Йөргәннәр көн дә белем эстәргә.

Бервакыт илгә явыз яу килгән:
— Кол булмасагыз, юк итәм, — дигән.

Кем риза булсын хурлыклы шартка,
Орышка чыгу кала ир-атка.

Тигез түгел шул тик көчләр генә,
Болгар ирләре һаман чигенә.

Берзаман дошман Биләргә җитә,
Алда зур орыш — илне ни көтә?

Биләр каласын якларга диеп,
Батырлар килә көбәләр киеп.

Батырлар килгән төрле яклардан:
Кызылтаулардан, Нократлардан.

Дошманны кыра батыр Иштирәк,
Андый баһадир дөньяда сирәк.

Исәп-хисапсыз дошманның явы,
Орыш шаһиты — Хуҗалар тавы.

Тигезсез яуда шәһит Иштирәк,
Илне сакларга нинди көч кирәк.

Инде нишләсен унике сылу,
Мөмкин түгелдер качып котылу.

Әсир алынган унике гүзәл,
(Тырышмал Хуҗа бигерәкләр җәл!)

Җиргә күммәкче кызларны дошман,
Көн-төн туфрак ташырга кушкан.

Кызлар бергәләп тауга басканнар,
Йолдызлар булып күккә ашканнар.

Тырышмал Хуҗа таудан ташланган,
Шул җирдә чишмә чыга башлаган.

Табына халык изге чишмәгә,
Юлчылар килә суын эчмәгә.

Исең китмәле суы тәменә,
Җаныңа шифа, сихәт тәнеңә.

## Шомырт чәчәк атканда

Шомырт чәчәк ата...
Өзә калсам,
Сөю сафлыгына кер төшәр.
Яшьлегемдә һәрбер чибәр кызга
Гыйшык тоткан идем мин исәр.

Әле ярый антлар итмәгәнмен,
Сине генә бары сөям дип,
Ярты яшьлек узган утлар йотып,
Бикле капкаларга сөялеп.

Әй сылулар,
Сезнең каршыгызда
Мин алдакчы түгел, түгел лә!
Шомырт чәчкәсеннән күңелләргә
Наз тараткан аклык түгелә.

Яшерегез шомырт чәчәкләрен,
Яшерегез миннән тизрәк:
Яшьлек белән картлык арасында
Бәргәләнеп ята бу йөрәк.

## Дөнья бу — уйлатыр

Карт хатын салкын,
Акылы — алтын.
Яшь хатын кайнар,
Сайлатмас — сайлар.

Карт хатын юатыр,
Яшь хатын елатыр.
Дөнья бу —
Уйлатыр...

* * *

Аллага шөкер, илемдә
Бик үк сансыз түгелмен:
Чәчәкләргә, мактауларга
Әллә азмы күмелдем?!
Әле һаман тәэсиреннән
Айнып бетмәдем бугай.

Уңышлардан баш әйләнсә,
Ярлыка үзең, Ходай!
Ярлыка үзең, гел генә
Иркәләмиләр безне.
Кышларның салкынын уйлап
Каршылыйм алтын көзне.

* * *

Телгәлисең инде җаннарымны,
Сәбәбе юк көе телгәлисең.
Кайчагында нигә гаепләрне
Үз-үзеңнән бер дә эзләмисең?

Һәрбер сүзең, уктай атыла да,
Кадала бит минем бәгыремә.
Үлә калсам әгәр, бер уч туфрак
Салмый калмассың бит каберемә?

Мин исәрдер, юкса ник табынам,
Карамыйча золым-җәбереңә?
Үз җәлладын алиһәсе иткәч,
Ходай гомер бирер Шагыйреңә!



# Сөләйман

## МӘҢГЕЛЕК КӨЙ

* * *

Җиһан — берни түгел, —
Олы бер көй.
Дөнья — берни түгел, —
Олы бер моң.
Гомер — берни түгел, —
Гади бер шәй.
Адәм — берни түгел, —
Гади бер җөй.

Мәңгелек көй умырткасы —
Мәңгелек Тын.
Мәңгелек ТЫн.
Мәңгелек ТЫН...

* * *

— Язганың — байтак,
Сызганың — байтак,
Ник сирәк язмаң
Улыңа атап?

— Күңелдә — туфан,
Бәгырьдә — вулкан.
Бик юка дивар,
Бик нечкә кыллар.

Сызырга куркам...
Тиергә куркам...

* * *

Бармагыңны сузсаң берчак ярдәм итеп,
борыныңача суырып алыр күзәнәкләп.
Тәхет төзи таштан түгел, таш башлардан,
карасы — ак, агы — кара: таныш мәктәп.
Бәгырь җебе әзме бире сузылгандыр,
әзме акыл бер мичкәгә сыгылгандыр.
Үзәгенең өзелгәнен сизмәс йөрәк,
аңлар вакыт, тагын күпме дәлил кирәк?

## Урта диңгез — Олы диңгез

*Сардиния: Кальяри — Рим...*

Урта диңгез, Олы диңгез —
Ияр тигән кыргый ат,
Таныдыңмы мин-кыпчакны,
Хәтерең, диңгез, яңарт!

Унбиш гасыр син-дәрьяга
Гомермени — бер сәнә...
Кораб-ияр максат түгел —
Күрешер өчен сәбәп.

Ташка катып исән калган
Мин — алмагач орлыгы,
Тере Хәбәр булып шыттым
Мин — Атилла оныгы.

Алмагачка тулы булган
Алтай — Диңгез арасы,
Хәтер күзәнәкләрендә —
Ап-ак чәчкә дәрьясы...

... Күк белән дәрья тоташкан,
Күбеккә баткан кораб.
Пәрәвездәй төн пәрдәсе
Корабны алган чолгап.

Йолдызларга тиеп китә
Кораб, суда йөзсә дә,
Дулкын саен бер талпына
Йөрәк, ничек түзсә дә.

Җидегән йолдыз чалкан ятып
Күктән безне күзәтә...
Әйтерсең лә Тәңре үзе
Чаткы сала үзәккә...

Шомлы дәрья, шомлы гүләү,
Диңгездә — сыңар саңак. —
... Әни, синең учларыңда
Бара сыман бу кораб...

* * *

Төнге күктән шәһәр —
Мәрҗән тулы, асыл,
Чиккән түбәтәйдәй
Җем-җем килә Марсель.

Очак канатына
Тиеп алды сыман
Ак-каралы дөнья,
Ак-каралы инсан.

Дөньяда — бармы син,
Әллә килерсең бер —
Марсельгә барыбер,
Марсельгә — барыбер...

Урамнары — текә,
Таудан эңгер төшә,
Диңгез дулкынында
Җанын тирби мишәр.

Дөнья җилен җигеп
Уза фани гомер —
Соңгы кабатмы бу,
Әллә килерме бер?..

... Миңа да барыбер,
Миңа да —
барыбер...

## Мин — минсез дөньяда...

Җирән карсак көчек
килә очып,
үз җиленнән
аяклары чәбәләнә
үз ләң-ләңен
таккан койрыгына.

Чәйнәр иде
минем ботны —
эмма...
тешләп кара
бу дөньяда
юкны.

Рәшә булып
үтте минем аша
ала-кола телле
чуар төркем.
Минем аша
шау-шу дөнья
үтеп бара.
Әйтерсең лә
челтәр аша үткән
төтен...

Кайсы мизгел
мине
рәшә йотты?
Йә бу дөнья
үзе рәшәме?
Яңгыр җиле иссен
тетеп-йолкып —
Гарасатның
үзен
дәшәмен!

Кемнең эле
күргәне бар
рәшәләрнең
Яшен утларында
яшәгәнен!

... Таудан
тәгәрәгән
тәгәрмәчләр —
бер дөньяның
меңләп чагылышы.
Мине тәгәрәткән
тәгәрмәчнең агачлары
Мең тарафка очты
таралышып...

... Шатлыкка сөялдең —
бармы иңе?
Кайгыга иярдең —
бармы чиге?..

Шатлыктан атылдың:
кайгы — күсәк.

Кайгыга басылдың:
шатлык — түшәк.

Кайгылар
төренгән
шатлыкка.
Шатлыклар
төрелгән
кайгыга...

... дүрт яклап
чит җилләр
кайда да...

адәм-корт
кимерек алмада...
...галәм-йорт
нәфескә чорнала...

...Мин — минсез дөньяда.

• • •

Иңдә — җиһан,
билдә — офык,
аяклар — очак иде...

абынып,
очтым упкынга...

...ул — синең кочак иде.

* * *

Шөкер, Алла,
Адәм заты —
кыяфәте
насыйп булган күрәчәккә.

Сайлый калсам үзем
җаныма сын —
сайлар идем микән кабат
янә адәм кыяфәтен
киләчәктә?

* * *

Бөркет — бөртек-бөртек,
берәм-берәм.
Карга — тамга-тамга,
төмән-төмән.

Ялгыз карга —
шом, томан...
Бөркет төркем-төркем —
йә — төш,
йә — ахырзаман...

## Чи-керт-кә-стан

*трепещет знак-кузнечик*
*над полем и под небом!..*

В. Хлебников

*r-p-o-p-h-e-s-s-a-g-r*
*Who*
*a) s w(e loo)k ...*
*... to*
*rea(de)rran(com) gi(e)ngly*
*,grasshopper;...*

E. Cummings

*Крылышкуя золотописьмом*
*тончайших жил,*
*Кузнечик в кузов пуза уложил*
*Прибрежных много стран и вер...*

Г. Айги

Суынып барган мич арты.
Дөм караңгы өй.
Оеп йоклый авыл йорты...
Чикерткәләр
...төш юрый.

Чикерткә дөньясының
офыклары — йокы...

Шәлперәйгән болын.
Әлсерәгән көтү.
Сикергәли
Чикерт-чикерт-
чикерт-кәләр
сикер-гәли...

Эңгер йота
саркып чыккан
кара сыер сөтен...

* * *

Күңелдә сүз —
суда йөзгән балык.

Сүзнең
телгә чыккан мәле —
йалтыравык кармак кабып
ярда яткан
балык хәле.

* * *

Кыяларда —
бөркет оялары,
күрим дисең —
бармы канатларың?
Язмыш чөйсә күккә — күрерсең дә,
ябылмасмы яшәү кабакларың?

* * *

Йодрыкларым, йомшап,
канат булды,
пакъ хисләрем —
манма моң гына.
Олы юлда Чишмә сукмаклары
вәзен булып керә җырыма.

*1997*



Мәгъсум
Хуҗин

# ТАР ТЫКРЫК СУКМАГЫ

ХИКӘЯ

Назыйм Айгузин Казанга баручы бер поездны уздырып җибәрде. Утырмавының сәбәбе ашыгыч шөгыле булмаудан түгел, анысы, мәхшәргә тартым бу заманда, ялгызакның да чират көткән эшләре бихисап. Поездга утырудан тотып калган сәбәп — көне гаҗәеп, шәһәргә һич тә кайтасы килмәслек. Менә әкәмәт — Назыйм Айгузинның кәефенә һәм кылырына табигать тәэсир итсен инде, әй! Мондый хәлнең булганы юк иде ләбаса!

Кар бөртекләре ярышып очалар. Кубесе — ябалак кар бөртекләре. Шулары җил тынып торган арада җиргә кунакларга өлгерәләр дә, болытлар арасыннан кояш куанып чыккач, күзләрне сөендереп җемелдиләр. Җиле дә сәер — бер мәлгә каядыр посып тора да аннары йөзгә иркәләп кагыла, тагын тына һәм элекке юнәлешенә каршыдан шәбәеп исәргә тотына. Өермә сыман булып акрын бөтерелә башлый, кинәт дуамалланып, кар бөртекләрен югарыга кире алып менеп китә. Тагын шып туктый. Һәм кар бөртекләре җиргә кунып җемелдәргә ашыгалар — кояш берүк чыга күрсен. Хәзерге заманда, фән-техниканың котырынып үсүеннәнме әллә дөньякүләм алга сикерештә безнең илнең читтә йокымсырап торуыннанмы, көн итү табигатьнең шушы манзарасына охшаш: кояшы-болыты, гарасаты-тынлыгы бергә буталган; яктысын болыт каплаган, рәхәтен гарасат күмгән чаклары ешрак әмма.

Айгузин, Обсерватория тукталышының поездга утыру мәйданчыгыннан төшеп, урманлы тау итәгендә дачаларга илтүче сукмакка кердә. Туктады, дачасына кире бару нияте юк иде. Әнә, кар ява. Җиле, әйе, сәер. Өермәсе әлегә сабый кебек, көчсез. Кояш куана. Ябалак кар бөртекләре җемелди. Назыймга үзен табигатьнең сихри үзгәрүчән манзарасы эчендә тою рәхәтлек бирде. Югыйсә ул табигатьтәге һәм дә яшәештәге тиз үзгәрешләргә мөкиббән китмәүче кеше һәм бу гадәтенә яшьтән күнеккән, мондый битарафлыгыннан зыян күргәне дә булмады. Аһ орып каңгырмавың, ыгы-зыгыга ашкынып тыкшынмавың, онытылып шатланмавың хеер — шушы кагыйдәгә табынып яшәде Айгузин. Һәм начар яшәмәде.

Яшьлегендә күтәрелеп бәрелгән чаклары булгалады булуын. Ләкин

шунда ук сөртенде. Вакыйгадан бөтенләй читтә калгалады. Ләкин аны юксынмадылар. Димәк, тормышның котыпларына ук барып чыгу хаҗәт түгел, яхшы-яманның уртасында торуың хәвефсез. Михнәт дәрьясын кичмәде, рәхәт диңгезендә йөзмәде Назыйм Айгузин — хиска бирелүчеләргә булсын бу котыплар.

Табигатьне тоеп кинәттән хәзерге рәхәтләнүенә бик тә гаҗәпләнде ул. Көтелмәгән уйлар өермәсен һәм, гомумән, хәзерге халәтен, табигать кешене сөендерү җаен таба белә икән, дип аклады. Шулай, табигать сарсарлар да куптара, әмма мондый явызлыкны сирәк — адәм баласының әшәке гамәленә җавап итеп кыла. Шулай, юньсезлекне беркайчан да гафу итми табигать, кырыс җәзасын бирә. Ә сарсар-давыллар кешеләр тормышында ешрак кузгалучан. Һәм аларны кешеләр бер-берсенә ачу тотып дулаталар, дип күңеленнән нәтиҗә ясады Назыйм Айгузин. Шулай, кешеләр бер-берсеннән гафу үтенешәләр. Ләкин яраны гафу савыктыра алмый. Кылган юньсезлекләре өчен, адәм заты арасында җәзадан котылуның тагын да гөнаһлырак әмәлләрен табучылар күп. Димәк... димәк, табигатьне тормыш итүгә охшату дөрес түгел икән, алар бер-берсенә һичкайчан тәңгәл килмәячәк. Һәм Назыйм Айгузин, тирән сулап, үзалдына әйтеп куйды:

— Дөнья, диген...

Чираттагы поезд Обсерватория тукталышына ташкын башыдай ыжгырып керде, соңламавына сөенүедер. Уртадагы вагоннарда гадәттә кешеләр азрак була, һәм Назыйм бишенче вагонны сайлады. Бу тукталышта төшүче дә, утыручы да башка юк иде.

Вагонда ике генә кеше. Унсигез-егерме яшьләр тирәсендәге кыз, тәрәзә янындагы башын куеп, вагон стенасына терәлгән төенчеккә таянып, барыр уңайга аркасы белән утырган. Башындагы ак шәле, ябалак кар, диярсең, җемелди иде — монысын Айгузин беренче булып күрде. Кызның каршындагы киң җилкәле ир, зур гәүдәсен тулгай-тулгай китереп, нигәдер кыбырсына, йонлач бүреген башыннан суырып алгач, озынча чәчләре күперде дә зур карбыздай башы түгәрәклеген җуйды. Ул кар көрәгедәй кулларын буташтырып нидер сөйли, Назыйм аның сүзләрен ишек катыннан ишетмәде. Кыз җавап кайтармый, ир кешенең сөйләвен тыңларга теләми, карашы тәрәзәдә. Тирән, бик тирән итеп сулады, күзләрен йомып торды кыз, түгәрәк йөзе кинәт агарды да тагын кызарды. Әтисе белән кызы ахры болар, дип уйлады Айгузин, ир кешегә, күзен-йөзен тулаем күрмәсә дә, кырык биш яшьләр биреп куйды. Кызын нигәдер әрли бугай әти кеше, ачуланыштан ерак торуың хәер, дип, ишек катындагы каршы як эскәмиягә утырды. Тик әти кеше баласына әйтмәскә тиешле сүзләр ишеткән кебек булды Назыйм. Колакларын торгызып тыңлады. Сөмсез сүзләрне аермачык ишетте.

— Әйткәнне тыңла, җүләр! Йөз тәңкә аяк астында ялтырап ятмый синең!

Ир кешенең куллары кызның күкрәкләренә кагылды, кыз йөзен читтә, гәүдәсе җыерылып алды, ләкин ир кешенең кармалауларына-кымтырыклауларына каршы хәрәкәт ясарга көче җитмәде кебек, урынына бәйләгәндәй утыра бирде. Кинәт кычкырып җибәрде:

— Ерткыч!..

— Кыланма! Юдинода төшеп калабыз. Анда минем таныш яши. И йөз тәңкә — синеке! Иелеп аласың да юк. Яратам тулуы җиткән хатыннарны! Әйдә, миннән булсын яхшылык — йөзне азсынсаң, йөз дә...

— Кит!..

Назыйм атылып килеп җиткәндә, ир кеше, кызны почмакка кысрыклап, аның корсагын иләмсез олы кулы белән туктаусыз капшый-кыскалый иде. Айгузин, бер мәлгә катып торгач, бәрәңге һәм кайнатмалар тутырылган

сумкасын утыргычка куеп, бөтен көчен җыеп, көмәнле яшь ханымга бәйләнүче бәндәне кулыннан каерып торгызды.

— Син... син акылыңнан шаштың мәллә?!

Үзеннән бер башка озын, кабарынкы яңаклы бу кешегә кырык биш яшь биреп ялгышкан икән Айгузин. Кырыкка да җитмәгән булыр көмәнле хатынны мәсхәрәләүче. Каушап калмады ул, уттай янучы күзләрен кыса төшеп Назыймга карады, гаҗәпләнеп, башын як-якка кыйшаткалады, Назыймның колагына иелеп пышылдады:

— Кулыңны ал, абзыкай.

— Алмыйм!

— Тәрәзәдән очасың бит хәзер! Кулларың канат урынына кирәк булыр. Боларны Айгузинның йөзенә өреп әйтте.

— Очмыйм! — Назыйм тегенең кулыннан кысыбрак тотты. — Ычкын моннан! — дип, көче җитмәячәген белсә дә, аралыкка таба тарткалый башлады.

— Картлач, юньләп әйткәнне аңламыйсың ахрысы. Син Сәвади Сайгушевның юлына аркылы төшмәкче буласың бит!

— Бернинди Сайгушевны да белмим мин! Ә Сәвадинең каралык икәнен беләм! Менә мин — Назыйм Айгузин — хәзер сиңа сарсар ясыйм, давылөермә куптарам!

Назыйм картның кулы кинәт хәлсезләнде, Сайгушев аның беләгенә кырлы тимер белән суккан кебек булды, ләкин Сәвадинең кулында әйбер күренмәде, ул кулының сөялле кырын Айгузинның борын төбенә китереп тәргән иде. Назыймның кулы Сәвади беләгеннән үзеннән-үзе ычкынды. Картның эченә типте кебек Сайгушев, ләкин бу хәрәкәтне Айгузин күрмәде, ул эчен тотып бөгәрләнде. Сәвади акрын гына:

— Озак такылдыйсың, — диде һәм Назыйм картны, култыкларыннан эләктереп, җиңел генә күтәрде дә, каршыдагы эскәмиягә дыңгылдатып утыртты. Үзе китмәде, Айгузинның аңы кайтуын көтте. Карт башын күтәреп күзләрен ачкач кына аңа тезен терәп утырды.

— Рәхәте уздымы?

Карт эндәшмәде.

— Сүзсез утыруың хәер. Мин бу буазны Юдинода алып төшәм, — дип башын артка — көмәнле хатын ягына ташлады Сайгушев. — Урыныңнан кузгаласы булма!

— Кем син? Юлбасар... — дип сүзләрен көч-хәлгә әвәләде Назыйм.

— Ялгышасың, картлач! Юлбасар түгел, синең кебек ыгы-зыгы куптаручыларны юлга бастыручы мин. — Сайгушев куен кесәсеннән кызыл тышлы таныклык чыгарды, аны ачып күрсәтмәде, кесәсенә кире салды. — Ә бу асыл кошны, — ул башын тагын артка ташлады, — милициягә тапшырам. Фатир басарга җыенганда тоттым мин аны. Әле берәр фатирны талап та өлгергән булыр. Төенчегенә бауны аркылы гына салуын күрмисеңме әллә? Ашыгу билгесе бу.

— Булмас-с, — дип сузды Назыйм. — Ана булырга торган бер генә хатын да кеше әйберсенә кагыла алмый.

— Булмас, имеш! Ничек кенә булыр әле! Үз күзләрең белән күреп, үз колакларың белән ишетеп торырсың. Сине дә Юдинода алып төшәм. Тик әнә хәерче сумкаңны онытма.

— Булмас!

— Ә син моның булмаслыгын берничек тә исбатлый алмыйсың! Каракны тотучы мин. Аны ничек каптыруымны үзем генә беләм. Читләр әйберсенә кагылу корсаклы хатынга да тыела!

— Кем син? Игелексез икәнсең... Һөнәрең юктыр синең. Һөнәр иясе игелексез була алмый.

— Һөнәремме? Бар!! Акчалы кеше мин! Акчалы кеше!

— Шул көчсезне кыерсытырга соң... Ана булырга торса да, бала гына бит әле ул...

Айгузин каршы якта утыручы көмәнле хатынга карамакчы булды, ләкин ул турны Сайгушев зур гәүдәсе белән каплаган иде. Алар акрын сөйләштеләр, хатын аларның сүзләрен ишетмәгәндер, ишетсә дә, Назыйм картка булышырлык хәлдә түгел ләбаса ул.

Кинәт вагонны тутырып ачы тавыш ишетелде:

— Әни-и-и!!.

Көмәнле хатын, утыргыч терәгендәге сапка тотынып, ачыргалана иде. Аны өянәк тоткан иде инде.

— Әни-и... Ай-й-й...

Хатын ачы тавыш белән кычкыра-кычкыра утыргычка ауды.

Назыйм Айгузин килеп җиткәндә, хатын күзләрен йомып ыңгыраша иде.

Поезд Юдинога җитеп туктады. Вагонга кешеләр керде. Ирләр, хәлне аңлап, кире борылдылар, күрше вагонга күчтеләр.

— Балам ла, шушы хәлеңдә ничек юлга чыгасы иттең соң? —дип көмәнле хатын янында кайнашты бер карчык. — Хәзер, балам, хәзер, Алла боерса, барысы да әйбәт булыр. Балакаем ла... Читкәрәк китегезче, бүтән вагонга күчеп бетегез, миңа булышырга берегез җитә. Менә син кал. Ә син нигә монда әле? — дип эндәште карчык аннары Сайгушев суккан уң кулын изүенә тыгып, сул кулы белән әчен тотып торучы аптыраган Назыйм Айгузинга.

— Мин... Мин — аның бабасы...

— Бабасы булсаң да, әнә теге башка ук бар. Кызыкаем, — диде карчык бала тудырырга җыенучы хатынга, — менә шулай ят әле, яме. Ярый ла үземә очрадың. Бәхеткәең бар икән. И-и акыллы да соң син... Тырыш, яме, кызым... Мин Мөхибә әбиең булам. Кияүгә чыкканчы ук кендек әбисе идем инде мин. Үзем дә олы малаемны урак урганда таптым. Синең дә беренче балаң малай булырга охшаган. Кызым, кызым, тыныч кына, яме... И-и рәхмәтләр яугыры...

Сәвади Сайгушев Казанга җиткәнче дә, вокзалда ашыгыч ярдәм машинасы көткәндә дә, Назыймның күзенә чалынмады. Аның Юдинода төшеп калуын күрмәгән иде Айгузин.

Ашыгыч ярдәм машинасына Мөхибә белән Назыймны утыртмадылар, яшь ананы сабые белән кайда урнаштырачакларын әйттеләр, хәлләрен шунда килеп белерсез, өч-дүрт көннән чыгарырлар да, оныгыгызны каршыларга әзерләнегез, диделәр. Шулай итеп, кырык ел хатыны белән яшәп бер генә баласы да тумаган Назыйм Айгузин бабай исеме алды. Әмма моны баланың анасы белмәде, моңа ашыгыч ярдәм машинасын бергәләп озатып калучы Мөхибә генә чынлап торып ышанган иде.

— Хатын-кызны шундый хәлендә юлга алып чыгалар диме инде?! — дип әрләде Назыймны карчык. — Гомер иткән кеше ләбаса син!

— Мин... ни, кем... әбекәй... — дип тотлыкты Назыйм, карчыкның әрләвеннән акланырга тиз генә җавап таба алмады.

— Мөхибә, дим бит инде үземне! Хәтерсез икәнсең.

— Исемеңне мин ишетмәгән идем. Башкага әйткәнсеңдер. Әш болай бит әле. Бабасы түгел мин бу яшь ананың.

— Ничек, ничек?! — дип башын алга сузды Мөхибә. Муенын нәрсәдер кыскандай булды да ияген каймалы, инде борынгыга әйләнеп бара торган тунының якасына ышкыды. — Бабасы булмагач, кеме соң син аның? Ире түгел ич инде. Хәер, Ходаем сакласын, имансызлар күбәйгән хәзерге заманда...

— Беркеме дә түгел мин аның.

Һәм Айгузин бу вакыйгага ничек тап булуын сөйләп бирде.

— Ай-й Аллам икән лә! — дип каушап төште Мөхибә. Нинди карарга

килергә, ни эшләргә белмәде, кызыл шакмаклы апъяулык белән кысып бәйләнгән төенчеген бер кулыннан икенчесенә күчергәләде. — Нигә башта ук әйтмәдең моны? Нишли ди ул бала ялгызы? Кеме дә булса бар микән инде аның? Казанныкы микән соң ул? Башта ук әйткән булсаң, докторларның айваена карамас идем, калмас идем ичмасам үзләреннән. Каян табам ди инде мин аларны? Бу Казанда йөри дә белмим бит мин. Автобус белән Сабамнан киләм дә трамваена утырып вокзалына төшәм, аннары поезд белән Юдингә, оныкларым янына. Кайтыр юлым тагын таныш. И-и Ходаем ла! Син... исемеңне ничек дидең әле? — Назыйм фамилиясен дә кушып әйтте. — Син, Назыйм карт, әйтәм ич, гомер иткән кеше ләбаса үзең! Нигә җибәрдең аларның үзләрен генә? Каян табам ди инде мин аларны? — дип баягы сүзләрен кабатлады Мөхибә.

— Алар киткән бала тудыру йорты... Бишбалта ягындарак булырга кирәк.

— Шуны да тәгаен белмисең ичмасам! Шәһәрдә яшәп!

— Белеп бетермим шул. Чөнки бала табу йортларына йөргәнем булмады. Гомеремә.

— Тупаслыгы тагын! Синнән бала таптырган кеше юк! Алар киткән йортны күрсәт кенә син!

— Анысы табылыр ла. Ниятенә керешсәң.

— Монысы ни дигән сүз тагын? Ике... ике сабыйны ярдәмсез калдырмакчы буласың мәллә? Әйдә, тап! Илтеп куй мине шунда! Ходаем ла, бүген кайта алмам ахры Сабама. Кичке автобуска өлгерсәм инде. Тик мине шушында хәтле озатып куярсың.

Карт, күзләрен читкә текәп, сүзсез тора иде. Битарафлыгы сизелә иде аның — гаҗәп холык, әй, әле күптән түгел генә яшь ана язмышы өчен ихластан кайгырган кебек иде югыйсә.

— Нигә урыныңнан кузгалмыйсың? — дип тезә бирде карчык. — Тап, дим бит! И-и Аллам ла, өемне бер генә көнгә дип калдырып киткән идем, күршекәем көтеп интегер инде. Нигә терәлеп каттың? Җәһәт бул, дим!

— Кул...

— Йөрергә аяк кирәк, кул түгел! Ә-ә, кулыңа ни булган соң?

— Сызлый, — дип уң кулының беләзеген ышкыды Назыйм. — Картлык галәмәтедерме... — Кулының Сәвади Сайгушев сугуыннан соң авырта башлавын әйтергә теләмәде. — Картлыкны сиздереп аласы итте бугай, — дип шаярткан булды Айгузин.

— Җитмеш яшеңнән сызлануга биреләсең, адәм көлер! Мин менә сиксәнне узып та сызлануны белмим. Аллага шөкер!

— Күрәзәче ахры син, Мөхибә әби, — дип авырдан елмайды Назыйм. — Ел башында җитмешемне бәйрәм иттем. Ялгызым гына.

Мөхибә төенчеген сул беләгенә элде, Назыймның сызлый торган кулына үрелде, ләкин кулын кире тартып алды.

— Ходаем, кичерә күр, — диде ул, сүзләрен дога укыгандай акрын гына әйтте. — Кичерә күр. Хәләлемнән соң ирләр белән күрешкәнем дә булмады, үз тәнемә дә кагылдырмадым. Әмма, Ходаем, синең Назыйм колың бик тә сызлана, йөзенә чыккан. Кичер гөнаһымны, Назыйм колыңа изгелек кылырга теләвемне кабул ит.

Карчык йомшак бармак битләрен картның кан тамырлары күпергән беләзегендә сыйпагандай шудырып йөртте.

— Картлык галәмәте түгелгә охшаган бу... — дип Назыймның кулына якынрак иелде Мөхибә. — Түгел. Сәбәбе башка. Авыртуы менә шушыннан тараламы?

Назыйм тешләрен кысып баш какты.

— Карт сөяккә шушы гына җитмәгәндер, — дип кулын алды Мөхибә. — Сөяге чатный башлаган белэгеңнең. Йа Ходаем, нинди юлга чыктым булды соң мин?.. Монда сиңа килешле дәвам юк шул, — диде карчык, төенчегенә кагылды. — Әйдәле, тизрәк бәбәй тапкан наныебыз янына барыйк әле, — дип тагын кызуланыбрак сөйләүгә күчте ул. — Шунда синең кулыңны да бәйләтербез.

Айгузин каршы төшеп сүз әйтергә җыена башлауга ук Мөхибә аны ымлап туктатты.

— Бәйләрләр, бәйләрләр, — диде карчык. — Докторлар изге җанлы була, бала табу йортларында иң шәфкатьлеләре эшли аларның.

... Бала табу йортында яшь ананың һәм сабыеның хәлләре ярыйсы булуын, инде ананың өенә хәбәр ителүен әйттеләр. Яшел Үзән шәһәреннән икән яшь ана, паспорты үзе белән булган, өенең адресын һәм телефон номерын, кәгазьгә язып, кесәсе саен салган икән, шуны үзе әйтеп аңлаткан ди докторларга. Балакай, акылы җиткән, күрәчәгенә алдан хәстәрләнгән.

— Сабыен яшертен табарга җыенган кебек бит әле бу. Әллә соң ата-анасыннан... — дип нәтиҗә ясый башлаган иде Назыйм, тик Мөхибә аны шып туктатты.

— Ничек телең бара? Гомер иткән адәм ләбаса син! Тузга язмаганнарны уйлыйсың ич! Уйлавы гына җитмәгән, авызын тутырып әйтә өстәвенә!

Карчык кинәт өченче затка күчте, монысы Айгузинны мәрхәмәтсез итеп санамаудан иде. Ләкин Назыймның холкы шактый кырыршы булуын, кайчак үҗәтләнүдән тыелып калмавын белми иде ул.

— Гомер иткән булганга андый фикергә килүем түгел, —диде Айгузин, тавышы Сәвади Сайгушевны белэгеннән тартып торгызгандагыча кор чыкты. — Минем гомернең беренче яртысында уйнаштан бала табу хурлык санала иде. Соңгы заманда гына атасыз бала табу батырлыкка әйләнде.

— Атасыз бала булмый, — дип Назыймның сүзен юкка чыгармакчы иде Мөхибә.

— Була! Хәзерге замандамы... — диде дә кинәт туктады Айгузин, поездда Сәвади Сайгушев белән булган вакыйганы сөйләргә җыенды. — Көмәнле хатынны... — дип дәвам итмәкче иде, тик тагын төртелеп калды.

Карчык, шул тукталудан файдаланып, сүз сөрештә өстенлекне тагын үзенә алды. Моңарчы таныш түгел ике кешенең сөйләшүе ара-тирә сүз көрәштерүгә охшап китә иде. Картлыкларында аларга балаларча самимилек кайтканмы әллә алар ачык күңеллелекне беркайчан да җуймаганнармы — хәзергә моны төгәл бәяләп булмый иде.

— Минем янда ямьсез сүзләр әйтәсе булма, — диде Мөхибә, тавышында ачулану төсмере юк иде, шулай да ул йомшак сүз әйтүне тиеш тапты һәм шуның белән Назыймның кабынып китүен тыйды. — Яме.

Карт эндәшмәде. Бала табу йортының ишек төбендә алар тагын бераз таптанып тордылар. Яшь ананың тәрәзә янына килергә әлегә хәле юклыгын шәфкать туташы, ишек ачып, икенче тапкыр искәртте, салкында туңып тормаска кушты, ананың өлкән юлдашларының монда килүләренә сөенүен һәм рәхмәтен җиткерде. Әмма Мөхибә карчыкның туны җылыны шәп тота, аның башында мамык шәл, аякларында яңа баскан киез итекләр иде. Назыймның, шәфкать туташы салкын турында кисәтүеннән соң, тәпе чымырдап алды, ул аякларын бер-берсенә какты, ботинкалары шакылдарга яратыр хәлгә җиткәннәр икән. Табигатьнең Обсерватория тукталышындагы сихрилеген инде яшерүенә, кар бөртекләренең шаярышып очмауларына һәм ара-тирә өермәдәй бөтерелмәвенә хәзер генә игътибар итте ул. Чалт аязган һәм кояш төштән күп авышкан иде. Айгузин сәгатенә карады. Ике тула.

— Шәһәрдә йөри белмим, дисең. Әйдә, автовокзалга илтеп куям, — диде Назыйм. — Бир төенчегеңне, мин күтәрим.

— Шушы төенчекне дә күтәрмәслек мәллә мин? — дип баскычтан төшә башлады Мөхибә һәм баягы фикерен куәтләүгә күчте. — Ямьсез сүзләреңне оныт. Матур сүзләр ишетү кешеләргә дәва икәнлеген бел. Юньлегә өйрәнергә яшең узмаган. — Шаяртуы түгел иде. — Бала тапкан ананың исемен сорарга оныткан бугыз менә. Озын гомер итеп шуңа да башыбыз эшләмәгән. Балакай, бәбәен юлда табу ихтималын сизгән инде, биләү әйберләрен әзерләгән, бүтән чүпрәк-чапрагы да мулдан иде.

Айгузин бүлдермичә тыңлады.

— Өендә кеше югында чыгып киткәндер. Сәбәбе дә, Назыйм энем, син әйткәнчә ямьсез түгелдер. Хатын-кыз, Назыйм энем, ераккарак карап уйлаучан була. Аның күңеле тирәнрәк, күпне сыйдыра. Аның күңел түре — оҗмах тәхете. Шуны аңлап җиткерми күп ирләр, — дип ямьсезлек турында башлаган сүзеннән шушы нәтиҗәгә килеп чыкты Мөхибә. — Шулай, энем, — дип Айгузинга исеме белән эндәшүне ешайтты сәфәрче карчык, — болытлардан биек таулар бар. Надан кеше түгелсең, таулы якларны барып күргәнең булмаса да, укып беләсеңдер. Болытлардан биек таулар күп. Күп...

Троллейбус тукталышына җиткәч, Мөхибә Назыймга озата йөрмәскә кушты.

— Туп-тулы сантый түгел лә мин, — диде ул. — Бер узган юлымны онытмыйм. Урманнарыбыз куе чакта да адашмадым. Их-х, урманга җиләккә йөреп тә карадым соң! Яшь чакта. Хәзер дә баргалыйм, кыш буена җитәрлек итеп киптерәм кура җиләген. Каен җиләген кайнатам, анысы да оныкларыма күчтәнәчкә җитә. Ризык, әрәм-шәрәм итмәсәң, бәрәкәтле була. Озатмасаң да, адашмыйм, — дип тагын баштагы фикеренә әйләнеп кайтты карчык. — Вокзалда кайсы трамвайга күчеп утырасын беләм. Кулың тиз сихәтләнә күрсен. Адашмыйм, Алла боерган булса. Вокзал янындагы таш йортларны күрүгә танып алам мин.

Таштан түгел, кирпечтән алар, дип төзәтмәкче иде Назыйм, элеккерәк заманда мондый йортларны шулай атау исенә төшеп, үзе дә борынгыга әйләнеп барган карчыкның тасвирына сөенеп куйды, сүз әйтмәде. Ул Мөхибәне автовокзалга тикле илтте. Карчык моңа инде каршы төшмәде. Һәм озатуы әйбәт тә булды. Чөнки кассада, билет юк, диделәр. Алай да Айгузин, сугышта катнашучы булуын искәртеп, соңгы рейска билет алды, моның серен сиздермәскә булды. Әмма Мөхибә өнле карчык, Назыймга билет бәясен тиененә хәтле түләде дә, офтанып:

— Шулай инде бездә тәртип, — диде, күңеле сыкрануын яшермәде, — сугышта калган кешенең тиңенә кимсетебрәк карыйлар. Югыйсә без-толларга игелекле мөнәсәбәт булырга тиеш иде. Теләп алынмаган лабаса толлык... Һай, тол калу сугыш ярасыдай лабаса!.. Шөкер, сугыштан исән кайтучыларга кайбер өстенлекләр бирделәр. Азаясыз шул сез дә. Сугыш тол иткән хатыннар да азая.

Назыйм моңа өстәргә сүз тапмады, хатын-кыз белән сөйләшү җайларын оныта бара инде ул — хәләле вафатына өч елдан узды. Айгузин буфетта кофе эчәргә тәкъдим итте.

— Аягүрә ашау гадәтем юк, — диде Мөхибә. — Ризыкның туклыклыгын җуйдырырга оста аннары андагылар. Юл чатында ризык кадерен бетерүчеләр алар. Карыным ачса да, түзәм мин, түзәм. Ачлык кичергән кеше. Аннары да килеп, унике яшемнән бер генә көн дә уразамны калдырмадым. И-и, заманалар, диген...

Назыйм иртәнге якта үзенең, дөнья, диген, дип әйтеп куюын хәтерләде. Карчык замананы күплеккә әйләндерде, күргән газап-михнәте дә күплектә ахрысы бу әбекәйнең, дип уйлады Айгузин. Шулай да әби бик бетерешмәгән, таза озын гомерле нәселдән булыр, гәүдәсен туры йөртә, йөрүе акрын акрынын,

хәер, сиксәндә түгел, җитмештә дә чатыр чаба алмыйсың. Назыйм, әңгәмәне тоту җаен тапмаса да, Мөхибәне утыртып җибәргәнче көтәргә булды. Карчык үзе дә моңа риза иде, белмәгән кешеләр арасында калганчы, юл матавыкларын бергә күргән карт белән сөйләшеп утыруны тынычка санады, ә аның якташлары автовокзалда әлегә күренмәде. Картның сүзгә катнашмавына борчылмады ул, сөйләвен белде.

— Үзгәрде заманалар, нык үзгәрде, Назыйм энем. Бигрәк тә яманы — кеше гомерен кисүне чүпкә санаучылары ишәйде. Партия дигәнегезнең дә гөнаһы зур шунда, тотанаклы эш итә белмәде партиягез, барысы да әйбәт, дип мактанудан узмады.

Партия өчен мин җавап бирмим, мин партия әгъзасы түгел, партиядән күптән чыгарылган кеше булам, дип уйлады Айгузин, карчыкның фикеренә каршы төшмәсә дә, бу кадәресендә үзен гаепсез санады. Ләкин өнле карчык бөтен гаепне башкалар өстенә тапларга җыенмаган икән.

— Үзебез дә гаепле, — диде ул һәм: — үзебез күбрәк тә гаепле, — дип кабатлады. — Яшьләрне гомер-гомергә өлкәннәр тәрбияли килгән. Без шушы изге гадәтне санга сукмадык. Ялкавын да, юлбасарын да үзебез үстердек. Үзебез ук фатиха биргәнбез аларга. Кешене тәрбиядә партиягезгә ышанып ят инде, йә! Ышанычсызлыгын күрәләтә белә торып бит әле! Үзебез гөнаһлы. Үзебез! — дип ачыргаланды Мөхибә. — Намазыңны үз балаңнан яшереп укы да, шул баладан игелек көт, аңа өмет багла инде, йә?! Коммунист булып китте малаем. Әнисен догадан тыеп.

Карчыкның сөйләвеннән аның электә кем булуын абайлый-сизенә алмады Назыйм. Гади авыл хатыны, дип нәтиҗә чыгарыр иде, Мөхибә укымышлы фикер йөртә; зур урында эшләгәндер, дияр идең, гомере буе дин тотуын искәртә. Диндарлар власть тирәсендә яшертен дә кайнаша алмадылар лабаса — власть кешеләре, әле сугышка чаклы ук, белгән догаларын капылт оныттылар. Дөнья йөзендә иң йогышлы чир — власть, диген бугай бер акыл иясе. Моны Назыйм Айгузин үзе кичерде. Түрәлеккә күтәрелә иде ул заманында, шул чакта дин кануннарын күңеленнән җил очыртты. Хәтәр җил булган икән, хәзер Назыйм бисмилласын да ахырынача хәтерләми, тырышып караса да, яңадан ота алмый. Өлкәннәр мәҗлесләренә туры килгәндә, амин тотуы да ираннәрен селкеткәләп яңакларын калтыравык сыпыргалаудан узмый. Ә Мөхибәнең ихластан диндар булуына шик юк, әнә, хәзер дә, шушы шау-шулы бинада да, догасын Назыйм ишетерлек итеп кабатлый. Тик аның нәрсә укуын карт белми, диндә шыр надан ул. Гыйбадәт кылучыны бүлдерергә ярамавы, шөкер, әдәп кагыйдәсе булып күңеленә сеңгән. Шуңа күрә Мөхибәне, карчык дога укыганда гына түгел, ә дөньяви хәлләр турында сөйләгәндә дә, бүлдерергә базмый Назыйм.

Мөхибә, догасын тәмамлап бераз тын утыргач:

— Әллә ниткән борчулы юлга чыкканмын икән бүген, Ходаем, — диде. — Догаларымны ишек бавын тотар алдыннан да кат-кат кабатлаган идем югыйсә. Аллаһы Тәгалә кабул итмәгәндер шул. Үзем сизмәгән гөнаһым булды микән соң... Шулайдыр да, бу озын гомердә гөнаһ та кылганмындыр. Заманы хак юлдан тайпылдырырга гына тора бит, өстәвенә юл дигәне гел дә тайгак. Ходаем, инде сәфәремнең калган өлешендә хәвеф-хәтәргә юлыктырма! Туган туфрагыма исән-сау кайтырга язсын.

Карчык тагын пышылданды. Назыйм сәгатенә күз төшерде.

— Каян тап булдым бу акылын җуяр карчыкка, дип офтанасыңмы? Теләсә ни сөйләнә, дисеңме? Кеше турында алай начар уйлама, — дип елмаеп алды Мөхибә, әмма Айгузин аның елмаюын, бу карчыкның йөзенә күтәрелеп караган арада булса да, бөтен самимилеге белән күрмәде, сикәлтәле җыерчыклар елмаюның балкышын телгәләгәннәр иде. — Сәгать чамасы бардыр шул

әле автобус китәргә, — диде дә Мөхибә, тәрәзәгә карап таплады. — Әйе, сәгать өч тирәседер. — Ялгышмый иде карчык, һәм аның төгәл сизенүе Назыймның баягы нәтиҗәсен ныгытты, чынлап та күрәзәче бит бу Мөхибә әбекәй, дип уйлады. Карчык исә Назыймның мондый бәясен белми иде, сүзен үзенчә сөрә бирде ул. — Сәгать хәтта төгәл өчтер. Кояшның торышы шулай күрсәтә. Төш җитәрәк капылт аязды да куйды, Ходаем. Бәбәйне биләүләп бетергәндә, чалт аяз иде инде, рәхмәт яугыры. Исән-имин үсә күрсен сабыем, ата-анасына игелеге тисен. Хәерле сәгатьтә тугандыр, бәбкәм. Яшәргә атлыгып тора, наныем. Илгә иләмән булырлык кодрәт һәм гакыл бирсен балакаема. — Һәм Мөхибә: — Бар, кайт, Назыйм энем, — дип сүзен кинәт бүтәнгә борды. — Әле докторларның эш сәгате чыкмаган, күрен үзләренә, кулыңа шифалы дәвасын табар докторлар. Мин моннан автобуска күземне йомып та чыгып утырам. Аннары бит, Назыйм энем, инде Саба кешеләре килә башлар, үзләре үк мине күреп алырлар. И-и якташларымны сагындым да шул инде... Рәхмәт яусын сиңа, Назыйм энем, мәрхәмәтле җансыңдыр. — Мөхибә тагын тәрәзәгә карап алды. — Шөкер, кояшның йөзе сөйкемле тора, ачуы юк. Шәт, ай буе хәтәр хәлләр булмас. Бүген төнлә, Алланың рәхмәте белән, искечә февральгә керәбез. Ходай тынычлыгын бирсен. Ярабби...

Назыйм врачка күренә кайтты. Рентген бүлмәсе эшләми иде инде. Анда керергә иртән килергә куштылар, сөяк чатнаган булуы бик тә ихтимал, диделәр, нәрсәләрдер сөрткәләп бәйләделәр. Кулының сызлавы басылды. Ләкин өенә кайтып чишенгәндә, сызлау тагын сиздерде. Тулы чәйнекне ялгышып уң кулы белән күтәргәч, Назыйм ыңгырашып ук куйды. Беләгендә елан угы кармалана кебек иде.

Табынын җыештырып бетергәндә, ишек кактылар. Ике тапкыр. Кыңгырау шалтыратмыйча, ишек төя, ят кеше инде, дип уйлады Назыйм. Гадәтенчә, ишек шакучының кемлеген сорамыйча, йозакны ачмакчы иде, кинәт шөбһәләнеп, тишектән карады. Ишек төбендә, бит мускулларын уйнатып, Сәвади Сайгушев тора иде. Айгузин каушады, башында төрле сораулар кайнашты: нигә килгән бу, ничек тапкан, ни кирәк аңа, инде кулны имгәтүе җитмәгән, әллә нияте тагын да әшәкерәкме... Шулай да тавышын таныттырмаска тырышып үзгәртеп, башка сорау бирде.

— Кем кирәк?

— Син кирәк, Назыйм карт. Кызлар кебек, тишектән карап торма. Ач.

Хуҗа кеше ачмаска сәбәп тапмады. Сайгушев, ишектән йөлт кереп, йозакны бикләп тә куйды, бу йортта булганы бар һәм йозак төймәсен кайсы якка борасын электән белгән кебек иде аның хәрәкәтләре.

— Каян... ничек... нигә... — дип тотлыкты Назыйм.

— Каянмы? Урамнан. Ничекме? — дип өстеннән пальтосын сала башлады Сайгушев. Күзрикле, колакчынсыз, кепкага охшаш бүреген чөйгә элгәндә: — Таксига утырып, — диде. — Нигәме? Сине сагынып, картлач.

Айгузин ни әйтергә дә белмәде, Сайгушевны кертүенә үкенде, аны төрткәләп чыгарырга көче җитмәячәк, үзе чыгып качар иде — Сайгушев ишекне гәүдәсе белән каплаган. Нишләргә соң, каравыл кычкырырга микәнни, дип куркынды йорт хуҗасы, ләкин җебеп төшмәскә исәп итте.

— Юньсез икәнлегең әллә каян билгеле, — диде ул, Сайгушевны үткәрергә теләмичә, түргә уза торган ишеккә аркылы басты. — Юньсез бәндә булмасаң, яманлап йөрмәс идең. Чәй эчеп бетергәч килдең. Табын җыештыргач.

— Ә, әйе, чәеңне куй. Эчәсе килә. Әнә, вареньеларың сумкада. Карт башыңнан юлда әйберләреңне онытып йөрисең.

— Мин... мин сумкамны онытмадым! Син аны, мин күрмәгәндә, үзең алып качкансың! Син алдан төштең! Вагонга башка кеше кермәде. Син...

— Чамаңны онытма, абзый! Әйберләреңнең исән булуына сөен дә

китергән өчен миңа зур рәхмәтләреңне укы. Шуны да искәртим, паспортны, кадерләп, куен кесәсендә йөртергә кирәк.

— Паспорт?! — дип кычкырып ук әйтте Назыйм һәм, дача базында иелгәч, паспортының кесәсеннән төшеп, аны сумкасына гына салуын хәтерләде. — Бир паспортны!

— Ашыкма, абзыкай. Соңрак бирермен. Чәеңне кайнат. Тамак кибеп бара.

Сәвади, Назыймны җиңел генә читкә этәреп, түр якны карап чыкты.

— Ике бүлмәле икән фатирың. Күршеләрең тасвирлаганча, ярыйсы. Нигә аптырыйсың? Аптырама. Мин монда көндез килеп киткән идем инде. Ялгыз кеше икәнлегеңне баштан ук әйтмәдең бит, гаеп үзеңдә. Шуңа күрә кемлегеңне әлгәре күршеләреңнән сорарга мәҗбүр иттең. Назыйм абзый фатирга кертмәкче иде, дидем үзләренә. Ышандылар. Нигә терәлеп каттың?! Чәй кайнатырга куштым түгелме мин! Саңгырау түгел идең кебек. Әйберләреңне чәлдерүдән куркасыңмы, шуңа күрә мине саклап торасыңмы? Кирәкми миңа синең иске-москың. Әйдә соң, алайса, чәйне бергәләп кайнатыйк, — диде Сайгушев һәм Назыймның җилкәсенә кагылып алды.

— Чәй кайнар әле ул, — дип йомшап төште хуҗа кеше.

— Барыбер яңартырга кирәк. Һинд чәең бардыр, шунысын пешер. Сәвади Сайгушевтан әйбер кызганма, абзый. Кызганасы булма!

Сәвади чәйне үзе пешерде һәм чәйне үзенә генә ясады. Өрә-өрә коры килеш эчеп бетергәч, куе чәйне стаканга тагын яртылаш агызды. Назыймның дачасыннан кайткан кайнатмаларның һәркайсыннан берәр калак салып болгатты, нәрсәдер җитмәгәндәй, өстәл өстен күзләп чыкты.

— Бал тотарга кирәк, абзый кеше, — диде һәм Назыймның кулына ымлады. — Нигә бәйләдең аны?

— Сызлый.

— Катырак эләкте бугай шул.

— Сөяге чатнаган булмагае.

— Үзең гаепле. Кирәкмәскә кысылмый акыллы кеше.

— Оятсыз син! Имгәтүең җитмәгән, өстәвенә мыскыл итәсең!

Назыйм үзен белештермәс дәрәҗәдә калтыранды, өстәлдәге пычакка үрелде — гаҗәп, бүгенге хәлләрнең үзен бер котыптан икенчесенә ташлавына каршы тора алмый иде. Айгузинның кулы кинәт хәлсезләнде, Сайгушев аның кулын зур учына каптырып өлгергән иде. Алар күзгә күз караштылар. Бераздан Назыйм:

— Ай-й-й! — дип нечкә тавыш белән сыкранды, гәүдәсен Сайгушев капкынындагы кулы ягына кыйшайтты, кулына карап өнсез торды, бармаклары агара иде, кан килми башлаган. — Ай-й! Җибәр... — дип үтенде карт, тавышы инде балаларча елак иде.

— Менә шулай, абзый, икенче кулсыз кала яздың бит, — дип урынына утыртты Назыймны Сайгушев һәм, ниһаять, картның кулын ычкындырды. — Селкет кулыңны, бармакларыңны җәһәтрәк йөрт, кан тизрәк төшәр, — дип мыскыллап киңәш бирде. — Кызу канлы үзең, ә! Йә беләккә атылып ябышасың, йә сынык пычакка үреләсең.

Сайгушев пычакны Назыймга таба тәгәрәтеп җибәрде, картның күзләре шар булды, Сәвадинең пычакны ничек сындыруын күрмичә дә калган иде. Айгузин ярдәмгә чакырып кычкырырга җыенганчы, Сайгушев:

— Тавыш куптарма, картлач. Кычкыра башлаганчы авызың томаланасын искәр, — дип кисәтеп өлгерде. — Минем яхшы киңәшемне тот. Кем әйтмешли, хур булмассың.

Йорт хуҗасына тын утырудан бүтән чара калмады, кулларын угаларга да курыкты ул. Бүген аны Мөхибә карчык игелек иясе булуы белән аз

сөйләштерсә, Сайгушев дигән бәндә ерткычлыгы белән телдән яздырды.

— Озакка сузам. Миңа болай килешми. Дәрәҗә төшә, — дип тезде Сәвади Сайгушев. — Җавапларыңны кыска тот. Кулыңны күрсәтеп, милициягә бардыңмы?

— Мин...

— Җәвит иттеңме, дим?

— Юк.

— Дөрес иткәнсең. Мә паспортыңны.

Сайгушев паспортны эчке кесәсеннән имән һәм урта бармаклары арасына эләктереп чыгарды да Назыймга таба очыртып җибәрде. Карт тотарга өлгермәде, паспорт, су кранына бәрелеп, раковинага төште. Назыйм аны борылып алды, кая куярга белмичә, әйләндергәләде, кулындагы бәйләүгә кыстырмакчы булды, паспорт анда сыймады.

— Кабаланма, картлач. Паспортыңны кире алмыйм, кирәге юк аның миңа. Малаең барлыгы язылган анда, ә мин — гомер буе өйләнмәгән кеше. Кирәкми миңа бала, артык шаһит. Минем балаларым юк. Малаеңны үзең белән яшәтмисең, ә, иркенлек яратасың, ә. Бу яктан миңа охшагансың.

— Малай... Малай юк инде...

— Ничек юк? Паспортыңа теркәлгән бит. Син паспорт алганда, унсигезе дә тулмаган булган. Картаеп беткәч, хатыныңнан бала таптыргансың. Бүтәннәрне кыерсытырга, хәтта изәргә яратасың икән, абзыкай. Ярамый алай. Юньле булу кирәк. Минем кебек.

— Малай юк инде... — дип тагын уфылдады Назыйм. Сайгушев ни кылса да, аңа сүзе белән дә каршы төшәрлек хәлдә түгел иде, хәтта бу ерткыч бәндәнең — Назыйм Сәвади Сайгушевның юлбасар икәнлегенә шикләнми иде инде — каршысында утыруына битараф иде ул. — Югалды малай...

— Югалыр шул! Синең кебек начар ата белән яшәргә хурлангандыр. Артыңа борылып карамыйча качарсың син карун яныннан!

Айгузин башын акрын гына чайкады, хәлнең ничек булуын Сайгушевка сөйләүнең мәгънәсезлек икәнен аңыша иде ул.

— Акчаң күпме? — дип уйларыннан сискәндереп айнытты хуҗаны юлбасар.

— Акча?.. Мин бай кеше түгел. Акчам юк минем, — дип гәүдәсен турайтты Назыйм, ләкин торып басмады. — Син үзеңне, акчалы кеше, дигән идең бит. Нигә сиңа тагын акча?

— Мин, акчаң бармы, димим, күпме, дим! Фәлсәфәгә бирелмә. Минем акчада синең эшең юк!

— Синең дә минем акчада...

— Сораганмын икән, димәк, минем синең акчада эшем бар! Карунланма, югыйсә... Минем гадәтне төшенгәнсеңдер. Акча ул, абзыкай, коптан да битәр, очарга ярата. Аннары, белергә тиеш идең, акча беркайчан да кесәне тишми. Теге корсаклы хатынның да халат кесәсеннән нибары егерме бишлек кенә табылды.

— Кеше түгел икәнсең! — дип гырлый-гырлый әйтте Назыйм, аның, Сайгушевка юлбарыстай ташланып, аны кисәкләргә өзгәлисе килде. Моны беркайчан да эшли алмаячагын белеп, көчсезлегеннән гомерендә беренче тапкыр хурланды. Тыныч тормышта кеше җанын алырга кул күтәрергә теләве дә беренче мәртәбә иде. — Шул баланы шундый хәлендә тала инде, йә... Башка сыйдырырлык түгел! Фашистның фашисты син!

— Картлач, кызма. Акчаң кайда? Миңа чүпрәк-чапрак кирәкми.

— Комодта. Өске тартмасында. Үлемтеккә, дип җыйган. Кит кенә тизрәк!

— Үләр чамаң юк әлегә синең. Тагын җыярсың.

Сайгушев кайнатма җимешләре төбенә утырган чәйне сөзеп эчте, стаканны өстәлгә тавышын чыгармыйча куйды, урыныннан торып, калын

фуфайкасын итәгеннән тарткалап рәтләде. Алгы якка чыгып киенде, Назыйм янына кире керде.

— Тавышланасы булма! — дип бармак янады.

Түр бүлмәдән комод тартмасын ачкан тавыш ишетелде. Сәвади Сайгушев Назыйм янына әйләнеп тә чыкты, акчаны тиз тапкан, димәк. Йорт хуҗасы ике терсәге белән өстәлгә таянып, учлары белән йөзен каплап утыра бирде.

— Кайгырма, картлач! Исәнлегеңә сөен! Кулың — вак нәрсә. Үзең гаепле. Ун сумыңны маяга калдырдым. Үлемтегеңә акча җыярга онытма. Ә мине оныт! Онытмасаң, мин дә сине онытмам! Милициягә хәбәр салма! Соңгы ялгышың шул булыр ату. Минем хакта берәүгә дә сөйләмә. Аң бул!

Сәвади Сайгушев дигән бәндә ишекне йомшак ябып чыгып китте. Назыйм ишек бикләргә дә тормады.

Озак утырды ул. Әгәр урыныннан кузгалса, Сайгушев тагын килеп керер кебек тоелды. Ниһаять, урыныннан җәһәтләнеп торды, ашыгып өстенә киенде, ишек тишегеннән коридорны озаклап карады, колагын куеп та тыңлады. Кеше йөргәне-барлыгы сизелмәде. Ачык йозакны ачмакчы булып бимазаланды, аны Сайгушев киткәннән соң бикләмәвен хәтерләп, сүгенә язып куйды, һәм күңеленә кинәт мондый уй килде — әгәр бандит урамда көтеп торса? Бардырыр ул сине милициягә! Милициягә түгел, теге дөньяга илтеп үк куяр! Инде караңгы төшкән, сине бәреп китүен берәү дә күрмәс. Бүтән әмәлен табарга кирәк, дип тынычлана төште Назыйм. Ашау бүлмәсенә керде, Сайгушев тоткан әйберләрне юмады, чүп чиләгенә ташлады. Тик пычак сыныкларын аннан кире алды. Ләкин аларның эшкә ярарлыгы юк иде, шуңа күрә чиләккә атып бәрде. Өс-башын алыштырасы итте, озын калын халатын киде. Аның җиңе киң дә иде, кул бәйләве күренерлек түгел. Назыйм, телефоннан шалтыратырга күршеләренә кергәч, сиздерергә теләмәде. Белсәләр, Сайгушев турында баштанаяк сөйләргә туры килмәгәе иде. Мондый очракта милиция генә белүе хәерле. Ә күршеләр милициягә шалтыратуымны аңышачаклар бит инде, дип уйлады ул. Әгәр болай эшләсә?!.

Айгузин башта төрле номерлар җыйды һәм шунда ук өзә барды яки бер цифрны җыеп бетермәде.

— Йә сөйләшә, йә җавап бирми, — дигән булды ул.

Һәм, ниһаять, хуҗаларга сиздермичә генә нуль икене җыйды. Төребкәне тиз алдылар.

— Ни хәлләрең бар? Исәнлекме? — дип хәйләсенә кереште Назыйм карт, ләкин, дөрес шалтыратмыйсыз, дип төребкәне куйдылар. Айгузин тагын нуль икене җыйды.

— Нигә ташлыйсың төребкәне? Син ич инде бу, тавышың синеке. Тиз генә килеп кит әле. Бик тиз, — дип ашыктырды карт. Бу сүзләре милициядә кызыксыну уятты бугай әллә инде кызык тыңлыйсылары килдеме, инде төребкәне ташламадылар. — Адресны онытмагансыңдыр. Шулай да кабатлыйм, язып ал. — Назыйм адресын әйтте, йортны ничек тиз табасын да өйрәтте. — Әйе, әйе, Назыйм абыең инде, Айгузин. Күптән күрешмәдек шул. Юк, җитмеш яшьлек юбилейны уздырмадым. Шатлыгын шатлык та, җитмеш яшь җитмеш инде, агайне. Аннары гел дә ялгызым гына яшим бит. Карчыгымның вафатын беләсең, малай турында да ишеткәнсеңдер. — Назыйм, бүлдерүләреннән куркып, тукталмыйча сөйләде. — Синең белән иркенләп утырасы килде. Сөйләр сүзләр күп җыелды. Шуңа күрә өзлексез такылдыйм менә. Киңәшәсе иде. Ашыгыч шул. Иртәгә минем барасы җирем бар. Хәзер үк кил! Әйе, әйе, күршеләрдән шалтыратам. Мин сиңа аларның телефон номерын биргән дә идем. Әйе, шул, онытмагансың, — диде Айгузин һәм күршеләренең телефон номерын әйтте. — Ә-ә, отставкага чыкмадыңмы соң үзең? Иртәме? Шактый бар шул әле сиңа. Кунакка гражданскийдан йөрим, дисеңме? Ярар соң, сиңа

анысы да килешә. — Шушы читләтеп әйтүе милиция дежурныен тәмам ышандырды бугай, торебкәдән, котегез, дигән сүз ишетелде. — Котәм, яме. Шешә бөкесен дә ача торырмын. Сиңа әз-мәз капкалау зыянсыз, мин генә сезнең сафтан төшеп калдым менә, — дип сөйләвен кырт туктатты Назыйм.

Аның формадан килмәскә искәртүеннән соң әйткән сүзләрен милициядә инде тыңламыйлар, телефон торебкәсе сулкылдый иде.

Назыйм чакыруы буенча килгән кеше түгәрәк йөзле, уртача буйлы, киң җилкәле ир уртасы яшьләрендә иде. Сабан туе көрәшчесенә охшап тора, нык бәдәнле. Өстендә көрәнсу җәйге пальто, башында йонлач бүрек, аны батырып кигән. Өйгә кергәч, кулларын кесәләреннән алмыйча торды. Карашы белән түргә ишарәләде — андамы, дип соравы иде.

— Беркем дә юк, үзем генә, — дип иркен сулады Назыйм.

— Нигә чакырдыгыз алайса? — дип кырысланды милиция кешесе.

— Миңа хәзергә урамга чыгарга ярамый. Аның аста сагалап торуы ихтимал. Һәм сагалыйдыр. Ул башкисәрдән гомер уйламаган әпәкелекләрне күтәргә мөмкин. Адәм җанын кызганучылардан түгел.

Алдандык ахры, дип уйлады милиционер һәм кашларын сикертеп көлемсерәде.

— Сез, абый кеше, милицияне, төпсез чуманга утыртып, Чулман кичтермәкче буласыз бугай, — дип ризасызлыгын белдерде ул. — Чулманны төпле чуман белән дә кичеп булмавын онытып җибәргәнсез.

Инде Назыйм көлемсерәде.

— Минем телефоннан сөйләвемнең хәйлә икәнлеген аңладыгыз. Рәхмәт. Хәйлә шуның белән бетте, — дип милиционерга түргә узырга ишарәләде Назыйм. — Шаяртуга оста түгел мин. Айгузин абыең мәзәк кора белми, зур кимчелекләренең берсе шул аның. Һәм ул шушы кимчелеген белә! — дип өстәл янынннан ике куллап урындык тартты.

— Шулай да нәрсә булды соң?

— Ул бәндәдән кан исе килә! Валлаһи, кеше каны исе бөркелеп тора!

Назыйм дулкынлана башлады, әле аягүрә басып, әле утырып, Сәвади Сайгушев белән бүгенге очрашулары турында сөйләде. Айгузин сөйләгәннәрне милиционер язып бармады, баштарак бүлдермичә тыңлаган иде, ахыргарак сорауларын күп бирде, Сайгушевның йөзе-кыяфәте тасвирларын кабатлаттырды.

— Сайгушев... Сәвади... Сәвади... — дип үзалдына әйтте милиционер. — Яңа "кош" булырга охшый бу... Яңа очып килгәндер бу...

— Бәлки, вокзал белән аэропорт тирәләрен караштырырсыз. Тиз үк очып китүе дә ихтимал бит. Минем биш йөз тәңкә җитеп торырга да мөмкин аңа. Ун сумын маяга калдырдым, дигән иде. Калдырыр...

— Биш йөз! Биш йөз бер сездән ул, Назыйм абый. Бүген шәһәрдә әллә бер сезне генә талаганнар дип уйлыйсызмы?

Милиционер, әгәр Сайгушев турында Назыйм нәрсә дә белсә, кая хәбәр итәсен әйтте, Сайгушев очрап нәрсә таләп итсә дә, карышмаска кушты.

— Бер көндә бер минем алда ике җинаять кылды, — дип милиционер фикеренә кушылды Назыйм.

— Ул тоткан әйберләрне инде юдыгызмы? — дип китәргә җыенып беткәч сорады милиционер.

— Ишек тоткаларын юдым да комодны сөрттем. Башкасын, әнә, чүп чиләгенә ташладым.

Ике кулын кесәләренә тыгып килгән милиционер төргәк күтәреп китте. Назыймның малае югалуы турындагы хәбәренә ул төгәл җавап кайтара алмады, моның белән башка тикшерүче шөгыльләнүен, бу хәлне ишетеп кенә белүен әйтте, белешергә ышандырды. Тикшерүче киткәч, Айгузин барлык

бүлмәләрдәге утларны кабызды, ләкин утлар ялгыз күңелне барыбер яктырта алмады.

... Их, дип сыкранып уйланды ул, карчыгым янымда булса, малаем күрсә, Сайгушев миннән йөз чакрымга ерак йөрер иде бит!.. Күңелне генә газаплап калмый шул ялгызлык... Карчыгым вафатына өч ел... Малайның югалуына өченче ай... Карчыкны үз кулым белән җирләдем, монысына ышанмыйча ихтыярың юк. Ә малай... Малай исәндер. Нигә алайса бер хәбәр дә бирми ул? Ни гаебем бар минем аның алдында? Нигә мине ялгыз калдырырга тиеш иде ул? Нигә?! Акыллы бала иде ич ул! Нигә... Ни булды икән аңа, ниләр булды икән...

Айгузин төн буена йокламады. Күзләре йомыла башласа, каты чәйне коры килеш кенә эчте. Утларны әле сүндерде дә тагын кабызды. Уйламаган нәрсәсе калмады кебек, ләкин озын гомернең хатирәләре, алдагы кыска гомергә өметләр уйлар тезмәсен суза да суза иде. Әллә соң Сайгушев дигән бәндә аны бер сәбәпсезгә капкынга кысарга җыена да гомеренә йомгак ясыймы Назыйм карт? Шулай булса, киләчәккә өметләнү мәгънәсезлек ләбаса. Юк! Өметсезлеккә бирелмик! Хатирәләр үзләре үк өмет уята. Хәтерлик...

Назыйм Айгузин куркаклардан түгел. Үз йортлары белән Казанның Сәвин ягында яшәгәндә, дөм караңгы урамнарны ялгызы узу аны һич тә шикләндермәде. Юлбасарлар котырынган чакларда да шүрләмәде. Исән калачагына ышанып җитмәсә дә, сугышта үлемнән дә курыкмады. Сугышта үлем үзен иркен сизә, дигән гыйбарәне кайсыдыр китаптан әле ул чакта укымаса да, куркып үлемнән котылып булмавын аңлый иде. Шулай, куркып яшәмәде Айгузин. Шуңа күрә, рәсми әйтсәк, партия-совет эшендә әйбәт кенә күтәрелеп барганда, иң аскача тәгәрәвенә дә офтанмады ул. Монысы болай булган иде.

Госпитальдән кырык иkenең мартында чыкты Назыйм. Уң аягының балтыр сөягенәчә сугыш чәпәгән яра тиз төзәлеп җитмәячәк иде, һәм аны кайтарып җибәрделәр, мондый яра озакка сузыла, аны өйдә дә дәваларга мөмкин, диделәр. Кайтуын көтеп кенә торгандай, элекке эшенә чакырдылар. Эшләмичә дә булмый иде, тамакны яра туйдырмый. Бер айдан аны инструкторлыктан райбашкарма рәисенең урынбасары итеп күчерделәр. Син — яшь коммунист, үсәргә мөмкинлек бирәбез сиңа, укытырбыз, тик хәзер түгел, сугыш беткәч, дип өметләндерделәр. Тырышты Назыйм, ярты төнгәчә эшендә булды, ялны белмәде. Аягы төзәлә төште, таяксыз йөри башлады. Яшьлек яраны сыпырып ташлагандай итәр кебек иде, бу чакта аңа егерме ике яшь кенә иде. Тик, каһәре, ярасы хәзер дә ике-өч елга бер ачылгалый, яралануына илле елга якын вакыт узгач таябылып бетми.

... Кырык өченең урак өстендә шәһәрдән авылларга вәкилләр җибәрделәр — шәһәр кешесе өйрәтеп тормаса, авыл апайлары һәм малайлары ура-суга белмәгәннәрдер шул. Шәһәрдә туып үскән Назыйм Айгузин да вәкилләр арасына эләкте. Ындыр табагын, әвен куюны — ул җәйдә, фронтка ашлыкны тизрәк озату өчен, әвеннәр суктырылды — беренче тапкыр күрде егет. Ләкин аның авыл кешеләрен крестьян эшенә өйрәтү вәкаләте бер генә атна дәвам итте.

Айгузин әвенлектә көрәк белән атып арыш җилгәрүчеләрне карап тора иде. Ике хатын ике яктан алмашка ыргыталар. Оста чәяләр соң! Арыш сары көшел булып якынрак өелә, алабута орлыклары итәккә каралып җәелә, җиңелрәк чүпләр еракkарак оча. Җилгәрүчеләр ялга туктагач, Назыйм да атып карады, ләкин чүпләр арыш көшеле өстенә төштеләр. Хатыннарның өлкәнрәк яшьтәгесе озын саплы себерке белән көшел өстен себерде, егетне ачуланмады.

— Көчең чамалырак ахры, энем, — диде ул. — Аннары җилнең агышын битең белән тоеп торырга кирәк. Син җил көчсезләнгәндә чөйдең. — Себеркесен

куеп агач кәрәкне алгач: — Син алыштыра алсаң, берәр көн эштән калмакчы идем, — дип шаяртмыйча әйтте. — Башкаларның кыш чыгарлык алабута җыярга карт-карчыклары, бала-чагалары бар, минем булышчым юк бит, нәрсә ашатырмын аяксыздан-кутсез ике балага... Алабутасыз да калам бит...

Кулларын тезләре арасына кысып, кемгәдер ялварулы карап утыручы ике бала күз алдына килде Назыймның. Шуларга ярдәм итәргә җай табуына сөенеп:

— Кайгырма, апа, — диде ул һәм, кешел итәгендәге алабутага төртеп: — Сиңа менә шушы әзерен бирербез, — дип куандырмакчы булды ачлык киләчәгеннән шөбһәләнүче апайны.

Хатынның йөзе җимерелде, нәрсәдәндер җирәнә иде ул, кинәт күзләре акайды, кәрәк сабын төптәнрәк каты кысып тотты.

— Син миңа алабута ашатмакчы буласыңмы?! — дип кычкырып, Айгузинга таба килә башлады хатын. — Син миңа ашлык бирдермәскә исәп итәсеңмени әле?! Минем балаларым үскән чагында ипи күрмәсеннәрмени? Шуларны ач утырту өчен көне буена колхоз... колхоз... — дип тотлыгып торды ул, — колхозда тир түгәммени мин? Балаларыма, дигәнемне кисә алмассың! Үзем иписез дә яшәрмен, Алла боерган булса. Сөт-чәй-бәрәңге белән тук булырмын. Балаларым өлешен беркемнән дә кистермәм! Күземә күренмә!

Һәм бу хатынны Назыйм башка күрмәде, басу уртасындагы әвеснеккә бүтән барырга туры килмәде аңа. Шул көнне кичке уңайда ул вәкиллеген тәмам кылды.

Амбарда төнге смена оештырмыйча булмый иде. Кайткан ашлыкны — орлыкка дигәнен — эшкәртеп өлгерә алмыйлар, кыза башлавы ихтимал. Колхоз рәисе, төштән соң өй борынча йөреп, картларны күндерергә булды, ә Айгузин фермага төште, анда эшләүчеләргә төнге сменага әйтергә тиеш иде. Әмма төнлә дә эшкә чыгарга берәү дә атлыкмады, һәркайсы сәбәбен тапты.

— Өемне төнгә дә ялгыз калдыра алмыйм, — диде берсе. — Балалар үзләре генә кунарга куркалар.

— Абый җаным, иртүк фермага килә алмыйбыз бит без аннары, — дип ялваргандай әйтте Айгузин белән бер яшьтәгерәк кыз. — Малларыбыз кетәчәк бит безне. Иртәгә мин көтүгә чыгарга тиеш, минем чират. Ярар инде, мин яшь кеше, бер генә тапкырга түзәрмен дә ди, өйдәгесенә дә катнашмыйм ди, әбиебез барысын да тәртиптә тота, кайттым — бар, киттем — юк, дигәндәй. Бу апалар соң... Белмим инде... Кеше ич инде без дә. Машинаны да ял иттерәләр.

Озынрак буйлы, тулы гәүдәле хатын:

— Мин авырыйм, — диде, кызгылт йөзен сыпырды, чигәләрен ышкыды.

— Синме?! — дип гаҗәпләнде Айгузин. Көче кайнап торган мондый кеше авыруны белмәскә тиеш кебек тоелды аңа һәм аның шушы уе авызыннан сүз булып очып та чыкты. — Син авырыйсыңмы? Шушы гәүдәң беләнме? Кай төшең авыртсын ди синең!

Хатын-кызлар абзар өрлекләренә дип кайтарылган, каезлангач ике ел ачыкта ятудан көлсу төс йоккан имән бүрәнәләр өстендә утыралар, Назыйм аларның каршында басып торып сөйләшә иде. Кырыйда утырган авыру хатын куллары белән этенеп торды, башын игән килеш бармаклары белән чигәләренә баскалады. Акрын атлап Назыйм янына килде һәм егетнең күлмәк җиңеннән чеметеп тотты.

— Кай төшемме? — дип сорады ул.

Назыйм ни әйтергә дә белмәде. Иртәгә көтүгә чыгачак кыз пырхылдап көлеп җибәрде, урынсыз көлүеннән уңайсызланып, учы белән авызын каплап, маңгае тезенә тигәнче башын иде.

— Әйдә, — дип Назыймны җиңеннән иләп кенә тартты авыручы хатын, — абзар артына чыгабыз. Кай төшем авыртканны күрсәтәм!

Шәһәр вәкиле көлмәк җиңен ачу белән селтәнеп ычкындырды да эндәшмичә китеп барды. Хатын-кызлар шәрран ярып көлделәр. Назыйм Айгузинның кешеләр белән мөнәсәбәттә бер көндә алган икенче сабагы булды бу.

Урамда аңа колхоз рәисе очрады. Рәис сораганчы ук:

— Күнмәделәр, — диде Назыйм.

Моны ишетүдән кәефе кырылмады рәиснең, ул елмаебрак:

— Төнге сменага чыгачаклар алар. Беренче тапкыр гына аларга барып егылуыбыз түгел, — дип егетнең сүзләрен кире какты. — Аларны үгетләргә кирәкми. Хәлне аңлыйлар. Әйбәтләр. Кешеләр барысы да әйбәт лә, анысы. Тик адәм баласының мөмкинлеге чамалы, ялсыз-йокысыз яши алмый...

Фермада эшләүчеләр төнге сменага барысы да чыккан иде. Алар ярты төнгәчә ял итмичә эшләделәр, шуннан соң колхоз рәисе аларны кайтарып җибәрде. Эшчән хатыннарның көндез Назыйм Айгузинга чынлап та каршы төшкәннәрме әллә егет белән, аны юри котыртып, шаярып аласылары килгәнме — сугыш заманындагы хатыннар патшалыгында бу кадәресе гөнаһ саналмас — вәкил кеше моны соңыннан да белмәде. Ерак басудагы уракчылар янына барам, дип, колхоз рәисеннән атын сорады ул һәм, тарантаска утырып, атны урам иңләтеп кирегә борды. Гарип сатучыны кибеткә китертеп, аңардан ике буш шешә таптырды, аларга аракы тутыртты — сугыш заманында аракыны мичкәдән дә саталар, хәзергечә кысынкылык юк иде, шулай да авыл аракыга баш имәде, сугыштан эшкә яраксыз хәлдә яралылар кайткан көннәрдә генә хәмердән авыз иткәләделәр.

Назыйм уракчылар янында туктамады, алар турысыннан атын юыртты-рып узды. Урман читенә җиткәч кенә дилбегәне тартты. Юлның бер ягында арыш, икенче ягында бодай чәчелгән иде. Ике яктан да учларын тутырып башаклар өзде. Кабымлыкка башка ризыгы юк иде. Урман эченәрәк кереп, бәләкәй аланда туктап, бер шешәнең авызыннан аракының яртысын чөмергәч кенә, өлгереп җитмәгән миләш чемнәре өзде, чикләвек кәлпәләрен шактый тапты. Аракы артыннан кабарга урман җимешләре ярап куйды. Болай булгач, ике шешә аракы исертмәс кебек иде. Ләкин — кешенең мөмкинлеге һәр яклап чамалы! — Назыйм лаякыл иserде. Ярый ла икенче шешә аракыны, тарантас башын өстәл итеп, чуманга утырып эчте, югыйсә урманда аунап калган булыр иде.

Авылга кайчан һәм ничек кайтуын хәтерләмәде ул. Ат үзе борылып юлга төшкән булыр, дилбегә тәгәрмәчкә уралып өзелгән, мескен атка башын каерып хәтсез ара узарга туры килгәндер. Урман чыккач, басуларның иркенлегенә хәйранлап хозурланган кебек тә тоела, колхозчы агайнеләрнең кырда ничек эшләүләрен шушы калкулыктан күзәтеп кенә торам, бинокль белән, дигән карарга килгән кебек. Ындырда көрәк күтәреп куган хатынга ачуы кабарып алды, кышын шушы басуларда агач көрәгең белән кар тоттырам әле мин сиңа, дип ачу алмакчы булды хатыннан, абзар артына чакырган албасты гәүдәле хатын белән икегезне пардан куярмын, дип төкереген чәчте. Юл кайтуын авыл кешеләре күргәннәрдер, караңгы төшмәгән булгандыр әле. Чөнки, томан аша гына, бер малайның:

— Абый, күпер дыңгырдыгында кепкаң төшеп калды, — дип тарантаска кепка ыргытканын күргән кебек була. — Исерек абый, Исерек абый! — дип үртәлеп һәм кушамат тагып качты бугай малай.

Иртәгесен айныгач, башка бер нәрсә дә исенә төшмәде шәһәр вәкиле Айгузинның. Бәлки, урман авызында туктап, усал телле ике хатыннан үч алырга карар итүе төш кенә булгандыр, исерек Назыймнан куркып чатыр чабучы малай да очрамагандыр. Хәер, болары булмасын да, ди, ләкин барыбер авыл кешеләренең күзләренә күренерлеге юк инде аның. Колхоз рәисен ат утарында эзләп тапты, иртә иде әле, ат җигүчеләр килмәгән иде.

— Мин киттем, — диде ул колхоз рәисенә һәм, кием-салымнары, бүтән кирәк-ярагы тутырылган юл биштәрен асып — солдат гадәте — капкага борылды.

Колхоз рәисе эндәшмәде, шәһәр вәкилен капкагача озата барды, Назыйм тыкрыкка борылгач кына:

— Берничек тә ярдәм итә алмыйм шул, — диде. — Зыяным тимәде сиңа, файда итә дә алмыйм. — Кычкырып туктатмады, чөнки: — Авыл гафу итмәс шул сине, — дигән ышанычы үзгәрмәслек иде. — Кеше — уракта, мин — кунакта, димеш мәслəгеңне кабул итми авыл.

Вәкил Назыйм авылдан шулай чыгып качты.

... Айгузин авылда исереп хур булуын, ике хатынның үзен ничек мыскыллауларын төшереп калдырып, райбашкарма рәисенә үзе сөйләде. Аны эшеннән алдылар, партиядән чыгардылар, шөкер, сугышта яралануын искәреп, хөкемгә тартмадылар, үсеш баскычы җимерелүнең сөенече шул гына иде. Монысы, шөкер, бәхетсезлектә килгән бәһасез бәхет иде. Ә теге бер көндә ике сабак укыткан усал телле хатыннарны, бу хакта берәүгә дә сөйләмәсә дә, гомере буе онытмады. Аларга, фуриялəр, дип исем кушты. Фуриянең нәрсә аңлатуын китаптан укыган иде — укырга ярата ул, — фурия рим мифындагы үч алучы хатын-кыз Алла икән. Авыл хатыннары, Алла ук булмасалар да, урак өстенең эшсез вәкиле Айгузиннан, уйлый-сөйләшә белмәгәне өчен, үчләрен оста алганнар иде.

Назыйм партиягә яңадан керү өчен тырышмады. Ун класс белеме белән калды, җитәкче эш бүтән кызыксындырмады аны, үсеш баскычыннан бер тапкыр мәтәлеп башы тишелүне бик тә җитәргә санады. Һәм, үзенең уйлавынча, ялгышмады, токарьлыкка өйрәнеп, пенсиягә чыкканчы заводта эшләде, үзенә үзе хуҗа булды.

Урак өсте вәкиленнән эшче сыйныф вәкиленә шулай әйләнде ул. Эшче сыйныф исә илдә өстенлек итте, диктатура аныкы, пролетариат диктатурасының өстенлекләре чиксез саналды. Айгузинның куркып яшәмәвенә, бәлки, менә шушы күрсәтмә дә сәбәптер.

... Әнә, эшчеләргә фикердәш тиешле крестьян агае —фуриясе белән! — бушка тир түгүдән, налогын түләмәсә, кычкыртып сыерын алып чыгудан, череп баюга китерүе ихтимал бакчасын кисүдән дер калтырап яшәсен! Телләрен тыярлар!..

Назыймның, сабак укыткан ике хатын исенә төшкәндә, шулай уйлаганы да булды. Ләкин ялгышуын бик соң — ялгыз фатирында йокламыйча чыккан төндә генә аңлады. Аның фикерен Сайгушевның үкертеп талавы түгел, ә Мөхибә карчыкның көндезен кылган игелеге — юк, юк, алай гына да түгел, аңа калса, Айгузин, бала көткән хатынга ярдәмгә ташланып, үзе дә игелек кылды лабаса! — Мөхибә карчыкның тормышны яратуы үзгәрттерде. Мөхибәнең шушы изгелеген — дин тотуы изге итәдер аны — йокысыз төн чыкканда төшенде. Мин Мөхибә әби рухын аңлаганда, фуриялəр киләчәктә миңа сүз катарга куркырлар, дигән нәтиҗә ясады Назыйм карт. Тик килер гомере кыска калгандыр, баш очында Сайгушев карчыгадай очып йөргәндә, гомернең эх иткәнче киселүе бик тә мөмкин, "милиция минеке" булса да, мине генә саклап тормас...

Хәтер капчыгы актарылганда, Айгузинның моңарчы да курыкканы исенә төште. Малай чакта ук ике тапкыр курыккан икән ул.

... Назыймнарның үз алмагачлары да бар, сигезәү хәтта. Ел саен күп итеп алма бирәләр, җиргә коелганнарын җыеп та бетермиләр. Ә сул күршеләре алмагачларын Назыйм белгәндә генә утырттылар, аларның алмагачлары яшь, былтыр чәчәкләрен өзгәннәр иде, быел беренче алмаларын көтәләр. Шул алмалар кызыктыра малайны, үз алмаларын ул инде ашап туйган, тәмлелеккә

үз алмалары да тәмле, ләкин алмагачлары Назыйм туганчы ук утыртылган, картаеп баралар. Әнә, күршеләрнең яшь агачларындагы алмалар тәмлеләрнең дә тәмлеләредер! Күрше абыйдан әнә теге алсуланганнарының берсен сорыйсы килә, кыймый, бирмәстер кебек. Чәлдерсәң инде шул агачтан бер алманы, санамаганнардыр, бер алмалары югалуын сизмәсләр әле.

Һәм малай, күршеләренең өйдә юк чагын чамалап, киртә өстеннән сикереп төште дә, бәрәңге сабаклары арасыннан иелеп барып, алмагачы төбенә чүгәләде. Хәзер алманы үрелеп тә алып була, аскы ботактагысына аягүрә басмыйча да буе җитә. Этләре өрә башласа да куркыныч түгел, Акбай, дип пышылдап эндәшсәң, туктаячак, Назыймның тавышын таный, бәйдән ычкындыргач, Назыйм белән уйнарга ярата. Өрсәни тагын, котырынып өрсен, хуҗалары барыбер дә өйдә юк бит.

Назыйм алмага үрелде. Кулы, менә җитәм, менә җитәм, дип тора. Һәм Назыймны кызыктырган алма малайның учына үзе керде. Тик шул мәлдә малайның бөтен тәненә салкын йөгерде, эссе көндә дә шундый өшеткеч салкын булыр икән... Өзмәде Назыйм алманы, үзләре бакчасына, бер атлап, ике сикереп, дигәндәй, очып кына чыкты. Шунда гына тәненең өшегәне кайтты.

Әллә кайчангы хәлләрне бергә тезеп уйлансаң, алар арасында гаҗәп эзлеклелек, бәйләнеш барлыгын беләсең икән. Назыймның икенче тапкыр куркуы беренчесенең дәвамы лабаса, кеше әйберсенә кызыгудан икән анысы да.

Кайсы елда икән соң бу? Ә, әйе, утыз икенең кыш көнендә, Назыймга унөченче яшь киткәч, аны әтисе Йошкар-калага алып барган иде. Кунак йортында тордылар, икесенә аерым бүлмә, зур гына үзе, кояш ягында, искергән бинада мондый яңа кебек бүлмә булыр икән, әй. Икене кундылар. Әтисе көндезләрен йомыш белән йөргәндә, Назыйм шул бүлмәдә укып утырды, урамга чыкса да, кунакханәдән ерак китмәде. Урамда уйнарга танышлары юк, көннең дә рәте буталган, буран да буран, каян табыладыр шул хәтле кар — өзлексез ява. Казанда да кар явып калган иде, кышкы каникул көртләр өюдән бүтәнне белмәде быел. Иртәгә китәләр инде, Казанда аяздыр, каникул беткәнче тимераякта шуып, чаңгыда йөреп рәхәтләнергә өлгерер әле Назыйм.

Кичен әтисе бер абый белән кайтты. Әтисе, чәй янына утыргач:

— Теләнеп йөрүләре кыен ла соң! — диде. — Үзем өчен түгел ләбаса, дәүләт агачын дәүләт заводы өчен сорыйм. Әллә ничәмә кәгазьгә кул куйдырттылар. Болай барса, илнең бөтен агачы рөхсәт кәгазе эшләүгә китмәгәе.

Малай бу офтануның мәгънәсенә төшенеп җитмәде. Таныш түгел абыйның:

— Элемтәнең ныклыгын кәгазь беркетә, агайне. Тик моның бер генә "ские" бар — кәгазьне тамга бизәсен. Тамгалар күбрәк булган саен — шәбрәк, — дигән сүзләре колагы янышнан гына узды аның.

Абый иелә төшкәч, малайның борынына аракы исе бәрде. Назыйм, күзләрен тутырып, әтисенә карады, эчкәне сизелми иде әтисенең. Эчә күрмәсен, эчсә, атна буена туктамый аннары. Йошкар-калада, Матур-кала булса да, тагын атна торасы һич тә килми Назыймның. Абый кеше чалбар кесәсеннән капкачлы сәгатен чыгарып карады, аны өстәлгә куйды, чылбырын эләктермәгән икән. Әтисе белән абый кеше тәмәке көйрәтергә чыгып киткәч, Назыйм сәгатьне теге абый кебек еракка тотып карады, колагына куеп тыңлады, бер көйгә теркелди иде сәгать. Әгәр... әгәр Назыйм сәгатьне алып яшерсә? Абый кеше, аракы эчкән килеш, сәгатен өстәлгә куюын хәтерләмәс тә бит. Әтисе таптырсамы? Ничек таптырсын ди, абый кешенең сәгатен өстәлгә куюын күрмәде бит ул, соңыннан да сәгатькә игътибар итмәде. Алмадым, дияр Назыйм, ә сәгатьне... Кая яшерер икән соң сәгатьне? Әй, сәгате булса, яшерер урын табылыр ла! Бәдрәфкә, дип чыгар да, кар астына тыгар. Аннары Казаннан килеп алып китәр. Йошкар-калага юлны белә хәзер. Әтисе Назыймны әрләмәс

тә әле. Нигә әрләсен икән, малаеның сәгатьле булуы начар түгел ич, Назыймга сәгать алып бирергә барыбер акчасы юк ич аның.

Сәгать хуҗасы тәмәке тартырга чыкканнан кире кермәде. Бик тә шәп әле бу, хәзер сәгать урламыйча да Назыймныкы була. Һәм малай сәгатьне кесәсенә салып алды, аннары куенына яшерде. Шул мәлдә коты очардай булып нәрсәдәндер курыкты, авызыннан бөтенләй көтелмәгән сүзләр атылып чыкты:

— Әти, теге абый сәгатен оныткан. Табабызмы инде без аны капкачлы сәгатен бирергә?

Сәгатьне бирергә теге абыйларга әтисе белән барды Назыйм. Тик абый кеше сәгатен кайтаруга әлләни сөенмәгән кебек иде, сәгатьне өстәлгә ташлагандай итеп куйды ул.

... Алма һәм сәгать вакыйгаларыннан соң, Назыйм кеше әйберенә кызыкмады, гомумән, әйбер колы булмады, өендә иң кирәкле нәрсәләрне генә тотты, хатынының еш кына кабатлауларына карамастан, мая өстенә мая өймәде, хатынына да рөхсәт итмәде. Сайгушев талаган биш йөз сум акчасы беренче запасы иде. Үлемтеккә, дип җыйган. Хатынын җирләгәндә, мондый чыгымга әзер булу зарурлыгын белде ул.

... Таң алдыннан Назыймны йокы басты. Әмма карт, бу төнне йокламаска, дигән сүзендә торды. Салкын су белән юынды. Яктырып кына килә, урамда йөрүчеләр ишле түгел.

— Ярый ла алманы һәм сәгатьне алмаганмын! — дип сөенде Назыйм карт. — Ярый ла курка белгәнмен! Шул чакларда коелып төшмәсәм, бурлык юлына басасым икән. Йөрер идең хәзер кеше әйберен Сайгушев сыман урлапталап! Хәер, моңарчы төрмәдә черер идең инде. Җинаятьчеләр арасыннан астыртын эш йөртүчеләр генә озаграк яши... — Төн утырып ясаган нәтиҗәсен кемгәдер ныклап аңлатырга теләп сөйли иде ул, тирәсендә кемнәрдер бар кебек иде. — Ә... Ә бүген Сайгушевтан куркуым — үз гомеремдә өченче тапкыр куркуым икән. Монысы малай чактагы куркуларыма бөтенләй дә охшамаган...

Назыймга хатыны иртәнгә гел җылы ризык әзерли иде. Ялгызы калгач та шушы тәртипне тотты ул. Тик бүген ризык пешерәсе килмәде, элекке көннән калган тавык шулпасын кичә үк бетергән иде, шуннан соң кичәге ыгы-зыгылы, давыллы көн коры-сары белән узды. Кайткач, бәрәңге йә ботка пешерермен әле, дип уйлады. Иртәнге якта шәһәр яны поездларында кеше күп була, шәһәрдән Юдингә һәм Васильев бистәсенә эшкә ашыгучылар шактый, балыкчылар Обсерваторияне узып та китәләр, бу чакта Сәвади Сайгушев поездда йөрмәс. Милиция хезмәткәренә, бандит белән очрашса, җибеп төшмәскә ышандырса да, куркуы көчәя генә барды. Иртәнге поездны сайлап дөрес иткән иде Назыйм, ләкин Обсерватория тукталышында бер үзе генә калгач, Сайгушевны очратудан куркуы калтырануга ук әйләнде. Монда торып та куркуны басып булмый, Казанга баручылар теге яктан тиздән киләчәк поездга утырып китәчәкләр. Һәм карт тау итәгендәге дачасына урамнан әйләнеп керде, тар тыкрык сукмагы үзе үк шикләндерде аны. Әгәр Сайгушев аны дачасында көтеп торса? Юк ла инде, болай уйлау чиктән аша, бандит аның дачасының кайдалыгын түгел, дачасы барлыгын да белми бит. Беләдер, кичә кайнатмаларны сумкасы белән урлаган иде. Паспортны карагач, дачасы кайда, дип сорашып йөргән булмагае...

Дачасында озак кайнашмады Айгузин, базда кайнатмаларны, кәгазьгә аерымлап төргән алмаларны карчыгы йөрткән сумкага — Сайгушев тоткан сумканы милиция кешесе алып китте бит — тутырды да кайтыр юлга ашыкты. Табигатькә кичәге кебек сокланып торырга теләге юк иде. Табигате дә бүген кичәгечә тынып та дуамалланып тормый, гел дә тыныч бүген, бу аязлык шактый сузылыр кебек. Ә картның күңелендә гарасат һаман котыра, әллә тынарга исәбе юк тагын. Сайгушев очрау ихтималы да поездда йөрүчеләр күбрәк чакта кайтырга ашыктырды аны.

Айгузин килгәндә, Мөхибә карчык бала табу йортының айванындагы озын эскәмиядә мул төенчегенә таянып утыра иде. Назыйм, аны күреп, артка тартылып куйды, карчыкны очратырмын, дип уена да китермәгән иде. Ә Мөхибә йөз чакрымдагы Сабасыннан килеп тә җиткән әллә кайтмаган да инде.

Мөхибә Назыймны ишарәләп чакырды, янәшәсендәге күн тышлы тәбәнәк кәнәфигә күрсәтте. Карт, изүен чишеп, бүреген салып, шунда җайлап утыргач кына, карчык:

— Исән-имин уздырдыңмы көнне-төнне, Назыйм энем? — дип пышылдабрак сорады һәм кучтәначләр бирү тишегенә ымлады. — Тавышланырга ярамый монда.

Назыйм, моңа үзе күреп ышанырга теләгәндәй, кечкенә тәрәзәгә карады. Шуннан соң гына карчыкның хәл белешүенә:

— Әйбәт, — диде. — Әйбәт. Исән-сау. Кулларның... — диде дә шып туктады, икенче кулын да Сайгушев кысып авырттыруын сиздерәсе итмәде, Сайгушев белән поездда булган хәлне дә әйтмәгән иде ул. — Кулның сызлавы басылды. Чатнавы зур түгел икән, әле врачка күрендем.

— Кичә, шушы бала хәле белән, — дип, тагын ишарәләп кенә, коридор ишегенә күрсәтте карчык, — сорамаганмын, ваемсызланып, — дип үзен әрләде. — Нишләттең соң кулыңны?

— Әй-й, булды инде шунда! Дачага барган идем бит кичә дә. Беләзеккә... шүрлектән... чүкеч төште...

— Төшмини, шүрлеккә чүкеч япергәч соң! Гомер итеп, чүкеч урынын да белмәгәч, — дип әрләү сүзеннән Назыймга да өлеш чыгарды Мөхибә. — Әә, Назыйм энем, мин теге баланың исемен белештем бит. Гөлсәхра икән аның исеме. Гөлсәхраның әти-әнисе дә, кайнатасы белән кайнанасы да кичә үк килгәннәр, — дип шәфкать туташы әйткәннәрне Назыймга ирештерүгә күчте карчык. — Оныклары туугa бик сөенгәннәр, ди. Гөлсәхра өеннән качып чыгып киткән икән. Син уйлаганча ямьсез түгел икән сәбәбе. Кеше турында начар итеп уйларга атлыгып торган чакларың еш бугай синең. Дөнья ул, Назыйм энем, әйбәт кешеләр белән тулы.

— Сай... — Айгузин, Сайгушевлар белән дөнья тулы, дип каршы төшмәкче иде, бандит турында Мөхибәгә әйтмәскә кәҗәр итүе келт итеп исенә төште. Сүзенең бүленүенә сәбәп итеп, йөткерде. — Сайрак шул минем акыл.

— Шулай, Назыйм энем, Гөлсәхраны поездда бәбәй табарга бүтән нәрсә мәҗбүр иткән. Үзе шулай теләгән. Аны гаепләргә ярамый.

Карт җилкәләрен сикертте.

— Хатын-кыз тузга язмаганны эшләргә оста инде.

— Һаман да начарга түнеп уйлыйсың бит, кем, Назыйм! —дип картны ачуланды Мөхибә. — Гөлсәхра тол калган икән инде! Син юкны такылдыйсың! Тефү, тефү! Гөнаһка кертәсеңме инде мине, гомер итеп, яхшыны өстен итә белмәгән башың белән, дим!

— Шул яшеннән тол калганмы?! — дип ышанып җитмичә сорады Назыйм. — Корсаклы килешме?

— Шул яшеннән! Әле иренең кырыгы да җитмәгән! — дип үзенә хас булмаганча кызуланды карчык. — Синең холкыңда, Назыйм энем, ак белән кара бергә кушылырга атлыгып торалар икән. Үзең Гөлсәхрага кучтәнәч китергәнсең, үзең Гөлсәхрага яла якмакчысың.

— Бардыр холыкның чатаклыклары, — дип аска карады карт.

Мөхибә тиз генә тынычланмады. Моңа, Назыймның киреле-морлы сөйләве белән бергә, шәфкать туташыннан ишеткән хәбәрләре дә сәбәпче иде.

— Үтергәннәр Гөлсәхраның кияүен! Поездда йөрәгенә чәнчегәннәр! Шуннан соң, баламны поездда табам, дип үзенә сүз куйган Гөлсәхра. Исерекләр чәнчегән!

Сайгушев чәнчегәндер, дип сискәнде Айгузин. Ләкин карчык:

— Исерекләр поездда теләсә кемгә бәйләнеп йөргәннәр, Гөлсәхраның ире шуларны тыйган, — дип ачыклагач, шикләнүе кимеде.

Сайгушев түгелдер, Сайгушев үз эшләре арасыннан да шаһитлар нияртмәс, дип уйлады Айгузин.

— Өчәү булган исерекләр, — дип авыл хатыннарына хас рәвештә тәгәлли барды карчык. — Тотканнар ди инде шуларны. Хөкем ясаячаклар ди. Хөкемдә генәме соң хикмәт — ана тол калгач, бала ятим тугач... Поезд тулы кеше өч исерекне тыя алмасыннар инде, йә...

Димәк, Сайгушев Гөлсәхраның ирен чәнчүчеләр арасында булмаган, чөнки тегеләрне тотканнар, ә Сайгушев иректә һәм аның яңа җинаять кылуы ихтимал. Хәер, җинаятьчеләр өч исерек һәм Сайгушев белән генә бетсә икән, дигән фикергә килде Айгузин.

— Баласы бәхетле була күрсен, Гөлсәхра бүтән зур кайгы кичермәсен, — диде Назыйм.

— Хатын-кызга тол калудан да авыр кайгы юк, Назыйм энем, — дип йомшады карчык. — Толлыкның ни икәнен кичергән кеше генә белә...

— Шулай, шулай... Үзем дә карт көнемдә ялгызым. Өстәвенә малаем да югалды. Әллә Гөлсәхраның ирен чәнчегән кебекләр кулыннан узды инде...

— Малаең? Син, менә мондый йортларга йөрмәдем, дигән идең бит кичә. Алдаша торган кешемени син? — дип аптырады Мөхибә.

— Юк, мин алдашуны белмәдем, — дип башын чайкады Назыйм карт. — Бар иде малаем. Малаебыз. Уллыкка алган идек. Балалар йортыннан. Алты яшендә. Үз хәтере тота башлагач. Әти-әнисе балалар йортына үзләре биргән. Акыллы бала иде. Упкынга төшкәндәй юкка чыкты менә. Чит итмәдек. Ялгышып та бармак белән дә чиртмәдек, — дип хәсрәтен ачты карт. — Үзе дә безгә мәрхәмәтле иде. Үз ата-анасыдай күрде. Безнең малай түгеллеген белсә дә. Шундый хәлләр, Мөхибә әби... — дип тирән сулады карт, боларны Мөхибәгә сөйләгәч, күңеле бушанды, карчыкны кеше кайгысын җиңеләйтерлек игелекле кодрәт иясе итеп саный иде, сиксән яшьлек карчыкны бүген шул әүлиялек сәфәр чыгарган лабаса. — Инде бер өметем, — дип дәвам итте Назыйм карт, өметенең чынга ашырлыгын тикшереп карарга теләгәндәй, күзләрен кыса төшеп, уйланып торды, — өметем, Мөхибә әби, малаем, малаебыз үз әти-әнисен эзлидер, дим. Миңа белгертәсе килмәгәндер ниятен. Әти-әнисен тапкач, миңа хәбәр салмыйча калмас. Балага үз ата-анасы якынрак. Якын. Тапсын иде әти-әнисен! Сөенер генә идем! Мине барыбер ташламасына ышанам мин аның... Гөлсәхраның баласы гомеренә җуелмас кайгыга карап туган икән. Һич гаепсезгә. Үскәч, гөнаһсыз адәм, ул да әтисен эзләп йөрер инде...

— Бу дөньяда берәү дә кайгы-хәсрәтсез булмый микәнни... — дип Назыймның сөйләвенә йомгак ясагандай әйтте Мөхибә. — Шулайдыр шул. Шуңа күрә дә Ходай Тәгалә адәм баласын гөнаһ кылмаска өндидер. Гөнаһ кылмаучыларга гына җәннәт ишеген ача ул. Гөнаһ кылмаучыларны гына оҗмахта яшәтеп, аларның кайгы-хәсрәтен бетерә Аллаһы Тәгалә...

Күчтәнәчләрне сәгать дүрттә ала башлаячаклар, аңарчы сәгать чамасы вакыт бар иде. Карчык белән картның, күптәнге танышлар булмагач, сөйләшер сүзләре бетеп торды.

Назыймны йокы баса башлады, аның, күзләре йомылып, башы салынып төшә дә, кинәт сискәнеп китә ул. Мөхибә моны күрә, талчыга карт, җитмешендә бирешкән, кайгылары авырдан икән шул, килер көннәргә өметен басмагайлары, дип уйлана. Назыймны юатырга сүзләр эзли, хәзергә таба алмый.

Карт, черемнән айнып, күз төпләрен каты басып сыпырды.

— Йокы сагынып алды үземне. — дип шаяртты. Һәм: — Йорт-җирең исән-сау торганмы, соңлаган өчен күршең әрләмәдеме соң? — дип сорады.

Аның соңлаган соравы Мөхибәгә сүзне яңа эзгә салырга җай булды. Урыныннан кузгалып куйды ул. Назыймга табарак борылды, шушы кечкенә хәрәкәтләре аның бөтен тәненә һәм сөйләвенә җиңеллек бирде.

— Әйе шул, ике көн буена гел ямьсезлек турында сөйләшәбез, — диде карчык. — Әйттем ич инде, дөнья әйбәт кешеләр белән тулы. Үзебез танып бетерә алмыйбыз шуларны. Кайтуым да, килүем дә хәвеф-хәтәрсез узды, Назыйм энем. Өйдәгеләр дә исән-сау.

— Өйдәгеләр? Өемдә күршем калды, дигән идең бит әле кичә. Син үзең төрлечә сөйләргә яратасың ахры, Мөхибә әби, — дип карчыкны ялганда тотмакчы булды Айгузин.

Мөхибә кеткелдәде.

— Хәйлә корсам, мин үземне тоттырырлык итмим! Авылның хәзерге тормышын аңлап җитмәгәнгә шикләнүеңдер. Малаем, киленем, өч оныгым белән бергә яшим мин. Хак дөресе. Ә өемдә күршем калды. Хәзер бит авылда карт-карчык үз балаларының хезмәтчесенә әйләнде. Ничекме? Менә болай. Яшьләр бөтен хуҗалыкны карт-карчыкка ташлыйлар да йә эшенә, йә укуына чыгалар да китәләр. Өйдә гамьнәре юк. Сиксәнен тутырган карчык пешерсен дә төшерсен, эшем кешеләренең кайтуына ризык өстәлдә торсын, йөзләрен чытмыйча гына ашасыннар иде, дип борчыла белсен әле өстәвенә. Менә шуңа күрә күршекәем белән, беребез сәфәр чыкканда, икенчебез ике өйне бер итәбез. Төенчегемдә Гөлсәхрага күршем биргән күчтәнәчләр дә бар, бәбәй ашыбыз булыр, диде. Гөлсәхраның бәбәенә биләү әйберләре дә юнәттек. Ә балаларым барысы да әйбәт минем. —Мөхибә мамык шәлен төшергән иде, яулыгы кысыбрак торган, аны бушатыбрак бәйләде. — Малаем бик дәрәҗәле, — диде карчык, озаклап елмайды.

Айгузин бу елмаюда шаянлык сизмәде, намазлыкка кунаклаган әбидә нигә шаянлык булырга тиеш икән, дип гаҗәпләнде.

— Малаем арада олысы, — дип дәвам итте карчык, — ике кызымнан олысы. Әйтәсе юк, мәртәбәленең мәртәбәлесе. Кулыннан эш килә, авылда дәрәҗәсе бик тә зур. Кичә төнге унда машина белән китереп куйдылар үзен. Тәрәзәдән карап тордым, машинаның ишегең кечкенә капкага туп-туры итеп туктаттылар. Арыганын белгәннәр инде. Малаем балта остасы минем хәзер, көне буе балта чабу да чүкеч сугу элеккечә өстәл төю түгел шул — бер генә дә артык адым ясамасын, дигәннәрдер. Керде балакаем өйгә. Менә, Назыйм энем, уңга да сөялә, сулга да сөялә улым, бөтенләй беткән. Киленем чишендереп яктырды. Иртүк торып тагын эшенә китте, айнып җитмәгән иде. Исән чыгып китте, ничек кайтып керер инде... Малаем, коммунистлыкка кергәч, намаз укудан тыймакчы иде мине. Аңардан яшереп укыдым. Хәзер минем намазлык җәйгәнне күрергә вакыты юк, бик тә эшем кешесенә әйләнде. Балта белән акча суга. Үзенә җитә тагын акчасы.

Инде Назыйм башын чайкап көлде, исерекләргә гомеренә көлеп кенә карады ул, вәкил чагында лаякыл исерүеннән соң, аракыны авызына якын китермәде. Мөхибәне сүз әйтеп бүлдермәде, тыңлап кына утырды.

— Киленемнең әйбәтлеген белсәңме?! Бөтен Сабасында юк минем киленемә тиң! Чын менә! Күршекәемнең килене хурлавым булмасын, аның килененнән дә әйбәт минем киленем! Әнкәй, дип бөтерелеп йөри янымда, авырый калсам, эшендәге чүт төймәләрен оныта, баш очымнан китми. Киленем тота йортны. Миннән ни файда соң, өй каравыллаудан бүтәнгә ярамыйм. Шулай да какмый киленем. Үзем дә, ботка пешерсәм дә, куерак ягыннан киленемә бүләм...

Мөхибәнең килененә ихластан хөрмәте йөзенә чыккан иде. Әүлия килен туры килүенә сөенече гомерле, дип уйлады Назыйм.

— Олы кызым Юдиндә, үз йортлары белән торалар. Киявем поезд йөртә,

Харьков дигәненә дә бара. Мәскәвенә дә. Кече кызым авылда, яңа йорт җиткерделәр. Абыйлары, улым инде, бик тә булышты, рәхмәт яугыры, кулында эш уйнап тора шул, туганнарына ярдәмен кызганмый. Кече кызымның һөнәре генә ошап бетми үземә. Кешенең... Йомшак җиренә инә кадарга өйрәттеләр аны. Тефү, тефү, гөнаһымны кичер, Ярабби... —Карчык авызын учы белән каплап торды. — Юдиндәге кызым доктор бит, авылдагысы апасы эзеннән китмәкче иде, тик институтка алмадылар, хәзер, балалар үстергәндә, укуын онытты, укол кадавыннан уза алмас.

— Шәфкать туташлары врачлардан күбрәк дәвалый авыруларны, — дип сүз катыштырды Назыйм. — Һөнәре әйбәт кече кызыңның.

— Шулай булмагае! — дип кырт кисте карчык. — Нәрсәнең юньле, нәрсәнең начар булуын аермый ди Мөхибә! Аермам менә! Укол кадау да дару эчерү доктор кушканны үтәү генә! Үз башыңны эшләтәсе юк! Үз башыңны эшләтергә иренмәскә кирәк! Башың эшләмәсә, ялкауга чыгасың, хәерчегә каласың. Нигә кызым соранырга тиеш ди?! Ялкауланырга барыбер дә юл куймам мин аңа! Төпчек баланы иркәләү хәтәр икән. Иркәрәк үсте ул. Гел дә хатын-кызга гына кадап калмый ич инәсен! Азуы да бар яшь кешенең...

Айгузинның шәфкать туташының мактаулы якларын яклап әйтерлек дәлилләре булса да, эндәшмәде ул. Диндар карчыкны кызының бүтәннәрнең ялангач тәнен күрүенә борчылуын бетерерлек сүз эзләмәде.

Бераз вакыт тагын тын утырдылар. Ләкин Мөхибәнең балалары һәм оныклары турында сөйләүдән теләге кайтмаган иде.

— Тамак кыруымнан ук аңлагансыңдыр, хәзер кызымның кызын мактыйм, — дип сөйли бирде карчык, бу искәртүенең Назыймга ничек тәэсир ясавын белер өчен, аңа таба карап алды. — Мактыйм гынамы соң, мактанам! Менә кече кызымның кызы чынлап торып начальник инде! Эшләгән төшендә аның сүзеннән чыккан кеше юк. Биетеп тә күрсәтә инде ул кул астындагыларны! Берсе-берсе каршы сүз әйтергә базмый үзенә, кушканын үтәп кенә торалар. Әй-лә, ил башында утыручыларның сүзләрен шулай тыңласыннар иде ул. Юк шул, аларның сүзен тотмыйлар. Менә син дә каршы төшәсеңдер әле, — дип кинәт башкага күчте карчык. — Без, без, дип, кушканның гел дә киресен кылырга күнеккән бит сез. Анысы, бу дөньядан китәр заманым җитсә дә, иләмәнебезнең вәгазьләренә үзем дә ышанып бетмим. Бигрәкләр дә боргалый да сыргалый, һич кенә дә төгәл сүзе юк. Ил тәхетендә утырган кешегә ярамый болай. Торгынлык дигәнегездән әллә кайларга чигендек ләбаса. Хәзергесенә, заманалар узгач, чигенү чоры, дип исем тагарсыз микән? Исем кушу белән котылырсыз аннары. Безнең илдә юньсезлек кылган түрәдән җавап сорарга гадәтләнелмәгән, лаеклы ялга җибәрәләр андыйларны, лаеклы түгеллеген һич кенә дә исәпләп тормыйлар.

— Сез, сез, дигәннәрең миңа кагылмый, Мөхибә әби, — дип бүлдерде Айгузин. — Мин дә синеңчә уйлыйм. Гомеремдә иркенлекне һәм муллыкны күрәм икән бер, дип ышанган идем башта. Сиксән бишенче елда. Шуннан соң ышанычым кимеде дә кимеде, инде бөтенләй бетте. Яшермим фикеремне.

— Нигә яшерергә ди?! Бөтен ил шуны сөйли бит. Безне төрмәгә утыртып, берни дә кыра алмаслар. Шуңа күрә иркенләп сөйлибез бит менә. Без әйтмәсәк, кем әйтер боларны? Яшьләрме? Яшьләрнең шүрләүчеләре дә булыр. Без әйтик әле, безнең хакыбыз зуррак, илнең таудан тәгәрәвенә дә элек-электән без шаһит! Сине төрмәгә ябудан халыкның хәле яхшыра, дисәләр, үзем барып керәм төрмәләренә! Чын менә! Үз илеңдә тәртип урнаштырып байыйсы урында, дөнья буйлап хәер сорашып йөр инде, йә?! Шулмы ил башлыгының эше! Яратмыйм хәер сорашуны! Шуңа күрә кече кызымның, үз башын эшләтмичә, ялкауланып, хәерче хәленә төшүеннән куркам... — дип үзенә турыдан кагылышлы мәсьәләгә килеп чыкты карчык. — Чит кешеләр санын күреп, күңеле азмагае, дим. Күңел азу, анысы инде, ялкаулык билгесе.

... Ике карт кешенең сәясәт дигән нәстәкәйнең эченә кереп сөйләшүе гаҗәбрәк иде. Ләкин мондый әңгәмә булды. Чөнки хәзерге буталчык һәм азгынлык көчәйгән заманда берәү дә читтән күзәтеп кенә тормый, һәр вакыйгага мөнәсәбәтен белдерә, ахырында, телен әйләндереп әйтмәсә дә, күңеленнән һәркем нәтиҗә ясый. Туры сүзле Мөхибә белән Назыйм да фикер иясе кешеләр, ил язмышы турында олыдан кубып уйлану аларга һич тә ят түгел (хәер, Назыймы, акны карадан аерып, тәгаен сөйләргә гадәтләнмәгән). Аннары, Мөхибә әйткәндәй, аларның хаклары зур, алар илнең җитмеш еллап гомерен үзләре күреп беләләр.

— Ерактан әйләнеп йөрдек, Назыйм чордаш, — диде карчык, тынычланган иде ул. — Кызымның кызы — зур начальник, дигән идем. Начальник шул! Балалар бакчасында тәрбияче ул. Таптың түрә тәхете, дисеңме? Ю-ук, Назыйм энем, балаларны тыңлата алу иләмән хезмәтеннән авыррак. Беләсеңме, өйдә әйбер тотуда гел дә үземә охшаган шул оныгым! Өйдә юньлерәк җиһаз да торгыза алмыйлар, барлык юньлене балалар бакчасына ташый. Өйдәге тәм-томны да, балаларның кайсына бирәсен әйтә-әйтә, иртәдән тутыра башлый. Рәхмәт яугыры! Әйбәт кияү туры килсен үзенә, бәхетле яшәсеннәр. Тик йөргән егете юк әлегә, — дип тирән сулады карчык.

— Тормыш дигәнең без телägәнне генә кылып тормый шул.

— Балаларымның балалары гел кызлар минем. Берсе дә кияүгә чыкмады әле. Малайлы кеше, кызыңны киленлеккә бир, дип сорап бара, малаеңны кияүлеккә алабыз, дияргә гадәтләнелмәгән. Оныкларымның башлы-күзле булганнарын күрсәм канә... Олыгаебрак киттем. Аякларым бик сызлау, болай чатыр чапкандай йөрүемнең газабын үзем генә беләм. — Карчык туны итәкләре өстеннән тез башларын ышкыды. — Озын гомер ителде. Күзләремнең нуры бетә. Монысы, — дип сул күзе төбен сыпырды ул, — бөтенләй күрми. Уңын да томан каплый бара. Ходайның рәхмәтедер, — дип тагын көлемсерәде карчык, — оныкларым чамадан узып шаярышканны уңы күрми башласа, шул наныйларыма бармак янарга сул күзем күрә! Ышанмаслык хәл менә!

— Күңел күзең җете, Мөхибә әби! — дип сөендерде карчыкны Назыйм. — Әүлия син!

— Әүлия үк түгелдер дә, тик начар кеше дә түгелмен. Әүлиялыкка зур гыйлемлек тә кирәк, Назыйм энем. Революция дигәннәренә чаклы кечкенә булып укый алмадым. Совет чорында дүрт сыйныф кына укып калдым. Гарәп әлифбасында. Латин һәм урыс әлифбаларын соңыннан өйрәндем. Киленем яздырган гәзитләрне үзем укый идем, хәзер аның укыганын тыңларга гына калды. Әбием, әтиемнең әнисе, бик тә укымышлы иде. Булган гыйлемемне әбием бирде. Тормыш та өйрәтте. Гап-гади авыл карчыгы мин. Шуннан бик тә канәгать үзем. Аллага шөкер.

... Бала табу йортына килүчеләр ишәйде. Шәфкать туташы тавышлан- маска кушты, кереп китәргә җыенгач, коридор ишеген кире япты да карчык белән карт янына килде.

— Бик озактан утырасыз, бирегез кучтәнәчләрегезне, —диде ул. — Гөлсәхра кемегез соң сезнең? Әтисе белән әнисе бүген иртән дә килгәннәр иде инде. Гөлсәхрага күп ризык кирәкми бит.

Назыйм пакетын шәфкать туташына ачмыйча сузды, ләкин кыз аны актарды, яшь анага ашарга ярый торганнарын гына алды. Мөхибә кинәт каушады, бер үк сүзләрне дә кабатлады.

— Мин... мин Гөлсәхра малаеның кендек әбисе булам. Кендек әбисе китергән ризык сабыема анасы сөте белән керсен. Баланың кендек әбисе мин. Әйберләремнең барысын да ал, анда ярамас ризык юк. Сабыйга нәрсә кергән кендек әбисе әйбәтрәк белә. Кендек әбисе мин сабыйның. Тәһарәтем бар, шөкер, тәһарәтсез йөрмим. Кичә һәм бүген калган намазларымны иртәгә җыеп укыйм,

Аллаһы боерса... Карале, дим, кызым, кайчан чыгарырлар икән аларны?

— Берсекөнгә чыгарырлар да инде. Икесенең дә кәефләре әйбәт кенә.

— Шулай була күрсен, Ярабби. Гөлсәхра, наныем ла инде үзе, җиңелдән тапты бәбәен, Аллага шөкер. Карале, дим, кызым, бу картның күчтәнәчләрен аерып бир, яме, поездда синең өчен борчылган Назыйм исемле карттан, диген. Күчтәнәчләребезне алдан алуың әйбәт, кызым. Болай булгач, соңгы автобуска калмыйм икән, аннан алдагысына өлгерәм. Рәхмәт, кызым, игелек күр, сабыйга мәрхәмәтеңнең савабы үзеңә тисен. Шулай ул, кешенең бәхете — башкаларга игелек кылуда...

Айгузин Мөхибә карчыкны автовокзалга бүген дә озатты. Карчыкның шәһәр йортларын исендә калдыруы турындагы кичәге сүзләренең мәгънәсен бүген белде бит ул — зур әйберләрне генә шәйләп йөри икән ич Мөхибә әби.

Бүген Назыймга сугышта катнашучы таныклыгын күрсәтергә туры килмәде, автобуста буш урыннар бар иде. Шулай да ашыгырга мәҗбүр булдылар, юлаучылар автобуска утырышканнар иде. Назыйм Мөхибә карчыкны автобуска кертеп үк утыртты. Бер егет, алдагы урынын карчыкка биреп, артка күчте.

— Рәхмәтләр яусын сиңа, Назыйм энем. Авырмыйча яшә. Чир күрмә. Кулың тиз савыксын. Малаеңны көт. Тиз кайтыр ул, Мөхибә карчык әйткән иде, диярсең, — дип саубуллашты Мөхибә.

— Үзеңә дә изге теләкләрем, Мөхибә әби, — дип башын иде карт.

Аларның соңгы очрашуы булган икән бу...

Назыйм шәһәр үзәгеннән әйләнеп кайтасы итте. Үзәктәге "Табигать байлыклары" дигән кибеттә үзгә ризыклар саткалыйлар, онытылганда бер ат ите чыгаргалыйлар, бәлки, шул вакытка туры килер, чираты озын була инде озынын, торыр, ашыгасы җире юк. Дачадан кайткач пешергән бәрәңгесе, кем әйтмешли, коелып бетте, кичкә озаклап кайнатып аш пешерер, бу яшьтә ачлы-туклы йөрү сәламәтлегенә шәп тондырыр югыйсә. Әмма кибеттә ат ите юк иде. Сыер ите алды, җелекле сөяклесен үзе салдырды, ашка өресе мул чыга андый итнең. Троллейбус тукталышы янындагы хуҗалык әйберләре кибетенә керде, пычак сайламакчы иде. Ләкин сайларга түгел, сайламыйча алырга да юк икән пычак. Бу кибеттә күптән булмаган иде, шүрлекләрнең шәрәләнүенә хәйран калды. Нишләде бу тормыш, кая барабыз без, бармыйбыз, алтынчы ел инде элекке үребездән дә кирегә тәгәрибез, дип уйлады Айгузин. Каһәр суккыры Сайгушев, азган җан, пычакны сындырды, кибеттә пычак юк чагында. Пенсиягә чыгар алдыннан үзе ясаган пычагының йөзе дугаланып килгән иде, бәрәңге әрчергә җайлы иде тагын. Үткен һәм очлы, бәрәңге күзәнәкләрен чокып кына ала иде. Кибеттә пычак та калмасын инде, йә?

Шулай уйланганда, Мөхибә карчыкның троллейбуста сөйләгән мәзәк хәле исенә төште.

Мөхибә троллейбуста Назыймга:

— Сиңа да тиштерим әле талон, — диде. — Күбәйде болар.

— Мин бушлай йөрим бит. Кирәкми.

— Кирәктер, димим лә. Кая куйыйм ди бу талоннарны?

— Нигә шулай күп алдың соң? Гел шәһәрдә йөрергә ахры исәбең.

— Юк ла, — дип йодрык хәтле генә калган төенчеген селтәде карчык. — Үз өемдә эшем бетмәгән. Бүген Гөлсәхра да бәбәй хакы өчен генә килдем. Ниятемне киленем бик тә хуплады, аның да сүзен аяк астына салып таптарга ярамый, алай итсәм, юньсез булырмын. Ходаем, кичер...

Карчык, бала табу йортына барганда, бер егеткә акча сузган. Бер генә талон сораган, акчасы вөчлек икән. Шаян телле егет булгандыр, әбигә мондый киңәш биргән.

— Әби, кибеттән әйберләр алырга килгәнсеңдер инде син авылдан, —

дигән егет. — Кибетләрдә барыбер бер нәрсә дә юк, әби, ичмасам, троллейбус талонын учыңны тутырып алып кал, анысы да бетәр.

— Беләм инде егетнең шаяртканын, — дип аңлаткан карчык талоннары күплеген. — Шаяртуына сөенеп куйдым бит шул егетнең! Алайса өч сумлык бирсен, дидем, бер дә аптырап калмадым! — Карчык, гадәтенчә, еракка китеп нәтиҗә чыгарган. — Боздык ла тормышны. Сикәлтәле-чалулы булса да, юлдан бара идек, көн итү тарафында, дим. Тар тыкрыкның чокыр-чакырлы сукмагына капылт кына кердек тә киттек...

Тар тыкрык, тар тыкрык, дип күңеленнән кабатлады Назыйм. Иртән дачасына барганда, Сайгушев очраудан куркып, тар тыкрыктан турыга бәрмәгән иде ул. Сайгушев кичә, сумкадагы кайнатмаларны күреп, Айгузинның дачадан кайтуын сизенгәндер дә, Обсерватория поселогы кешеләреннән Назыймның дачасы кайсысы икәнен белешкәндер, тар тыкрыкта бүген көтәдер кебек иде аңа. Сайгушев, пычрак җан, тар тыкрыкта адашып калгыры, шунда сине дөмектерергә дә күп сорамас. Уйлап та тормас. Аннары Сайгушевның Назыйм дачасы кайдалыгын иртүк белә алмавы сәбәбен китереп чыгарды — бандит кичә Айгузинны өе янында саклаган. Айгузинның милициягә хәбәр салуыннан шүрләгән, бүген монда килеп җитәргә өлгермәс. Шулай да, куркырга сәбәбе булмаса да, иртән тар тыкрыкка, әйе, кермәгән иде Назыйм. Бүген көндез табуы ихтимал картның дачасын Сайгушев, менә монысы — мөмкин хәл. Казаннан табан ялтыратмаса...

Өенә туры кайтмады Назыйм. Чистай урамы тукталышында троллейбустан төшеп, Сәвингә борылды. Мондагы асфальт җәелгән бердәнбер урамнан шактый ара узгач, аңа арттан эндәштеләр. Тавышы таныш иде, әмма Сайгушев тавышы түгел, юлбасарның пышылдавын да аера Айгузин, онытмас та кеше талаучының тавышын. Адымын акрынайтса да, артына карарга шикләнде карт. Эндәшүче үзе куып җитте — кичә килгән милиционер икән ләбаса! Милиционер, каршыга килүчеләр узып киткәндә, Сәвиндә гомер булмаган урам исемен сорады, төрле юнәлешкә төртеп күрсәтте, шул якта түгелме янәсе.

— Төштән бирле эзлим үзегезне, — дип уенсыз сөйләүгә күчте ул аннары. — Болар арасында Сайгушев юкмы? — дип берничә фотоны кәрт колодасыдай җәеп җибәрде.

Айгузин күзләренә ышанмыйча торды. Арада Сәвади Сайгушев фотосы да бар иде. Карт, калтыранып:

— Монысы, — диде.

Милиционер фотоларны тиз генә кесәсенә тыкты.

— Зур кошны очырганбыз, Назыйм абый! Сәвади дә, Сайгушев та түгел ул. Татарда булмаганчарак аның исем-фамилиясе. Сабир Сабируллин диелер бу юлбасар! Башкача йөрүе дә бик мөмкин. Ярый, рәхмәт, иптәш Айгузин, — дип аркылы урамга җиткәч туктады милиция кешесе. — Күрешкәнгә чаклы. Кирәгегез чыкса, мин үзем табармын сезне. Әмма Сабируллин-Сайгушевны очратсагыз, безгә хәбәр итмичә калмагыз. Шулай да бик чыгып йөрмәвегез хәерле. Дачагызга да бармагыз. Бу бандит кулларын кеше каны белән юудан чирканмый, — дип кисәтте ул һәм аркылы урамнан ашыгып китеп барды.

Тикшерүченең соңгы сүзләре, Назыймның күңеленә, минем малайны шушы Сайгушев юк иткән мәллә, дигән шик салды. Их-х, малай... Малаебыз... Акыллы бала иде соң... Иртән институтына китте, кичен кайтмады...

Назыймның туган йортын сүтүләренә инде чирек гасырлап узды. Ләкин төп нигезе урынын онытмый, монда еш килә ул. Төп нигез гел үзенә чакыра кебек аны. Ни сагынсаң да, монда кайтып нигез яңартып булмый, монда күптән биш катлы йорт күтәрделәр. Шул йорт Айгузиннар нигезен бөтенләй диярлек каплады. Назыймнар йорты урыныннан кырлары метр чамалы гына өчпочмактай җир буш калды. Шунда чүп-чар ташлыйлар, кадерле җирнең

кадерен бетерәләр. Пычракка чумуын абайламый адәм баласы, чүплек ерак түгел ич, шунда илтүне ярамыйга саныйлар мәллә, үзләре торган йортның почмагына калдык-постыкларын түкмәсәләр соң... Назыйм чүпләрне җыеп пакетка тутырды.

— Бабай, бабай, Чүпче бабай! Әнә тегендә чүп тагын да күп! — дип үртәләде Назыймны бер малай, картның куып тота алмаячагын белә, шуңа күрә Айгузинны оятсызланып мыскыллады.

— Синең гаебең юк бала, — диде аңа Назыйм. — Без гаепле, өлкәннәр гаепле. Акыл бирә белмибез сезгә! Тар сукмакка үзебез үк төшерәбез сезне.

Ләкин малай аның сүзләрен ишетмәде, дөресе, тыңлап та тормады.

— Чүпче бабай, Чүпче бабай! — дип, үз табышына сөенгәндәй, үчекли-үчекли, йортның аргы башына таба йөгерде малай.

Гаҗәп, әй, аңа гомерендә ике кушамат тактылар, ике тапкырында да малайлар эше булды бу: Исерек абый да Чүпче бабай. Ярый ла бу кушаматларны ишетеп тормадылар.

... Айгузин күршеләре белән генә аралашты, үтә кирәкле йомышы купканда гына өеннән чыкты. Ерак туган-тумачалары —аның якын туганнары инде юк — һәм бергә эшләгән иптәшләре килеп йөрмәде, һәркем тормыш куа, Назыйм картның хәлен белмәгән өчен берәүне дә гаепләргә ярамый. Заманасы шундый, кешеләр якыннан аралашуның мәгънәсен оныта баралар. Милиция тикшерүчесе дә онытты Айгузинны, инде икенче ай хәбәр бирми. Сайгушев-Сабируллин эшен дә, кем әйтмешли, тартма төбенә салдылар бугай. Мөхибә карчык белән бер сөйләшеп утырса, ичмасам, күңеле бушаныр иде. Әмма аны кайда очратасың ди. Авылына барсаң инде. Килүеңнең сәбәбен ни дип аңлатырсың тагын. Мәгънәсез сәфәр булыр бу, бикләнеп утыра бир, Назыйм карт, өеңдә. Кешеләргә синең кирәгең беткәндер. Малаең да, ахрысы, бөтенләйгә югалды. Гөлсәхраны күрәсе килә килүен, яшәгән җирен бала табу йортында белешер иде. Ләкин ни дип барып керерсең аларга? Мин, сеңлем, сине бандит кулыннан коткардым, диярсеңме? Тузга язмаганны! Мактанып әрсезләнү генә җитмәгән иде җитмеш яшеңдә! Ялгызлыкны күпмегәдер онытып торырга бер генә чара каладыр — Мөхибә карчыкны күрергә кирәк. Юк, анысы да тормышка ашырырлык теләк түгел —кеме ди ул Мөхибә карчыкның? Аннары аның, сугыш вакытындагы вәкиллегеннән соң, бер генә авылга да бер генә тапкыр да барганы булмады. Теге чакта авыл апайларының бер көндә, чынын-шаяруын бергә кушып, ике сабак укытулары гомеренә онытылмады. Авылда барысы да Мөхибә әби кебек түгел. Назыймны ындыр табагында һәм фермада мыскыл иткән хатыннарга ишләре хәзер дә бардыр. Шәп сабаклар алды Айгузин, аларның кабатлануына бөртек тә ихтыяҗ юк...

Шунысы да бар бит әле: Мөхибә карчыкның да теле үтә чарланган. Айгузин аның бер сүзен һаман онытмый. Назыйм карт беренче очрашуда:

— Мин кешеләргә начарлык та, яхшылык та кылмадым, — дигәч, Мөхибә усал итеп:

— Яхшылык кылмагач, гомерең заяга узган икән, — дигән иде. Һәм мондый киңәшен дә биргән иде. — Назыйм энем, син кешеләргә изгелек кыл. Инде алар синең яхшылыгыңны аңламаслар дип шикләнсәң дә, барыбер изгелек эшлә үзләренә. Инде аңламасалар, кешеләргә кылган яхшылыгыңны суга сал. Адәм затына эшләгән изгелегеңне балыклар аңлар.

... Апрель азагы якынлаша. Бакчада җиң сызганып эшләргә вакыт җитте. Ә бакча корты Назыйм Айгузин — үзенә үзе биргән бәясе шундый аның — февраль уртасыннан бирле бакчасына аяк та басмады. Һәм... Әй-й, нигә Сайгушев-Сабируллиннан кот очарга тиеш соң әле, аның алдында гаепле кеше сыман, барам бакчага, күңел шунда тынычланыр, дигән катгый фикергә килде Айгузин.

— Утыртыр-чәчәр вакытта, сырт сөякләрен иркәләп, өйдә ятмассың ич, — дип үзалдына әйтеп куйды Назыйм. — Сөякләрне бакчада язу килешә мица. Мөхибә әби әйткәндәй, Аллаһы боерса, быел да бакча килешер үземә.

Ярый барган икән дачасына. Бакчада рәхәтләнеп эшләде, ару-талуны белмәде, әй-й, бакчада талуы да рәхәт кенә ич! Куллары эш сагынган икән, сөяге чатнавы сизелмәде, төзәлгәндер, ике айдан артык вакыт узды бит Сайгушев-Сабируллинның тимердәй кулы белән сугуына. Шатлык өстенә — шатлык: кичке уңайда кайтканда, Гөлсәхраны очратты ул! Вагонга керүгә аның күзләренә таныш йөз чалынды кебек. Аралыкта басып торып, вагондагы кешеләрне күзәтте. Әнә ич таныш йөз, Гөлсәхра ич! Бәбәен күкрәгенә кыскан.

Карт, кешеләрне аралый-аралый, Гөлсәхра янына барды. Яшь ана беравык аңа аптырап карап торды да танып алды.

— Бабай, Назыйм бабай ич сез!

Назыймның күзләренә яшь килде — гомер булмаганны! Гөлсәхраның аркасыннан сөйде. Яшь ананың да күзләре дымлы иде. Ул картка үз урынын күрсәтте, әмма Гөлсәхра күршесендәгеләр кысылышты да Назыйм да сыйды.

— Улым, улым, Назыйм бабай шушы инде, — дип сөенде Гөлсәхра. — Бабай белән таныш әле, улым. Күреш, күреш, әйбәт бабай ул.

Бәбәйне үзенә чакырды карт, ләкин түгәрәк йөзле, зәңгәрсу күзле сабый Назыймның ите кипшерә башлаган кулларына карап кына торды — бу таныш түгел кулларның нигә үзен чакырулары сәбәбен белергә теләгәндәй уйлана кебек иде бәбәй. Назыймга шулай тоелды.

— Улым, кулыңны бирмисең мени бабайга? Алай ярамый ич, —дип Гөлсәхра малаеның кулын картның учына куйдыртты.

Сабый кулының йомшаклыгы Назыймга бу фани дөньяда гөнаһсызлыкның гел яңарып торуын тәнендә тойдырды. Гөлсәхралар очрамаса, шуны белмичә үләсе икән. Назыйм Айгузинның, җитмешенә җитеп, сабый кулына кагылганы юк иде бит. Малае, уллыкка алганда, алты яшьлек иде, малаеның кул кимерчәкләре катыланган иде инде. Малаеның куллары да йомшак иде лә аның!

— Рәхмәт яусын! — дип сабыйның маңгаен сөйде ул.

— Менә шундый инде без, Назыйм бабай, — диде Гөлсәхра, ана күңеленең киңлегенә хас булганча, баласы белән үзен бер җан иякләре итеп сөйләде. — Үсәбез инде без. Кунакка йөри башладык. Кендек әби янына да барачакбыз әле без, име, улым. Җәй генә җитсен, име. Хәзер Казанга барабызмы, улым? Казанга барабыз, име, улым. Безнең йокы вакытыбыз да җиткән, име, улым. Менә шушы имезлекне суырабыз да йоклап та китәбез әле без. Йоклап та үсәбез без, үсүдән башканы белмибез әле без, име, улым...

Гөлсәхралар Назыймны эзләгәннәр, ләкин ничек табасың ди, аның турында, исеменнән башка берни дә белмиләр бит. Исемен Мөхибә карчык әйткән. Ул Гөлсәхралар бала табу йортыннан чыккан көнне каршыларга килгән икән. Хәзер, Юдиндәге кызы янына килгәндә, Яшел Үзән шәһәренә бара икән, бәбәйне бик тә ярата ди.

Игелек кылуда гомере буена тынгылык белмәгән һәм белмәс Мөхибә карчыкның хәлен белешмәү гөнаһ лабаса, димәк, Назыйм карт авылга һичшиксез барачак.

Сабый йоклый иде. Назыйм аңа еш кына озаклап карап тора, мондый чакта Гөлсәхра, гәүдәсен кымшатып, малайның йөзен карт күрерлек итеп бора. Гөлсәхра Назыймга, бәбәй табу йортына китергән күчтәнәчләре өчен, рәхмәт әйтте.

— Теге чакта вагонга сез кергәч, — диде Гөлсәхра, йөзенә кинәт хәсрәт җәелде, — сумкагызга башлап күзем төште. Дачадан кайта икән бабай, дип уйлап алдым да кинәт кенә карлыгкан кайнатмасы ашыйсым килде. — Һәм

Назыймны, сумкасына үрелүдән туктатып: — Юк, юк, Назыйм бабай, хәзер кирәкми, — дип дәвам итте Гөлсәхра. — Мин Казанда чагында ук китереп сыйладыгыз бит. Безнең үз бакчабыз да җимешле. Шундый чакта кайнатма ашыйсы килүе сәер инде. Ашау турында уйларлык идеме соң ул чакта...

Ана, кулын тидерер-тидермәс кенә итеп, бәбәен битеннән сөйде. Аның йомшак күкрәгендә сабые изрәп йоклый иде. Әтисенең нык һәм ышанычлы күкрәгенә беркайчан да сыена алмаячак бу гөнаһсыз бала...

Гөлсәхра Назыймны үзләренә чакырды, карт, сумкасыннан кәгазь-каләм алып, адресны язды, барырга ышандырды, Мөхибә карчыкны Гөлсәхраларда очратырга өметләнде. Мөхибә белән ешрак очрашса, аңардан тормышны яратырга өйрәнер иде ул, моңа җитмеш яшьтә дә соң түгелдер. Югыйсә тормышта эз калдырмыйча китәр кебек иде. Яшел Үзән каласына Мөхибә әби якшәмбе саен килә икән.

Ләкин Назыйм Айгузин Гөлсәхраларга бара алмады. Ә Казан вокзалында аны бүген үк бөтән төрле очрашу көтә иде.

Поезд, Юдин ягындагы платформаны узып, Арча юнәлешендәге платформага барып туктады, тегесендә буш юл булмавын радиодан хәбәр иттеләр, моны вокзалдагыларга алдан белдергәннәр икән, Гөлсәхраны туганнары Көнчыгыш платформада көтәләр иде. Назыйм Гөлсәхралардан шунда аерылды, аларга һичшиксез барачагын кабат әйтте, аларны үзе дә кунакка чакырды.

Вокзалның төп бинасы алдыннан тугызынчы трамвайга таба бара иде ул. Бина башы турына җиткәндә, товар йөртүче поездның алгы вагоныннан төшеп, җиргә чүгәләүчеләрне күрде Айгузин. Нигә алай итәләр икән, дип уйлады, чүгәләгән кешеләр түгәрәген әйләндереп алган кораллы солдатларга игътибар иткәч кенә аңлады — кулга алынган кешеләр икән болар. Бүтән шәһәрдән китергәннәрдер, вагонга утыртмыйлар, төшерәләр иде бит.

— Сайгушев ич тегесе! Сабируллин! — дигән сүзләр авызыннан атылып чыгуын сизмичә дә калды Айгузин.

Сабируллин-Сайгушев та Назыймны күреп алды. Картка сикереп ташланырга теләп, күтәрелә башлады ул, ләкин аның аркасына шул мәлдә үк автомат көпшәсе терәлде.

— Картлач, телеңне тыярга кушкан идем түгелме мин сиңа?! — дип үкерде бандит. — Барыбер башыңа җитәрмен!

Аның аркасына катырак итеп төрттеләр. Сабируллин-Сайгушев ава язды, таяна алмый, куллары богауда иде, башкаларына богау салмаганнар, аларның кулларын артка куйдырганнар иде, димәк, Сабируллин-Сайгушев бу җинаятьчеләр арасында иң куркынычы икән. Бандитның богауда һәм чолганышта булуы Айгузинга яшьлек көче кайтарды кебек, ике айдан артык шушы бәндәдән куркуы юып алгандай югалды. Карт, юлбасарны нык каптыруларына инде тәмам ышанып, тегеңә җирәнеп, нәфрәтләнеп карап узды. Ычкына алмассың капкыннан, Сайгушев-Сабируллин, богаулагач та әшәкелегеңне чәчеп маташма, дип бандитның йөзенә бәрәсе, җырлап яшә, дип мыскыллыйсы килде Айгузинның, ләкин боларны әйтергә мөмкин түгел иде. Хәер, юлбасар үзенең хәлен болай да аңлыйдыр, үч алмакчы булуы котырынуы-ярсуы гынадыр...

Өендә очынып йөрде Назыйм. Авыз эченнән көйләде. Тик җыр сүзләре белми икән. Кайсыдыр җырның баштагы сүзләре, бүтәненең ахыргы сүзләре генә исенә төшә. Матур җырламасын да инде, аны сәхнәгә чыгып җырларга мәҗбүр итмиләр ич. Гомер итеп, ялгызың гына калганда, хәсрәтеңне басарга йә шатлыгыңны зурайтырга җыр белмә инде?!. Җырсыз үтте гомер. Өйрәнергә кирәк. Соң түгелдер...

Ә хатыны җырлый иде Назыймның. Әмма аның җырлавын да яратмады ул. Хатынын:

— Сарык кебек мөгрәмә! — дип тыяр иде.

Хатыны:

— Сарык мөгрәми. Үзегез Сәвиндә торып мал асрагансыз, үзең шуны да белмисең. Сыер гына мөгри, — дип каршы төшсә:

— Синең җырың — сарык мөгрәгәндәй! — дип тындырыр иде аны.

Берчакны, туганнарына баргач, хатыны телефоннан кемгәдер яңа көй өйрәтеп маташа. Тартып торып алды Назыйм телефон төребкәсен, хатыны акаеп калды. Әллә суккан да тагын төребкә белән, хатыны кич буе колагын тотып утырды. Ачуланмаган иде хатыны. Өйләренә кайткач:

— Даруыңны эчә күр, онытма, — дигән иде хатыны.

Назыймны яратуын сиздерүе инде. Шул тугры хатынны җырдан тый инде, әкәмәт. Назыймның күңеле тарлыктан инде бу.Хатыны белән бергә җырларга өйрәнсә ни булган? Син җырлый белмисең, дип һич тә кыерсытмас иде хәләле. Их-х, акыл, диген... Җырсыз гомер кичер инде... Өйрәнергә кирәк, әле гомере бардыр, сырхау кеше түгел. Ялгызлыкта җыр бигрәк тә кирәк...

Ишек кыңгыравы шалтырады. Назыйм, элеккерәк гадәте буенча, кем булуын сорамыйча, йозакны ачты, хәзер Сайгушев-Сабируллиннан куркырга кирәкми иде бит инде. Ләкин ишекне бәреп, бандит атылып керде. Бер мәлгә икесе дә, күзләренә карашып, сүзсез тордылар. Ниһаять, карт кухняга чигенә башлады. Юлбасар, бармакларын кәкрәйтеп җәеп, корбанына ташланырга җыенган ерткыч кебек, Айгузинга таба атлады. Ашыкмый Сайгушев-Сабируллин, Айгузинның котылыр чарасы юклыгын белә.

Назыйм өстәлдәге пычакны алды. Бандит пычакны теге чактагыча сугып төшерергә өлгермәячәк иде, ара ераграк, сикереп ташланса, пычак аңа барыбер кадалачак. Ләкин карт пычакны җәһәт кенә үз йөрәге турына китерде, күкрәгенкиерде. Сабируллин-Сайгушевның күзләре тагын да акайды, гәүдәсе артка чайкалды.

— Картлач... Нишләвең? Ташла пычагыңны!

— Ташламыйм! Син мине үтерергә килгәнсең! Каным синең пычрак кулыңа йокмасын! Кузгалма! Урыныңнан аз гына миңа таба селкенсәң дә, кадыйм пычакны йөрәккә!

— Картлач... Назыйм абзый, ташла, дим, тимим мин сиңа. Кунып кына чыгармын. Яшеренергә синең фатирдан да ышанычлы урын юк. Алар мине монда килер дип уйларына да китермәячәкләр. Аннары минем үз юлым.

— Чыгып кит! Югыйсә...

— Җүләрләнмә, абзый! Сине вокзалда юри куркыттым. Акчаңны бишле белән кайтарырмын... Миңа тактырасың бит үлемеңне... Онытмачы, син сугышта да кулыңа агач мылтык тоткансыңдыр...

Ишеккә китереп типтеләр. Назыйм моны ишетерлек хәлдә түгел иде, ә бандит ишек ягына борылды да, пистолет тоткан ике милиционерны күреп, кухняга ташланды. Картның акрын ауган гәүдәсе бандитның икенче кат тәрәзәсеннән сикерү юлын бүлде. Назыйм Айгузинның күкрәгенә күптән түгел үзе ясаган очлы пычагы — монысы да сыгылмас пычак — сабына хәтле кергән иде...

Сабируллин-Сайгушев калтырана, аның тез буыннары гомерендә беренче тапкыр тотмый иде. Ул идәнгә сыгылып төште.

— Мин түгел... Миңа сылтамагыз! Ул үзе... Мин үтермәдем аны! Үзе! Ү-з-е!

Җинаятьләре өчен дүрт тапкыр тотылган, өч тапкыр төрмәдә утырган Сабир Сабируллин-Сәвади Сайгушевның болай ачынып беркайчан да ялварганы юк иде. Дүртенче тотылуында кулына богау салгач та качу әмәлен тапкан бәндәнең бишенче тотылуында, кылганнары өчен, явызланып һәм ерткычланып горурланырга көче җитмәде бугай.

Юлбасар сул аягына тезләнеп, башын иеп, милиционерларның хәрәкәтләрен кырын карап күзәтә иде.

— Ал кулыңны кесәңнән! — дип кычкырды аңа милиционерларның берсе һәм, богау тотып, җинаятьчегә таба атлады. Сабируллин-Сайгушевка монысының, гәүдәсе белән, пистолет тоткан иптәшен каплавы гына кирәк булган икән — ул, юлбарыс җәһәтлеге белән атылып торып, богау тоткан милиционерның касыгына тондырды, икенче милиционер атырга өлгергәнче, елтыр пычак белән (килешли каяндыр тапкан бит, әй!) аның күкрәгенә кадады. Богау тоткан милиционер аңына килгәнче, аның аркасына йөрәк турыннан пычак кереп батты.

— Шулай, агайнеләр, — дип акрын гына әйтте Сабируллин-Сайгушев. — Хуш... — Бу сүзне куплетка уйлаган иде бугай, әмма кинәт яртылаш кисте, — җебегән картлач...

Пычагының канын богау салырга теләгән милиционерның кителенә сөртте. Әле генә ике кешенең гомерен кискән пычакның кыны кесәсендә булган икән — хәнҗәр сыман пычак шунда шуып керде. Аннары Сабируллин-Сайгушевның түш кесәсенә оялады.

Сабир-Сәвади мәетләргә күз ташлады, үлүләренә ышанды. Һәм, киемнәрен төзәткәләп, ашыкмыйча чыгып китте. Гаҗәп, чыгу юлында аның каршына берәү дә очрамады. Югыйсә милиционерларның ишек ватып керүен күршеләр ишеткәннәрдер, бәлки, хәзер алар ишекләренә колакларын куеп тыңлап та торалардыр, ләкин Сабируллин-Сайгушевның юлын берәү дә кисмәде. Хәер, бу заманда кемдә кем кайгысы соң...

Яңгыр сибәли. Кыпын Обсерватория тукталышында табигать манзараларына — бигрәк тә аның сарсарына — сокланучы Назыйм Айгузин язгы яңгырның шавын ишетә дә, аның тәрәзәне иркәләп сөюен күрә дә алмый инде. Тормышны яратырга бик соңлап өйрәнә башлаган иде мәллә соң ул? Тормышында начарлык эшләмәвең әйбәт. Ләкин кешеләргә яхшылык кыла белмәвең үзе үк начарлык түгелме икән?...

Хәер, Назыйм Айгузинның бу хакта, тирәнгә төшеп, беркайчан да уйланганы булмады.

*1990*

---

## “Казан утлары” якындагы саннарда тәкъдим итәчәк проза әсәрләренең кайберләре:

**Тәлгат Галиуллин.** Гомер тәлгәшләре. *Эссе.*
**Ләбибә Ихсанова.** Кемгә сөйлим серләремне. *Повесть.*
**Ркаил Зәйдулла.** Кечкенә кешеләр. *Хикәяләр циклы.*
**Барлас Камалов.** Хатирәләр яңарган көн. *Повесть.*
**Таһир Нәбиуллин.** Качкын. *Повесть.*
**Айдар Хәлим.** Мөртәт. *Хикәя.*

*Укучыларыбыз иҗаты*

# "ЧИТ ҖИРЛӘРДӘ ЙӨРЕП..."

*Узган елда бик зурлап олуг юбилее уздырылган шагыйребез Мөхәммәдьярның: «Нинди гаҗәеп шәһәр бу Казан?! Олы вә кечесе — һәммәсе шагыйрь, шигырь яза...» — мәгънәсендәге мәгълүм юллары еш искә төшә. Чыннан да, заманыбыз нинди генә авыр, катлаулы булмасын, — әдәбиятка, аның чишмә башы булган шигырьгә табынучылар арта бара. Һәм үзләре дә язучылар, туган илне — телне яратуны, милләткә мәхәббәтне, Казанны, Татарстанны сагынуны шигырь итеп әйтергә омтылучылар күбәя. Студентлар да, галимнәр дә шигырь яза, әлек башка жанрда эшләп танылган язучылар-әдипләр яза, үз илендә, үз җирендә яшәгәннәр һәм читкә киткәннәр яза. Барсының да әйтер сүзе бар һәм аны, мотлакан, шигырь белән, көйле һәм ритмлы, гүяки дога кебек җиткерәсе килә, мөгаен... Ул сүзне безнең журналыбыз аша юллыйсы килү дә табигый. «Казан утлары» даими рәвештә, төрле төбәкләрдә яшәүче әдипләрнең иҗатын үзенең битләрендә күрсәтеп барырга тырыша; күптән түгел генә Чувашстанда туып-үскән шагыйрьләр иҗаты белән таныштырдык. Ә инде элек-электән әдәбиятыбызга бик күп исемнәр биргән, Башкортстан үстергән шагыйрьләрнең иҗатыннан сәхифәләр — һәр санда диярлек. Башка регионнар белән дә шулай, дип әйтә алабыз.*

*... Күптән түгел редакциябезгә Татарстан республикасының Үзбәкстан республикасындагы даими илчелеге вәкиле имзасы белән хат-бандероль килеп төште. Баш редакторга адресланган бу хатында хөрмәтле илчелек вәкиле Үзбәкстанда яшәүче татар диаспорасы иҗатыннан үрнәкләр җибәргән, танышып чыгуны, кызыксындыра калса, журнал битләрендә урын бирүне үтенгән. Таныштык. Әлбәттә, профессиональ каләме белән язылган, бүгенге шигърият кимәлендәге әсәрләр түгел. Ташкенттагы татар-башкорт җыр-бию ансамбленә йөрүчеләр, әдәби түгәрәк әгъзалары, үзешчәннәр... Иң мөһиме: туган телгә, шигырьгә гашыйклар, Казанны — илаһи күңел мәркәзе итеп сагынучылар, мөһаҗирләр. Иң кызыгы: авторлар — барысы да диярлек Башкортстанда туып үскәннәр икән. Афина Гобәйдуллина — Белореттан; саф башкорт кызы, әлеге ансамбль солисткасы; Рәхимә Вәлиуллина да, үзе язуынча, «чәчән-башкорт гаиләсеннән» икән. Шигырьләрен тугандаш татар халкына, Казанга сәлам итеп юллаганнар. Флюза Мәүликаева — Эстәрлебаш районы, Яңгырчы авылы кызы; авиация заводында эшли. Наил ага Зиннәтуллин исә Кушнаренко районы Әсән авылыннан киткән; элекке эшче (шул ук авиация заводыннан), хәзер — ялда. Үзбәк, рус, татар телләрен белә, төрки халыклар әдәбиятларына гашыйк икән бу агай. Милләттәшләребезгә хөрмәт йөзеннән бу санда без аларның берничә шигырен укучыларыбызга тәкъдим итәргә булдык.*

*... Икенче хатны безгә Туймазы шәһәреннән, күптәнге танышыбыз журналист Замир Низаметдинов җибәргән. Ул анда үзенең якташы, укытучы, ике аяксыз, әмма сау-сәламәт, көчле рухлы шагыйрь — Бишкурай авылында яшәүче Даим Яушев турында яза, шигырьләрен дә юллаган. Аңа — июньдә 60 яшь тула икән. Бу үтенечне дә игътибарсыз калдырмыйча, Д. Яушевның берничә шигырен бу сәхифәбездә укучыларыбызга тәкъдим итәбез.*

*Хәерле сәгатьтә, хөрмәтле дуслар!*

Флюза
Мәүликаева

## Сөембикә турында бәет

Бу хәл күптән инде, күптән булган, —
Юлларны да еллар күмгәннәр...
Аны белгән бабай һәм әбиләр
Күптән инде, күптән үлгәннәр...

Ә яшәгән — гүзәл татар кызы, —
Буе-сыны һуштан язарлык,
Сызылып киткән кашлар, озын керфек —
Һәр йөрәккә уклар кадарлык.

Көянтәсен асып суга барса —
Хәтта кошлар тынып калганнар,
Ак каеннар зифа буйларын — шул
Чибәр кыздан икән алганнар...

Төнен ай сокланган кызга карап,
Көнен кояш күзен алмаган.
Булмаган ди, дөнья батырлары —
Чибәр кызга күзен салмаган.

Төрле миллэт халкы батырлары,
Гашыйк булып, куллар сузганнар,
Кыз йөрәген яулый алмагачтын
Буран сыман шашып, тузганнар.

Хәтта берсе таш зинданга япкан —
Бәлки куркыр, кулын бирер дип,
Яшь йөрәге карыша алмас, дип,
Байлык күрсә, бәлки эрер дип...

Әмма горур, гүзәл татар кызы
Баш имәгән, куркып калмаган.
Яшь йөрәген әсирлеккә биреп,
Башка халык динен алмаган.

Ташлаган ул үзен таш зинданның
Биек манарасы башыннан,
Җанын азат иткән әсирлектән —
Ул баш тарткан дошман ашыннан...

Бу чибәр кыз — татар кызы булган,
Сөембикә аның исеме,
Болындагы тере чәчәкләрдә
Әллә шул яшь кызның төсеме?

Әйе, ул батыр кыз Сөембикә —
Бөек татар халкы баласы.
Шул яшь кыздан, дуслар, күбебезгә
Бар әле, бар үрнәк аласы!

... Менә шулай, милләттәшләрем, татар —
Борынгыдан горур, батыр ул:
Әсирлеккә бармас, соңгы мәлдә...
Мәңгелеккә үзен атыр ул!

## Кыр казларым, мине калдырмагыз!

Эһ-э-э-э-й, кы-ы-ыр казлары-ы-ым!
Сәлам әйтми үтеп китмәгез!
Төркемегез белән мине, үтенәм,
Зинһар өчен читләр итмәгез!

Мине дә сез бәхет күлегезгә
Үзегез белән алып китегез!
Калдырмагыз инде ялгыз монда —
Зинһар мине дә иш итегез!

Кыр казларым, сезнең кебек мин дә,
Кыйгылдашып, калмый очармын,
Сездә булган моңсу серләрегезне,
Беләм, мин дә бик тиз отармын!

Кыр казларым, э-һ-э-э-э-э-й, кыр казларым,
Бәхет күлләренә илтегез!
Йөрәгемнең соңгы сулышларын,
Зинһар өчен әйтәм, сизегез!

Калдырсагыз әгәр монда ялгыз, —
Язын, беләм, мине тапмассыз.
Кыр казларым, аһ, ак казларым, дим,
Кара кайгы миңа салмассыз!!!

❧

Афина
Гобәйдуллина

## Сагыш

Туган илем, туган төяккәем
Еракларда миңа эндәшә.
Әллә чит җирләрдә яшәгәнгә,
Алар мине сагына, көнләшә.

Әйе, еракларда ишетәм мин
Уралымның горур тавышын.
Моңлы сандугачның сайрауларын,
Инйәремнең талгын агышын.

Ишетәм мин урман шавың һаман,
Иркәләгән кебек җилләрең.

Чакыралар мине туган якка
Төнбоеклы тирән күлләрең.

Чәчәклардән чәчәкләргә кунган
Бал кортының тавышын ишетәм.
Телләремдә тоям башкорт балын, —
Туган илкәемдәй хис итәм.

Ишетәм мин курай уйнауларын,
Башкортымның моңлы җырларын.
Күз алдыма шунда килеп баса
Иркен яланнарың, кырларың.

Чакыралар алар туган якка,
Атаң-анаң монда көтә, дип.
Туган илеңә бик кирәксең син, —
Гомеркәең читтә үтә! — дип...

## Каеным

Яшьлегемдә бер каенны
Үземә сердәш иттем:
Шатлыгым белән бүлештем,
Күз яшемне дә түктем.

Минем язмышны каеным,
Үз язмышыдай итте.
Бергә шатланып, кайгырып,
Безнең яшьлекләр үтте.

Зифа буйлы ак каеным
Олпатланды, киңәйде.
Күрергә дип каеныммы
Илгә кайтам һәр җәйне.

Авыл башында каеным
Һәр елны каршы ала.
Киткәндә, моңсуланып,
Яфрагын болгап кала...

❂

# Рәхимә Вәлиуллина

## Нәҗагай

Язгы яшен булып килеп кердең,
Сүнгән йөрәгемне уяттың.
Татлы сүзләр белән иркәләдең,
Төне буе сөйдең, яраттың...

Яшеннең дә бар тик нәҗагае, —
Ышануы авыр сүзеңә:
Яшенме син, әллә аҗаганмы?
Бар теләгем шуны белергә...

Әзер идем хәтта ташланырга
Коеп яуган коен — яңгырга...
Алданганмын икән нәҗагайга —
Өлгермәде яңгыр яварга.

Капыл яныл, тагы капыл сүндем.
Теләгем юк бушка көяргә.
Ә аҗаган уйный башка җирдә, —
Мәхәббәттән "әзер үләргә"...

Тик, аз гына кыен булды миңа,
Яумаганга көткән яңгырым...
Үпкәләмә миңа, зинһар өчен,
Ошамаса шушы шигырем!

## Аңладым

Бала чакта әни, сиңа
Биргәнмен кайгы:
Үзем ана булгач кына,
Аңладым аны.

... Яшьлегемдә урамнардан
Кайтып кермәдем.
Сиңа борчу салганымны
Хәтта сизмәдем...

Чит илләргә чыгып киттем
Сине елатып.
Искә төшә хәзер генә,
Йөрәк сызлатып...

Үз кызларым үскәч кенә
Сине аңладым.
Шуңа хәтле гаебемне
Бер дә тоймадым.

Әнкәемдәй, дим, түземле
Буласы иде...
Кызларым тик минем кебек
Булмасын иде!

... Ә кызларым өйрәткәнне
Бер дә белмиләр.
Минем йөрәк янганлыгын
Нигә сизмиләр?!

# Наил Зиннәтуллин

## Казаным

Күп шәһәрләр гиздем, ләкин
берсе генә — язарым:
Гүзәллеге чиксез, бакый
кадим шәһре Казаным!

Безгә мөкатдәстер монда
мәдрәсә-мәчетләре... —
Ята Казан туфрагында
динебез шәһитләре.

Язды музыкалы пейзаж —
ямьләп Казан җиһанын,
Сара Садыйкова, Сәйдәш...
һәм дә Нәҗип Җиһанов.

Биек пьедесталдан Тукай
күрә нурлы Казанын:
"Бәйсезлектә яшә шулай,
юлың туры Казаным!"

Муса сугыш уты аша
шигырен тоя халкының;
"Шигъри гәүһәр Казан яшәр, —
анда гыйлем ялкыны!"

Күп шәһәрләр күрдем, ләкин
берсен генә язармын:
Гүзәллегең чиксез, бакый —
татар шәһрем — Казаным!

## Татарстан — бәйсез илем

Татарстан, бәйсез булып,
тигез тормыш сөрсәңче!
Кардәш илдән сәламем бу,
шатлыгым бу — күрсәңче!

Халкымның бар үз тарихы,
фәлсәфәсе, шөһрәте.
Бетмәс гүзәл сәнгате бар,
мәңгелек шигърияте!

Бу тарафта үсте — үсәр шаулы,
матур шәһәрләр.
Сүнмәс илһам бирер сиңа,
шагыйрь, — Идел, сәхрәләр.

Иркен, тиңсез өлкән бостан —
һәм мәңгегә яшь илем,
Яшә шулай, Татарстан,
син — җырым, син — яшьлегем!

## Даим Яушев

### Шундый хәлләр

"Хәлләрең соң ничек?" — дип сорадың,
Туктап калдың, көтеп җавапны.
"Сөбханалла"дан да кулай булган
Таба алмам бер сүз — канатлы.

Бер "җәелеп" җавап бирим әле —
Түзем-сабыр тупла тыңларга:
Түшәк-болытларда кырын ятып,
Аяз офык әзләр көннәр бар.

Кайсы көнне шәмнең төпсәседәй,
Пыскып кына сүнәм-сүреләм.
Көне килсә, йөрәктән сут тама —
"Яшим!" — диеп күккә үреләм.

Була көне, хәтта сәгате дә —
Ике үлеп, ике тереләм.
Тәрәзәмә төшкән тасма нурлар
Буар елан булып күренә.

Бәгъзе туар таңда әҗәл көтсәм,
Ярсыйм-янам, кайчак ашкынып.
Шигъри нурда йөзәм, колач җәеп,
Ера-ера хисләр ташкынын.

Чәчәк төсен, кояш күрмәс булам,
Очын күрмим барыр юлның да!..
Җылы җилдә туңып калтыранам,
Бозга бассам, гүя җылынам...

Хәлләр шулай... Кара белән акны
Аерырмын күзем йомганчы.
... Хәлләремне сиңа сөйләгәннән
Миңа гына җиңел булсачы!..

### Мин үземме?

Танымый торам үземне —
Мин болай түгел идем.
Кояшмы юлын үзгәртте —
Олы үзгәреш сиздем.

Йөрәгем уты ялкынсыз,
Сүрән куз бер уч кына.
Кешеләрем шул ук сыман —
Анда юк чын дус кына.
Дөнья урталай ярылды —
Яманга да, яхшыга.
Тәнемне таза йөретәм,
Җаным тия шакшыга.
Юллар ачык кодрәтлегә,
Җаһил-куштанга гына.
Хакыйкать: ике өч була,
Берне кушканда гына
(.. Бердән дә мәхрүм калганнар —
Йөзнең туксаны була).
Минме соң әллә үзгәрдем —
Ишеткән-күргән — афәт —
Тып-тыныч таңда уянсам,
Ябырыла гарасат.
Мин үземне таныр идем,
Илем мине танымый;
Җаным үземнеке калды,
Алмаштырды — канымны...

## Урын алмашырга талпына

Бу җаныма күкрәк читлегендә
Урын, күрәсең, тар-кысандыр.
План корып, минсез, йөрәк белән
Ирек эзләп чыгып очардыр.

Җиләдеме, күпсенәме мине,
Лаек санамыймы — ятсына.
Сабырлан, дип карыйм. Исәбе юк —
Урын алмашырга талпына.

Тәнем-гәүдәм җанга лаек иде.
Җылыталдым кулдан килгәнчә.
... Көчләп тота алмам. Сиңа — бәхил!
Җылыңны да бирдең кирәкчә.

Галәм-гареш байкап, хәлдән таеп,
Кайтырсың да, кәсле туфракта —
Баш очымда үсәр зәңгәр чәчәк,
Син кунарсың аңа шул чакта...

## Туфанны сагынганда

Килеп керде — аяк очларына
Басып кына... Кочты җилкәмнән. —
Туфан икән... Һәм уянып киттем:
Туфан моңлы йөрәк — җилкенгән...

Дулкын-дулкын чәчләренең хәтта
Исен тойдым төштә булса да.
Әллә усаклары елап искә
Алды микән шул чак Усада?

Исән чакта мин күрмәдем сине:
Сагыш моңнарыннан исердем.
Наз саркыган шигырь-гәүһәрләрең
Йөрәгемә генә күчердем.

Киек казлар юлын каплап алып,
"Агыла да болыт агыла".
Йөрәгеңне бәйли алмый калган
Милләт бүген сине сагына.

"Аралагыз мине" кайгылардан,
Үзкаемә калсын сагышым:
Хәсәннәргә тимәс тук язмышны
Иңнәремә салып барышым.

Әрнеш-хәсрәт тулы капчыкларның
Тонналарын алар күтәрде.
Йөрәк каны белән майладылар
Шыгырдаган язмыш күчәрен.

Рухи ачлык килә ябырылып,
Эңгердән соң — туклык котыра.
Рух белән телем икмәк хакын
Туфан, Аязлардан син сора.

Тар күкрәккә бар галәмне төяп
Туар берәү Туфан шикелле.
Һич шигем юк: Хәсәннәре туар,
Луизалар туу — икеле.

Тын елганың ярларына басып
"Сүз кушасы килә талларга",
Монда тәмуг... "Анда" инде берүк
Оҗмах булсын изге җаннарга!

## Ашыгам

"Ашыгасың", диләр. Хаклык бардыр.
Йөрәк микән шулай ярсулы.
Кендек әбиен дә көтми генә
Мин туганмын җиргә ашыгып.

Бирәчәгем булса, мин ашыгам
Бәхилләргә шул ук сәгатьтә.
Йөрәк үз-үзенә урын тапмый, —
Кеше калса кайгы-хәсрәттә.

Капка шыгырдаса, мин ашыгам
Күтәрергә ишек келәсен.
Бәлки юлда җәфа-каза күргән
Мосафирдыр, каян беләсең!

Мөмкин кадәр бүген барам кебек,
Мин яшәмим һич тә тарсынып.
Сорагызчы: кемгә җылы кирәк?..
Китеп баруым бар ашыгып...

## Өйрәттем

Мактануым түгел, гыйбрәт өчен
Бер урында әйтү кирәктер:
Муеныма салган бауны сүтеп,
Үземне яшәргә өйрәттем.

Үгетләдем үзем сабырлыкка,
Түземлеккә. Шыңшып җыр гына,
Тешне кыскан хәлдә моң сыгылды,
Бәргәләнеп елар урында.

Моңым гамьле иде. Арттыралдым
Минем хәлдәгегә — мохтаҗга.
Бер нур эзләп үзем элмәк сүтәм:
"Сүнә дә бел, дидем, кызганда",

"Бөгелер дә сынар кимсенүдән,
Тик бау гына аның даруы"
Дигәннәргә, яшен ташы булып,
Гомеремнең үтеп баруы.

"Сабыр төбе — алтын" дисәләр дә
Алтын хакы түгел чамасыз.
И Ходаем, син дә кодрәтең сал
Калганнарга миндәй чарасыз!!!



# Нурулла Гариф

## ПАРЧАЛАР

### *Ничек яшәргә?*

Авылыма кунакка кайткач, өй ишеген ачып кергәндә тертелеп калдым. Бусага төбенә мәрхүмә әниемнең элек башына ябып йөргән калын шәле җәелгән. Арттан керүчеләр килеп бәрелгәч, атлап керергә мәҗбүр булдым.

Алар өчен бер чүпрәк кенә иде шул ул. Түздем, тавыш чыгармадым. Газизләребез башындагы яулыклардан гына түгел, кеше башларына басып йөрер заман бит, бездән генә калырмы?

Авыр хатирәләр белән яшәү кешегә авыр, ә хатирәләрсез яшәсәң — кешелеклелек югала. Ничек яшәргә?

### *Нинди заман?*

Бер көн шулай, егерме еллап күрмәгән классташымны очраттым. Заманында бергә уйнап үскән булсак та, хәзер уңайсызлана-уңайсызлана бер-беребезне "өйрәнәбез". Карашлар очрашуы биткә кызыллык сибә. Бүлдерә-бүлдерә хәл-әхвәл сорашсак та, һәркем үзенекен уйлый. Сер бирәсе, кимсенәсе килми, янәсе. Әкренләп сүз башка классташларга күчеп, күңелләргә җиңеллек килә. Кеше турында сөйләшү җиңел. Әнә бит, аларның да язмышлары төрледән-төрле икән, бишлегә укыганнарының хыяллары чәлперәмә килсә, икелегә сөйрәлгәннәре "тугызлы"да элдертә. Акыл алдан йөри торган заман булса, ахмаклар шулай күбәер идемени?

### *Безнең сыйфат*

Борынгы Чаллы шәһәрчеген каймап аккан инешнең яр буйларында уйланып йөрим. Яр астында — аякны тартып алалмаслык сазлык. Вакыт дигәнең бик тиз үзгәрүчән икән. Әле моннан бер 50 — 60 еллар элек кенә бу тирәдә 17ләп изге чишмә булуын сөйлиләр. Соңгы дистә елларда гына ком басып киткән аларны.

Татар милләте язмышы чишмәләребездә дә кабатлана. Нигә безне һәрчак ни дә булса басып китә икән? Чистартырга кирәк чишмәләрне, шуның белән, бәлкем, үзебезнең дә күңелләребез пакъланып китәр...

Ә иртәгә кабат Казанга китәргә кирәк. "Дөнья куасы" бар шул. Ә сез — чишмәләр — безнең кемлегебезне искәртеп, исләремә кабат төшәрсез әле.

### *Зират*

Кечкенәдән үк иң курыкканым зират иде. Әмма — дөнья баса икән! — әби-бабамнарны, кадерле әниемне җирләгәч, бу халәттән котылдым инде. Зират капкасыннан, җае туры килгән саен, эчкә узам. Ә анда башка дөнья: ташлардагы еллар исәбе дә узгач кирегә ага монда.

Каберләргә тукталмыйча юлымны дәвам итәм. Бара торгач, ташлар, тимер рәшәткәләр дә бетеп, ауган агач киртәләр дә сирәгәя башлады. Һәм менә ул хәрчак үзләренә чакырып, күңелгә тынгылык бирмәгән каз аягына охшаш тамгалар. Кыйшайган, череп ауган имән казыкларында алар бихисап: әйтерсең лә яңа яуган ак кардан бер төркем казлар узган... Мин беләмен, бу казыклар төбендә ятучылар

безнең нәселдән. Мин аларның бер дәвамы. Уйларымнан айнып, кайту юлына борылам. Зираттан чыкканда, яңа каберләрдән соң башланган буш җирләргә күзем төшә... Күңелдә туган уйларда бары бер генә теләк: ни генә күрергә язса да, туган кавемемнән аерма мине, Ходаем.

Бу — балаларыма да васыять.

## *"Шым бул"мы? "Шум-бунт"мы?*

Тирә як татарлары бу авылны, су кырыендагы аулак урынга урнашканлыктан, "Шым бул" дип атап йөртәләр.

Пугачев яуларыннан соң бу баш бирмәс татар төбәгенә, спирт завод төзелеп, урыс халкы күчереп утыртыла. Алар авыл атамасын үзләренчә шаяртып аңлаталар. Тулский белән Рязань урамнары эчемлексез узмаган зур бәйрәмнәрдә исерешеп, кара-каршы еш сугышканлыктан, "Шум и бунт" сүзләреннән килеп чыккан, диләр.

Шомбыт атамасына бу ике халыкның да үзенчәлекле сыйфатлары керми калмагандыр, дип уйлыйм мин.

## *Измә*

Мич чыгару өчен яхшы измә комны 30, кызыл балчыкны 70 процент кушканда килеп чыга, диләр. Хәер, нинди кызыл балчык, нинди ком бит әле, анысына да карыйдыр.

Казаклар белән Чаллы авылы арасындагы борынгы зират кызыл балчыклы яр өстенә урнашкан. Аннан менә ничә ел инде измә өчен кызыл балчык алалар. Ярлар ишелә бара, тарихның яраларын искәртеп, югарыдан кеше башлары, сөякләре тәгәри тора. Үзебезнең болгар-татар бабаларыбыз башлары. Халык белә дә бит, кызыл балчык кирәк булгач ни эшләсен инде. Моны аңларга да баш кирәк бит.

## *Кайда безнең алтын капкалар?*

Кайда гына барып, борынгы шәһәрчекләр белән кызыксынма, тирә-як авыл халкы аның "алтын капка"сы булуын һәм аның кайдадыр якын тирәдә генә яшерелеп саклануы турында күп төрле риваятьләр, имеш-мимешләр сөйләми калмас.

Алтын капкалар... Белмим, алтыннан булдыlармы икән алар, әмма капкалар булган. Шәһәр капкасы, авыл, кыр капкалары турында татар халкында сөйләмнәр шул чаклы күптер ки, боларның барысына да бер зур мәгънә салынгандыр.

Әле без үскәндә дә бар иде алар. Авыл малайларына бу зур дөньяның бер чиге иде ул. Безнең өчен генә түгел, гасырлар буе бер телдә, бер иманда кайнаган татар кешесенең чикләре иде алар.

Ул капкалар төзек булганда, азмы-күпме без дә төзек, ата-бабаларыбыз калыбында идек. Аңа чаклы бу дүрт гасырдан артык дәвер эчендә авыл җирендәге татар халкын яклап та, нәсел тамырларын киптермичә саклап та килүче шул ук кыр капкаларыдыр кебек тоела миңа. Еллар үтә торгач, "өстә" белделәр шул татар хәйләсен. Хәзерге вакытта юкка чыктылар ул капкалар. Үткән тормышларны искә төшереп ыңгырашып ачылмыйлар алар хәзер...

Ә иң зур капка, ил капкасы ачык иде. Аны кайсы якка кирәк, шул якка каерып ачып гасырлар буе урыс җилләре айкады.

Инде менә үзебезнең дә үзлегебезгә кайткан чак. Без дә капкалы булырбыз, алла боерса, авылыбыздагы кырлар, күңелләребездәге иман капкалары...

## *Урыс-татар дуслыгы*

1934 ел. Яңа Сала авылы халкын зар елатып мәчет манарасын киселәр. Кисүчесе — күрше Шомбыт авылы урысы Сергей. Авыл ирләренең куллары

йодрыкланса да, аларны бу адымнан тотып торганы — районнан килгән кораллы хәрбиләр булды.

1935 ел. Районнан тагын фәрман килгән: күрше Шомбыт авылы чиркәвенең тәреләрен төшерергә кирәк. Әле күнел ярасы аз гына да басылмаган Яна Сала кешеләрендә моны эшләргә теләүчеләр табылмыймы соң? Бу юлы маржалар жылый. Ә жимерүчеләрне саклаучы хәрбиләрнең күзләрендә шул ук бер салкын караш...

— Нәрсәсе комачаулый аның сезгә? — дигән урысларга да жавап әзер:

— Әнә, Сергейдан сорагыз!

Бары да бер юлы аңлашыла, барысы өчен дә бер түләргә кирәк... Һәм түләделәр дә. Әтисен тыңламаган Сергейны исерек килеш аунап ятканда терелэй үз дуңгызлары ашаса, "безнекеләр"нең дә бер өлеше сугышта ятып калды, кайтканнары да ярты-йорты гына иде.

Әйе, дога белән каргышка пәрдә юк шул.

## *Соң түгел әле*

Күрше авылның борынгы зираты ташландык кырда калганлыгын ишетеп, җае чыкканда бу турыда шул авылда яшәүче олы яшьтәге колхоз рәисеннән сорарга туры килгән иде. Бу хәбәрнең дөреслеген белгертеп, кулларын болгый-болгый горурланып сөйләде ул бу хакта. Хәер, "урыны" дип, бүгенге көндә кырда калган 10-15 сутый чамасы җир ул. Бу урынны сукаламыйча читләтеп узу, тирә ягына агачлар утырту яхшы булыр иде дигән тәкъдимне дә хуплаган иде. Әлеге эшләрне эшләү өчен эш бүлмәсеннән бер телефон трубкасын күтәрү яисә иртәнге нарядта бер сүз әйтүе дә җитә торган чагы иде аның. Әмма юк шул, ул вакытта "дәрәжә" җыйналган уңыш, савылган сөтләр белән генә үлчәнә торган иде.

Менә хәзер инде заманалар үзгәреп, пенсиягә чыккач уйлана бугай. Буш вакыт күп булгач, барыбыз да барасы җиргә дә ерак калмагач исенә төшкәндер. Хәзер инде вакыт та, акыл да бар, тик мөмкинлекләре генә элеккечә түгел. Ә кул белән эшләү, тел белән сөйләү генә түгел шул. Ана күңел байлыгы да, иман ныклыгы да кирәк.

Хәер, шулай да изгелек эшләргә беркайчан да соң түгел. Бабаларының зират урыны бүгенге көндә дә сукалана әле...

## *Намаз тәме*

Дөнья үзенең үзгәрешләрен күпкә соңрак башлады шул. Бу үзгәрешләр берничә дистә еллар элегрәк булса да үзлегебезгә, асылыбызга кайту мөмкинчелекләре күпкә җиңелрәк булмас идеме икән?

Авылдашлар әйтүенә караганда, мәрхүмә әнием исән булса, авылның остабикәсе булачак иде. Хәтеремдә, яшь булса да авылның бар карт-корысы гарәп хәрефләрен танырга, Коръән сүзенең мәгънәсен аңларга аның янына йөрде. Колхоз эше белән авыл тормышының авырлыкларына да карамастан, намаз уку өчен вакыт тапмый калмады ул.

Үзем дә кечкенә чакта әнигә ияреп "намазга баса" идем. Артыграк кызыксынсам, вакыты-вакыты белән: "И улым, дөньялар болай барса, намаз укуның савабын аңлау, тәмен тою сезгә насыйп булырмы икән?" — дип шик тә белдерә иде. Шикләре урынлы булган, ахры. Хәзер исә, көн саен үзләре теләп намазга басучы балаларымны күреп оялып куям. Үземдә дә намаз уку теләге күптәннән туса да, һаман да беренче адымны атларга куркып йөрим. Чөнки гөнаһ булса да әйтим инде, үткән заманнар сәясәтендә агуланган анда намаз тәме табылырмы?

## *Мин синең өчен шатмын, Нурия!*

Бу тормыш дигәнең кешеләрне төрле тарафларга тарытып, тагын кабаттан очраштыра икән. Минем белән дә булды ул андый очрашу. Хәер, аңлатыбрак сөйлим әле.

Университетта кичке укуым бара дигән уй белән акланып, аз булса да акчасы булыр дип, заводта эшләп йөргән чагым иде. Дөрес, акчасына карап эше дә шундыйрак иде. Бер айлык планыңны бер атнада тутырасың да, көнне ничек уздырырга белмичә завод эчендә болганып йөрисең. Сәгатьләр буе чәй эчеп гайбәт сату да гадәти күренеш монда. Олырак апалар, сөйләшер сүзләре беткәч, безгә бәйләнә башлыйлар иде. Яныбыздагы яшьрәк лаборант кызларны кызартып безгә сораулар ява: кайчан өйләнәсең дә, кайчан туеңа чакырасың — фәлән дә фәсмәтән. Бу сүзләрне авылга кайткач күрше-күләннәрдән дә, әти-әниләрдән дә ишетеп туйганлыктан, мондый чакларда эчеп бетермәгән чәйләрне дә читкә куеп чыгып китү ягын карый идек. Өч ел эшләү дәверендәге мондый чәй эчүләрдән берсе бигрәк тә күңелгә сеңеп калган. Ул көнне күрше цехтан кергән бер апа теләгәннәрнең кулларына карап язмышларын бага иде. Күбесе чынга да алмый — шаяралар, бар икән әле күрәселәр, дип көлешәләр. Бу эштән кызык табып, без — яшьләр дә — чиратка бастык.

Безгә күрше генә лабораториядә эшләүче Нурия исемле бер кыз бар иде. Чибәр, эшкә уңган бу кызны безнең кемнең кем икәнен яхшы белүче апалар миңа гел димләп тордылар. Күрәмсең, моңа охшаш сүзләрне Нурия үзе дә еш ишетеп торган, ахры, очраклы һәр очрашуда кояштай балкып исәнләшә иде. Сеңлем дә Нурия исемле булгангамы, мин дә аның исемен йомшак, матур итеп дәшкәләгәнмен икән, бу турыда ул үзе берничә тапкыр искәртте дә әле.

Ләкин аралашуыбыз шул исәнләшүдән ерак китә алмады. Юләр чак бит әле, бүгенгесе белән генә яшибез, кайдан йомшак җил иссә, шул уңайга авабыз. Хәер, анда гына да түгел иде бугай сәбәбе.

Менә бер заман авызы ерык бу кызга да чират җитте... Багучы апа: "Сеңлем, борчылмасаң гына әйтәм, ике тапкыр кияүгә чыгасың, икенчесендә генә бәхетле буласың", — диде. Апаның күз карашлары шундый ышандырырлык иде ки, Нуриябез куркуыннан кычкырып елап җибәрде һәм битен каплап чыгып йөгерде. Багучы ханым олырак хатыннарга: кызлар кирәкмәс, дигән идем бит, бу кызга яра ясадык, ахры, белмичә генә язмышына тап булган булса җинелрәк булыр иде, диде. Ә чират үзенең уен көлкеләре белән дәвам итте. Ул көнне үзем дә өч балам булачагын белеп чыгып киттем.

Тормыш үз агымында дәвам итте. Бары Нурия генә мине күргән саен тагын да ныграк кызара, кычкырып әйтмәсә дә, күзләре белән нидер сөйли иде кебек. Ә миңа көләргә җай чыкты: Нурия, кайчан кияүгә чыгасың инде, икенче юлы үзем алыр идем, дип шаяртып, аны тагын да кайгыга сала идем.

Шуннан соң бераз эшләгәч, мин башка цехка күчтем, өйләндем. Соңрак Нурия дә безнең яшьләр торагындагы бер таныш егетенә кияүгә чыкты. Аларның матур гына яшәп китүләре безнең өчен багучы апаның Нурия язмышына юраган сүзләрен юкка чыгарган иде. Ләкин... Шул чордан соң унөч ел вакыт узды. Бу язманың барлыкка килүенә дә кабат Нурияне очратуым сәбәп булды.

Хатын-кызның бәхете һәрчак аның елмаюлы йөзендә чагылыш таба, диләр. Миңа таныш булмаган бер ир белән кояштай балкып янымнан узып китте ул. Җитәкләшеп баручы бу бәхетле пар миңа шушы хатирәләрне искәртте. "Әллә чынлап та безнең язмышлар алдан язылганмы" дигән уйлар белән мин дә яраткан хатыным белән өч балам янына ашыктым.

## *"Коммунист Хәмит"*

Авылдашым Хәмит абый үзе турында язганга үпкәләмәс дип уйлыйм. Коммунизм үтеп, коммунистларны эт итеп сүккән заман булса да, ...кайсы Хәмит... дисәләр, горурлык белән "Коммунист Хәмит" дип әйтерлек абруйлы кешебез бар безнең. Гомер буе көтү дә көтеп, каравылын да торып, авыр эшләрен дә эшләп, шул ук чагында фермадан астына бер салам да салып кайтмаучы, хәләл малы белән тормышын алып барып, гомеренең кырык елын партиядә уздырган Хәмит абый ул. Аның бөтен байлыгы, җыйган малы — горур исеме. Әтисенең исеменнән малайлары да файдалана. Алар өчен ул безнең якта бер пароль кебек. Кем малае дигәнгә,

"Коммунист Хәмит"неке дисәләр, барысы да белеп, булдыра алганчы булышып, ярдәм күрсәтеп җибәрәләр аларга.

Безнең халыкта: "Ана малы белән кыз тормый, ата малы белән ул тормый" дигән мәкаль бар, шуны үзгәртеп: "Ата-анасына булган хөрмәт балаларына да житә икән", — дип әйтүем бу.

Бәлкем гыйбрәт алучылар да булыр...

## *Без күпме?*

Авырлык беләнрәк тормыш алып баручыларны күрсәм, гел мәрхүм күршебез Хәпиз (Хафиз) абый искә төшә. Машиналы заман булса да, гомере буе уфалла тартып сыерын да асрады, өен дә жылытты ул. Авылда бердәнбер булган җил капкалы, салам түбәле өйдә торсалар да, Өммегөлсем апай белән алты баласын да үстереп кеше иттеләр.

Дөресрәге, татар арасында да югалмады, урыс арасында да эремәде ул Хапиз абый. Җиргә ябышып булса да исән калды, яшәде. Шул ук вакытта, җор кеше дә иде әле ул. Аның халык арасына таралган кинаяле сүзләре бүгенге көнгәчә мәкаль кебегрәк яши бирәләр. Берсен сезгә дә сөйләп узыйм әле. Шулай бер вакыт күрше авыл урысы: "Синең, Хәпиз, гомер буе ярдәмчең дә булмады инде", — дип сүз башлагач: "Сөйләмә юкны, даром Хапиз маленки, пол Маскуа товариш", — дип тегенең авызын япкан ди. Янында торган авылдашы: "Кит инде, Хәпиз абый, анда безнекеләр алай күп түгел", — дигәч: "Татарлармы, син нәрсә, алар анда Кытайдагы кебек бер миллиард", — дип анысының да сүзен юкка чыгарган.

Кем белә, әлек түгел, хәзер дә татарның дөньяда күпме икәнен санап бетерә алган кеше юк бит. Ярты Мәскәү түгел, ярты Кытае да аның телен оныткан татар түгелме икән әле?

Менә шундый сәер кеше иде ул Хәпиз абый...

## *Гаян чәе*

Өч-дүрт әйтеп тә, утынын, печәнен алып кайттыра алмагач, тракторчы булып эшләүче ерак туганы Рәхимулланы Гаян абый акылга утыртмакчы була. Тегесе эштән кайтып килгәндә, соңгы горурлыгын җыеп чәйгә чакыра. Көненә кырыкмаса-кырык кеше техника сорап килгән Рәхимуллага, әзрәк ял итәрлек мөмкинлек чыкканлыктан, аны-моны аңышмыйча кереп тә китә. Хәйран гына төшереп алгач, тагын каклаган каз алып керү хәйләсе белән чыгып киткән Гаян абый, яхшылап кайрап куйган балтасын яшергән җирдән ала да, капка төбенә чыгып, анда торган "Беларусь"ның арткы тәгәрмәченә җан-фәрман китереп тә суга. Сугуы була, резин көпчәктән балта кире атылып китеп, Гаян абыйны бәреп тә ега. Шулай итеп, ике теше сынган, аңсыз калган Гаян абый капка төбендә ярты сәгатьләп тәгәрәп ята.

Озак көткәннән соң, нәрсә булды икән, дип, урамга чыккан Рәхимулла булып узган эшләрнең сәбәбен соңыннан гына аңлаганлыктан, "житкән икән моңа" дип алпан-тилпән тракторына утыра да китеп бара.

Тирә-якта хәзер кунакка чакыручыларга "Гаян чәенә" түгелме дип шаярталар. "Туган итмәгән туганның чәе әче суган" икәнен белсә дә, "кара эшнең каршы төшәсен" белмичә халык теленә кереп калды Гаян абый.

## *Хикмәтле хөкүмәт*

Әниләр сөйләгәнчә яшел кычыткан, черек бәрәңгеләр ашау тәтемәсә дә, кечкенә генә шакмак шикәрне дә дүрткә бүлеп ашаган заманда яшәдек без. Бабай шул чаклы зур осталык белән бүлә иде аны, беркемнең дә үпкәләрлеген калдырмый иде. Ә икенчесенә үрелгәндә кулга сукмасалар да: "күбрәк тәмлерәк ашыйсын килсә, әнә, "Хөкемәтулла абыеннан сора" дигән сүзләрне еш ишетергә туры килә иде.

Шунлыктан мин кечкенә чагымда, югары очта яшәүче Хикмәтулла абыйның бу эштә ни катнашы барлыгын белә алмыйча гел аптырый идем. Житмәсә, ул үзе әле безгә туган да булып, аларның үз тормышлары да безнекеннән артык түгел иде.

Хәзер, олыгайгач та Хикмәтулла абыйны күргән саен, һаман шул бала чактагы хатирәләр искә төшә.

Бүгенге көндә балалар шоколадка акча сораса, юклыгын әйтеп, сәбәбен "Хөкемәтулла бабай"га сылтыйбыз. Балалар исә "кем соң ул Хөкемәтулла бабай" дип аптырыйлар. Аптырарлык та шул.

Без "хөкемәт"нең кем икәнен белүен беләбез дә, тик нигә һаман башка халыклар кебек кешечә яши алмавыбызның гына хикмәтен аңлап бетерә алмыйбыз.

## *Исем белән җисем арасы*

Исеме Мулланур булса да, гомер буе шул матур исемен матур килеш йөртә алмады сабакташым. Егет чагында ук аракыга алданып, әти-әнисенә, соңрак хатыны белән балалары өчен дә бер имгәккә әверелде ул. Исеме дә Мулланурның нурын югалтып, "муллый"га гына калды. Кайда абынсаң, шунда исерек Муллый ятканлыктан, юлдагы һәр кара түмгәкне дә нәрсә икән дигәндә: Муллыйдыр дип кенә җибәрә башладылар.

Атаң кушкан атың, халык кушкан белән бергә туры килсен өчен гомер буе тырышырга кирәк шул. Классташым Мулланур моны бер аңлап, хатынының, бала-чагасының, авылдашларының хөрмәтен кабат кайтара алырмы?

Исемең җисемеңә туры килсен икән лә бу тормышта!..

## *Утырып уйлар уйладым*

Борынгы Чаллы шәһәренең әлеге зираты тарихта билгесез булып, без аны ярдан кеше башлары чыгып торганлыктан гына табып тикшергән идек. Бу табылдык тирә як авыллар халкында гаҗәпләнү уятты. Күнелдә бер абыйның: "Гомер буе шушы тирәдә көтү көтеп, ашап-эчеп, йоклап йөрдем, әмма бу җирнең зират өсте булуы мөмкинлеге башыма да килмәгән иде", — дип сөйләгәннәре истә калган.

Быел да зират яныннан агып яткан елга буенда йөргәндә, кабат баш сөягенә тап булдым. Ел саен язын елга яры җимерелеп, су ташкыны аларны күпләп Шомбыт елгасына ташый икән.

Кулымдагы баш сөягеннән миңа ике зур тишек карый. Бу башта нинди уйлар кайнап, исән чакта бу күзләрдән дөньяга нинди караш ташланды икән дип уйлыйм. Әмма озак хисләнергә туры килми, дөньяның һәркем өчен вакытлы булуы искә төшеп, үз уйларымнан үзем куркып бүгенге дөньяма кайтам. Киләчәктә аунап яткан безнең башларны да шулай тотып карап, боларда нинди уйлар йөрде икән дип уйлаучылар табылмасмы?

Хәер, хәзергә бу бездән тора, монда үткәннәр белән киләчәкнең гаебе юк. Әллә бармы?.. Бүгенге көндә бит үтәчәк заман.

## *Нәфескә бәйле татар феномены*

1989 елда Болгарда ислам дине кабул ителүенең 1100 еллыгы бәйрәмендә бер вәгазь сөйләүченең "Татарның гасырлар буе кол булып, изелеп, үз байлыгына үзе хуҗа була алмауның сәбәбен әйтимме?" дип, озак итеп сорау рәвешендә сөйләве бик күп кешене үзе янына җыйды. Сорауны озакка сузганга, башка төрле уйлар килде. Дөрестән дә, кем калдырды икән безне бу хәлгә: урысларммы, коммунистлармы дигәндәй? Әлеге сорауга җавапны дин әһеле авызыннан ишетү бигрәк кызык иде.

Шулай да соравы озын булса да, җавабы кыска булды мулла абзыйның. Гаеп татарның үзендә, дөресрәге, аның нәфсесендә булып чыкты. Ул гомер буе ат урынына эшләгән, байлык җыйган, байлыктан арысын күрмәгән. Шул байлыгына

кызыгып, аны алдаганнар, талаганнар. "Татарның нәфесе безнең һәрберебезнең күңелендә утыра" дип бетерде ул сүзен.

Аның белән тулаем килешмәгән булсам да, нәфескә бәйле уйлар миңа бүген дә тынгылык бирми.

Авылга кайткан саен пенсия алып та, үлә-үлә эшләүче пенсионерларны күрәм дә уйлап куям: мал, дөнья артыннан куганчы, тәрбияле оныклар, дөнья гыйлеме һәм кешеләр күңелендә изге хисләр, хөрмәт билгеләре калдыру дөресрәк булмасмы? Бу яшьтә намазга басып, ходайдан картлык көннәрендә үзләренә саулык-сәламәтлек, дөньяларга иминлек сорасалар үз кадерләре дә күбрәк булыр иде.

Кешегә яшәгән саен азрак кала, анысын барыбыз да беләбез, ә менә безнең халыкка азрак калган саен күбрәк кирәк булып чыга. Җир йөзендә татарның нәфескә бәйле бу феноменын аңлата алучы берәр галим-голәмә табылырмы икән? Әллә мин дөрес уйламыйммы?

## *Балаларыбыз үзебезнекеме?*

Шәһәрдән авылга күчеп кайткан дустым белән әллә нигә бер очрашып булса да, озак кына дөнья хәлләре, үткән-сүткәннәр, узган-булганнар турында сөйләшеп утырабыз. Яшьлегебезне искә алып, тора-бара сүз үзебезнең балаларга күчкәч, күршем уфтанып куйды да, әллә мактанып, әллә зарланып, балаларының шәһәрдә түгел, гади татар авылында торып та, үзара урысча сүзләр кыстырып сөйләшүләре һәм авыз эченнән әллә нинди аңлашылып бетмәгән реклама "сагызлары" әвәләп йөрүләре турында искәртте. Җитмәсә балалары әле кечкенә булуларына да карамастан, әниләренә генә түгел, әтиләренә дә җикеренеп: үзебез беләбез, тыгылма, өйрәтмә, дигән сүзләр кыстырып җибәрәләр икән. "Кая бара бу дөнья?" — дип сорады ул?

Дөнья кая барган булса, шунда бара инде ул. "Көннәр буена телевизорынны кәгъбә ташы кебек күрә башласаң, тиздән балаларың бөтенләй дә үзеңнеке булмас әле", — дидем мин аңа. Ул 20 нче гасыр шайтаны, ак киптергеч күк бала күңеленә тагын нинди генә пычраклар агызмас әле...

Гасырлар буе татарлыгыбызны сакларга ярдәм иткән кыйблабызны үзгәртмәскә кирәк безгә. Шул чагында гына, кайда яшәсәк тә, балаларыбызны үз ата-бабаларыбыз калыбында калдырырга мөмкин булыр.

Тукта. Кешегә акыл өйрәтүе җиңел ул. Кайтып үз балаларыма да тагын бер кат күз салыйм әле...

## *"Кәбир самолют"*

Гомер бакый урыс арасында яшәп үскән ул Кәбир абый. Яшен тизлегендә аракы таба алганлыктан дус-ишләре "самолют" дип кушамат такканнар аңа. Әмма исеме ковер сүзенә охшаганлыктан, соңрак "ковер самолют"ка әйләнеп китә ул. Поселокта беренче алкаш булса да, аннан эшчән, төгәл, хаклы кешене таба алмассың. Шунлыктан бурычка аракы сорап килгәч, аның гозерен аяк астына салып таптаучы кеше юк. Аның тагын бер үзенчәлеге шунда, хәлләр ничек дип сорый да, авызыңны ачканчы: "Аллага шөкер дип әйт, син бит татар малае", — дип әрләп ташлый. Азрак ачылып китеп сөйләшсәң: "Эх, энекәш, мин бит башка дөньяда, чит кешеләр арасында туып үстем, татар авылында туып, әби-бабайлар кулында үссәм мондый булыр идеммени мин", — дип кулы белән күз яшен сөртеп ташлый да, минутында юкка чыга.

Белмим, Кәбир абый, башка заман булып та, әби-бабайлары кулында тәрбияләнеп үскән "ковер самолютлар" татар авылларында да буа буарлык хәзер. Сездәге кебек татарлык һәм күңел уйлары аларда булса, бәлкем, алай артык уфтанмас та идең. Юк шул. Ярый әле чын "ковер самолет" кебек күктә очып йөрмиләр, алай булганда татар җиренә кояш нуры да төшә алмас иде.

Хәер, татар җире киләчәктә дә тереклек итсен өчен кояш нуры гына җитәрлек түгел инде хәзер. Барысына да җитәрлек иман нурын каян табасы?!..

ПУБЛИЦИСТИКА

## Марсель Зарипов

# "КАРА МАЙ"НЫҢ КАЛДЫГЫ

Татарстан нефте һәм нефтьчеләре турындагы документаль китаптан

*Элек бер башак үскән урында ике башак, бер үлән үскән урында ике үлән үстерә алган кеше бөтен кешелекнең рәхмәтенә лаек булыр, үз иленә зур хезмәт күрсәтер иде.*

Джонатан Свифт.

* * *

1995 елның язы иде.

Татарстанның радио һәм телевидениесе атна буена шәһәр халкын башкалабызда нефтьчеләр үткәрәчәк азык-төлек ярминкәсенә чакырып, анда булачак сый-нигъмәтнең муллыгы белән кызыктырып торды. Мондый хәлнең әле ишетелгәне юк иде. "Кара алтын" осталары Казанның миллионлы халкын туйганчы ашатырга-эчертергә җөрьәт итәләрме? Мин җиде көн дәвамында аптырашта булдым: кайдан килгән ул муллык-байлык аларга, нинди яшерен запасларыннан?

Кибет киштәләре ярлы булып, халык күпчелек азык-төлекне талонга гына алган заманнарда, кибетләрдә ач-усал озын чиратлар тезелеп тормасын өчен, нефтьчеләр, ерак вахталарга киткәндә, өйдә калган гаиләләрен ничек туйдыру турында кайгырмыйча, яңа скважиналар, "кара алтын" ташкыны турында күбрәк уйлансыннар өчен, нефть төбәгендәге җитәкчеләрнең мөмкин булган һәр җирдән өстәмә азык-төлек соранып-кымтырыклап йөргәннәрен яхшы хәтерлим әле.

Ул вакытта, дәүләт фондыннан тыш, нефтьчеләрнең азык-төлек белән азмы-күпме тәэмин итеп торырлык ике генә ярдәмче хуҗалыгы бар иде. Аның берсе Яшел Әрәмәлек (Зеленая Роща совхозы — 1943 елда җир астыннан беренче нефть табылган урындагы авылда, икенчесе Ромашкино ятмаларының нәкъ үзәгендәге Түбән Мактамада иде. Әлбәттә, бу ике совхоз гына гаиләләрендә карт-корылар, хатын-кызлар, бала-чагалары булган йөз меңләгән нефтьчеләрнең ихтыяҗын канәгатьләндерә алмый иде. Шунлыктан, һәр литр сөт, һәр кисәк ит, һәр тавык-чебеш, теплицаларда үстерелгән һәр кыяр-помидор исәптә булды — алар бары тик шул нефтьчеләр өстәленә генә куелырга тиеш иделәр.

Әлеге зур ярминкә турында ишеткәч, мин башта, "кара алтын" осталары да хәзерге вазгыятькә яраклашканнар икән — читтән арзанга сатып алып кайтканнардыр да, биредә ике-өч бәягә кыйммәтрәккә сатарга уйлыйлардыр, дигән шиккә дә төшкән идем. Яшереп торасы юк: бүгенге

---

Журнал вариантын Марс Шабаев эшләде һәм иректе тәрҗемәләде.

кыргый базар шартларында шундый сөүдә гөрли бит. "Шүреләр" — "челноклар" дип йөртелә торган алып-сатарлар шәһәрләр, илләр, кыйтгаларның базарларын айкыйлар. Поездлар-самолетлар аларны Бөек Кытай Дивары артына да сәяхәт кылдыра, Төркиягә һәм Төркиядән дә өрле-бирле ташып тора. Хәзерге базарда тулы хөррият! Тукаебыз әйтмешли: кайсы алдый шунда, кайсы алдана.

Әмма бит нефтьчеләр үзләренең төп эшләрен — "кара алтын" чыгаруны тырышып башкара торалар, куелган бурычны үтәп, елына ике дистә ярым миллион тонна чамасы нефть бирәләр. Димәк, алыпсатарлыкта йөрергә аларның вакыты калмаска тиеш. Шулай булгач, бу ярминкәнең сере-хикмәте нәрсәдә соң?

* * *

МОННАН кырык еллар элек газеталар шаккатыргыч вакыйга турында хәбәр иттеләр: СССР Фәннәр Академиясенең Президенты академик А. А. Несмеянов җитәкләгән элементоорганик кушылмалар институтында синтезлау, ягъни химик реакция ярдәмендә аерым элементлардан яңа бер кушылма ясау ысулы белән кара уылдык (бөтен дөньяга атаклы "черная икра"!) эшләп чыгарганнар. Нәрсәдән дип уйлыйсыз? Дөрес — нефтьтән! Әлбәттә, бу ачыш искиткеч кенә түгел, ә күрелмәгән ачыш иде. Институтта, алга киткән илләр үрнәгенчә, бу затлы ризыкны татып, авыз итеп карарга һәм бәя бирергә дип, иң әүвәл журналистларны чакыралар. Алар, озын-озакка сузмыйча, бу куанычлы хәбәрне бар дөньяга ирештерсеннәр, янәсе. Зур җиңү бит! Кешеләр азык аксымын ясарга өйрәнделәр, диген сүз! Ачлык патшадан мәңгегә куркып торуга чик куела, кешелекнең яртысы туйганчы ашый алмыйча интегүләр бетә, болай булгач...

Әмма журналистлар нәзберек халык булып чыга, әлеге ясалма затлы уылдыкны кабып-татып караганнан соң, бер дә блокнотларын ачып яза башларга ашыкмыйлар, йөзләрен гене чыталар: "Тәмсез!" Бетте баш, ничәмә-ничә еллар тырышулар, мәңнәрчә тәҗрибәләрнең нәтиҗәләре җилгә очамы? Эш шунда була: авыз итеп карарга бирелгән затлы уылдык... яшькелт төстә икән! Шунлыктан, татып карауччыларда, Павлов этендәге шикелле, шартлы рефлекс туа: аларның күзаллавында чын уылдык ике гене төстә — кызыл һәм кара гына була ала ич.

Галимнәрдән бер зирәгрәге ясалма уылдыкны татып карауны дөм караңгыда үткәрергә киңәш итә. Шулай итәләр дә. Икенче төркем журналистларны чакыралар, утларны сүндерәләр дә, ясалма уылдыкны ак көмечкә юка гына сылап та, кашыклап та ашарга ирек бирәләр. Аннары сорыйлар: "Йә, ничек? Ошадымы? Тәмлеме?" "Бик шәп! Бик тәмле! Телләребезне йота яздык! Нинди гаҗәеп балыкныкы соң бу уылдык?" — диләр журналистлар.

Шуннан соң залда утны яндыралар.

* * *

ИЛ-ДӘҮЛӘТЛӘРДӘ яшәүче халыкларны азык-төлек белән тәэмин итү мәсьәләсе — гасырларның гына түгел, меңәр елларның кайгы-борчулары ул. Бигрәк тә азык аксымының кешелек дөньясы өчен җиткелекле булмавы нык сизелә. Борынгы ыру-кабиләләр дә көннәрен тамак туйдыру мәшәкате белән үткәргән, бүгенге тәрәккыят заманында да ул шулай. Җир шарында халык саны үскәннән-үсә бара, ә мөмкинлекләр, ягъни планетаның мәйданы үзгәрешсез: җир шарының диаметры элек тә кырык мең километр булган, хәзер дә, мөгаен, шулайдыр. Дөрес, бу мәйданның җитештерүченлеге, файдалы куәте арта тора. Элекке заманнарга караганда, чагыштырмача югары дәрәҗәдәге игенчелек, терлекчелек-кошчылык һәм башка төр эш-гамәлләр азык-төлек җитештерүне ишәйтсә дә, ашаучылар саны тагын да тизрәк үсә бара.

Рим империясе чорында җирдәге халык саны якынча 250 миллион чамасы булган. Бу сан икеләтә артканчы мең ярым ел вакыт үткән. Үлем-китем күп, кешенең гомере бик кыска булган. Яңа эрага кадәр җирдә

кешелек бер җанга артсын өчен алты минут вакыт кирәк булган. Үрчем елына йөз мең генә кеше тәшкил иткән. Икенче-өченче меңъеллыклар чигендә инде башкача күренеш: бер секунд саен өчәү туа, берәү үлә — нәтиҗәдә, артым — ике кеше, дигән сүз. Димәк, хәзер без елына 70-80 миллион кешегә ишәя торабыз. Җир шарындагы халык саны алты миллиардтан арта бара. Бу кадәр халыкны ничек итеп юньле-рәтле туйдырып тормак кирәк?!

Нефтьтән ясалган затлы кара уылдык — бу юнәлештә фәнни эзләнүләрнең беренчесе һәм соңгысы түгелдер. Шул ук академик А. Несмеянов институтында иттер-балыктыр, соядыр-фәләндер ишеләрнең ашарга ярамастай калдыкларыннан затлы азык алу ысулын тапканнар. Мәскәүнең сөт институтында сөт аксымыннан тәмле-туклыклы ит ашамлыклары ясарга өйрәнгәннәр, ит һәм сөт сәнәгате технологиясе институтында казылык, бифштекс, котлет кебек ашамлыклар ясаганнар — хикмәте шунда: аларга бер мыскал ит тә салынмаган! Хәзер инде аксымнан — бөреңге, бөртеклеләрнең калдыгыннан яки сөт аксымыннан — дөге, казеиннан — макарон, үләннәрдән сөт ясау ысуллары бар икән. Шундый чор килеп җитәр: кыр-басуларда, фермаларда үстерелгән-җитештерелгән табигый азык-төлек урынына кешелек дөньясы ясалма ризык кына ашый башлар...

Әллә соң нефтьчеләрнең Казандагы Чехов базарында оештырган ярминкәсе дә әнә шул чор килеп җиткәнне хәбәр итәме? "Кара алтын" осталары, чи нефть сатуның наданлык икәнен аңлап, әллә соң галимнәрнең тәҗрибә төсендә лабораторияләрдә генә эшләп азапланган ясалма азыкларын нефть промыселларында җитештереп, дөнья базарына тәрәзә уярлармы? Күз алдыгызга китерегез: нефтьтән ясалган шашлыкларның тәмле хуш исе!

Хыял, хыял...

* * *

ӘЛБӘТТӘ, ярминкәдә халык — диңгез иде! Тагылма әрҗәле йөк машиналары белән урамнар-тыкрыклар тулган, соңыннан белдем: биш йөздән артык машина килгән булган икән! Һәркайда күз явын алырдай чатырлар-палаткалар — "Татнефть" акционерлык җәмгыятенең барлык аграр хуҗалары һәм сәүдә оешмалары җөмһүриятебез башкаласын муллык белән, сый-нигъмәт белән яулап алырга килгән.

Нефтьчеләрнең ике дистәдән артык сәүдә оешмалары бар, аннан кала агроцехлар дип йөртелә торган ничәмә-ничә ярдәмче хуҗалык — болар барысы да ярминкәдә. Һәркайсы башкалардан уздырып сату итәргә тырыша. Алып килгән малның-товарның, азык-төлек, сый-нигъмәтнең исәбе-чуты юк. Аллы-гөлле итеп матурлап бизәлгән сату урыннары, сатучыларның уен-көлкеле сүзләре, кояштай елмаеп-яктырып торган йөзләре! Әйтерсең лә, өчәр-дүртәр йөз километр юл үтеп килмәгәннәр дә, чатырларын-палаткаларын урнаштырып-корып, товарларын барлап йокысыз төн үткәрмәгәннәр болар. Шулай төне буе ут уйнатып мәш килгәннәр. Иртәнге сәгать алтыдан инде һәркайсы үз урынында: ит чабучылар ит түшкәләре янында, пешекчеләрнең бер ише мангалларына ут ягып җибәргән, кайнар күмер төшерергә ашыгалар, серкәдә чылатылган ит кисәкләрен суган белән аралаштырып шампурларга тезәләр — тиздән һавага тәмле шашлык исе таралыр.

Исем китеп карап йөрим.

Чиста-әре карабодай, карабодай кырларыннан бал кортлары җыйган хуш исле бал — боларын азнакайлылар алып килгән. Онның кәрәгчәткә агы дисеңме, эрерәк тарттырганымы, комбикормлык фуражы дисеңме — Елховой нефтьчеләренең тегермәне ашлык-бөртекләрне алты төрле иттереп тарттырып биргән. Ысланган тавыклар, — Америкадан китерелгән "Буш ботлары" түгел! — үзебезнең Татарстан тавык ботлары, һәртөрле казылыклар — Әлмәттәге ярдәмче хуҗалык агроцехларыннан. Баулыда әле ярминкә ачылыр алдыннан гына Австралия технологиясе белән җиһазландырылган ит комбинаты ачканнар, ярминкәгә шунда җитештерелгән затлы ризыкларны төяп килгәннәр. Кем балык ярата, шул зәйлеләр янына ашыксын! Әнә, — яңа гына судан алынганнар диярсең! — сыла,

чуртан, сазан, корбан... Кенбатыш маеның төмле исе бөтен базарга таралган кебек — анысы норлатлылар өлеше. Бу нинди алтын таулары? — дисәм — Чулман-Кама буйларында үстерелгән сары суганнар икән. Урман тынлыгына иялəшкəн күзəннəрнең кечкенə елтыр күзлəре бу кадерле халыкка аптырап-куркып карый шикелле — боларын "Җəлилнефть" җəнлек үстерүчелəре китергəн. Кай арада котүен үрчетеп өлгергəннəр дə, кай арада сыр ясарга өйрəнгəннəр, диген — ямашныкыларның түгəрəк-түгəрəк, сап-сары сырлары күз явын алырлык!

Ак күбеклə рəсемнəр белəн бизəлгəн юан корсаклы мичкəлəр янында күбрəк ир-ат кайнаша: Лениногорск нефтьчелəренең "Ромашкино сырасы"н авыз итəргə җыелганнар. Сыраның төрлесен эчкəнем бар: Жигулиныкын, Риганыкын, Мəскəүнекен, Пильзеннекен, Баварныкын, Казанныкын, "Сабан-туй"ын, "Ак барс"ын... Əмма берсе турында да җыр-такмак ишеткəнем булмады. Ə менə "Ромашкино сырасы" турында авыз тутырып такмаклар əйттерəлəр иде. Кружкаларда сыра күбеклəнə, мичкəлəр тирəсендə халык артканнан-арта, чөнки сыра эчүнең дə үз хикмəте бар: аны озаклап, берəр төрле тозлы балык кабыргасы суыра-суыра, тəмлəп, дөнья хəллəреннəн башлап үз хəллəрең турында, сəясəт турында əңгəмə-бəхəслəр корып эчəргə кирəк. Ə сыра сатучының магнитофоны такмаклап тора:

— "Төмледəн дə нəрсə тəмле, нəрсə шəп?" — дип сора син. Тəмледəн дə тəмле була Ромашкино сырасы.

Ярминкəгə китерелгəн бу байлыкларның барысы да үз җиребездəн. Аларга бер төрле химия-фəлəн кермəгəн, чиста-саф. Шундый нигъмəтлəр бар чагында "Буш ботлары", фламанд майлары, фин-немец казылыклары-фəлəннəрне бер якта торсын! Аларның бит бар кызыктырырлыгы шул матур итеп рəсемлəп эшлəнгəн тышкы кабыгы гына, үзлəрен, тəслəрен саклансын дип, углекислый газ камераларында ыслап алганнар да, тутырганнар. Юкса, шул кадəр еракларда бозылмый-нитми ничек килеп җитсеннəр дə, ничек сатып бетермəк кирəк аларны?

Ə менə бер урында, əбилəр əйтмешли, чын "кəнсирт"! Хəзергəчə əйтсəк, шау-тамаша! Түгəрəктə сандык хəтле аккордеоннар-баяннар, көмеш кыңгыраулы саратски гармуннар əйттерепме-əйттерə, сиптерепме-сиптерə! Нефтьче "артист" егет-кызлар əле шаян "Əпипə"не тыпырдаталар, əле урыс "Барыня"сын чыкылдаталар. Түгəреклəп җыелышкан халык: "Эх-ма! Əйт шуны! Сип əйдə!" дип дөртлəндерəп тора. Кайбер кайнаррак йөреклелəре түзми, үзлəре дə тыпырдап биеп, түгəрəк эченə кереп китə. Ниндидер бер чая чиберкəй халык арасыннан нефтьчелəр генералы Ринат Галиевне танып алды бугай, биек үкчəле туфлилəре белəн тыпыр-тыпыр килеп, аны биергə чакырды. Бу ярминкəгə рух бирүче, җан өрүче хуҗа кыстатып тормады, матур гына биеп тə китте. Кəефе күтəрелгəн дəртле төркем Татарстан Президенты Минтимер Шəймиевне дə түгəрəк эченə тартып кертте. Халык сорагач, биеми хəлең юк! "Бас, əйдə, Президент! Син басмасаң, мин басам..."

Менə шундый күңелле вə файдалы бəйрəм булды бу ярминкə!

* * *

ХЫЯЛЛАРДАН арынып, бəйрəм шаукымыннан айныйк та, эшлекле гамəллəргə күчик əле.

Бик табигый сорау туа: үлəт вакытында нинди туй, дигəндəй, нинди бəйрəм булды соң əле бу?

Ил-дəүлəтнең күпчелек халкы хəерчелектə яши, икътисад үлем хəлендə, сөрелми-чəчелми калган ташландык басу-кырларны чүп баса, көтүлəрдəге мал-ларны бетерəлəр. Моңа кадəр Европаны икмəк белəн тəэмин итеп килгəн Россия Американы куып җитеп узып китəргə хыялланган Никита Хрущев заманында океан артыннан — Канада белəн Америкадан саф алтынга бодай сатып ала башлаган булса, хəзер инде сагыздан алып "Бушның тавык ботлары"на кадəр китереп тутырдылар. Шундый чакта Татарстан нефтьчелəренə каян килгəн бу муллык-байлык? Əле бит Бөек Ватан сугышы җиңү белəн тəмам-ланганнан соң өч дистə еллар үткəч тə, кызганыч вə хурлыклы да булган азык-төлек талоннары

белән яшәмәдекмени? Иткә-майга, шикәргә, хәтта аракыга да талоннар бар иде бит!

"Кара алтын" осталарының бүгенге муллыкка тиенүен аңлар өчен, сиксә-ненче еллар башына кайтып, календарь битләрен шуннан актара башларга кирәктер. Нәкъ шул елларда нефтьчеләрнең аграр революциясе башланган иде.

1980 елда Татарстан нефтьчеләренең ярдәмче хуҗалыкларында 13 мең гектар чамасы чәчүлек һәм көтүлек җирләре бар иде. Алар ул елны 7,5 мең тонна чамасы ашлык, 2,2 мең тоннадан артыграк яшелчә җитештерделәр, 3 мең баш чамасы эре мөгезле терлек, 21 мең баштан артык дуңгыз асрадылар, һәр сыердан 2,4 мең килограмм чамасы сөт савып алдылар. Бүгенге нәтиҗәләр белән чагыштырганда, күлдән бер тамчы гына иде инде! Шулай булса да, якын киләчәктә ит җитештерүне — өч, сөтне — дүрт, яшелчәне — биш, йомырканы бер ярым мәртәбә арттырырга диген бурыч та куйдылар.

Дөрес, баштарак нефтьчеләрнең бу ниятләренә ышанмыйчарак караучылар да булмады түгел, булды.

Җиде дистә еллар буена муллык-байлык килерен өмет итеп яшәгән совет халкын ни Хрущев, ни Брежнев, ни Горбачев куандыра алмады. Хәзер исә, хакимияткә Ельцин һәм аның еш алышынып тора торган командасы килгәч, бөтенләй дә эшләр кирегә китте. Россиядә барган "үзгәртеп корулар"ның беренче биш елында гына да сәнәгатьтә җитештерүчәнлек 40 процентка кимеде, чәчүлек җирләр 15 миллион гектарга кыскарды (бу —дүрт Татарстанның басу-кырлары була алыр иде!), фермаларда калган малларның саны 1961 ел дәрәҗәсенә төште... Саный китсәң, чәчләрең үрә торырлык!

Колхоз-совхозларны бетерәбез, алар — төпсез сазлык кебек: күпме генә акча салма, күпме генә бурычларын сызып ташлама — файдасыз... Менә шундый сүзләр сөйләнеп, башта аларның исемнәрен үзгәртергә тотындылар: крестьян хуҗалыклары ассоциациясе, авыл хуҗалыгы фирмасы, ширкәтләр... Татарстанда бигрәк тә кызык: элекке колхоз, ягъни "коллективное хозяйство" тәгъбиренең кыскартылган өйтелеше бүген... күмәк хуҗалык! Аны соң колхозлашу еллары башлангач та шулай "күмхуҗ" дип тә йөрткәннәр ич, әле утызынчы еллар башында ук! Исемдә генә булса иде хикмәт...

"Җир турындагы закон"ның уйланып-эшләнеп бетмәгәнлеге көн кебек ачык булса да, крестьяннарны ирексезләп диярлек фермерлыкка куалар, колхоз-совхозларны таратып, җирләрен-малларын, фермаларын-техникасын бүләләр. Әнә паең —үз өлешең, агай! Теләсә нишләтә аласың: җир сөреп иген үстерәсеңме, сатып эчеп бетерәсеңме — үз ихтыярың!

Болай барса, янә биш-ун елдан Россиянең авыл хуҗалыгыннан нәрсә генә калыр икән?...

Чынлыкта, колхоз-совхозлар социалистик системаның иң отышлы табышы — иң аз матди һәм техник чаралар кулланып, авыл хуҗалыгын үстерү мөмкинлеге иде. Илнең 210 миллион гектар чәчүлек җире, күмәк хуҗалыклардагы 120 миллион баш эре мөгезле терлеге, исәпсез-хисапсыз дуңгызы-сарыгы, кош-корты булып, җилек-җимеш һәм яшелчә бакчалары, бәрәңге басулары күкрәп утыра иде. Бөек индустриаль-аграр дәүләт булган СССРдагы милли керемнең чирегең авыл хуҗалыгы бирә иде.

Әмма совет чорында, иң әйбәт диген елларда да дәүләтнең авылга тоткан чыгымы бюджетта 12 процентттан артмады, гадәттә ул 7-8 процент кына була иде. Мондый аз чыгымнар белән ни Америка Кушма Штатлары, ни Голландия, ни Израиль, ни Германия, ни башка алга киткән илләр дә үзләренең азык-төлек мәсьәләләрен хәл итә алмас иделәр. Азык-төлекне үзләре өчен генә җитештереп калмыйча, башкаларга да сата алырдай илләрнең һәрберсендә авыл хуҗалыгына шактый зур чыгымнар тотыла. Кайбер илләрдә фермерлар алган табышның 50-60 процентын дәүләт бюджетыннан алынган дотация тәшкил итә. Мәсәлән, белгенлеккә төшкән Россиягә ашлык сатып баеп ятучы Америка 1987 елда фермерларга дәүләт бюджетыннан 17 миллиард доллар өстәмә түләү бирген һәм соңыннан бер тиенен дә кайтарып алмаган. Бу сумма, фермерлар үзләре тоткан чыгымнардан алты мәртәбә артык булып, җитештерелгән азык-төлек бәясенең 40 процентына тиңгәл килә.

Дәүләттән саран гына ярдәм алуга да карамастан, гектарыннан уртача 15 әр центнер ашлык җыеп, һәр сыердан 2,5 мең килограмм сөт савып, шәһәр кибетләрен талонлык булса да азык-төлек белән тәэмин итеп торган совет крестьяннарын илнең игелекле фидакарь затлары дип атасак, гаделрәк булыр иде. Ә инде һәр салганны йота баручы "төпсез сазлык"ны икенче җирдән эзләргә кирәк: ул — хәрби-сәнәгать комплексы. Армия, авиация һәм флот үз илебезне генә түгел, янәмәсе, Көнчыгыш Европадагы башка социалистик илләрне дә (СССР буйсындырган илләрне!) дошманнарыбыздан саклап торды. Моның өстенә, бал-майда йөзгән исәпсез-сансыз бюрократ түрәләр, халык җилкәсен кимерүче, инде үзләре күптән коммунизмда — "һәркемгә — теләгәненчә" алып яшәүче партсовноменклатура... Шулай булды, һаман да шулай түгелме? Исемнәре генә башка...

Чокырга тәгәрәгәнсең икән, аннан чыгу өчен иң элек чокырның тирәнлеген-мәү ягын карарга кирәк. Сәяси чаралар белән генә — колхоз-совхозларны таркатып, хосусый милекчелеккә хәер-фатиха биреп, матди ярдәм күрсәтмичә, җирне фермерларга сатып һәм аны теләсә кемгә, теләсә кайчан сатарга рөхсәт биреп кенә крестьяннарның икътисади хәлен яхшыртып булмаячак, әлбәттә. Фермерлыкка киткән крестьянның бер гектар җирен эшкәртү һәм уңыш алу өчен колхозга тотканда караганда 5-10 мәртәбә артык чыгым кирәк булачак. Чит ил банкларыннан бурычка акча теләнеп яшәгән Россия дәүләтенең андый чыгымнарга барырлык мөмкинлеге юк. Нәтиҗәдә, күп кенә фермерлар җирләрен кайтарып бирә башладылар, күмәк хуҗалыкка берләшкән крестьяннар да аптырашта. Нишләргә соң? Хәлләр яман бит! Бүгенге ислахчы-реформаторларның уйланмаган эш-гамәлләре тоталитар сталинчыл система җимешләрен генә кабатлый түгелме соң?

Сталин заманында кызыл комиссарлар наганнар белән төрткәләп-куып крестьяннарны колхозларга керткән, риза булмаганнарына "кулак" мөһере сугып сөргеннәргә сөргән, биш ел эчендә илдәге эре мөгезле терлекләр саны белән дуңгызлар саны яртылаш, сарык-кәҗәләр саны өч мәртәбә кимегән булган. Ә хәзерге аграр реформаларның биш елы да шундый ук диярлек югалтуларга китермәдеме икән? Колхозлашканда да югалт, колхоз-совхозларны таркатканда да югалт — ничек итеп авыл хуҗалыгы үссен дә, ничек итеп муллык-байлык көтмәк кирәк?!

* * *

Бетеп барган авылларны җирләре-ние белән үз карамакларына алып, шул җирләрдә иген игеп, мал үрчетеп, үз тамакларын үзләре туйдыру уе Татарстан нефтьчеләренә илдә Брежнев хакимлек иткән еллар азагындарак килгән иде. Азык-төлек муллыгын булдыру турында чираттагы гомумсоюз программасы кабул ителгән сиксәненче елда ул хыялларның һаман да кәгазьдә генә калачагын абайлап алган нефтьчеләребез: "Нигә әле без үзебезне үзебез туйдырырлык мөмкинлекләр таба алмаска тиеш?" — дигән фикергә киләләр. Менә шуннан соң башлана да инде "кара алтын" осталарының аграр революциясе!

"Аграр революция" дип авыз тутырып әйтелсә дә, 1980 елда "Татнефть"нең ярдәмче хуҗалыклары җитештереп, нефтьче гаиләләренең өстәленә менгән ризыкны исәпләсәң, җан башына елына 9 кило ит (тере үлчәүдә), 24 литр сөт, ике потлап яшелчә туры килә. Бер уйласаң, кечә телгә дә җитәрлек түгел инде! Ә шулай да... башлап җибәрү хәерле бит. Иң сөендергәне — ташландык авылларга җан керә, авыллар терәкләнә башлый.

Аннан соңгы ун ел эчендә юньле-рәтле хуҗасы булмаган тагын 10 мең гектар җирне үз кулларына алалар нефтьчеләр. Вакытында чәчеп, вакытында җыеп алырга өйрәнәләр, ашламаларның "минералка"сын да, тиресен дә мулдан, әмма белеп куллана башлыйлар, эре мөгезле терлек көтүләрен бермә-бер, "мыркылдык"ларны бер ярымга арттыралар. Бер генә чагыштыру: совет власте елларында сөт савымы елына уртача егермешәр килограммга гына артып килсә, "кара алтын" осталары аны ун ел эчендә алты тапкыр күтәрәләр!

Инде жан башына елына 60 кило ит, 109 литр сөт туры килә. Иң соңгы елдагы уңышларын да китереп кушканда, мондый саннар килеп чыга: ит җитештерүне 40 мәртәбә, сөтне 54 мәртәбә арттыралар нефтьчеләр!

Менә болары чынлап та аграр революция!

* * *

Бездә ил-дәүләт башына килгән җитәкчеләрнең һәрберсе үзенә кадәр булган "юлбашчы"ның эш-гамәлләрен себереп түгәргә тотына, яңа юллар эзләгән булып азаплана. Нәтиҗәдә ил һаман да артка тәгәри тора. Менә шундый мәгънәсезлек!

Татарстан нефтьчеләренең яңа генералы Ринат Галиев үзенә кадәр эшләнгән-яуланган үрләрне сызып ташларга ашыкмады. Киресенчә, ярдәмче хуҗалыкларны ул тагын да тернәкләндереп, тизләтеп-дөрләтеп җибәрде: чәчүлек һәм көтүлек җир мәйданнарын янә дә арттырды, терлекләр санын ишәйттерде. Уңыш бермә-бер яхшырды, ит-сөт җитештерү яңа югарылыкка күтәрелде. Алынган азык-төлекне үзләрендә эшкәртеп, казылыктыр-башкасыдыр, каймагыдыр-сырыдыр, икмәгедер-күмәчедер нефтьчеләр өстәленә турыдан-туры, арадашчыларсыз гына менә башлады.

Нефтьчеләргә өчкә-дүрткә өзелергә туры килә иде: "кара алтын" да чыгарырга кирәк, бер тотынгач, авыл хуҗалыгы белән дә шөгыльләнми мөмкин түгел. Инде менә унбиш ел дигәндә, үзләреннән арткан азык-төлекне кая, ничек урнаштыру мәшәкате дә өстәлде, сәүдә эшенә өйрәнү кирәк булды.

Унбиш ел — зур гомер түгел, шулай да билгеле бер тукталыш булырлыгы бар. 1995 елда нефтьчеләрнең җир мәйданнары 60 мең гектарга җитте, бу — уртача бер район җире кадәрле, агроцехлары 29 булды. Димәк, үлеп баручы шул кадәр авылга җан керде, тормыш кайтты. Әле хәзер дә "кара алтын" осталарының ышанычлы канаты астына сыенырга атлыгып торучы авыллар аз түгел: бу болгавыр заманның җил-давыллары бигрәк хәтәр бит.

Бу уңышларның сере, нигезе ни-нәрсәдә соң?

Ничек кенә тиргәсәк тә, марксистик икътисади сәясәт фәненең бер алтын кагыйдәсе бар: җирнең җитештерүчәнлеге аңа салынган көч-хезмәт һәм чыгымнарга бәйле. Файдалы казылмаларны табуда булсын, игенчелек-терлекчелектә булсын —кыскасы, хуҗалык итүнең һәр тармагында бу — шулай. Бу кагыйдә кичә дә дөрес иде, бүген дә дөрес, иртәгә дә, мәгаен, аны кире кага алучы табылмастыр.

Моны исбатлау өчен берәгәйле бер-ике мисал китереп үтик.

Россиянең бүгенге "капитаннары" авыл хуҗалыгы мәсьәләләрен сакчыллык ысулы белән, үзләре әйтмешли, "экономично" хәл итмәкче булалар. Менә соңгы елларда ил бюджетына салынган саннар: 1994 ел — авыл хуҗалыгына 6,4 процент, 1995 ел — 3,8 процент, 1996 ел — 3,5 процент, 1997 ел — 2,1 процент... Әле бу процентларның кәгазьдән гамәлгә күчеп, күпмесе авылларга барып җиткәндер — анысын бер Аллаһы Тәгалә генә белә! Бер чегән дә атын ач тоткан-тоткан да, аты үлеп киткәч: "Ашамый торырга өйрәнеп кенә җиткән иде, харап булды шаи!" — дип кайгырган, имеш. Безнең илнең авыл хуҗалыгы да шул чегән аты хәлендә түгелме соң?!

Бюджетны хөкүмәт — инде яманатлары таралган Чубайс-фәләннәр кәгазьгә төшерә, аннары яртышар ел талаша-талаша, "халык хезмәтчеләре" — Дәүләт Думасы депутатлары кабул итә. Бу акыллы башлар халыкның тормыш-көнкүреше өчен иң кирәкле, иң мөһим хуҗалык тармагын җимерүне алдан ук шулай планлаштыра икән — нәрсә әйтмәк кирәк?!

Туган Татарстаныбызда эшләр ничегрәк тора соң? Реформаның беренче биш еллыгында җөмһүриятебез авыл хуҗалыгына бюджетыбызның чирегең төгәенләп килде һәм авыллар исән калды. Алай гына да түгел, азык-төлек җитештерүдә Россия айлап-көнләп артка тәгәрәгәндә, без бер процент булса да, үсешкә ирештек. Бер процент!

Нефтьчеләр дә үзләренең ярдәмче хуҗалыкларын Маркс тәгълиматы

буенча алып баралар: башта — чыгымнар, бил бөгү, тир түгү, аннары — нәтиҗә. Һәм менә ничә ел инде житештерү күрсәткечләре гел үргә бара, гел үсештә. Кайбер тармакларда бу үсеш өч-биш мәртәбәгә житә. Шуңа күрә дә, житештергән байлыкны кая, кемгә тәкъдим итәргә, ничек сатып бетерергә дигән мәсьәлә алга килеп баса. Югарыда телгә алынган ярминкәне дә нефтьчеләр "менә без нинди, күрегез!" дип мактану өчен яки күз буяу өчен үткәрмәделәр. Аларга үзләрен таныту кирәк иде: башкаларны кысрыклый төшеп булса да, үзләренә базарда урын яулау иде исәпләре.

"Кара алтын" осталарының агроцехларына әйләнәсе колхоз-совхозлар арасында бер генә рәтлесе дә юк иде, барысы да белгенлек-хәерчелектә иде. Иген уңышы бик түбән, кутәрәмгә калган кысыр сыерлар, ярым ватык-җимерек техника... Барыннан да битәр — халык үзләреннән йөз чөергән эшлексез-сәләтсез житәкчеләр... Шул үлеп барган авылларны тергезәсе, кайгыртучан хуҗа көтеп зарыккан уңдырышсыз басуларны яңартасы, терлек фермаларын торгызасы-тәзекләндерәсе, авылдан әле бөтенләй качып бетмәгән кешеләр күңеленә өмет өрәсе бар иде.

Әнә шундый таркалган хуҗалыкларны аякка бастырып, нефтьчеләр унбиш ел эчендә гектарыннан уртача 32 центнер уңыш алырга өйрәнделәр. 1997 елда исә бу күрсәткеч 47 центнерга житте!

Моннан ике дистә еллар элек булган бер вакыйга искә төшә. Буа районы авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы Юрий Ефремовның район үзәгеннән ерак бер колхозның рәисе белән телефоннан сөйләшкәнен тыңлап утырам. Юрий Ефремов әлеге рәисне: "Әгәр син гектарыннан 28 центнер уңыш җыеп ала алсаң, үзеңне Социалистик Хезмәт герое исеменә тәкъдим итәчәкбез!" — дип ымсындыра. Хәзер Ю. Ефремов —"Татнефть"нең аграр мәсьәләләр буенча генераль директор урынбасары. Аның һаман да төп гаме-кайгысы — җир, уңыш, икмәк. Ул хәзер үз кул астындагы агрономнарга мондыйрак бурыч куя: гектарыннан 45 центнер уңыш алу гына аз, 50-60 центнер өчен көрәшергә кирәк! Кичәге белән бүгенге көн таләпләрендәге аерманы сиздегезме?!

Крестьян хезмәтенең асылы кайда да бер: нефтьчеләрнекеме ул, әллә атаклы голланд фермерларныкымы — эшеңне һәрвакыт җиренә житкереп, кара тиреңне агызып башкарырга кирәк. Әмма шулай да "кара алтын" осталарының максатлары башкарак, шулай булгач, идарә итү алымнары да үзгәрәк. Шунлыктан, ярдәмче хуҗалыкларга тоткан чыгымнары да, тырыш хезмәт нәтиҗәләре дә уйландырырлык.

* * *

МОННАН йөз илле еллар элек Татарстанның хәзерге нефтьле җирләреннән капитан Николай Рычков экспедициясе узган. Ул заманда әле, әлбәттә, нефтьнең исеме дә, исе дә булмаган. Экспедициянең юлы Акташ тирәләрендәге бакыр базларыннан алып Алабуга якларына кадәр килеп чыга. Алабуга тирәләрен телгә алып, Н. Рычков болай дип яза: "Бу якларда нарат урманнары бихисап күп, җир-туфрак бик тыгыз-авыр, артык кызыл балчыклы, шунлыктан игенчелеккә дә, терлекчелеккә дә яраксыздыр. Алабуга халкының төп житештергәне — суган, ул монда бик шәп үсә икән, хәтта ерак-ерак шәһәрләргә дә озаталар аны."

Шул ук суган үскән кыр-басулар буйлап, йөз илле елдан соң, мин дә урыс авылы Котловкага барып чыктым. Ул хәзер "Прикамнефть" идарәсе агроцехының үзәк утары икән. Якында гына гомер тынгы белмәс чал Чулман-Кама агып ята. Юлның ике ягында да кайчандыр Н. Рычков "игенчелеккә дә, терлекчелеккә дә яраксыз"га чыгарган, өсте аз гына күренсу төстәге кызыл балчыклы кыр-басулар. Бу җирләрдә ничек хуҗалык итмәк, нинди уңыш көтмәк, крестьянны ни-нәрсә белән каундырмак кирәк? Әмма, совет хакимиятенең житмеш елы Н. Рычков сүзләрен раслап килсә, соңгы еллар исә башкачарак уйларга мөмкинлек бирә.

Җирле хакимият Котловканы тергезү-җанландыру өчен кулыннан килгәннең

барысын да эшләгән шикелле: административ, сәяси, оештыру чаралары — берсе дә калмаган. Колхоз рәисләрен биялөй урынына алыштырып торганнар, әмма бер юньле-башлы хуҗа да табылмаган: берсе эчсә, икенчесе урлашкан. Мескен авылны бер колхоздан икенчесенә типкәләп йөртеп тә эш чыкмагач, ниһаять, 1991 елда таланган-йолкынганнан калган мал-мөлкәте, җирләре-ние белән нефтьчеләр кулына бирәләр.

Котловканың яңа тарихы егерме километр асфальт юл салудан башланып китә. Авылның урамнары, фермалары, ындыр табагы, машиналар утары — барысы да асфальтка төренә. Яңа сыер абзары салалар, берсе янгач, икенчесен торгызалар, яңа техника сатып алына, кибет ачыла, аз санлы булса да, башлангыч мәктәп төзелә.

Авылга җан керә. Баксаң, җирләре дә игенчелек өчен яраклы икән, рәтен-җаен белеп эшләү генә кирәк икән. Әйтик, барыбер үсми дип, арпа чәчүне бөтенләй бетергән булганнар, ә нефтьчеләр беренче көздә үк аны гектарыннан 30 центнер җыеп алганнар. Чәчү әйләнешендә иң кирәкле булган борчак, карабодай ишеләрен дә элекке елларда "оныткан" булганнар, "кара алтын" осталары аларны гектарыннан 18 һәм 20 шәр центнер алганнар. Башка игеннәр дә куандырырлык булып үсә. Малларга мулдан яшел азыктыр, печәнә-фәләнедәр җыеп алына. Бирелә игенчелек төп шөгыль түгел, төп шөгыль — терлекчелек. Беренче елда ук ит җитештерү ике мәртәбә, сөт саву өч ярым мәртәбә арткан.

Әлбәттә, бер елда гына могҗиза тудыра алмаганнар. Әмма шунысы хак: халык каушау-куркудан арынган, киләчәккә өмет белән карап яши башлаган. Ә монысы — иң мөһиме!

Шулай ук таралып-җимерелеп беткән бик күп хуҗалыкларны —әйтик, "Ирккеннефть" агроцехларына әверелгән татар авыллары Кодаш һәм Кызыл Бакчаны да телгә алып, җәелеп сөйләргә булыр иде. Кыскасы, нефтьчеләр кулына күчкән 29 хуҗалыкның һәр кайсысы турында әйтерлек-күрсәтерлек мисаллар җитәрлек. Әмма максат ул гына түгел.

Кодаш белән Кызыл Бакча авылларында ике ел эчендә нәрсәләр эшләнгән? Өчәр бүлмәле, икешәр квартирлы алты йорт, биш бүлмәле дүрт йорт, унөч коттедж (көттә йорт!) төзелгән. Һәр ике авылга да газ кертелгән: рәхәтләнә авыл халкы! мең квадрат метрлы механикалаштырылган мастерской, 120 машинадыр-тракторлдыр сыйдырышлы өсте ябулы җылы мәйдан, ябык ындыр табагы, орлык киптергеч ромбик сушилка, ашлык склады, мал азыгы склады, төзелеш материаллары саклау урыны, үлчәү урыны, 10 мең тонна сыйдырышлы силос чокыры, ашламалар склады, 200 баш терлеккә исәпләнгән сыер абзары, терлекләр өчен җәйге лагерь... Авылларда юллар асфальтланган. Резин итек киеп, пычракка батып-чумып йөрүләр онытылган.

Тырышып эшләгән кешегә кадер-хөрмәт тә зур. "Татнефть" акционерлык җәмгыяте, сабан туйларыннан кала, халык ел да бик яратып көтеп ала торган тагын ике бәйрәм үткәреп килә. Берсе — рәсми һөнәри "Нефтьчеләр көне", икенчесе — Уңыш бәйрәме. "Нефтьчеләр көне"ндә һәр һөнәрнең иң яхшы осталары — бораулаучылар, операторлар, слесарьлар, электриклар, монтажчылар, тракторчылар һәм башкалар, чын олимпиадалардагыча ярышып, мактауга һәм кыйммәтле бүләкләргә лаек булсалар, Уңыш бәйрәмендә исә ярдәмче хуҗалык батырларын шулай ук данлыйлар-олылыйлар. Аларның исем-фамилияләре "ат башыдай" хәрефләр белән нефтьчеләрнең газетында басылып чыга, үзләренә кыйммәтле бүләкләр тапшырыла.

Норлат нефтьчеләре ярдәмче хуҗалыклар булдыруга башкалардан соңгарак калып тотынган иделәр. Ник дигәндә, бик тә мөшкатьле-авыр шөгыль бит ул крестьян эше. Монысы — бер сәбәп. Аннары, хәлләре дә башка төбәкләргә караганда әйбәтрәк иде: тирә-якта, нигездә, гел колхоз-совхозлар, алардан алып булмаса, кирәгеңне шәхси хуҗалыклардан сатып алырга була иде. Менә шуңа күрә, ашыкмадылар да, башкалар маташып карасын әле, шуннан күз күрер, диделәр. Әмма, үзгәртеп кору җилләре һаман кире якка исеп, ил-дәүләт базар икътисады дигән сазлыкка кереп баткач, аннан әле тиз генә чыгарына өмет калмагач, норлатлылар да үз тамакларын үзләре туйдыру юлларын эзли башладылар.

"Норлатнефть" идарәсе башлыгы Марат Хуҗин карап торышка аз сүзле, йомшак табигатьле, диндар кеше шикелле. Чынлап та, дин дигәндә, ул догаларын да белә, уразасын да калдырмый. Ә холкы-табигатенә килгәндә, Марат Хуҗин шактый кырыс, эшлекле җитәкче. Алар идарәсе "Москва" колхозының өметсез-хөерчә бригадасы булган кечкенә генә татар авылы Әхмәтне үз карамагына алган. Һәм, биш ел эчендә, башкалар чирек гасырда да майтарып бетермәслек эшләр башкарып, авылны танымаслык иткән.

Һәркайдагыча, эшне юл төзекләндерүдән башлаганнар —юлларга-урамнарга ун километр асфальт түшәлгән. Ферма каралты-кураларын яңартканнар да, саф токымлы буаз таналар сатып алып, һәр сыердан бишәр мең литр сөт сава башлаганнар. Күпләр көнләшерлек сан бу! Аннары асфальтланган ябык ындыр табагы, механикалаштырылган мастерской, гараж, орлык һәм фураж саклагычлар төзелгән. Мәчет күтәргәннәр, ике сатучылы кибет ачып җибәргәннәр, бер бинада ук клуб, балалар бакчасы һәм, — өлегә җиде бала гына булса да! — башлангыч мәктәп пәйда булган. Юкса, авылда яшь хатыннар да бала табуны онытып бетереп бара иде ләбаса! Алга таба ишәер, Аллаһы боерса! Орлыгы, кем әйтмешли, Бохарада түгел. Кичләрен клуб тирәсендә яшь егет-кызларның күңелле гөрләшеп-серләшеп, уеннар уйнап йөрүләре шуңа ишарәли шикелле.

Кайчандыр кемнәрдер шушы тирәдә үсемлек мае сыктыра торган завод корып азапланган булганнар. Көчләре җитмәгәнме, түземлекләреме — башлаганнар да ташлаганнар. Марат Хуҗинныкылар, заводның калдык җиһазларын җыештырып, җитмәгәнен юнәтеп, аны эшләтеп тә җибәргәннәр: хуш исле, сап-сары көнбагыш мае сыга башлаганнар. Мае булгач, аңардан олифа, буяулар да ясарга тотынганнар, махсус цех җиткезеп куйганнар. Бу эшләрнең башында элеккеге укытучы, аннары район мәдәният бүлеге мөдире булган, кайнар канлы Хафиз Гафуров тора. Ул үзе өчен яңа бу шөгыль белән шул кадәр мавыгып киткән, хәзер инде көнбагыштан хәлвә эшләп чыгаруны оештырырга хыялланып йөри. Ә ник булмасын икән? Көнбагыш мае — үзләренеке, он — үзләренеке, күршедә генә — шикәр заводы. Татлы тамыр — чөгендерне дә үзләре үстерәләр, гектарыннан 300 әр центнер уңыш алалар. Димәк, хәлвә цехы буш хыял гына булып калмаячак әле.

Мин барганда, болар сөт заводы төзелешендә мәш киләләр иде: сыр, май, каймак, кефир, катык ишеләрне үзләре ясарга җыеналар. Үз сыерларыннан савып алган сөт өстенә, күрше авылларның шәхси хуҗалыкларыннан да сөт җыярга була. Юкса, авыл халкы артып калган сөтен кая куярга белми, ә бит һәр йорттан бәрәр тонна сөт җыярга мөмкин. Болай хәтта үзең сыер асрауга караганда да мөшәкатьсезрәк булачак!

Тагын бер яңалыкны әйтергә онытканмын икән: нефтьчеләр биредә җил тегермәне дә корып куйганнар. Гади тегермән генә түгел бу, бер үк вакытта электр станциясе дә. Әйе, әйе! Аның җилдә әйләнүче канатлары тегермән ташларын да эшләтә, электр энергиясе бирә торган динамомашинаны да әйләндерә. Бер атуда — ике куян! Журналист-хәбәрче буларак, мин Россияне айкап чыккан кеше: Кубань, Кабарда-Балкар, Чечен-Ингуш, Карачай-Чиркес, Ставрополь... Аннары Себер яклары: Красноярски, Алтай крайлары, Кемерово, Новосибирски өлкәләре... Россиянең үзәк төбәкләрен әйтеп тә тормыйм инде... Әмма бер кайда да җил көче белән эшли торган электр станцияләре күрмәгән идем. Ә бит хәзерге заманда күмер, нефть, газ ягып алына торган электр энергиясе бик кыйммәткә төшә. Шуңа күрә, байтак кына илләрдә җилне эшкә җигеп электр энергиясе алу хәзер отышлы санала һәм андый электр станцияләре соңгы елларда 33 процентка арткан да инде. Мәсәлән, Германиядә җил көче белән 505 мегаватт, Һиндстанда 375 мегаватт электр энергиясе җитештерелә. Үзен бөек дәүләт санаган Россиягә, күрәсең, бушка килгән энергиянең кирәге юктыр. Ә ил электр җитмәүдән интегә. Әнә, Ерак Көнчыгышны гына алыйк — һаман бер кайгы үзләрендә: электр энергиясе...

Ә норлат нефтьчеләренең башлары түгәрәк икән: җилне эшкә җиккәннәр дә, онын да тарталар, электр утын, җылысын-яктысын да алалар. Күпме акча янга кала!

* * *

КАМАЗ автогигантының йөз меңләп эшчесе алты зур заводка сыеп эшләсә, шул кадәр үк нефтьчеләр утыз мең квадрат километр мәйданга чәчелеп эшлиләр, өле бер өлеше самолетлар белән Себер нефтьчеләре янына вахтага да йөри. "Кара алтын" осталарының һәр өченчесе авылда, үз йортында яши. Кемнәрнеңдер һаман мазутка батып, пычранып йөрисе килми, кайберәүләрен ата-бабадан калган игенчелек хезмәте мавыктыра. Андыйларны да эш белән тәэмин итәргә кирәк. Гадәттә, нефть төбәкләрендә яшәүче гаиләләр һөнәрләре буенча икегә бүленә. Ире нефть суыртса, эзләнү экспедицияләрендә йөрсә яки Себергә очса, хатыны гаиләне карый, фермада эшли, балалар укыта, бакчасында казына. "Кара алтын" табудан читләшеп, игенчелек белән шөгыльләнүче нефтьчеләр дә байтак.

Бер кызыклы мисал. "Актүбәнефть" идарәсендә ярдәмче хуҗалыклар булдырырга карар кылгач, үзләре ашар өчен түгел, ә сатып акча юнәтер өчен дип, нигездә бәрәңге үстерергә ниятлиләр. Бирредә һәр гаиләнең үз бәрәңге бакчасы бар, үзләренә кирәкми, өле артыгын яхшы гына бәягә сатып җибәрергә дә була. Акчаның ташып торган чагы юк аның.

Болар бәрәңгене бик алдынгы чит ил ысулы белән үстермәкчеләр. Иң әүвәле җыеп алынасы уңыш өчен заманча җиһазландырылган махсус саклау урыны төзиләр. Анда бәрәңге кыш-яз "йоклап" ятарга тиеш, шуңа күрә, даими өч градус җылылык тота торган итеп, бу эшне компьютерга йөклиләр. Шуннан соң нефтьчеләргә әйтәләр: "Кемнәр бәрәңге үстерергә тели?" Өч мең кеше арасыннан бу эшкә нибары дүрт кешене генә сайлап алырга кирәк була. Ә теләк белдерүчеләр исә егерме тугыз булып чыга.

Бәрәңге басуын механик Әхмәдиша Мөбәрәкшин белән аның ике энесе — Нияз һәм Гаязга арендага бирәләр. Аларга Мансур Миңлебаев та кушыла. Килешүнең шарты — түләү уңыштан. Уңышның уннан бер өлеше — үзегезгә, диләр. Шушы тырыш дүрт кеше беренче елда ук һәр гектарыннан 420 центнер бәрәңге җыеп ала. Мондый уңышны бу якларда гомер күргәннәре булмый. Колхоз-совхозлар гадәттә 100 центнерны да яхшы уңышка исәплиләр. Саклаганда ул бәрәңгенең дә өчтән берен черетсәләр, өлеге арендаторларның югалтулары нибары биш процент кына тәшкил итә. Шул рәвешле, 100 гектардан җыеп алган уңыштан үзләренә дә шактый мул өлеш тия, артыгын Себергә — андагы нефтьчеләргә дә озаталар.

* * *

Нефтьчеләрнең шулай итеп ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә ныклап тотынулары илдәге, республикадагы вәзгыятьнең үзгәрүе белән бәйле.

1991 елда "кара алтын" осталары кулына, дистә еллар нефть чыгара торгач, ниһаять, беренче тапкыр валюта — доллар килеп керә. Татарстан, бәйсезлек — суверенитет игълан итеп, үз җирендәге байлыкларга үзе хуҗа икәнлеген белдергәннән соң, Россия түрәләре белән тарткалаша торгач, үзебездә чыгарыла торган нефтьнең бер миллион тоннасын булса да чит илләргә үзебез сату хокукын алган иде. Ирекле бәяләрдә. Шулай итеп, өлеге бер миллион тонна нефть сатудан алынган табышны үз ихтыяҗларыбызга тотарга мөмкинлек туды. Аннары тагын да "кыюландык", алдагы елларда нефтебезнең өчтән берен үзебез сата башладык. Дөрес, Россиянең "Внешэкономбанк" дигән ертлачы моның өчен бездән гаять зур күләмдә таможня пошлинасы — тамга салымы басып кала калуын.

Шул рәвешле, кулга долларлар керә башлады. Инде аның белән нишләргә? "Баедык!" — дип, шырдый-бырдыйга туздырып бетерергәме, әллә уйлап-исәпләбрәк эш итәргәме? Әлбәттә, күплеп чит ил товарлары кайтарып тутырырга да мөмкиндер. Әмма озакка җитәрме соң ул муллык?

Нефтьчеләр башка юл сайлыйлар. Инде илле ел буена читләргә чи нефть озатып яшәвебез җиткәндер, аны үзебездә эшкәртерлек

заводлар корырга вакыттыр; ярдәмче хуҗалыклар җитештергән азык-төлекне дә үзебездә эшкәртеп, затлы-төмле ризык итәргә кирәктер, диләр. Әнә ич, Голландия фермерлары сөттән дөньяга атаклы сырдыр-майдыр, каймактыр-кефирдыр ясарга иренмиләр. Ә иттән нинди генә ризыклар ясарга булмый?! Һәм шулай эшлиләр дә.

Сөрүлек басу-кырлар, көтүлекләр, печәнле болыннар — болар җитештерү чаралары. Әгәр дә җир асты байлыклары, әйтик, шул ук нефть алган саен кими-саега бара икән, җир өстендәге игелекле туфрак, тәрбияләп-ашлап торсаң, гасырлар буе сине туйдыра ала. Әле алай гына да түгел, оста хуҗалык итә белгәндә, Җир-әнкәнең уңышын күп мәртәбәләр арттырырга мөмкин. Җөмһүриятебездә соңгы елларда тотрыклы рәвештә һаман да югарырак уңыш җыеп алуыбыз — шуңа ачык мисал. Югары уңыш алдың — монысы бер. Аны ит-сөт, ипи-күмәч, шикәр-конфет, үсемлек мае һәм башка ризыкларга әверелдердең — икс. Хәләл көчең кергән шул байлыкны табышлы итеп сатып та җибәрәсең. Булдымы өч? Ә базар — базар инде ул! Анда бәяләр ирекле...

Менә ни өчен "кара алтын" осталарының үз тегермәннәре, икмәк пешерү заводлары, ит-сөт комбинатлары, мех фабрикалары, сыра кайнату заводлары, минераль су конвейерлары һәм башка санап бетермәслек милке-мөлкәте пәйда булды. Хәзер нефтьчеләр үзләре җитештергәнне үзләре рәхәтләнеп ашый-эчә. Үзләреннән артканын сатып, уч тутырып акчасын да ала.

Әле мондый хәл дә булды. 1993 елда нефть суыртуны бер мәлгә туктатып торырга туры килде. Күрше демократик-социалистик дәүләтләр бездән читләшеп, СССР дигән бөек ил-дәүләт таркалгач, "кара алтын"ны озатыр җир калмады. Гомумсоюз хуҗалыгында торбалар аша төрле якларга елына 600 миллион тонна нефть, — шул исәптән, татарстан нефтен дә, —куып торган булсалар, хәзер ул мөмкинлек бетте. Фаҗига, бәла, һәлакәт! Нефтьчеләргә хезмәт хакы түләргә акча юк... Нишләргә? Менә шунда ярдәмче хуҗалыкларга рәхмәт әйттеләр дә инде. Халыкка үзләре җитештергән азык-төлек белән түли башладылар: онын-ярмасын, итен-сөтен, сырын-казылыгын дигәндәй, бирсен дә кызганмадылар. Россиядә башланган аңлаешсыз реформа-ислах әнә шундый гайре табигый галәмәтләр дә китереп чыгарды шул. Тәмәке фабрикасында хезмәт хакын тәмәке белән, тегү фабрикасында эчке күлмәк-лифчиклар белән түләү шикелле хикмәтләр башланды... Йа, Хода!

Тормышта дөреслекләр күп, ә хакыйкать бер генә була, дип әйткән ди бер акыл иясе. Авыл хуҗалыгы тармагында ирешелгән уңышлар нефть табудагы уңышларга бәйле булса, үз чиратында, "кара алтын" осталарының иминлеге-муллыгы да авылларның гөрләп яшәп торуларына бәйле. Ә моның өчен күпме тир түгәргә, хәләл көчеңне сарыф итәргә кирәклеген нефтьчеләр үзләре генә беләдер.

* * *

Ә чыгымнарга килгәндә... Беркемдә дә артык акча юк. 1995 елда гына да ярдәмче хуҗалыкларны тернәкләндерү өчен миллиардларча сумнар тотылган. Ул сумнар хезмәт хакына өстәлсә, бүлекләүләргә, әлкәннәргә ярдәмгә тотылса, шифахане-санаторийларга юлламага түләнсә һ.б. һ.б. кирәк-ягракларга сарыф ителсә, бер дә начар булмас иде. Юкса, тишек-тошык җитәрлек, ямаулык теткәзеп булмый.

Аннары шунысы да бар: "Татнефть" акционерлык җәмгыяте кесәсеннән хезмәт хакы алып, аны "шүре" — "челнок"лар ташыган чит ил товарларына исраф итү акыллы эшме? Бу бер "Татнефть"кә генә кагылмый, шул ук сүзләрне КамАЗ автомобиль төзүчеләренә, Түбән Кама нефтехимикларына, энергетикларга, барлык эшчеләргә, крестьяннарга да әйтергә була. Йорттагы хуҗабикәләр, лаеклы ялдагы әлкәннәр, студентлар-шәкертләр дә колак салсын иде моңа. Кыскасы, күпмилләтле Россиянең һәр гражданины уйланырга тиеш: безнең барлы-юклы хезмәт хакларыбыз, пенсия-стипендияләребез кемнәрнең төпсез кесәсенә ага тора? Чит илләр кесәсенә ләбаса! Алар, Россиядәге үзгәртеп

коруларга, базар икътисадына ярдәм итәбез дигән булып, үз кесәләрен калынайту ягын гына карамыйлармы? Акча даими әйләнештә йөри ул. Әгәр дә үз кибет-базарларыбызда үзебез җитештергән товарларга, азык-төлеккә тотылса, ул яңадан да үзебезгә әйләнеп кайтачак, кул җитмәс капитал булып чит ил банкларының тимер сейфларына бикләнмәячәк.

Хуҗалык итүдә, икътисадта Маркс тәгълиматы саклана, дидек: капитал салу, ягъни җиткелекле чыгымнар тоту һәм тырыш хезмәт.

Нефтьчеләр түккән чыгымнар турында күп сөйләнде. Алар, чынлап та, гаять зур. Ә табыш ягы, күпме генә мактансак та, әллә ни ис китәрлек түгел. Өч дистәгә якын ярдәмче хуҗалыкның 1995 елда нибары икесе — Әхмәт һәм Зеленая Роща (Яшел Әрәмәлек) авылларында гына табыш алу чыгымнардан өстенрәк булган. Калганнары зыянга эшләгән. Хикмәт нәрсәдә соң?

Инде искәртеп киткән идек: бер генә илдә дә дәүләт ярдәменнән башка авыл хуҗалыгын үстереп булмый. Америкамы ул, Канадамы, Германияме, Голландияме — барыбер һәркайсында дәүләт бюджетыннан зур-зур чыгымнар тотыла. Ә бездә? Россиянең федераль бюджетыннан авыл хуҗалыгына нинди саран тамчы гына тамганын әйтеп киткән идек. Уңай яктан телгә алып, Татарстанда бу чыгым бюджетның егерме биш процентын тәшкил иткәнен дә әйткән идек. Әмма... Әмма ул егерме биш процентның бер тиене дә нефтьчеләрнең ярдәмче хуҗалыкларына тәтеми шул!

Дәүләт үзен туендырып торучы крестьян хуҗалыкларын талауның дистәләрчә ысулларын белә. Ләкин аның ярдәм итү ысуллары тагын да күбрәк. Турыдан-туры акчалата булмаса, сыгылмалы бәяләр, акыллы уйланылган салымнар, кызыксындырырлык-үсендерерлек кредитлар белән. Кирәк чагында техникасы, ягулыгы, чәчүлек орлыгы, ашламасы белән. Теләк кенә кирәк!

Кызганыч ки, сәнәгать предприятиеләре —завод-фабрикаларның аграр цехлары дип йөртелгән ярдәмче хуҗалыклар, кемнеңдер уйлап җиткермәве аркасында, башта ук гомуми статистик исәп-хисапка кертелмичә калдылар. Янәсе, һәр предприятиенең эчке үз эше бу. Булдыра алсаң, үз көчең белән маташып кара... Шул рәвешле, бер төрле ярдәм дә күрсәтелми килә. Нефтьчеләрнең агроцехлары да шул хәлдә. Дәүләтнең үги балалары алар...

Әйе, җөмһүриятебездә авыл хуҗалыгына бюджетның чиреге салына. Әмма авыл күтәреп булмаслык зур салымнардан гарык. Хәләл хезмәтеңә, җитештереп тапшырган игенеңә-терлегеңә, яшелчәңә-бәрәңгеңә юк кына бәя куялар, анысын да вакытында түләмичә тинтерәтәләр. Шулай булса да, әле басу-кырларыбыз игелә, терлек көтүләребез исән-сау. Тулаем җитештерү 1997 елда җан башына 2,6 тоннага артты, дип сөенәбез. Россиянең кайбер төбәкләрендә авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү 30-50 процентка түбән тәгәрәде бит!

Татарстандагы тотырыклылык, иген уңышының елдан-ел арта баруы һавадан гына төшкән хикмәт түгел. Җитәрлек булмаса да, авылларга төрлечә ярдәм ителә. Мәсәлән, ашламаларны гына алыйк. Минераль ашламалар хәзер бик кыйммәт, айлар-еллар буена хезмәтенә түләнмәгәнлектән, крестьянның аны сатып алырлык акчасы юк. Банкка кредитка керәп батсаң, муеныңа элмәк салдылар дигән сүз — процентларын гомереңә дә түләп бетерә алмассың. Менә шул чагында республика хөкүмәте ашламаларның ярты бәясен үзе күтәрә. Әйбәт ич бу! Әйбәтен әйбәт... Тик бу игелек нефтьчеләргә тәтеми шул. Аларның ярдәмче хуҗалыкларына бер җиңеллек тә юк. "Татнефть" бай әле, тулысынча үзе түләсә дә, аннан гына ярлыланмас, диләр. Ә бит шул ук "Татнефть" акционерлык җәмгыяте алган табыштан Татарстан бюджетының утыз алты проценты тутырыла. Утыз алты проценты!

Янә бер мисал. "Азнакай" совхозында гектарыннан 120 шәр центнер гәрәбәдәй кукуруз суктырып алалар. Мондый уңыш белән Американың Айова һәм Иллинойс штатлары гына мактана ала. Лениногорск нефтьчеләренең ярдәмче хуҗалыкларында 100 гектар җиргә исәпләгәндә 230 центнер ит җитештерәләр, Татарстандагы уртача күрсәткечләрдән 3-4 тапкыр артык дигән сүз бу! Менә шундый могҗизалар эшли ала кукуруз азыгы! Әмма куанырлык эш юк. Чөнки фураж сатып алына, ул бик кыйммәт, димәк, табыш

урынына барыбер зыян гына... Республика авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының чәчүлек орлыкка кукуруз бирелергә тиешле хуҗалыклары исемлегендә янә дә нефтьчеләрнең агроцехлары иске алынмаган. Нефтьчеләр ул гөрәбә орлыкларны тоннасына алты миллион сум (иске акча белән) түләп алырга мәҗбүрләр. Нинди табыш алмак кирәк?! Сызгырырсың, кодагый!

Аптырагач, нефтьчеләр авыл хуҗалыгына тотылган чыгымнарны "кара алтын"ның үзкыйммәтен арттыру хисабына тутыралар. Ә үзкыйммәт болай да югары. "Бездәге нефтьнең бер стаканы бер стакан газлы судан арзанрак", — дип лаф орулар бетте хәзер.

Инде хәзер, ялгызак фермерны ул, кооператив-фәләнме, ассоциация-фирманы, элекечә колхоз-совхозмы — һәммәсе дә бер тигез шартларда эшләп китсен, башлангыч ярдәмне тигез күрсәтик, дип сөйләнәләр. Нефтьчеләрнең ярдәмче хуҗалыклары янә дә бу исемлектә юк. Әйтерсең, нефть төбәкләрендәге басулар өстендә башка кояш, әйтерсең, анда яңгырлар мулрак ява, әйтерсең, андагы сыерлар-маллар азрак ашап, күбрәк ит-сөт бирә! Шул да булдымы тигез шартлардагы тигез ярдәм?!

Татарстанның "азык-төлек кәрҗине" бер генә. Нефтьчеләрнең ярдәмче хуҗалыклары җитештергән азык-төлек тә шул ук "кәрҗин"гә керә түгелме соң? Ярдәмче хуҗалыкларга тоткан чыгымнар өстенә, әле бит төрле акциз, пошлина, салым ише ике дистәләп башка төрле түләүләр дә бар. Бюджетының өчтән бер өлешеннән артыгын тәэмин итеп торган нефтьчеләргә үгисетеп карау ярыймы инде? Демократик хакимиятнең гаделлеге шул буламы?!

Әгәр дә Татарстандагы һәр хуҗалык иген уңышы алуны тагын да арттырып, һәр сыердан уртача бишәр мең килограмм сөт савып ала башласа, шул рәвешле, нефтьчеләрнең ярдәмче хуҗалыкларына тиңләшсә, иллә дә әйбәт булыр иде! Республиканың бюджетын нефтедолларлар гына түгел, ә бәлки чит илләргә саткан иген һәм ит-сөттән кергән табышлар да тулыландырып торыр иде. Иртәме-соңмы, нефть күлләребез саегыр, ә сыйфатлы итеп, тир түгеп эшләгәндә, Җир-ана безне юмарт туйдырып торырга әзер.

* * *

Татарстан нефтьчеләренең ярдәмче хуҗалыкларын алга таба нинди киләчәк көтә? Дәүләттән төрле җиңеллекләр-ярдәмнәр алып эшләүче башка крестьян хуҗалыклары белән ярыша алырмы алар? Шул кадәр "кара алтын" чыгарып, кулга валюта кереп торганда, һаман да зыянга эшләп килүче авылларга зур-зур чыгымнар тоту кирәкме икән? Шул ук акчага дөньяның төрле кыйтгаларыннан җаның теләгән азык-төлекне сатып алырга да була түгелме соң?

— Без — оптимистлар. Киләчәккә өмет белән яшибез, — дип башлады сүзен «Татнефть» акционерлык җәмгыятенең генераль директоры Ринат Галиев. — Юкса, авыл хуҗалыгы белән дә, нефть белән дә шөгыльләнеп маташмаска кирәк булыр иде.

— Өметләнерлек нигез бармы? Нәрсәгә таянып алай дип әйтәсез? — дип сорадым мин.

— Иң әүвәл аек акылга таянам. Хәзергедән уңайлырак вәзгыять булырына ышанам...

— Һава шартлары үзгәрерме? Кышын да кояш җәйгечә балкып-җылытып торырмы? — дип шаяртмакчы булдым мин.

— Без авыл хуҗалыгы тармагында безне дә башкалар белән тигез хокуклы итүләренә исәп тотабыз. Җир-әнкәнең кайсы гектары кемдә — фермердамы, колхоз-совхоздамы, әллә безнең ярдәмче хуҗалыктамы — барыбер түгелмени? Барыбыз да җыеп алганыбызны ил "кәрҗине"нә сала барабыз. Шулай булгач, шартлар да, ярдәм-җиңеллекләр дә, кадер-хөрмәт тә бер булырга тиеш. Ни өчен без генә дәүләтнең үги балалары булырга тиеш соң әле?

Менә без санап карадык: «агроцехлар» дип авыз ачкан 1980 елдан алып быелга кадәр — димәк, унҗиде ел дәвамында бөртекле ашлык

житештерү — дүрт тапкыр, ә ит һәм сөт — ун тапкыр, — ун тапкыр! — арткан. Куанырлык эш-гамәлләр түгелме ә?! Житештергәнебезне үзебез төмле ризыклар итеп ясый башладык. Кара: 1997 елда ит азыкларын — казылыгын-фөләнендер, башкасындыр — 624 тонна, сөт азыкларын — сырын, маен, каймагын, дигәндәй, — 487 тонна, ипи-күмәч ишеләрен 475 тонна итеп нефтьчеләребез өстәленә куйганбыз. Артканын сатканбыз да.

— Чит илләрнең азык-төлек товарлары ничек безнекеләр белән ярыша ала? Аларны кайтару өчен дә күпме өстәмә чыгымнар кирәктер. Ә үз товарыбыз кул астында гына, илт тә кибеткә тапшыр! Нигә кибетләрдә базарга караганда һәр әйбер кыйммәтрәк хәзер? Сатып алучы һәрвакыт арзанракны эзли бит.

— Төп сәбәп — бәяләрнең тәңгәл-тиң булмавында. Азык-төлеккә бәяләр чикләнгән, ә кирәкле техниканы сатып алу алтын бәясенә төшә. Икенчедән, чит ил фермерларының чыгымнарын дәүләт каплый, дәүләт күтәрә һәм ул өлеш аз түгел.

— Ә ил-дәүләтләргә аннан ни файда?

— Һәр дәүләт өчен дә илдә азык-төлек тотрыклылыгы кирәк. Шуңа күрә, дәүләт фермерларга ярдәм итә, ә тотылган чыгымнарын пошлиналар, салымнар һәм башка керемнәр белән кайтарып ала бара. Россиядә бу нәрсә юк. Шунлыктан, житештергәннәребез кыйммәт, кыйммәт булса да — табышсыз. Крестьян хужалыклары комбайн-трактор ишеләрне сатып ала алмый. Икътисад жимерелдә. Житештерү, эшләп чыгару булмагач, тиешле салымнар да жыелмый. Жыелмаган салым күләме, кемнәрдер кимсетеп "аграр сазлык" дип йөрткән авыл хужалыгына тиешле ярдәмне бирмичә, аны янга калдырган суммалардан күп мәртәбә артыграк. Үзебезнекен ашый белмибез, ә чит ил товарларына капканы киң ачабыз. Чынлап та, кибетләрдә хәзер муллык, акчаң гына булсын!

— Акчаң булса шул! Кибет киштәләренең сыгылып торуыннан ни мәгънә? Күпчелек халык аларны музей караган шикелле карап кына йөри бит. Кесәсендә булганы ипи-сөткә, чәй-шикәргә житсә — шуңа шөкер! Россиядә ил-дәүләт башына сәләтле-булдыклы хакимнәр килерме икән бәрәр вакыт?..

— Һәр кешегә көн саен кимендә өч мәртәбә өстәл янына утырырга, авыз чөпелдәтергә кирәк. Акча булмау — бәла ул... Шуңа күрә дә, ярдәмче хужалыкларны бетерү турында сүз дә булырга мөмкин түгел. Инде шул кадәр чыгымнар тоткач, тир түккәч, йөрәк авырулары алгач... Юк, башлаган игелекле эшне һич ташларга ярамый! Инде ике-өч хужалыгыбыз булса да, файдага эшли башлады... — Генераль директор көрсенеп куйды. — Дөрес, чыгымнар зур, гаять зур! Бәлки, кирәгеннән артыгын да юмартланабыздыр... Эшне төмам күтәрәмгә калган хәерче авыллардан башлап жибәрдек ич. Кайнар нотыклар сөйләп кенә өллә ни майтарып булмый. Чыгымнарыбыз зур булса да, эшебез изге дип уйлыйм. Ул авылларда безнең балаларыбыз, оныкларыбыз яшәячәк бит! — Ринат Галиевнең йөзе яктырып китте. — Күр әле син, дистә ярым ел эчендә нәрсәләр майтарып ташладык! Гектарыннан уртача 47,6 центнер уңыш алдык бит! Республика буенча 37,6 центнер булдымы әле? Аерым хужалыкларда эшләр тагын да куанырлык иде: "Никитинский" хужалыгында — 60 центнердан артык, "Дуслык"та — 59,4 центнер, чамасы, "Жәлилчә"дә — 56,2, "Бирючевка"да — 51,5, "Ямаш"та — 51,4, "Березовский" белән "Берлек"тә — 51 шәр центнер! Бу саннар, кем әйтмешли, "музыка булып тоела миңа"! Шундый сөендерерлек нәтижәләр булганда, ярдәмче хужалыклар бер кайгысыз, рәхәтләнеп байлык-муллыкта яшәргә тиеш тә бит... Юк шул! Аларның артык бер тиеннәре дә юк. Тырыш-эшчән крестьянны кычкыртып талау сәясәте кайчанга кадәр дәвам итәргә мөмкин?! Әмма бу илдә уйлау-фикерләү баштүбән куелган шикелле, миңа калса.

Инде соңгы чиккә килеп життек. Колхоз-совхозларны үзерлексез-нисез генә таркатып, жирне пайларга бүлгәләп, ирекле сату-алу ясамакчы булабыз. Авыллар бөлгенлектә. "Фермерлар" дип, заманча атап йөрткән ялгызакларыбыз кирәкле техникасын шымытыр түләп алсынмы? Менә сиңа ил буенча бер-ике сан: крестьяннар 1991 ел белән чагыштырганда 1996 елда тракторларны — 15 тапкыр, йөк автомашиналарын — 20 тапкыр, комбайннарны дүрт

тапкырга диярлек ким сатып алганнар. Без аларны агач сука белән җир тырмарга калдырмакчы түгелме соң?! Үзләре тыпырчынсыннар шунда, дип, кул селтәргә тиешме без?

— Чит ил фермерларына тиңләшергә уйла-мыйсызмы?

— Әлбәттә, акыл белән, рәтен-җаен белеп, фәнне дә эшкә җигеп эшләгәндә, безнең дә чит ил фермерлары белән ярышырлык чамабыз бар. Патша Петр Беренче дворян балаларын Голландия кебек илләргә төрле һөнәрләр үзләштерергә җибәрә торган булган. Без исә ел саен игенче-терлекчеләребезне чит ил фермерлары янына җибәрәбез. Франциядә, Англиядә, Канадада булып кайттылар инде. Барсыннар, күрсеннәр, өйрәнсеннәр. Уку-өйрәнүнең ояты юк аның. Яшьме син картмы — барыбер. Юлга озатканда мин үзебезнекеләр белән иркенләп-төмләп сөйләшеп алам. Анда баргач, карга санап, ах-вах килеп, хәйран калып кына йөрмәгез, күргәннәрегезне сеңдерә барыгыз, кайткач, алар үрнәгендә эшләрлек булсын, дим. Килер бер көн: тәҗрибә туплау өчен үзебезгә башкаларны чакыра башларбыз әле!

— Җир сорап, үзбаш фермер булырга яшьләргә теләүчеләр бармы?

— Берничә гаилә шулай эшләп караган иде дә, хәзер барыбер үзебез сөйрәп барабыз аларны. Алтын таулары вәгъдә иткән бушбугазларны каргыйлар. Хәзер аерылырга теләүчеләр юк инде, тындылар. Крестьяннар кызганыч: аларны уйланып бетмәгән тәҗрибәләр өчен файдалану кемгә кирәктер — белмим.. Юк без агроцехларыбызны бөтенләй бетермәячәкбез! Киресенчә, тагын да нәтиҗәлерәк эшләү ысулларын эзләячәкбез. Без ярдәмче хуҗалыкларны тулы хозрасчетка күчердек хәзер: үзләре эшләп тапканны үзләре тота, үзләре янга калдыра бара. Алар —чикләнгән җаваплылыктагы җәмгыятьләр хокукында. Бригадалар, звенолар, фермалар да яңача идарә ителәләр. Һәркем гомуми уңыш, гомуми табыш өчен тырышырга тиеш, түләве дә хезмәтенә карап булачак. Актүбә бәрәңгечеләре Әхмәдиша Мөбәрәкшиннар үрнәге гадәти күренеш булып калырга тиеш.

Шулай да барлык егерме тугыз хуҗалыкны да өстерәп бару кыенга килә. Берәүдә дә Әндрәй казнасы юк. Безгә генә салынып, һаман зыянга гына эшләүче кайбер хуҗалыклардан баш тартырга да туры килмәгәе. Инде авылларын аякка бастырдык, кирәгенчә ярдәм иттек — яшәп карасыннар үзбаш!

Их, хөкүмәтебез бераз ярдәм дә күрсәтсә... башкаларга биргән кадәр генә бирсеннәр иде. Күрер идеңер — кем яхшырак эшли?..

Һәрхәлдә, илдә азык-төлек мәсьәләсе ничек кенә үзгәрсә дә, без ач калмаячакбыз! Иманым камил!

* * *

И хыял... Минем каләмем инде бөтенләй башка ярминкә турында язарга ашкына. Имеш, ул ярминкәдә басу-кырларда үстерелгән-җитештерелгән сый-нигъмәтләр түгел, ә махсус завод-лабораторияләрдә ясалган азык-төлек сатыла икән. Нефтьтән ясалган азык-төлек! Бәяләре бермә-бер арзан, имеш, ә тәме, хуш исе табигый азыкларга биргесез. Гайре табигый хәлме? Әнә бит японнар, американнар ясалма сыер-дуңгыз итләре, тавык ботлары эшләп чыгаралар икән инде...

Кешелекне азык-төлек белән тәэмин итүнең башка юллары калмаса, нишләргә? Озакламый Җир шарында хәзерге алты миллиард урынына унике миллиард халык булачак. Аларны ничек туйдырырга? Галимнәр исәпләп чыгарганнар: алына торган барлык нефтьнең ике процентыннан азык-төлек җитештерә башласалар, кешелек Ачлык патша дигән мәрхәмәтсез явыздан гомергә котылачак икән. Бөек максат, татлы хыял!

Бу хыялларны башлап тормышка ашыруда Татарстан нефтьчеләре беренчеләрдән булса, дип, хыял өстенә хыял да өстим әле мин. Кем белә, гасырларга тиң ул бөек вакыйганы иң әүвәл язып чыгу бәхете дә миңа насыйп булыр бәлки, ә?!

Бу татлы хыяллар тормышка ашармы, ашса, кайчанрак булыр? Төгәл генә әйтеп бирә алмам, ялгышырмын дип куркам. Әмма ул без уйлаганнан күпкә тизрәк булырга мөмкин. Шуңа күрә, ул бөек вакыйганы күрә алырмын, язып та чыгармын дип өметләнәм әле.

## ӘДӘБИ МИРАС

Габделбари Баттал Таймас

# МИН БЕР ЯКТЫЛЫК ЭЗЛӘГӘН ИДЕМ

Качу планы. Кузи бистәсенең җимерек өендә биек алабуталар белән капланган бакчада хатыным белән тиз генә күрешеп сөйләшүдән соң лагерьдан качу уе тагын да конкретрак төскә керде. Тагын бер тапкыр кәгазьләрне тикшергәннән соң, бу максатны тормышка ашыруны кичектерергә ярамый иде.

Бу очрашудан берме, икеме көн узгач, ягъни 19 августта (бу датаны бик яхшы хәтерлим) мин Казанның "Елга тамагы" дигән җирендә пристаньнан пароходка утырып, көньякка таба юл алдым.

Корылган план буенча, җимерек өйдән киткәннән соң, эз калдырмау өчен мин өйгә кайтмаячак, хатыным һәм улым белән бер җирдә дә күрешмичә, алар белән күнелдән генә саубуллашачак идем. Мин туры мөселман мәхәлләсендәге бер кардәш тиешле кешенең өенә китәчәк идем, өйдән кирәк-яракларым, өс-баш киемнәрем дә шунда "киләчәк" иде, төс-кыяфәтемне анда үзгәртәчәк идем. Мине пристаньга кадәр илтәчәк һәм минем чынлап та пароходка утырып, Казаннан китүемне, үз күзләре белән күреп, безнең өйгә хәбәр итәчәк кеше — рус хатыны Х. белән шулай ук анда күрешәчәк идек. Күргәнегезчә, план шәп уйланылган иде, тик аны башкарып чыга алырбыз микән?

**Хуш, сазлыгым!** Сазлыкта торф чыгару эшендә безне, лагерь тоткыннарын караучы бер надзирателебез булып, ул үзенә күрә гөнаһсыз бер Кызыл Армия сержанты иде. Тагын, киң ишегалдының өйдән шактый ерак булган урам як капкасы төбендә, гадәт буенча, бер сакчы тора иде. 19 август (1920) иртән урынымнан тормыйча, сакчыбызга авырып китүемне, шуңа күрә бүген эшкә бара алмавымны әйттем дә, юрганны башыма хәтле ябынып яттым. Сакчы: "Ярар", — диде, башка иптәшләремне алып китте. Бүлмәдә мин ялгызым калдым. Берничә минут узгач, урынымнан сикереп торып, иптәшләремнең бер-ике юрганын буйга бөкләп, үз юрганым астына сузып салдым. Каршыдан караганда, бу минем юрган астында кеше яткан күренешне бирә иде. Тиз генә киендем дә, ишегалдына атылдым һәм аның арт ягындагы биек коймадан мәче җитезлеге белән сикереп төшеп, юлга чыктым. Тиз-тиз атлап шәһәргә юнәлдем. Тарихи Казан елгасы буендагы такта күперне кичкәннән соң, башка бер мәмләкәтнең чиген узган шпион кебек, сазлык тарафына борылып, һавага бер "хушлашу" төкереген очырдым... Шәһәрнең мөмкин кадәр аулаграк урамнарыннан узып, төрек мәхәлләсендәге кардәш тиешле кешеләрнең өенә киттем...

**Үзгәргән кыяфәт**. Өйдән җибәрелгән капчык һәм сумкаларны шунда таптым. Аксыл-зәңгәр костюм, бер пар кара күн итек, кара фуражка, бер пар кара аяк чүпрәге һәм пенсне күзлек җибәргәннәр. Бу комплект мөкәммәл иде. Сазлыкта эшләгәндә сакал җибәргән идем, ул сакал, күп кенә совет ватандашлар сакалы кебек, кайчы, тарак күрмәгән, тәртипсез бер хәлдә иде. Совет гаскәри

---

Ахыры. Башы журналыбызның апрель санында.

вәкиле булганлыгымнан, мөмкин кадәр бу сары сакалга рәт кертергә кирәк. Йөз формасы буенча да, мондый ихтыяж бар иде. Шуна күрә мөселман мәхәлләсе Иске бистәнең караңгы һәм тыныч бер жирендә өйдә чәч алучы якташка китеп, сакалга башка бер форма, ул вакытта большевикларда бик модада кәжә сакалы кебек рәвеш бирдердем. Чәчләрне бритва белән кырдырдым. Өйгә кайткач, аксыл-зәңгәр кием, башыма да кокардасы урак-чүкечтән гыйбарәт булган фуражка кидем. Аякларыма күн итек киеп, колакларга тагылган күзлек урынына пенсне (борынга тагыла торган күзлек) тактым. Мондый кыяфәт белән бернинди куркусыз урамга чыгып киттем. Танылу ихтималыннан бер дә курыкмый идем, чөнки мине бу кыяфәттә сазлыкта бергә эшләгән иптәшләрем дә бик авырлык белән генә таный алырлар иде...

**Батыр хатын**. Хатынымның якташы һәм сабакташы, мине Идел пристанена кадәр озатачак рус хатыны Х. да очрашу урынында булган өйгә килгән иде. Бер фаэтон тоттык та, мадам белән янәшә утыртып, пристаньга таба юлга чыктык. Бу эшләр 192О елның 19 августында көпә-көндез эшләнә иде. Шат күңелле һәм сөйкемле мадам мина: "Бер-беребезгә бик якын итеп утырыйк, безне күргәннәр ирле-хатынлы дип уйласыннар да шикләнмәсеннәр", — диде. Әхлакый яктан бәлки бик үк яхшы күренмәгән бу утыру рәвешен шул вакыттагы ситуациягә карата кабул итмичә булмый иде. Бу фидакяр хатын әлеге тәкъдимен бары тик изге нияттән чыгып кына ясады: чөнки аның үзенә түгел, минем өчен кирәк иде бу "форма", "жинаятьче кеше" белән шулай якын утырып, аның качуына ярдәм итүе белән ул үзен дә куркыныч астына куя, шуна күрә аның бу кыланышын зур тәвәккәллек, егетлек дими, ни дисең. Икебезне бергә тотып алган вакытта, китәчәк жиребез, югарыда "татлы хатирә белән искә алган" Чека подвалы, яки дә бөтенләй теге дөнья икәнен бу хатын белми түгел иде. Аллага тапшырып, мадам әйткәнчә утырып, сөйләшә-сөйләшә Идел ярына таба юл тоттык. Ат тотучы бар икәнен истә тотып, үз хәлләребез һәм эшләребез турында түгел, жыен юк-бар хакында тыныч кына сөйләшеп бардык. Биш ай ярымнан бирле вакытымны төрмәләрдә, лагерьда тупас, тәртипсез кешеләр белән үткәргәннән соң, зыялы, шат күңелле, чибәр һәм ачык йөзле хатын-кыз компаниясендә 5 — 6 км юл узу бик рәхәт иде. Бу "рәхәтлек"не оештырган бердәнбер хатынымның яхшылыгына, нәзакәтлелегенә, тугрылыгына тагын бер кат рәхмәтле идем...

**...Үле "елга тамагы"**. Шәһәр белән "елга тамагы" дигән борынгы жирләр арасындагы юлыбыз "вакыйгаларсыз" узды. Су буена җиттек. 1918 елның көзендә Казаннан киткәннән бирле, совет дәверендә минем бу борынгы урыннарга беренче килүем иде. Хәзер монда элеккеге жанлылыкның, халык төркеме кайнашуының әсәре дә юк. Яр буендагы кибетләр, чәйханәләр, рестораннар, трактирлар, отельләр һәммәсе бикле. Элек товарлар белән тулып ташыган амбарлар, складлар буш һәм ташландык хәлдә. Заманында моннан шәһәрнең үзәгенә хәтле йөргән Бельгия компаниясе трамвайлары, рельслар бозыклыгыннанмы, электричество көче кимүдәнме, вагоннар тузуданмы, бөтенләй эшләмәс булганнар. Язучы Максим Горький аерым әсәрләрендә зур симпатия белән тасвирлаган "грузчикларда" да кәеф, дәрт калмаган. Чөнки бу вакытта төяү-бушату эшләре бөтенләй туктаган иде. Элек Казан пристаненнән "Кавказ-Меркурий", "Рус", "Самолет" компанияләренең зур һәм яхшы пассажир пароходлары, мәһабәт гәүдәле, авыр йөк ташучы суднолары килеп-китеп йөрделәр. Югарырак Рыбинск, Нижний Новгород белән астагы Самара, Саратов, Царицын һәм Астрахань арасында, тагын Нижний белән Кама елгасының югарысында Ураллар итәгендәге Пермь шәһәре арасында йөрүче пароходлар да һәрвакыт Казан аша китәләр иде. Яз көне Идел белән Кама елгалары өстендәге калын боз катламы беткәннән соң, Казанга беренче пароход килү һәм су юлы ачылу шәһәр халкы өчен зур бер сөенеч һәм бәйрәм кебек була торган иде. Яңа өйләнешкәннәр, гашыйк парлар, гадәттә, пароход сәяхәтенә чыгалар иде... Идел белән Кама буйлап пароходта йөрү иң күңелле, иң зәвыклы сәяхәтләрдән хисаплана. 192О елның 19 августында без пристаньга килгән вакытта исә "Елга тамагы"нда, ичмасам, ник бер пароход күренсен...

**Пароход көткәндә.** Яр буенда жыелган халык, югарыдан килеп, көньякка таба китәчәк пароходны, иң кадерле кунакны көткән кебек, көтеп тора. Пароход

бераз кичегә иде. Бу бер дә минем өчен күңелле хәл түгел. Чөнки Казан тирәсендә озаграк маташырга мәҗбүр булсам, кулга төшүем бик мөмкин иде.

Сәгатьләр уза торды. Шунда безнең хәбәрләрне һәм качу планыбызны белгәннәрдән, авызы алтын коронкалар белән тулы бер әфәнде пәйда булды. Ул бер кооперативта эшләүче иде. Пристаньга да кооператив машинасы белән, бәлки, мине озату өчен килгәннәр. Бу әфәнде безгә, пароход килгәнче, шәһәрнең моннан бик ерак булмаган "Бишбалта" дигән бистәсендәге танышларыннан бер төрек гаиләсенә барып, чәй эчәргә тәкъдим итте. Билгеле инде, без, шималь төрекләре, чәй турында сүз чыкса, түзеп тора алмыйбыз. Аннан да бигрәк, бу вакыт уздыру өчен кулай тәкъдим иде. Без аны шатланып кабул иттек. Дустыбызның машинасына утырып, Бишбалтага киттек. Өй хуҗасы минем һәм мадам Х. ның кем булуын белми иде. Без дә аңа ачылуны кирәк һәм файдалы тапмадык. Пристаньга кире килгәндә дә әле пароход һаман күренми иде. Шуңа күрә без пристаньнан бераз читтә, инде үләннәре саргаеп корып беткән чаерлыкта йөренергә тотындык.

**Аллага шөкер, пароход күренде.** Кире пристаньга килгәндә, анда хәрәкәт, җанлану, кайнау күзгә ташланды. Никадәр түземсезлек белән көткән пароход күренә, ул пристаньга якынлаша икән. Касса да ачылган һәм пассажирлар "койрык" булып тезелгәннәр иде. Ул арада безнең Казаннан ялган документ белән икенче тапкыр качып баручы һәм танытмау өчен кара күзлек кигән иптәшебез И. Ар. миңа якынлашты һәм колагыма: "Бу пароходка Бакуда булачак Шәрекъ милләтләре конгрессына баручы бер төркем төрек коммунистлары утырачак, игътибарлы бул, танымасыннар", — дип пышылдады. Аның белән бергә китәчәк яшь хатыны кочагындагы баласы белән, бәлки дә курку, бәлки өмет хисләре дулкыны эчендә чайкалып, бер амбар күләгәсендә башын иеп басып тора иде...

Мин дә "койрыкка" барып кушылдым һәм чиратым җитүен зур түземсезлек белән көтә башладым. Һәр пассажирның билетын алып, кассадан читкә китүе, "койрык"ның тагын бер кешегә кыскаруы минем котылу юлымда тагын бер адым алга китеш кебек тоела иде. Ниһаять, кассирга хәрбиләр өчен махсус льготамны аңлатып, мин дә Астраханьга кадәр бушлай билет алу бәхетенә ирештем. Безнең батыр, кыю мадам, халык төркеменә катышып, мине күзләре белән ярдан күзләп тора иде. Мин тиз генә ханымның кулларын кысып, саубуллаштым да, пароходка мендем һәм иптәшем И. Ар. гаиләсенә кушылдым. Димәк, аягыбыз җирдән аерылды. Иркен бер сулыш алдык. Христофор Колумб җиргә аяк баскач ничек шатланса, безнең аягыбыз җирдән аерылуга аннан ике тапкыр ныграк сөенгәнбездер.

Х. ханым, тиз генә читкә китмичә, хакыйкатьтән бер "тормыш иптәше" ролен азагына кадәр уйнау өчен, пароходның пристаньнан кузгалып китүен көтә башлады. Пароход кузгалгач, сумкасыннан кечкенә генә кульяулык алып, һавада селки һәм миңа кул белән үпкәнен белдерүче ишарәләр ясый башлады. Хатынымның бу тугрылыклы дусты болай итеп безгә гомеребез буена онытылмаслык батырлык һәм нәзакәтлелек күрсәтә иде. Боларның бөтенесен оештыручы исә тугрылыклы хатыным Газизә ханым иде.

**Пароходтагы рәтсез тормышыбыз.** Пароходка утырдык һәм максатыбызга ирештек. Әмма безгә бер каюта бирмәделәр, палубада, ачык җирдә, бөтен кешенең күз алдында калу безнең өчен бер дә шәп түгел иде. Каютабыз булып, кереп бикләнсәк, тышка сирәк чыгып йөрсәк, бар яктан да яхшы булыр иде. Палубада исә, пассажирлардан, бәлки дә Баку конгрессына баручы төрек коммунистларыннан берсе безне күреп, танып алу куркынычы көчле иде. Хәер, алар арасында мине таныган кеше булуы икеле иде. Чөнки боларның бөтенесе авыллардан килгән, гражданнар сугышы вакытында теге яки бу "хезмәт" күрсәтеп, үсеп киткән яшь коммунист түрәләр иде. Пароходта алар арасында Шамил Усман(ов) исемле бер егетнең яшь хатыны белән баруын хәтерлим. Моңа да карамастан, без, палубаның тыныч, яшеренрәк җиренә утырып, үз хәлебезне контрольдән ычкындырмый идек.

**Хәлебез рәтләнде**. Аллага шөкер, Казанда утырган пароход сай урыннарда йөри торган кечкенә пароход булганга, Казаннан 6О км ераклыктагы Богородск

пристанена кадәр генә барачак булып, аннан соң пассажирлар зуррак башка пароходка күченәчәк иделәр. Бу күченү вакытында зур пароходның капитанына үзебезнең хәрби хезмәткәрләр булуыбызны һәм беребезнең хатыны белән кечкенә баласы да булуын сөйләдек, аерым каюта, һич югы бөтенебезгә бер каюта бирүен үтендек. Чынлап та, "документлар" буенча, икебез дә берәр хәрби организациянең хезмәткәрләре бит һәм икебез дә Бакуга эш белән барабыз. Инде Казаннан шактый ераклаштык. Мондый вакытта эшнең бик җаен белеп, килештереп сөйләшергә кирәк, югыйсә, шик уятуың да күп түгел. Без дә Богородск өлкәсендәге пароходның капитаны белән сөйләшкәндә, чын хәрбиләр булып рольне начар уйнамадык бугай, безгә ике кроватьлы бер каюта бирделәр. Урнаштык һәм рәхәт булып китте...

... **Хисләрем–тойгыларым.** Киттек. Идел буйлап озын сәфәргә чыктык. Әлеге пароход белән Астраханьга кадәр барачакбыз. Аннан соң мин башка пароход белән Хәзәр диңгезен кичеп, Бакуга, Бакудан ул вакытта әле большевик власте астында булмаган мөстәкыйль бер социалистик (фәкать большевистик түгел) җөмһүрият булган Гөрҗестанга (Грузиягә) китәргә уйлый идем, ә аннан инде Европага, яки Төркиягә китәргә хисап итә идем. Биш ай ярым тоткын халәте кичергәннән соң, минем өчен пароходта сәяхәт итү бер дә начар түгел иде. Тик билгесез вакытка тагын гаиләмнән аерылуым гына эчне пошыра. Бу пароходның безне кая илтәсе билгеле булса да, бу сәфәремнең мине нинди язмышка дучар итәсе билгеле түгел. Хәер, мин киләчәкне ул хәтле уйламый да идем. Ул вакытта минем башымда һәм күңелемдә котылу сөенече белән аерылышудан туган ачы хис нәүбәтләшеп алышынып торалар иде.

Юлыбыз озын, сәфәребез монотон, һава шактый кызу һәм бөркү. Пароход барган су, диңгез булмыйча, бер елга гына. Шуңа күрә сәяхәт вакытында безгә нинди дә булса үзгәреш бирердәй, кызыксындырырдай зур-зур дулкыннар да, котырган шторм да юк. Юлыбыз гел җылы якка, көньякка таба. Бу якларда да элеккеге җанлылык, элеккеге хәрәкәт һәм халык төркеме күзгә чалынмый. Халык, гражданнар сугышыннан яңа гына чыгып, хәл ала башлаган иде. Дәүләтнең асты-өскә килгән, хаерчелек баскан иде. Халык, үзенең "кылган" эшләренә борчылып, үкенеп, аптырап, кайгырып тора кебек. Һәркем борчулы, ачулы, нервлы. Элек Идел буендагы пароход пристаньнарында авыл хатыннары ашау-эчү әйберләре сата торганнар иде. Болары бу юлы да бар, тик сата торган нәрсәләре генә элеккеге кебек мул һәм төрле-төрле түгел һәм бик кыйммәт иде.

Лагерьдан, баткаклыкта тирес чыгарудан котылдым. Нинди зур бәхет, нинди зур уңыш түгел идеме бу? Ләкин инсан бик сәер бер мәхлук шул, табышмак кебек бер нәрсә. Монда сәгадәткә һәм хөрриятькә ирешкәннән соң, пароходтагы бер төсле генә тору, монотонлык минем эчемне пошыра башлады. Лагерь һәм юл иптәшем И. Ар. әллә нинди басынкы кеше булганга, аның белән дә күңелсез була башлады. Аннан, лагерьда атналар буе бергә яшәгәнгә, аның белән сөйләшер сүз, темалар да беткән иде бугай...

**Култык таяклы кеше.** Болай эч пошудан туеп йөргәндә, пароходның бер камерасында уку залы яки китапханә кебек бер җир күрдем. Бу китапханәне култык таяклы, озын буйлы, какча гәүдәле бер абзый тота иде. Мин аны шунда ук таныдым: хатынымның туган ягы булган Сарапул шәһәреннән, элек башыннан ниләр кичкәне беркемгә дә билгесез, "ризыгын ходайдан алучы", аяклары аксак булуга карамастан, өлкәдән-өлкәгә йөрүче Иванов исемле бур урыс иде. Аның миннән Казанда чакта бурычка акча сорап килгәне бар иде. Минем аны бер генә тапкыр күргәнем булса да, ул мине Сарапулда да күргән булуы мөмкин иде. Китап залына киттем. Укырга берәр журнал, я китап аласым килгән иде. Тик анда амбалаж кәгазенә басылган, шунлыктан тышкы кыяфәтләре бик ямьсез күренгән совет газеталарыннан, юка журналлардан гайре укырга берни юк иде. Шулай да, вакыт уздыру өчен, ике данә юмористик мәҗмуга алдым. Аксак абзаң белән сөйләшүебез гаять "рәсми" иде. Мин үземне танытудан саклана һәм аны тануымны белгертми идем. Мәҗмугаларны кире китергәндә, абзаң йөземә туп-туры карап: "Сезләр Шамовларның кияве түгелме?" — дип сорап куймасынмы бер заман! Димәк, ул мине таныды. Мин исә чыраемны бер дә үзгәртмичә генә: "Нинди Шамовлар? Мин бернинди Шамовларны да белмим", — дип җавап

бирдем һәм бер дә кызыклы китап булмавын әйтеп, янадан китапханәгә кереп йөрмәдем. Тик, бу кешенең мине тануына бер дә исем китмәде, дисәм, ялган булыр. Ярый әле, Иванов, минем Шамовларның кияве булу-булмавым белән артык кызыксынмыйча, мине эзләп йөрмәде. Бу да минем бәхет эше иде. Чөнки абзаң, теге яки бу сәбәп белән бергә совет органына мөрәҗәгать итеп, минем кем икәнемне исбат итәргә тотынган булса, кем белә, башыма тагын нинди бәлаләр төшкән булыр иде...

**... Астраханьга җитү.** Ниһаять, Иделдәге сәфәребез ахырына якынлашты: беренче максатыбыз, Идел су юлы порты булган Астрахань шәһәренә килеп җиттек. Монда үземне бар яктан да рәхәт, азат һәм имин хис итә идем. Инде Казаннан бик еракларда мин. Бу шәһәрдә мине танып, кулга алдырырдай кеше юк дип уйлыйм. Шуңа күрә шәһәрнең теләсә кайсы җиренә киттем, Губчеканың янынннан гына үтеп, анда тимерчыбык белән әйләндереп алынган бер бина эчендә тулып яткан мескеннәрнең аяныч хәлләрен күреп, үземнең дә биш айга якын элек шул хәлдә булуымны уйлап, бу сәгатьтә исә ирektә йөрүемә сөендем һәм ояпдым...

Мондый вакытларда, ягъни җинаятьчеләр, шпионнар, агентлар белән туп-тулы заманда һәм җирдә, такма исем белән, аудан курыккан киек кебек йөргәндә, иске бер таныш-белешкә яки башка бер ышанычлы кешегә туры килү — чүлдә су һәм яшеллеккә тап булу кебек үк сөенечле һәм көч бирә торган бер хәл. Лагерьдан качканнан соң совет илендә йөргән көннәрдәге алган тәҗрибәм буенча моны бик яхшы аңлаган идем. Шуңа күрә монда Астраханьдагы ике очрашуымны язмый булдыра алмыйм.

**Каһирәдән бер белгеч.** Каһирәнең мәшһүр Әл-Әзһәр университеты тирәсендә заманында бер төрек гайрәт иясе Мәһмәт бәй исемле кеше тарафыннан төзетелгән "Мәһмәт бәй мәдрәсәсе" бар. Вакыфның куйган шарты буенча, бу мәдрәсә хөҗрәләрендә бары тик төрек шәкертләре генә яшәргә тиеш була. Шәкерт, бу хөҗрәдә бушлай яшәүдән тыш, тагын Мәһмәт бәй вакыфыннан, белмим, аена күпмедер көлчә (кабартма) һәм берничә куруш акча да алган. Шәкерт Әл-Әзһәрдә алган дәресләрен дәвам итә алган, ләкин бу эш мәҗбүри булмаган. Бу шәкертләр болай да "университетлы" саналганнар. Шуңа күрә анда һичбер төрле дәрес дәвам итмичә, берни дә укымыйча, өйрәнмичә, еллар буе "көлчә" ашап, кесәсенә сары лира туплаган, хөҗрәне кулдан ычкындырмау өчен өйләнми яткан кемсәләр дә юк түгел иде. Ул вакытларда, ягъни минем 1904 тән 1908 елга кадәр Каһирәдә уздырган вакытта, бу вакыфның аерым хөҗрәләрендә казанлы һәм Кырым төрек шәкертләре дә яши иде. Болар арасында Европа Русиясенең Пенза тарафларыннан Х. исемле карт кына, ябык кына бер әфәнде дә бар иде. Ул да инде бу хөҗрәләрнең берсендә байтак еллар яшәгән, яшәү рәвеше тәртипле, әхлагы нормаль һәм үзенең нәрсә өйрәнергә теләгәнен белүче бер кеше иде. Ләкин аны әллә ни күп нәрсәгә өйрәнгәндер дип уйламый идем. 1908 елның җәендә Каһирәдән киткән вакытымда ул шунда калган иде бугай. Тик бу әфәнде Русиягә кайткач, Астраханьга килеп, мөгаллим булган һәм бер укытучы кызга өйләнгән, имеш. Минем болар хакында, гомумән, хәбәрем юк иде. Бу әфәнде белән Каһирәдәге танышлыгыбыз фәкать сәламләшерлек кенә булса да, бу юлы Астраханьда кырык еллык дуслар кебек күрештек. Һәм чәй табыны янында, еллар буе бер-берсен сагынып яшәгән ике дус кебек, самими сөйләштек. Хатыны да күркәм һәм зәки генә ханым күренә, сөйкемле һәм ачык йөзле иде.

**Илдән-илгә йөргән бер укытучы.** Элек Төркиягә күчеп, озак еллар буе мәмләкәтебездә яшәгән һәм Бурсада бер йортның хуҗасы булган да, нишләптер, кире Астраханьга кайткан һәм бер мәчеттә имамлык итә башлаган, большевистик революциядән соң да анда калырга мәҗбүр булган, хәзер бу хәленнән ничек котылырга белми торган С. хуҗаны Х. әфәнде белән бергә зиярәт иттек. Бераз дөнья хәлләрен, чор проблемаларын сөйләшеп утырдык.

Икенче бөтендөнья сугышына кадәр бу С. хуҗа белән Бурсада очрашмадым микән мин? Минемчә, хуҗа әфәнде, миннән соң бер юлын табып, совет чолганышыннан чыга ала, аннан Кытай Төркестанына ычкына, аннан соң исә бер кытай сәүдәгәре кыяфәтендә хаҗга китә һәм хаҗдан кайтышлый, Бурсага

килеп, иске өенә урнашып кала, имеш. Соңыннан бу укытучының Бурсадагы өен сатып, янадан Шәркый Төркестанга китүен дә ишеттем.

Тормыш-көнкүрешләре һәм "фәлсәфәләре" минекеннән аермалы булган бу ике кеше белән мине большевистик режимга каршы булу һәм миллият фикерләренә тугрылык принциплары берләштерә иде. Бу принциплар буенча мин алар белән дә аңлаша, дәртләшә ала идем. Башым иелгән, өметләрем төшенкә булган ул дәвердә, фикри һәм рухи көч туплау җәһәтеннән, урта дәрәҗәдә булган бу ике кеше дә минем өчен үзенә күрә "мәгънәви азык" иделәр...

... **Астраханьнан — Бакуга.** Казаннан киткәч, төп максатыбыз Азәрбәйҗаннан бәйсез Грузиягә китү, ягъни Советлар Берлегенең тышына чыгу булуын югарыда язган идем инде. Шуңа күрә Азәрбәйҗанда озак вакыт калу мәгънәсез булачак иде. Тик башта Бакуга китәргә кирәк иде. Астраханьга кадәр бер "совет хәрби хезмәткәре" сыйфатында бушка сәяхәт иттек. Чынында хезмәткәр булмасам да, хөкүмәт бакчасында һәм сазлыгында тамак хакына гына эшләвемне искә алсак, бу бушлай сәяхәтемне аклап булыр дип уйлыйм... Шул рәвешле, Хәзәр диңгезендә дә акчасыз сәяхәткә хакымны сөйләп, Астраханьда тагын совет учреждениеләренә мөрәҗәгать итәргә уйласам да, иптәшем моннан юньле нәрсә чыкмасын аңлатып, мине ул фикердән кире күндерде. Чарасыздан диңгез пароходына билетны акча белән алырга мәҗбүр булдык. И. Ар. Астраханьнан Бакуга кайбер "товарлар" илтү һәм аннан да кайбер нәрсәләр китерү максаты белән минем белән бергә китәргә булды. Аның да "документында" Бакуга кадәр дип язылган иде. Каһирәдән таныш булган мөгаллим Х. мине озату өчен пристаньга кадәр килергә теләде. Астрахань порты сайда утырганга күрә, зур диңгез пароходлары шәһәргә якынлаша алмыйлар һәм бу сәбәптән шәһәрнең 8О км түбәндәрәк диңгез суларында бер пароходтан икенчесенә күчеп утырырга кирәк иде.

**Бакуда.** Юлда Хәзәр диңгезенең көнбатыш ягында Дагыстан туфракларында урнашкан Петровск (бүгенге Махачкала) шәһәрен узгач, Азәрбәйҗанның башкаласы Бакуга җиттек. Бакуга беренче генә килүем иде. Белгәнемчә, Русиядә, демократия төзү өметләре җимерелгәннән һәм Петроградта кызыл диктатура урнашканнан соң, Русиядән киләчәк большевизм афәтеннән саклану фикере белән, рус булмаган милләтләрнең күбесе киләчәк язмышлары турында баш вата башлаганнар иде. Көньяк Кавказ төрекләре дә, 1918 елның 28 маенда, димәк, большевикларның властьне үз кулларына алуга 6 ай да 11 көн узгач, үз җирләрендә Азәрбәйҗан исеме белән бер мөстәкыйль җөмһүрият корулары турында игълан иткәннәр иде. Менә Баку шул бәйсез Азәрбәйҗан хөкүмәтенең баш шәһәре иде инде. Мин Бакуга башка вакытта, 192О елның сентябрь башларында барганда инде бу шәһәр бәйсез Азәрбәйҗан башкаласы булмыйча, Советлар Берлегенә аннексияләнгән Кызыл Азәрбәйҗан республикасының мәркәзе иде. Чөнки большевиклар Азәрбәйҗанны шул ук елның 27 апрелендә басып алганнар иде. Шул сәбәптән Азәрбәйҗан бары бер ел да унбер ай гына мөстәкыйль тормыш белән яшәп калган һәм кече милләтләрдән, Литва һәм Грузиядән соң, мөстәкыйльлеген игълан иткән өченче өлкә булса, бу мөстәкыйльлекне иң беренче булып югалткан иде.

Лагерь һәм юл аркадашым И. Ар. ның белгән бер мөселман кешесенең өенә киттек. Бу мөселман асылы белән Казаннныкы иде бугай. Максатым Грузиягә китү булганлыктан, мин тирә-юньне күзәтә, тикшерә башладым. Ул көннәрдә Бакуда гадәттән тыш бер җанлылык, хәрәкәт һәм фагыйлият бар иде. Дәүләттә иминлек саклау эшләре алып барылуы шөбһәсез иде. Чөнки "Шәрекъ милләтләре конгрессы" ачылырга күп вакыт калмаган иде. Кин Русиянең һәр почмагыннан, хәтта чит илләрдән дә делегатлар Бакуга агыла. Казан делегатлары да, күргәнебезчә, Астраханьга кадәр безнең белән бер пароходта килделәр. Шәһәрдә, Русиядә күренгән хәерчелек, кытлык, тәртипсезлек тә бик сизелми. Большевиклар, ул вакытта уздыра торган "шәрекъ политикасы" буенча, нишләптер монда базарларны яптырмаганнар иде. Илдә "социализм" төзү эшенә артык зур тизлек бирелмәгән иде әле, күрәсең. Шунлыктан монда һаман да элеккеге муллыкның, кинлекнең эзләре бөтенләй үк бетеп җитмәгән иде әле. Болар барысы, безнең кебек хәерчелек, ярлылык иле Русиядән килгәннәрнең башында, "черек" капитализм дәвереннән

калган татлы хатирәләрен уяндырып, сагыш-моң туугa сәбәпче булалар иде...

... **6 айдан соң тагын бер тапкыр**. Очраклы рәвештә, Зәки Вәлидинең Бакуда булуын ишеттек. Күрешү теләген кайсыбыз беренче, минме, юкса Вәлидиме, белдерде, хәзер хәтерләмим инде. Бер якташ мине үз артыннан ияртеп алып китте. Урнашкан өе безнең өйдән бик ерак булмаган бер мәхәлләдә "Приютская" урамында булуын хәтерлим.

Элеккеге башкорт лидеры идәнено келәмнәр җәелгән иркен генә бер бүлмәдә утыра иде. Янында "адъютантлары" да бар. Боларның кайсыберсе башкорт булмыйча, Казан төреге иде. Югарыда аңлатуымча, 6 ай элек мин Вәлиди белән шимальдә Уфа шәһәре янындагы Аксионово станциясендә очрашкан идем. Ул вакытта мин дошман кулындагы бер сәяси "җинаятьче" булсам, Вәлиди эш башында торган зур бер "дәүләт кешесе" иде. Хәзер көньякта Азәрбәйҗан җирендә тагын бер тапкыр кара-каршы очраштык. Бу юлы инде икебез дә бертөрле хәлдә идек: мин биш ай ярым совет төрмәләрендә ябылып ятканнан соң, ялган документ, ялган исем белән Русия чиген узу фикерендә бу якларга килеп чыккан, кесәмдәге кәгазем буенча, Казандагы бер хәрби оешманың хезмәткәре "Габдулла Рәхимов" идем, 3. Вәлиди исә, 6 февральдә Мәскәү хөкүмәте белән бозылышып, хәзер советларга каршы көрәшер өчен "җир астында" (подпольеда) эшләү һәм яшерен оешма кору максаты белән 192О елның 29 июнендә (12 июлендә), димәк, минем качуымнан 5 атналап элек, Мәскәүдән китә, ягъни кача. Бу качу хикәясен үзеннән сөйләтик: "Мәскәүдә Ленинның империя (федерация) мәсьәләсе буенча төзегән проекты буенча бәхәс безне Мәскәүне ташлап, яңа бер юлга кереп китәргә мәҗбүр итте. Ленин һәм иптәшләренең Шәрекъ өлкәләрендә социализм төзү мәсьәләсендә урыңдагы хезмәткәрләргә һәм җирле социалистларга ышанмаулары, бу өлкәләрдәге җитәкчелекне рус пролетариаты тәмсилчеләренә бирергә теләүләре аңлашылды. Шунлыктан без бергә җыелдык, киңәштек: яшерен оешма төзергә, аңа мин һәм тагын берничә кеше керәчәк, рәсми вазифаларыбыздан ваз кичеп, теләгәнебезне советларга көч ярдәмендә кабул иттерергә карар бирдек. Мин, Сталиннан ала алмаган рөхсәтне, партия сәркатипләре Крестинский һәм Преображенский ярдәме белән кулга төшереп, хосуси вагоннарда сакчыларыбыз һәм бюробыз белән бергә, ике ай ял итү сылтавы белән 9(22) июньдә Астраханьга таба юлга чыктым. Юлда беркөн иртүк, тышкы кыяфәтне үзгәртеп, кызыл гаскәри рәвешенә кердем, гаиләмне һәм ике солдатымны алып, поездан төшеп калдым. Иптәшләребез безне күз яшьләре белән озатып калды. Януыбызда коралларыбыз, куенымда кайбер тарихи һәм сәяси язмаларым, "Бабурнамә" һәм "Капитал" китаплары бар иде. Берничә көннән соң Бакуга һәм бер ай соңрак Ашхабад шәһәренә җиттек" (*Ә. Зәки Вәлиди Туган. Бүгенге Төркестан һәм якын киләчәге. — Каһирә, 1929 — 194О. — 376 — 377 б.*).

Күренә ки, Вәлиди Мәскәү хөкүмәте белән бозылышканнан соң, Төркестанга китә. Һәм "Шәрекъ милләтләре конгрессы" җыелган вакытта яшерен рәвештә (әлбәттә, ялган документ һәм исем белән) Бакуга килә. Димәк, 192О елның сентябрендә ни мин дошман кулындагы "сәяси җинаятьче", ни Вәлиди эш башында торган бер дәүләт кешесе түгел идем. Һәр икебез Советлар белән хезмәттәшлек итәргә теләп тә, уңышка ирешә алмыйча, нәтиҗәдә, алардан ераклашып, ялган исем һәм документлар белән йөрүче кешеләр идек.

**Хәлләребездәге аерма.** Ләкин хәлләребездә бөтенләй үк аерма да юк түгел иде. Мин ул вакытларда һичбер төрле оешмага һәм сәяси агымга кермәгән, "политика" белән шөгыльләнмәгән, бары тик Русиядән читкә китүне генә максат итеп куйган бер адәм булсам, Вәлиди элеккеге хезмәттәшләре белән арасын бөтенләй үк өзмәгән, янында башка фикердәшләре булган, яхшымы-яманмы бер яшерен оешма җитәкчесе буларак, Бакуда әлеге конгресска килеп, анда катнашкан кайбер делегатлар белән яшерен очрашып сөйләшергә ниятләгән, кыскасы, әле дә ниләрдер оештыру хыялы белән янган бер политик иде. Мин аның белән Бакуда Приютская урамындагы өйдә күрешкән вакытта бу аерымлыкны күргән кебек, ул да үзенең югарыда күрсәтелгән китабында бу турыда язган (378 б.) һәм, шөбһәсез, хаклы иде.

**Чыгырдан чыккан эшләр.** "Политика" белән шөгыльләнмәгән бер кешенең политик кеше белән яшерен күрешүендә озын-озак сөйләшеп утыру мөмкин

түгел иде, табигый. Ни хакында сөйләшә алыр идек соң? Хәл ачык иде: советлар гражданнар сугышында көндәшләре ак генералларны җиңделәр. Көньяк фронтта Кавказ тауларына таяндылар, аны да үтеп, инде бәйсез милли Азәрбайҗан җөмһүриятенең мәркәзе булган шәһәрдә Шәрекъ кавемнәрен читлеккә кертү максаты белән бер конгресс җыялар. Төркестан революциядән соң да һичбер вакыт азатлыкка ирешә алмады. Анда күптән инде большевиклар хуҗа. Милли автономияле республикалар төзү яклы булган казах һәм башкорт төрекләре, күптән советлар белән аңлашып, солых алганнар иде инде. Әгәр солых алмаган булсалар, кызыл урыслар белән ак урыслар тукмашкан вакытта, йомшак тәшкиләтле, аз санлы, коралсыз һәм берләшмәгән бу төрек кабиләләренең, ике үгез сөзешкәндә сытылган черкиләр кебек, изелеп юк буласы хак иде.

**Большевиклар белән аңлашырга теләгәннәр**. Большевиклар властьне үз кулларына алганның беренче көннәрендә үк алар белән аңлашу өметендә, советлар белән хезмәттәшлек итә башлаган "сул социалист революционер группасыннан" байтак кеше бар иде. Тик иртәме-соңмы, бөтенесе бу хыялга алдануларына үкенделәр яисә бөтенләй юкка чыктылар. Советлар белән аңлашып, аерым файдалы эшләр башкарырга планлаштырган Вәлиди группасы да бу хосуста кагыйдәдән чыгарма түгел иде. Шөкер әле, сизмичә читлеккә кергән аркадашыбыз Вәлиди, һич булмаса, җанын коткара алды. Юкса, бер политик кына түгел, көч туплап килүче тарих галиме дә юкка чыгачак иде. (Бу фикерләребез газеталарда чыккач, проф. З. Вәлиди Туганнан 11.X.1948 даталы бер хат алдым. Ул хатта шәхсән болай диелгән иде: "Тасвир" белән "Милләт"тә мине советлардан бер-бер файда өмет итеп, алар белән хезмәттәшлек иткән бер кеше кебек күрсәтүен тамырдан ялгыш. Гражданнар сугышы вакытында башкортларның советлар тарафына күчүләре чып-чын бер мәҗбүрият нәтиҗәсе булды. Без Ленин, Троцкий һәм Сталин белән очрашуларыбыз вакытында һәрвакыт милләтче булып калдык. Тик алар безгә ышанмадылар. Безнең белән договорның, алар фикеренчә дә, зарурият булуын Ленин үзе партиянең VIII конгрессында сөйләде. Әмма адмирал Колчак безнең автономиябезне җимереп, гаскәрләребезне, хөкүмәтебезне таратырга әмер биргәч, без, Оренбург казачийларына, атаман Дутовка ияреп, Җонгариягә, Кытайга китмәдек. Колчаклылар безне турыдан-туры асарлар иде. Шуның өчен без кызыллар каршысында Сибириягә чигенә алмый идек...")

Советлар белән килешеп, алар ярдәме белән Шәрекъ мөселман кавемнәрен коткару идеясенә капканнарның тагын берсе Әнвәр Паша булды. Түбәндә аның турында аерым мәгълүмат бирелер.

**Тарихчы Һади Атласи.** Минем иптәш И. Ар., белмим кемнән һәм кайдан, тарихчы Һади Атласиның Бакуда булуын белде. Һади Атласи — Шималь төрекләре дөньясында танылган бер шәхес. Европа Русиясендә Самара губернасы Бөгелмә өязендә зур гына бер авылда имам булу белән бергә, дөнья хәлләрен аңлаган, Төркия, Мисыр һәм рус матбугатын укып барган, төрек тарихына караган гыйльми эзләнүләр белән мавыккан, кулы каләм тоткан зыялы бер мулла, хәлфә иде. Ул 1907 елның 20 февралендә (5 мартында) ачылган һәм 3(16) июнендә таратылган Икенче Дәүләт Думасына депутат итеп тә сайланган иде. Гаҗәп ки, укытучы булган хәлдә, мөселман депутатларының сул группасына кушылган иде. Казанда, "Йолдыз" газетасында секретарь булып эшләгән вакытымда безгә төрле милли-иҗтимагый мәсьәләләр буенча берничә язма да җибәргән иде ул. Бик оешып бетмәгән, хаталы формада язылган бу мәкаләләр, гадәттә, минем контролемнән уза иде. Бу контрольдән соң, авторның күпчелек язмаларында кулланган туры сызыклы һәм кечкенә кыләмле кәгазь битләре өстендә бик еш кызыл каләм белән ясалган төзәтүләр була торган иде.

Тарихи эзләнүләренең нәтиҗәсе буларак, Һ. Атласиның "Казан ханлыгы", "Себер ханлыгы", "Сөембикә" исемле әсәрләре Казанда басылып чыкты.

Мин аны Казанда берничә тапкыр очратканым булды. Пәһлеван гәүдәле, зур башлы, көр тавышлы бер төрек тибы иде. Йоп-йомры йөзе, кечкенә генә борыны һәм мөселманнарга хас гадәт буенча күркәм башының түбәсенә урнашкан кара кәләпүше белән борынгы заманның бер монгол-татар бәгенә охшап тора иде. Югары тавыш һәм зур җанлылык белән теге яки бу сәяси, милли һәм иҗтимагый мәсьәлә буенча бәхәсле әңгәмәләр корырга ярата иде. Заманында,

иске мәдрәсәдә укыганда, куәтле һәм ялкынлы бер "моназарачы" булуы күренеп тора. Кирәгеннән артык житди, бик оптимист һәм "мәзәккә бармас" бер кеше иде. Бер имам сыйфатында яшәгән өлкәсендә белем һәм фикер таратырга тырыша, заманына лаек бер мәктәп белән идарә итә иде. Бу — үзенә күрә бик кызыклы, игътибарга лаек шәхес, алдынгы фикерле мулла һәм зыялы төрек тибы иде.

Көчле ихтыяр көченә ия, башкалардан аерылып торучы бу шәхеснең кешелек сыйфатларын изүче, индивидуальлекне бетерүче режим белән көрәшүе бик табигый хәл. Менә шул сәбәпле ул гражданнар сугышы көннәрендә, кызыллардан качып, көньякка таба юлга чыга һәм бу юл аны кыргыз-казах далалары буеннан, бәйсез Азәрбәйжан жөмһүриятенә китерә. Бу тирәләргә дә большевиклар килеп житкәч, башка бер жиргә дә качмыйча, язмышына буйсынып, монда кала. Көнчыгышка качкан булса, без аның белән бәлки Уралның яки Сибириянең бер жирендә табышкан булыр идек. Аңа калса, хәзер монда, бөтенләй башка шартлар һәм хәлләр эчендә, бер-беребезне табуыбыз, язмыш билгесе түгел идемени?

Бер кичне иске танышым булган мулла һәм галимне күрергә киттем. Әлеге очрашу да минем өчен рухи бер азык булачак иде...

**Һ. Атласи бүлмәсендә.** Аның урнашкан йорты безнекеннән әллә ни ерак түгел иде. Атласида мөһим үзгәрешләр күрмәдем. Төс-кыяфәте искечә. Бары тик заманында башының түбәсендә ярым карбыз кебек торган "кәпәче" генә житешми иде бугай. Мулла мине бу тирәләрдә күрүенә әллә ни аптырамаган кебек, минем дә аның монда булуына исем китмәде. Чөнки куркыныч рус чуалышлары нәтижәсендә бик күп кешеләрнең төрле якларга таралуы, күз күрмәгән ерак илләргә китүе безнең өчен гадәти хәлгә әйләнеп бара иде инде.

**Һөжүм һәм арест.** Бу кызыклы шәхес белән сөйләшәчәк темалар күп иде. Узган ике ел эчендә башыбыздан кичкәннәрне кара-каршы утырып сөйләшә башласак, сәгатьләрчә генә вакыт житмәс. Тик безгә болай озын-озак сөйләшү түгел, кыска гына вакыт та насыйп булмады. Хәл-әхвәл сорашканнан соң, төп мәсьәләләргә күчәргә генә торганда, арт ишек ачылды. Һәм билләренә пистолетлар аскан ике кызыл чекист эчкә үтте. Берсе шунда русча:

— Сезнең кайсыгыз Атласов? — дип сорады.

Йөзе көл төсенә кергән безнең Һади әфәнде, тетрәнгән бер тавыш белән шулай ук русча:

— Я (мин), — дип жавап бирде.

Чекист:

— Сез кулга алынасыз. Менә ордер, — дип, бер кәгазь кисәге чыгарып күрсәтте.

Инде чират миңа килеп житте. Чекистларның берсе миңа борылып:

— Сез кемсез? Документларыгыз бармы? — дип сорады. Тиз генә кесәдән документларымны алып, аңа суздым. Укыды да, миңа карап:

— Мин дә Казаннан. Анда моның ише бер оешма да юк, — диде. Мин чыраемны бозмыйча гына:

— Бар ки, миңа шундый документ бирделәр, — дип жавап бирдем, тик бу жавабымның кемне дә булса ышандырачагына бик өмет итмәдем. Чөнки миңа бу документны саткан оешма чынлап та уйлап чыгарылган бер нәрсә иде.

Теге кеше бераз уйлап торды да, миңа:

— Китәргә мөмкин, — диде.

Шулай итеп, бу хәвеф, зур курку хисабына булса да, минем өчен узып китте. Югыйсә, бу имансыз большевик хезмәтчеләре, "зур гөнаһы" булган Атласиның янында торган безләрдән дә шикләнеп, "на всякий случай", Чекага китереп, сорау алырга да күп сорамаган булырлар иде. Нәтижәдә, безне кире жибәрмичә, берьюлы ике качкынны эләктерүләре өчен бәлки мактауга да лаек булган булырлар иде.

**Һ. Атласи үз илендә.** Русия чиген узгач ишетүемчә, Атласины кулга алып, Казанга китерәләр һәм 1920 ел азакларына таба, азат итеп, Бөгелмә өязендәге гаиләсе янына кайтырга рөхсәт бирәләр. Хәтта 1921 елның кышында ана "икенче баскыч" бер татар мәктәбендә немец теле һәм табигать белеме дәресләре укытырга да мөмкинлек туа. Югарыда әйткәнемчә, 1922 елда

Финляндиядә вакытымда, Русиядә ачлыктан газап чиккән аерым төрки зыялыларына Америка тәшкиләте арадашлыгы белән азык-төлек паеклары җибәргәндә, Һади Атласины да онытмадым. Бу пакетны алганлыкка Һ. Атласи имзасы куелган. 6.III.1922 тарихлы җавап кәгазе дә алдык. Һ. Атласи укытучы булып эшләгән вакытта, 1926 елда рус лицеенда белем алучы угылын, рухани, имам малае дип, мәктәбеннән чыгарган булсалар да, әтисенең тырышлыгы белән баланы мәктәпкә кире алалар.

**Яңадан арест һәм сөрген**. 1929 елга кадәр Атласины борчымыйлар. Тик шул елның январенда Чека хезмәткәрләре, төн караңгылыгында басып кереп, өенең астын-өскә китереп энәсеннән-җебенә кадәр тентиләр, китапханәсен актаралар һәм берничә хатны (алар арасында Төркиядән якташларыннан килгән хатлар да була) табып алып, Атласиның үзен дә кулга алып, янадан Казанга китерәләр. Казаннан Мәскәүгә җибәрелгән тарихчы андагы төрмәләрнең берсендә угылы Габделбәр белән очраша. Бу егет ике иптәше белән Русия чиген кичеп качарга маташканда тотыла һәм Мәскәүгә китерелеп, әтисе яткан төрмәгә ябыла. Һади Атласи Мәскәүдә сөргенгә хөкем ителә.

**Шималь Ак диңгез утрауларында.** "Сөрген" дисәк тә, бу гадәти бер сөрген булмый. Атласи, 1930 елда 10 ел каторга эшләрендә эшләү өчен, Төньяк Боз океанының бер тармагы булган Ак дингездәге Соловецк утрауларына җибәрелә. Атласиның ул вакытта шундый ерак каторга җире булган утрауларга сөрелүе мәшһүр казанлы "милли" коммунист Мирсәет Солтангалиев һәм иптәшләре "эше" белән бәйле булырга мөмкин. Чөнки казанлы "милли" коммунистлар, тагын шул ук маһияттә булган кырымлылардан Исмәгыйль Фирдәвес, Осман Деренарлы һәм коммунист булмаган язучы Әхмәд Өзәнбашлы да бу "рус Гвинеясына" яки "большевик Сахалинына" каторга әсире буларак, нәкъ шул вакытларда җибәрелгәннәр иде. Соловкида Атласи белән бер үк вакытта булган кырымлы Осман ага Карабибәрнең сөйләвенә караганда, анда алар, икесенең дә техник профессиясе булмаганга, каравылчы булып торганнар. Сөргенгә җибәрелгән көннән башлап, 3 ел узгач, башка бик күп арестантлар кебек, безнең тарихчы да, медосмотр карары белән яраксызга чыгарыла, ягъни утрауда эшли алмаслык дәрәҗәдәге инвалид булып санала башлый. Моның кебек әсирләрне, калган җәза срокларын тутыру өчен, утраулардан читкә җибәрәләр. Һ. Атласи да 1932 елда, 5 елы тулыр-тулмас, Архангельск өлкәсендәге бер поселокка сөрелә. Икенче бөтендөнья сугышы көннәрендә Германиядәге кайбер казанлы әсирләреннән ишетүемчә, 1935 елда, бәлки бу сөрген урыныннан Мәскәүгә китерелгәч, атып үтерелә...

**... Яңадан Казанга.** Бер тапкыр лагерьдан качып котылганнан соң, янадан Казанга кайтуыма, бәлки сез гаҗәпләнерсез. Моны дусларыма сөйләгән вакытта алар гел аптырыйлар, кайберләре хәтта моны бер "тилелек" дип тә атый иде. Дөресен сөйләргә кирәк, мәгънәсез бер адым булып күренгән бу эшкә хәзер үземнең дә исем китә. Ул вакытта мине мондый адымга нинди хәлләр һәм тойгылар этәрде соң? Бүген, әлбәттә, боларның барысын хәтерләп, җанландыру мөмкин түгел. Хәзер шуны гына әйтә алам ки, Казанда ялган документ белән көпә-көндез, бер совет чиновнигы сыйфатында йөреп, тагын бер ясалма таныклык белән Астраханьнан Бакуга барып кайтулардан алган "тәҗрибәм" миңа ул көннәрдә Советстанда ялган документ белән йөрүнең бер дә куркыныч булмавын күрсәтте, кыюлыгымны арттырды һәм мина маҗаралар сөю хисен өстәде бугай. Русия тышына чыгып китә алмадым. "Кара базарчылык"та безгә хас булмавы аңлашылды. Кулымдагы документ мине бары Казанга хәтле генә алып бара, аннан соң эшкә ярамаячак иде. Аның белән Казанга кайтсам, анда икенче документ сатып алып, башка бер җиргә китә алам дип уйлый идем. Шул ук вакытта, яшерен генә булса да, гаиләмне күрә алачак идем.

Шулай итеп, ялган таныклык белән йөрү тәҗрибәсе, бу тәҗрибә биргән кыюлык, моның нәтиҗәсе буларак миндә уянган маҗаралар сөю хисе, яңа документ таба алу өмете һәм гаиләмне тагын бер тапкыр күрү теләге — менә шулар мине Казанга китергән тойгылар булса кирәк...

**Кайту**. Казанга гаиләм янына кайтып барам. Ерак илләрдән кайтып килгәндә, буш кул белән кайту яхшы булмаганга, гаиләм өчен бүләк итеп,

кайбер нәрсәләр алдым. Болар арасында кипкән җимеш, бераз йөзем һәм зур гына пакет белән тоз булуын хәтерлим. Ул вакытта мәмләкәтнең күп кенә өлкәләрендә тоз кытлыгы булган кебек, безнең тирәләр өчен дә тоз зур бүләк булып хисаплана иде.

**"Лев Давыдович" пароходында.** Югарыга, төньякка таба барачак пароходның исеме "Лев Давыдович" иде. Беләсезме, бу кемнең исеме? Бу — мәшһүр кызыл командир һәм большевик Леон Троцкийның исем-отчествосы.

Бу юлы, Казаннан Астраханьга барган вакыттагы кебек, бик үз-үземә артык ышанычлы түгел идем. Бакуда һичбер эш кырмадым, бер төрле дә эш тапмадым. Җитмәсә, тоткын булып яткан җирдән качмыйча, кире шул җирнең нәкъ үзенә кайтып барам. Миңа тыныч кына утырырга, тик кенә торырга кирәк иде, югыйсә. Яхшы киемнәремне һәм башка нәрсәләремне бер сумкага тутырып, тагын бер кире кайту уе белән Бакуда бер мөселманга әманәт итеп калдырганга, өстем-башым бик гади иде. Әйберләрем арасында бер урыннан икенче урынга ташу ṭыелган зур гына пакет тоз да бар. Гади генә кеше булып, аста III класслы каютада бер урынга кереп сендем. Ләкин, тикшерү ихтималын күздә тотып, пароход кузгалып киткәнче, тоз пакетыннанерактарак йөреп тордым, тоз табыла калса, минеке түгеллеге аңлашылсын!

Пароходта тикшерү бик каты булмады бугай, безнең тоз пакетын тапкан кеше булмады. Кузгалып киттек. 1940 елда чит илләрдә, Мексика башкаласында, башына авыр чүкеч белән сугып, бер сталинист француз коммунисты тарафыннан үтерелгән Лев Давыдович исемен йөрткән бу пароходның III класслы каютасында, сөйләшүләре җанымны тырмаган, кыланышлары эчемне пошырган пассажирлар арасында барырга мәҗбүр булган бу сәфәрем вакытында, Казаннан көньякка таба китеп баргандагы кебек, кәефле түгел идем. Чөнки бу кайту юлы минем өчен соң дәрәҗә күңелсез бетәргә мөмкин. Әгәр пароход Казанга якынлашканда тикшерү булып, кәгазьләрем берәр шик уятса?! Яки Казанга кайтып, коры җиргә төшкәч, берәрсе таныса?! Бу уйлар, кәефемне шактый бозып, күңелсезләнүемә сәбәпче булалар иде.

**Җан юлдашы.** Пароходыбыз Самара өлкәсенә якынлашты. Бу шәһәрдә бер башкорт хөкүмәте оешмасында эшләүче каенишем Йосыф Шамлы пароходка утырды. Аның бу пароходта Казанга апасы (минем хатын) янына баруы иде. Бу очрашу минем өчен бөек бер нигъмәт иде: бердән, эч пошудан арыначакмын, икенче яктан, бу егетнең минем Казан тирәсендә бер "казага очрамыйча" җиргә төшәргә ярдәм итәчәген белә идем. Бу кардәшем минем өчен җан юлдашы булачак иде.

**Дулкынландыргыч сәгатьләр.** Көннәрнең берендә кичкә таба Казанга якынлаштык. Минем өчен бу җайлы вакыт иде: Казанга кич, караңгы төшкәч, килеп җитәчәк, караңгыда җиргә төшеп, шәһәргә юнәләчәк идек. Тик минем бу өметем акланмады: тирә-якны томан каплаганга күрә, томанның таралуын көтү өчен, пароход елга уртасында якорь атты. Булды бу! Әлеге форсаттан файдаланып, белмим, каян гына килеп чыккан совет чиновниклары (бәлки дә чекистлар) пассажирларның документларын тикшерергә тотындылар. Минем кесәмдә бер кайту документы бар, әмма ялган булудан тыш, срогы да чыккан, искергән иде. Казанга кайтып җиткәч кенә бер чекист тарафыннан бу кәгазьләрнең тикшерелүе бер дә шәп түгел иде. Моннан бер юньле хәл дә чыкмасы ап-ачык иде.

**Тагын бер тапкыр Казанда.** Шунда җан юлдашым-каенишем миңа нык ярдәм итте: мин әйберләремне аңа ташлап, пароходның ярымкараңгы, тыныч урыннарына посып, контрольдән качып йөрдем. Чекистлар кайсы урыннарны тикшереп китүен Йосыф миңа хәбәр итә дә, мин шул урыннарга китә идем. Ниһаять, контроль бетте. Йокыбыз качкан иде. Таң атты. Тик томан гына тиз таралмады, шуңа күрә Казанга бик тиз генә барып җитә алмадык. Шөкер, пароходыбыз безнең Казаннан 19 августта кузгалып киткән халык тулы пристаньга түгел, бәлки тыныч һәм аулак бер урынга туктады. Пароходтан чыкканда, таныклыгыма бер күз ату белән чикләнделәр, бер кат пароходта контроль ителде дип уйладылар бугай... Исән-сау коры җиргә аяк бастык. "Бүләк-күчтәнәчләремне" туры иясенә җиткерәчәк каенишемә бирдем дә, бер арба тотып, Яңа Бистәдә яшәгән бер танышымның өенә киттем. Гаиләм янына, үз өемә китә алмавымнан

бик авыр тойгылар кичерсәм дә, язмышым белән ризалашмый чарам юк иде...

**"Капкын".** Безнең каениш Кабан күле буендагы өебезгә барган һәм, әлбәттә, үзе белән минем дә кайтуымны хәбәр иткән. Ул көн кичкә таба хатыным мин яшеренгән өйгә килде.Хәл-әхвәлдән соң, хатыным нәкъ шушы көннәрдә Татарстан Җөмһүрияте Халык Комиссарлары Шурасы рәисе Сәед Галиевкә үтерү максатында ясалган һөҗүм аркасында шәһәрдә киң күләмдә арестлар башланганын, шуның өчен шәһәр халкының бик куркыныч көннәр кичерүен, бу чакта минем дә Казанга кайтып төшүем бик тә хәвефле икәнен сөйләде. Мин дә, яңа документ кулга керү белән, тизрәк Казаннан ычкыначагымны әйттем. Яңадан Казанга кайтуым ялгыш хәрәкәт булуын һәм Астраханьнан күчтәнәч итеп алып кайткан тозның гаиләм өчен бик ачы булачагын аңлап, кайтуыма бик үкенсәм дә, соңыннан үкенүдән ни файда!

Иртәгесе көнме, ике көн сонракмы, хатыным тагын килде. Паспорт табу юлларын эзләвен, тик безгә августта паспорт табарга ярдәм иткән "Колаксыз"ның Төркестанга киткән булуын, ул вакытта паспорт алган хәрби оешма хезмәткәрләренең дә әлеге провокация уңаеннан кулга алынуларын һәм үзенең башка паспорт сатып алырдай "ишек"не белмәвен, димәк, хәзергә кадәр паспорт кулга төшерүнең мөмкин булмавын сөйләде. Бу хәлдән соң мин инде Казанда түгел, капкында идем. Нишләргә? Казаннан тагын бер тапкыр ничек чыгып китәргә?

**Каравылчы будкасында**. Яшеренеп яткан дусның өе залдан һәм ике кечкенә бүлмәдән гыйбарәт иде. Мин нәкъ тышкы ишекнең каршысында гына булган кунак бүлмәсендә яшим. Зал белән кунак бүлмәсе арасында ишек ябылмаганга, тыштан кергән теләсә кем мине күрә ала. Бүлмә шул кадәр кечкенә ки, бер почмакка посып утыру да мөмкин түгел. Күрше-тирә кереп-чыгып йөри. Күзлекле бер сәер кешенең тышка чыкмыйча, көннәр буе өйдә ятуы, әлбәттә, кереп чыкканнарның игътибарын җәлеп итә, кызыксыну уята иде, моның исә сүз чыгып кешегә таралуы да бик мөмкин. Шуңа күрә бу өйдән китәргә кирәклеген мин өй хуҗасына сөйләдем һәм Казаннан киткән вакытта иң беренче барып, тышкы кыяфәтемне үзгәрткән һәм пристаньга бергә киткән мадам белән танышкан өйгә күчендем. Ләкин анда да озак тора алмадым. Чөнки элек бергә эшләгән иптәше — өй хуҗасы шүрли, хәтта курыкканын ачыктан-ачык миңа сөйли башлады. Минем бер лагерь качкыны булуымны искә төшерә, хәтта качкан өчен мине үтерергә дигән карар да чыгуы турында хәбәр бирә башлады. Бу хәлдә, бала-чагасы булган бу кешене артыгын интектерү, әлбәттә, дөрес түгел иде. Тик кая барып сыенырга соң?

Бер чара табылды тагын. Беренче яшәгән өйнең хуҗасы шәһәр читендә аулак бер урында яшәгән каравылчы белән элемтәгә керде. Бу каравылчы мине будкасында яшереп торырга ризалык бирде. Ул будка ун меңнәрчә мәет күмелгән иске бер ислам каберлегенең стенасына терәп үк салынган иде. Будка белән зират арасында бары бер тар гына юл уза. Будкада кухня кебек бер нәрсә дә бар. Каравылчы, хатыны һәм өч баласы белән бәз чаршау артында сәке өстендә, мин исә Сибириядән алып кайткан һәм бу юлы өйдән китертелгән мәшһүр толыбыма төренеп, идәндә ятып, бик рәхәт йоклый идем. Каравылчының шәһәр читендә япа-ялгыз утырган будкасына килгән-киткән юк. Килгән кеше булса да, мин көндезләрен өйдә утырмый идем: кырда, елганың сул (Казан) тарафында печәннәре чабылган болыннарда гизә идем.

**Кабер ташлары арасында**. Тик бу йөрүләрнең дә кызыгы бетте: кыш фасылы башланды, һавалар суынды, кичләрен кырау төшә, анда-монда су өсләрен боз каплый башлады. Мин генә рәхәт һәм җылы үз өемә кайта алмыйм. Көзнең соңгы көннәрендә, кыш башларында суык һавада теләсә кая барып йөрү шулай ук әллә ничек. Зур гәүдәле һәм күзлекле бер кешенең гел бушка кырларда йөрүе дә игътибарны җәлеп итәргә мөмкин. Шулай итеп, бу "кыр гизүләрем"не дә туктатырга мәҗбүр булдым. Моның урынына, йөрер өчен тагын да тынычрак, иминрәк, кеше күзенә бик күренми торган алан таптым, ул да булса, зур территорияне биләгән каберстан иде. Бу мөселман зиратында цивилизацияле халыкларның каберлекләрендәге кебек тәртип һәм планлы юллар булмаса да,бөтенләй үк тәэсиклектән мәхрүм түгел иде. Зиратлар — фәлсәфи фикерләр дингезендә гизү өчен иң кулай почмаклар инде алар.

Карап йөрим, мен төрле кабер ташларындагы язуларны укыйм, бер төркем тарихи исемнәр белән очрашам һәм тарихи чорларга хыялымда сәяхәт итәм. Казан губернасына иске Бохарадан яңа фикерләр китергән, күп кенә дини һәм тарихи әсәрләр язган, исеме һәм шөһрәте Русия чикләрен узган тарихчы һәм акыл иясе Шиһабетдин Мәрҗани дә бу зиратта ята. Бу остаз чытык кашлары, кискен карашлары, мәгънәле сызыклар белән тулы киң маңгае, мәһабәт гәүдәсе һәм олугъ чалмасы белән минем күз алдымда тора һәм гүяки "Мостафадел-әхбар" исемле тарихи әсәренең беренче җилдендә язган мәшһүр сүзен кабатлап, миңа "Әй, мескен..." дип эндәшә сыман тоела.

Казан төрекләрендә җәдитчелек дәверенең әйдәп баручыларыннан булган һәм төрле темалар буенча бик файдалы әсәрләр язып калдырган язучы һәм тәрҗемәче Каюм Насыйри да монда иде. Көне-төне кечкенә өстәл башында язып утырудан бөкресе чыккан, бер күзле һәм йончыган кыяфәтле бу әдипнең образы Мәрҗанинең күркәм һәм туп-туры образы янында бик сүнек һәм мескен булып кала иде... Тормышта бер-берсен сөймәгән бу ике акыл иясе, үләләр илендә дәгъвалардан, кинә һәм хөсетлектән азат булып, рәхәт һәм тыныч яталар. Нинди-нинди мәгърур һәм үзләрен генә яраткан байлар, гомерләрен сафсата сатып, схоластика өйрәнеп һәм өйрәтеп үткәргән, бер-берләрен чәкәләп торган бер төркем муллалар да монда күмелгән, һичбер төрле тавыш-тын юк.Көрәшләр, бәхәсләр, хирыслыклар, мин-минлекләр, комсызлыклар, хыяллар, планнар — бөтенесе арттa калган, юкка чыккан. Монда бөтен кеше дә рәхәт ята: кайгылардан, сагышлардан, хәсрәтләрдән котылганнар. Бары максатсыз, мәгънәсез, көчсез һәм беркемгә дә файдасы булмаган сукбай кебек йөрүче мин генә, бу дөньяның ваклыкларыннан, түбәнлекләреннән, пычраклыкларыннан, гауга һәм дәгъваларыннан котылган, чистарган бу якташларның хәленә кызыгып йөри идем...

**Тугрылыклы хатыным.** Һәр кич караңгы төшкәннән соң хатыным каравылчы будкасына миңа ашарга китерә, кеше игътибарын җәлеп итмәс өчен, мин яшәгән урынга, зиратның бер буш калган урыныннан, кыска юлдан килә иде. Элек зират яныннан да узарга курыккан хатыным, ул вакытларда кичке караңгылык төшкәч, каберстанның нәкъ уртасыннан узып йөрергә батырлык тапты. Болай гел-гел килеп йөрүләрдән соң аның үләләр иленнән курку хисе дә шактый кимегән иде бугай.

**"Печән сараенда".** Шимальдә һәм Кырымда киселгән үләнгә "печән" диләр, нинди матур төрекчә сүз! Беркөн безнең каравылчы шушы араларда шәһәрдә зур налетлар һәм эзләүләр булачагын хәбәр итте. Шуна күрә минем ул вакытта төннәрен өйдә (будкада) ятмыйча, тышта калуым яхшырак булачак иде. Бу кара хәбәр дөрес булып чыкты. Чөнки ул вакытта контрольләр, налетлар, арестлар һәм үтерешләр киң таралган һәм нормаль эшләр иде. Соңрак Русиядә киң таралган, зур территорияләрне биләячәк сөргеннәр фасылы әле башланмаган иде бугай. Төннәрен миңа урамда уздырырга кирәк, әмма кайда? Көндезләрен үткәргән каберстанда, гүр ияләре арасындамы? Моның да чарасы табылды. Өебезнең янында гына безнең каравылчы карамагына кергән печәнлек бар иде. Арестлар заманы узып киткәнчегә кадәр минем төннәрне анда уздыруым яхшы булачак. Кичке аштан соң шунда чыгып, төннәрен шактый суык булганга, толыбыма төренеп, колакларыма кадәр печәнгә күмелеп ятам. Шулай да, өшемәдем, рәхәтләнеп йокладым дип әйтә алмыйм... Аркамның каты кычытуыннан, печән исеннән иртәнгә таба башымда бер авырлык, тәнемдә сызлану тоя идем. Өшү һәм печән исе тәэсире астында булса кирәк, бик авыр, буталчык төшләр дә күрә идем. Минем Казанга кайту хәбәрем таралып, Чека агентлары эземә төшсәләр, төнге кунакларның бу печән сараен да тикшерәчәкләрен уйлап борчыла идем.

**Төнге дустым.** Бу печән сараенда тычкан һәм күселәр дә шактый иде. Ләкин мин аларның тавышларын да, кыштырдауларын да ишетмим. Сарайда минем төнге дустым бар иде, ул да булса, каравылчының бер почмакка бәйләп куелган, бик арык туры аты иде. Бу ат төннәрен тешләре арасыннан әллә ниткән тавыш чыгарып, печән чәйни һәм пошкыра иде. Аның тешләре арасыннан чыккан бу гыжылдау белән пошкыруы, печәнлектә һәм үләләр дөньясы белән якынлыкта минем япа-ялгыз булмавымны искәртеп, тынычландырып тора иде.

Көннәр уза торды. Кыш уртасы житте. Бу “капкын”нан чыгунын һичбер өмет чаткысы һаман күренми иде.

Жан коткару. Мондый өметсез рәвештә көннәр уза торды һәм, ниһаять, бер кич хатыным безнең будкага сөенечле хәбәр китерде. Иделнең икенче ягында 80 км лап ераклыкта Б. исемле өяз мәркәзеннән бер коммунист, партиясез иптәше белән берлектә, пар ат җигелгән тарантаска утырып, Казанга килгән. Бу коммунист минем хатынымның танышларыннан бер югары уку йортында укучы кызның якташы һәм кардәше, имеш. Хатынымның ризалыгы белән әлеге укучы кыз безнең “мәсьәлә”не ышанычлы коммунист якташына ачкан һәм “бу кешене үзегез белән алып, үз ягыгызга алып китә алмыйсызмы?” дип сораган. Коммунист, якташ кызның үтенечен кире какмыйча, риза булган, акча-мазар да сорамаган, бары бер шарт кына куйган: мин үз атым, арбам яки чанам (ел фасылының арба да, чана да кулланырга мөмкин бер вакыты иде) булып, шәһәр тышына чыкканчы, тагы да дөресрәге, Идел елгасының икенче ягына чыкканчы, алар артыннан үз атым белән барырга тиеш идем. Бераз авыр булса да, бу шартны без шатланып кабул иттек, ат-арба мәсьәләсен каравылчыга ачтык һәм бу эштә безгә ярдәм итүен сорадык. Ул кыска вакыт эчендә ат һәм арба табуның мөмкин булмавын (чынлап та шулай иде), үзенең печәнлектә миңа төннәрен иптәш булган, бар рухымны каплаган авыр тойгыларымны бераз җиңеләйткән, кабырга сөякләре тырпаеп торган арык туры атын һәм шул ук сарайның икенче почмагында янтаеп беткән иске шакшы чанасын сатып алырга тәкъдим итте. Каравылчының бу сәүдәсендә үз мәнфәгате дә бар иде, әлбәттә. Безгә никадәр изгелек эшләгән бу адәмне үпкәләтү яхшы түгел, шуңа күрә хәтерен саклау өчен билгеле бер сумма биреп, бу үләргә житкән атны һәм таралудан бик аз калган чананы сатып алырга мәҗбүр булдык. Каравылчы чананы бераз адәм рәтенә кертте. Арык атны исә, тиз генә, нинди дә булса юл белән симертү мөмкин түгел иде. Берәр рәсми кәгазьише дә булсын дип, каравылчының сандыгы төбендә яткан, патша заманыннан калган бер паспортны да алып, “һәр ихтималга каршы” дип, яшерен урынга тыгып куйдык. Бу паспорт буенча, мин бер надан авыл кешесе, игенче идем. Ул заманнарда һичбер документка фотография куелмый иде.

Көтелмәгән җирдән килеп чыгып, һич күрешмәгән килеш, безнең хәлне аңлаган бу яхшы күңелле коммунист безнең өчен “жан коткаручы” сыйфатында иде.

**Уңайсыз төн.** Хәзер датаны төгәл әйтә алмыйм инде. Чана куллану жайлырак булгач, димәк, кыш үз хокукларын файдалана башлаган иде инде. Кар ява башлаган, кечкенә инешләр боз белән капланган заман иде, кар җир йөзен бөтенләй үк капламаса да, урыны-урыны белән кар җәймәләре ята иде инде. Ике фасыл арасында була торган юл өзеклеге вакытында атларын арбага жиккәннәр дә, чанага җиккәннәр дә бар иде. Мин, арбам булмаганга, чанага утырачак, мине “капкын”нан коткарасы кешеләр исә арба белән китәчәк иде. Юлчылар, бу көнне бик иртә кузгаласыларын әйтеп, минем дә соңгы төнне өйгә үткәрүемне теләделәр. Миңа үз өемдә калу бик куркыныч булса да, ни чара ки, хәлләр моны таләп итә иде.

Кузгаласы көн гарәфәсендә, хатыным, теш табибы булганлыктан, иягемне зур ак бәз белән бәйләп, мине, тешләре белән бик интеккән бер крестьян кыяфәтендә, чанага утыртып, Кабан күле буендагы шактый аулак урындагы өебезгә алып килде. Ул төнне өемдә калсам да, печән сараенда үткәргән төннәрем белән чагыштырганда, аеруча авыр, газаплы бер төн булды: чишенмичә, киенгән килеш утырдым, күзгә йокы керми, теләсә нинди тавышка да колак салып, даими шик-шөбһәдә булдым. Ишек кагу белән, шундук урынымнан сикереп торып, иске-москы ташлый торган урын, тычкан-күсе оясы булган чормага качарга хәзер утыра идем. Хатыным да миннән ким борчылмады. Таңны тыныч кына аттырдык, бер “вакыйга” да булмады, бер иркен сулыш алып куйдык. Хәзер аяк өсте чәй эчеп, юлга чыгар вакыт житте.

**Юлчылык.** Сөйләшенгәнчә, кеше күзенә ташланмас өчен, ат караучы урынына мосафирларның пар атында мин китәчәк, аларның ат караучысы минем чанага утырып, безнең арттан барачак иде. Атлар жигелде. Хатыным һәм улым белән ишегалдында түгел, өйдә хушлаштым. Тагын аерылабыз, кайчан күрешәсебез,

кайда табышасыбыз билгеле түгел. Ул минутта гаиләмнән тагын бер тапкыр аерылу тудырган сагыш белән "капкын"нан котылу биргән сөенеч икесе бергә буталып, әллә нинди хисләр хасил итте.

Мин күзлек кия идем. Күзлекле ат тотучының сәер күренәчәген уйлап, күзлекне салырга карар бирдек. Арбаның алгы өлешендә ат тотучы өчен махсус аерылган югары урынга менеп утырдым һәм дилбегәне кулга алдым. "Печән базары"ннан һәм "Инжилчеләр урамы"ннан уздык. Бу төшләрдә халык күп булырга тиеш булса да, вакытның бик иртә булуы аркасында, тыныч иде. Тирә-ягымны һәм алдымны күрсәм дә, күзлегемне салгач, бөтен начар күрүчеләр кебек, үз-үземне каушаган кебек хис итәм. Үз-үземә әллә ничек хужа түгел кебек. Ни булса, шул булды, Идел ярына якынлаштык, әмма каршы якка чыкмыйча торып үземне тәмамы белән "капкын"нан котылган саный алмый идем. Каршы якка паром алып чыгачак. Ләкин ни күрик: зур елга өсте куе томан белән капланганлыктан, бездән алда килгән байтак юлчылар, атлар, арбалар, томан таралганны көтеп, жыелып торалар. Без дә алар кебек тукталырга мәжбүр булдык.

Ниһаять, томан пәрдәсе калыкты. Паромга мендек һәм каршы якка кичтек. Менә шуннан соң гына үземне "капкын"нан котылган итеп хис иттем. Һәм Казаннан икенче тапкыр, көпә-көндез, бөтен кеше күз алдында кача алуыма горурланып та куйдым. Ослан тавыннан Казанга соңгы тапкыр, күчерелмә мәгънәдә әйтсәк, югарыдан карадым. Бу уңышыма чынлыкта хатыным Газизәнең күп көче керүен дә онытмадым, әлбәттә.

**... Коммунист юлдашның өендә.** Мин, Казан "капкын"ннан котылуыма бик шат булсам да, Казаннан бик еракларда булмаган кечкенә шәһәрдә бик озак кала алмый идем. Тагын да ераккарак китәргә кирәк. Тик документсыз юлга чыгып булмаганга, бу иске шәһәрдә яшәп калырга мәжбүр булдым. Кечкенә мендәрем эченә яшерелгән, иске дәвердән калган һәм минеке булмаган таныклыктан башка бер кәгазем дә юк иде шул. Бу кечкенә шәһәрдә бер төрле рәсми кәгазь дә сатып алырга мөмкин түгел. Форсат көтеп ята башладым. Яшәгән өем, Казандагы каравылчы будкасыннан аермалы буларак, бик "комфортлы" булганга, бераз ял итеп алырга да мөмкинлек туды. Миңа карата авырыксыну хисе дә сизелми иде.

Өй хужасы еш кына самогонка куллана иде. Яхшылап сөзелмәгән, авыр бер янган ис биргән "ялганчы водка"ны бер дә авызыма аласым килмәсә дә, хужаның кәефен күрү өчен, ашаганда бер-ике йотым миңа да эчәргә туры килә иде...

**... Симбирск шәһәренә таба.** Беркөнне мине Б. шәһәреннән ерак урнашкан бер авылга кунакка алып килделәр. Мин кунак булган өйнең хужасы кечкенә бер сабын заводы тота иде. Алардан кем булуымны яшермәдем. Өй хужасының олы улы мине ишетеп белә икән. Кайчандыр һәр көнне үз исемемнән язып, һәр санда исеме чыккан газетачы түгел идеммени мин? Бу ачык фикерле кешегә "документ проблемасын" ачтым. Моңа каршы ул: "Сез Сембергә барыгыз. Анда фәлән урамда, фәлән номерлы өйгә тукталыгыз. Минем исемемне әйтегез. Мин Сембергә барганда гел шуларга тукталам. Бу араларда минем дә анда барасым бар, мине шунда көтеп торыгыз. Мин сезгә завод өчен чимал алырга бара дигән бер кәгазь китерермен, шуның белән эш бетәр", диде. Суга төшкән саламга ябыша" дигән кебек, мин дә бу сүзләргә канатланып, һәм, Б. шәһәренә кайту белән тиз арада бер арба тотып, Идел буендагы Симбирск шәһәренә таба юлга чыктым. Араба юлчылыгы вакытында "документ" сорап интектерүче булмаячак иде.

Инде яңадан Идел ярларына китеп барам һәм бу мәжбүри сәяхәтем вакытында Идел-Волга бассейнындагы борынгы 9 губерна мәркәзләренең тагын берсен күрәчәк идем.

**Сембердә "документ" көткәндә.** Сембергә бәла-казасыз килеп життем. Әйтелгән рус өен табып, безгә вәгъдә ителгән "документ"ны көтә башладым. Сабын заводы хужасыннан бер хәбәр дә юк иде. Вакыт уза торды. Өй хужаларының миннән шикләнә башлауларын, хәтта кызыллардан качып, Сибириядә Колчак идарәсе астындагы территориядә яшәгән бер мөгаллимгә охшатуларын сизә башладым. Алай да, рәхмәт яугырлары, полиция идарәсенә күрсәтү өчен миннән

паспорт-фәлән сорамыйлар иде. Бу шикләнүне сизгәч, һәм "фабрикант"ның килүеннән өмет өзгәч, башка бер урынга күченергә булдым. Эч пошудан, хатынымның Казанда училищеда бергә укыганда дус булган ике рус кызын эзләп таптым да, гаиләләрендә чәй янында сөйләшеп утырдык.

**"Документ" артыннан.** Сембердә байтак кына мөселман яшәвен белсәм дә, беркемне дә танымый идем. Кемгә барып егылырга, кемнән ярдәм сорарга? Шимальле мөселман төрекләре арасында имамнарның күбесе, бәгъзе мәмләкәтләрдәге аз санлы поплар кебек, уяу һәм айнык фикерле кешеләр иде. Һәрчак мондый имамнарга ярдәм сорап мөрәҗәгать итү файдасыз булмый торган иде. Шуңа күрә мин дә, элек исемен ишеткәнем бар һәм яшькә яшь булырга тиеш дип уйлаган бер имамның өенә киттем һәм, һич шикләнмичә, аңа кем булуымны, чын исемемне сөйләп, читен хәлемне, аннан чыгу өчен бер "документ" кирәк булуын аңлаттым. Имам әфәнде мине дикъкатьле тыңлаганнан соң, бераз уйланып утырды һәм болай диде: "Газизем, мин үзем бернинди дә документ табып бирә алмыйм. Фәкать монда З. исемле берәү бар. Бик уяның һәм һәр нәрсәдән хәбәрдар бер кеше, вакытында Петербургта мөәзинлек итте. Син торып тор, башта аның белән үзем сөйләшеп карыйм һәм икегезне таныштырыйм", — диде.

Имам әфәнде, бу Петербург мөәзине белән күрешеп, аның белән мине таныштырды. Төрек газеталарын укып барган З. әфәнде мине ишетеп белә икән. Мин аңа Бакуга китәргә теләвемне һәм шунлыктан документ табу кирәклеген сөйләдем. Чөнки Астраханьга һәм Бакуга барганым бар, андагы юл шартларын бераз белә идем. Аннан соң башка бер якка таба китәргә уйлый идем. Грузиягә китә алмасам, Иранга чыга алырмын дип ышана идем. Өстәвенә, әйткәнемчә, әйләнеп кайту өмете белән Бакуда бер сумка кием-салымымны да калдырган идем...

Озын буйлы, кызгылт-сары чәчле З. әфәнде хәлгә керә торган кешегә охшаган һәм миңа кулыннан килгән кадәр ярдәмне күрсәтергә тырышачагы сизелә иде. Миңа карата эшләгән яхшылыкларын, күрсәткән якынлыгын мин һәрвакыт татлы бер хатирә буларак күңелемдә сакладым, һәрвакыт әҗерен кайтарырга хыялланып яшәсәм дә, кызганычка каршы, насыйп булмады...

З. әфәнде "тырышып карармын", диде дә китте. Аның китерәчәк хәбәрен түземсезлек белән көтеп мин мәзкүр имам янында калдым...

**..."Яңа хезмәтем".** Икенче көнне имам өендә З. әфәнде белән янадан очраштык. Ул яхшы хәбәрләр китергән иде һәм безне бик сөендерде: Бакуга булмаса да, Петроградка бару өчен бер "документ" булачагын сөйләде. Чынлыкта минем өчен китәчәк җиремнең Баку булуы шарт түгел иде. Максат Симбирскидан ерагаю гына түгелме соң? Баку булмаса, Петроград булсын, миңа димәгәе! Ә менә яңа "хезмәтем" нидән гыйбарәт соң?

Сембердә Х. комитетының бер чиновнигы булган мин —"Абдуллаһ Рәхимов" камыт-сбруя, умарта төшерелгән мөһер сугылган һәм Х. комитеты тарафыннан Петроград янындагы Любань станциясенә, белмим, нинди дер комитет исеменә җибәрелгән бер йөк вагонының озатучы-кондукторы сыйфатында юлга чыгачакмын. Миңа бу комитеттан таныклык урынына йөри торган бер кәгазь һәм кулыма Петроградта бер инженерга тапшырылачак хат та бирделәр. Хәзер инде мин, "иясез шатлык" булып йөрүдән туктап, "дәүләт хезмәткәре" булдым. Камыт-сбруя һәм умарта! Боларның нинди сәбәп белән бер вагонга тәялүен хәзер дә күз алдыма китерә алмыйм. Һәрхәлдә, монда үзләре генә аңлаган бер "хикмәт" булса кирәк... Юкса, мине Сембердән ераграк җибәрү махсус оештырылган бер эш түгелдер бит инде? Кем белсен!

Сембер станциясендә комитетның бер хезмәткәреннән вагонны кабул итеп алдым.

**Сембердән хәрәкәт итә башлау.** Мин хәзер Сембердән Любань станциясенә китеп баручы бер "дәүләт хезмәткәре" идем: кесәмдә урак-чүкеч тамгалы мөһер сугылган, үлсәң дә укып булмастай ике имза куелган "рәсми документым" һәм "Дәүләт чиновнигы" булуымны бөтен барлыгы һәм авырлыгы белән исбат итә торган, рельслар өстендә төп-төз басып торган вагоным бар иде. Вагон өстендәге көчкә укылышлы, сөртелеп беткән цифрлар кесәмдәге "документка" да язылган

иде. Мин инде әле кичә генә Казанда каравылчы будкасының идәнендә тар җирдә аунаган һәм берничә кичен печән сараенда уткәргән мескен түгел идем. Хәзер Петроград кебек мөһим мәркәзгә таба рәсми эш белән баручы, бөтен хокукларга ия хезмәткәр — "гражданин Абдуллаһ Рәхимов" идем. Миңа хәзер кем кырын карый алсын!

Сембер станциясендә миңа тапшырылган вагон мөһерләп ябылган булганга, миңа үземә бу вагон тагылган поездның башка вагонына утырырга кирәк иде. Ләкин вагонны һичбер вакыт күздән ычкындырмаска кирәк. Кичкә таба кузгалып киттек. Идел буйларыннан ераклаша башладык. Сембер шәһәре зур Мәскәү-Самара тимер юлы өстендәге Инза атлы станциядән 100 км озынлыктагы тармагының беткән урынында, Волганың уң ягына урнашкан иде. Соңрак шәһәрнең бераз түбәнрәк ноктасыннан башлап, Волга-Бөгелмә линиясе исемле яңа бер юл төзелгәч, Сембер, Самара-Уфа (Сибирия) тимер юлына да тоташа.

**Вагонымны ничек йөретим?** Инза станциясенә килдек. Анда безнең кызыл вагоннар таккан поездыбызны тараттылар. Минем мөһерле вагонымны да күз алдымда, "ашыгыч түгел" дип, тупикка кертеп бастырдылар. Протестларым ярдәм итмәде: тегендә-монда барып, мөрәҗәгать итсәм дә, нәтиҗәсе булмады. "Мәскәүгә таба бара торган поезд юк!" яки "синең вагоныңнан да иртәрәк китәргә тиешле ашыгыч вагоннар бар", дип, кире боралар иде. Чарасыздан Инза станциясенең зуп-зур III класслы көтү залында такта сәке өстендә кунарга мәҗбүр булдым. "III класслы" дигәнем, әлбәттә, иске заманнар буенча. Югыйсә, минем сәяхәтем вакытында "класс" аермалары инде калмаган иде. Ягъни сәяси һәм икътисади тормышта класс, сыйныф аерымлыгы калмаган кебек, тимер юлларда да класс аермалары бетерелгән иде. Иртәгесе көнне көчкә вагонымны Рузаевка юнәлешендә китәчәк бер поездга тактыра алдым. Үзем исә "вазифа белән баручы хезмәткәр" сыйфатында кондуктор урнашкан сервис вагонына җирләштем. Рузаевка станциясен бәлки аз гына сез дә хәтерләрсез. Сибириядән Казанга кайткан вакытта мин казачий делегатлар вагоныннан төшкәч, анда бер платформада таулар кебек төялгән печән вагоннарының берсенә менеп утырган һәм шул йөк өстендә юлга чыккан идем. Рузаевка юлларны тоташтыручы бер станция булганга күрә, поездның анда бармыйча, башка китү мөмкинлеге юк иде. Поезд анда тагын туктады һәм безнең мөһерле вагоныбыз тагын бер читкә чыгарып куелды. Тагын чабу, тагын баш ору, тагын талашулар... Монда тагын бер яки ике көн калырга мәҗбүр идем. Безнең бичара вагоныбызның поездан ычкындырылып, бер якка алып ташлануы, бөек станцияләрендә генә түгел, уртача һәм кечкенә тукталышларда да еш булды. Шуның өчен Мәскәүгә кадәрге нормаль ике көнлек юлда ун көннән артык вакытым узды...

**Ниһаять, Мәскәүдә.** Мәскәүдә берничә вокзал бар. Безнең поездыбыз кергән вокзалның исеме Казан вокзалы иде. Чөнки Казанга илтүче тимер юлның башы монда иде. Вокзал бинасында Казандагы Сөембикә манарасына охшаган бер манара куелган. Ул миңа Казанны искә төшереп, күңелемдә сагыш белән шатлык катышкан бер хис уятты: Казаннан, гаиләмнән аерылганга кайгыра, "капкын"нан котылуыма сөенә идем. Кешенең күңелендә моның ише бер-беренә капма-каршы һәм буталчык тойгыларның бергә яшәвенә гаҗәпләнмәгез.

Мин Мәскәүгә ике революция арасында хатыным Газизәнең бу шәһәрдә Кавказдан Шәмси Әсәдуллаев мәктәбендә укыткан вакытында 1913 — 1914 елның кышында бер тапкыр Казаннан килеп киткән идем. 1917 ел революциясеннән соң исә беренче килүем. Тик бу килү булмыйча, китеп бару булса да, иркенләп йөри дә алмадым. Чөнки эчендә "камыт-сбруя" тутырылган "мәшһүр" вагоным сыртымдагы бер авыр йөк булып тора, ул йөкне ташлап, юлымны дәвам итә алмый идем. Әлбәттә, мин Мәскәү вокзалындагы вагонымны "язмыш кулына" калдырып, бу зур шәһәрнең бер-берсен танымаган халкы арасында буталып, ялгызым гына да "юкка чыга" ала идем. Мине кем эзләтсен! Сембер комитеты, бер укымышлыга Абдуллаһ Рәхимов исеме астында ялган документ ясап, эченә камыт-сбруя төялгән вагонны аңа тапшырдык, ул кеше кайдадыр юкка чыкты, ничек тә булса, бу кешене тотып, безгә бирегез, дип газеталарда игълан бастыра алмый бит инде. Ләкин Мәскәү кебек шәһәрдә вагонымны ташлап, качып китү минем акылыма сыймый иде. Әлеге мөмкинлекне мин хәзер

генә уйлап, Сембер комитетындагы начальникларның ни кадәр саф күңелле булуларын аңлап утырам. Ул вакытта минем башымда сыртыма авыр йөк булган вагонны ташлап качу фикере бөтенләй юк, бары бу вагонны башта Казан тимер юлыннан Николаевская тимер юлына күчерү һәм Петроград юнәлешендә баручы берәр поездга тагу идеясе генә бар иде. Чынлыкта мине Петроградка алып баручы бу вагон исә минем кайгыртуларымнан хәбәрсез, Мәскәүнең бер тупиГында басып тора иде. Ул суык һавада бал кабагы өшерме, мөһерен жимереп, камытларымны урлап бетермәсләрме — минем хәсрәтләремне вагон белми иде, әлбәттә.

Вокзалда мин мөрәжәгать итмәгән бер чиновник, бер начальник калмады. Ниһаять, вокзал территориясендә түгел, ә шәһәрнең эчендә моның ише эшләр белән шөгыльләнгән һәм мондый мөшкел хәлләрдә ярдәм иткән бер "комитет" булуын аңлаттылар. Адресын алып, шунда киттем. Комитетның начальнигы яшь кенә бер хатын иде. Документымны күрсәттем, зар-моңымны аңлаттым, вагонымда өшердәй әйберләр булуын сөйләп, Петроградка таба китәчәк берәр поездга вагонымны тагарга ярдәм итүләрен сорадым. Тик шәхесе белән чекистларга тарткан, бик тырыш кеше кыяфәтен китереп утыручы ясалма бюрократ хатынның боларга әллә ни исе китмәде, акланып, булыша алмавын әйтте. Шулай итеп, безнең эшебез Алла кулына калды. Вагонны күздән ычкындырмау өчен, станция тирәсеннән китмим, шәһәрдә йөри алмыйм. Кичләрем вокзалның көтү залында, каян килеп, кая барасылары, нәрсә көткәнлекләре, нигә, нилектән көткәннәре миңа караңгы булган кешеләр төркемендә уза иде. Көндезләрен исә үзем белән йөрткән чәйнигемә кайнар су тутырып, эченә хатыным биргән "такта чәй"не бер кисәк салып, көтү залының бер пычрак өстәлендә чәй эчеп, карынымны туйдыра идем. Ул көннәрдә, чәй тузаныннан ясалган мондый кирпечле чәйнең чыраен да күрмәгән кайберәүләр, миңа бик кызыгып карыйлар, шундый кытлык көннәрендә мондый дефицитны каян алуымны сорыйлар иде...

**Мәскәүдән хәрәкәт итү.** Тырыша торгач, ниһаять, вагонымны бер поездга тактыра алдым. Үзем башка бер вагонга утырып, соң ноктам булган Любаньга таба юлга кузгалдым. Инде туры Петроград юнәлешендә, иске һәм яңа башкалалар арасындагы Николаевская тимер юлының рельслары буйлап киттек. Бу тимер юл линиясенә "Николаевская" исеменең бирелүе патша Николай I заманыннан бирле килүен күрсәтә, 1851 елның 14 ноябрендә, димәк, Кырым сугышы башланырга 2 ел алдан эшли башлый. Бу —Русиядә төзелгән беренче озын тимер юл линиясе (беренче кыска тимер юл Петербург белән Царское село арасында ачылган). Озынлыгы — 649 км булып, төп-төз, парлы юл. Советлар большевиклар революциясенең 5 еллыгы уңаеннан, димәк, 1922 елда бу юлның исемен үзгәртеп, "Октябрьская" исемен куйдылар. Кайберәүләр моның бик кинаяле алышыну икәнен сөйлиләр: бу Октябрь юлы белән (революция) Николайлар (патшалар) юлының берләшүен күрсәтүче бер символ, диләр... Моның нәтиҗәсе буларак, бу ике юлның ике ахыр нокталары булган Мәскәү һәм Петербург вокзалларының да исемнәре үзгәргән.

Ниһаять, поезд оешып бетте, безнең вагон да аңа тагылды. Киттек. Юлда әһәмиятле бернинди "вакыйга"га очрамыйча, Сембердән чыгуыма нәкъ унбиш көн булгач, Любаньга килеп житеп, жиңел сулыш алдым.

Хәзер инде Любаньнан Петербургка барып, Сембер комитетыннан бирелгән хатны тапшырасы инженер У. ны эзләп табу кирәк. Любань станциясе Петербургтан болайга таба 75 км ераклыкта булса да, алайга таба поездлар йөри һәм мондый шәһәр яны поездларында документ-фәлән сорамыйлар иде. Моны миңа Сембердә вакытта ук әйткәннәр, ягъни бер тапкыр Любаньга килгәч, ул тирәләрдә документсыз да йөрергә була дигәннәр иде. Бер пригородный поездга утырып киттем. Эзләгән инженер У. ны таптым һәм хатны бирдем. Озын буйлы, әдәпле холыклы бер кеше иде: иске режим дәвереннән калган бер интеллигент булуы күренеп тора. Бергәләп кире Любаньга кайттык. Вагонның мөһерен ватып, хатта язылган буенча камыт-сбруяларны һәм бал кабагын кабул итеп алдылар, бернинди житешмәүчәнлек булмады. Миңа хәтта күпмедер микъдарда аяк ялы да бирделәр. Хәлбуки, мин үзем бу "хезмәтем" өчен эш хакы-мазар көтмәгән идем. Чөнки бу вагон аркасында мин Идел буеннан киттем һәм Фин култыгына якынлаштым, болар минем өчен житәрлек дәрәҗәдә "эш хакы" тәшкил итә иде...

... Вагонны тапшыру эше беткәч, мин янадан пригородный поезд белән Петроградка киттем. Французлар әйтмешли, "вакытның якасыннан тотып", бераз анда калырга тели идем. "Бераз" дидек, әмма күпме вакыт үтәчәк, бу минем кулымда булмаган кебек, аның бик озак булмавы да минем өчен хәерле иде. Барыннан да элек, мин бик аз белгән бу зур шәһәрдә бара алырдай бер җир табарга кирәк иде. Семберле 3. әфәндедән алган адрес белән электән дә бераз таныш булган имам Лотфи Исхакый әфәндене эзләп таптым. Ул шәһәрнең Адмиралтейская дигән районында Серпуховская урамында өч бүлмәле кечкенә бер квартирада яши иде.

**Имам Лотфи Исхакый.** Моннан күп вакытлар элек Ураллар янындагы Троицк шәһәрендә "Хезмәт" китап магазинында бераз гарип кыяфәтле бер кеше белән таныштым. Озын буйлы, әфә мыеклы, сакалсыз, башына бәрән тиресеннән фәс тибындагы бер башлык кигән, өстенә бүре тиресеннән тегелгән толып салган, 30-31 яшьләрдәге, күзләрендә зәкилек билгеләре җемелдәгән бу адәм бераз җилбәзәк һәм кешедән көлүче кебегрәк күренә иде. Бу, ул вакытта хөррият иле саналган Мисырдан яңа һәм алдынгы фикерләр алып кайткан казанлы төрек яшьләреннән берсе иде. Аны миңа Лотфи Исхакый дип таныткannar иде. Аның белән беренче очрашуым шулай булды.

**Икенче очрашу.** 1914 елның җәендә бер газета хәбәрчесе сыйфатында Петербургка баруымда Лотфи Исхакый белән тагын бер очраштым. Ләкин ул вакытта бу кеше миндә беренче тапкыр Троицкида очрашу вакытында калдырган тәэсирне кабатламады. Ике арада 15 еллап вакыт узган иде. Ул элеккеге матурлык-көязлеген бөтенләй югалткан, тышкы кыяфәтендә, хәрәкәтләрендә һәм сөйләшүендә дорфалык, тәкәллефсезлек күзгә ташланып тора. Петербургта үткәргән вакыты эчендә русчасын камилләштергән, төрекчә сөйләшкәндә дә еш-еш русча сүзләр катыштыра иде. Моның белән бергә, аның холык-фигылендә диндарлык, догматизм да сизелә. "Лях татарлары" дигән, ләкин төрекчә телне оныткан мөселманнар арасыннан Гайшә исемле бер укытучыга өйләнгән иде. Хатыны ире белән бары тик русча гына аңлаша алганга, Исхакыйның русчасы алга китүенә, бәлки, бу да ярдәм иткәндер. Ул көннәрдә Исхакый Казанская урамындагы бер мәчеттә имам һәм мөселман хәйрия җәмгыяте ачкан биш сыйныфлы мәктәптә мөдир һәм мөгаллим булып, хатыны да бу мәктәптә рус теле укыта иде. Исхакый Петербургта югары уку йортларында укыган төрек укучы-студентлар белән дә аралаша. Думадагы мөселман сайлаулары белән бәйле очрашуларда була, кайчагында "Шәрекъ кичәләре"н оештыру эшенә дә катнаша иде.

**Имин урын**. Лотфи әфәндегә, Семберде бирелгән адрес буенча килүемне һәм өендә бераз кунак булу мәҗбүриятендә калуымны сөйләдем. Минем бу үтенечемне ул шик-шөбһәсез генә кабул итте. Даирәсенең бер бүлмәсендә югары инженерлар мәктәбе студентларыннан бер төрек егете торса да, Исхакыйның ялгызлыктан интеккәне сизелә иде. Ул дөнья күргән, җиһан гизгән, төрле кешеләр белән очрашкан, кеше хәлен аңлый белүче, үзеннән түбәннәргә хәер булу белән бергә, мине үз янына алуында бу ялгызлыкның һәм эч пошуның да бераз роле булды бугай, дип уйлыйм. Ни булса да, минем өчен ул вакытта бер нәрсә мөһим иде, мин бу өйдә бераз вакытка имин урын таптым.

Бу безнең өченче очрашу иде. Икенче очрашуыбыздан 6 ел узган инде. Бу юлы каршымда 6 ел элек күргән хәрәкәтчән, сүзчән, урта яшьләрдәге Исхакыйның бары хатирәсен генә,20 ел Троицкида күргән әфә мыеклы, кискен карашлы, җилбәзәк кыяфәтле яшь Исхакыйның бары күләгәсен генә күрдем: картайган, чүккән иде, кечкенә генә бөкресе чыккан, чәчләре һәм очлары киселгән мыеклары агарган, үзе бик зәгыйфь, ябык күренә иде, еш-еш йөткерә, дәвамлы үлекләп шешкән геммороен күптән түгел генә кистергән, әлеге чиренә җитди игътибар итмәве аркасында аз канлылыкка дучар булып, шуның нәтиҗәсендә сулыш тарлыгы белән интегә иде. Хатынынnan да аерылган иде...

**Сөхбәтләр.** Лотфи әфәнде белән бәрабәр яши башладык. Бу даирәдә миннән элек яши башлаган студент иртүк чыгып китә, кич кайта иде. Кайда ашап-эчүе билгесез. Бәлки мәктәптә студентлар өчен "очсыз" бирәр буфет булгандыр.

Исхакый белән без тиз аңлаштык. Өйдәшемнең сихәтлеге бозылса да, башы урынында иде: элеккеге үткен теллелегеннән, шаянлыгыннан күп нәрсә

югалтмаган. Көн буена сөйләшеп бетмәс-төкәнмәс сүзләребез бар иде. Лотфи әфәнде Шәрекъ дөньясындагы "тәхсиле-голум" максаты белән йөргән вакытларында башыннан кичкән мажараларны, күргән яки ишеткән вакыйгаларны, очрашкан кешеләре турында бераз сагыш катыш горурлык белән сөйли иде. Аерым кимчелекләренә карамастан, бу хикәяләр "вакыт үтерү" өчен безгә гел ярап тора иде...

**... Авыр көнкүреш.** Сүздә элеккеге мактаулы "Шималь пайтәхетендә", хакыйкатьтә исә бер кытлык һәм хәерчелек илендә яши идек. "Хәрби коммунизм" дәверендә идек: магазиннар, кибетләр буп-буш, бөтенесе бикле. Кайбер азык-төлекне Сенная диелгән мәйданда, бөтен налогларга һәм җәзаларга карамыйча, спонтан корылган "бет базарында", ул да итәк астыннан һәм ун бәясенә, алырга була иде. Ләкин мин кулымда һичбер төрле рәсми кәгазем булмаган (Сембердә алган документ белән, әлбәттә, инде яшәп булмый иде) һәм "беркайда да теркәлмәгәннәр" группасы кешесе булганга, моның ише "итәк асты" сәүдәсенә керешергә дә батырчылык итми идем. Беркайда да эшләмәгәнгә, "комитетлар" да миңа икмәк карточкасы бирә алмыйлар. Совет тәртипләре буенча, "эшләмәгән — ашамый!" хөкеме бар. Шунлыктан мин бер телем арыш ипиенә дә интегә идем. Ягъни социализм Русиясендә минем икмәк ашарга хакым юк иде. Рәхмәт яусын, имам әфәнденең күршеләре арасында үзләреннән артканнымы яки берничә урыннан алганнымы, икмәк сатучылар бар иде, мине ят күзләрдән саклау өчен, алардан икмәкне Лотфи әфәнде үзе барып ала иде.

Авыру имамга кайбер мөселманнар кайчагында сөт, ак май һәм, белмим, әллә каян табып, берәр кисәк бодай икмәге дә китергәлиләр иде. Сөт дигәнен күтәреп эчәр микъдарда иркен булмыйча, бары чәйгә салу өчен генә җитә иде. Аны бары имам өчен генә тота идек, минем чәемә сөтнең тамчысы да төшми иде. Авыру кешенең өлешенә керергә минем бер хакым да юк иде. Мин башлыча арыш икмәге һәм чәй белән канәгатьләнә идем. Казаннан алып килгән "такта чәем" дә бетеп китте...

**Ягулык кытлыгы.** Шулкадәр зур башкалада ягулык кытлыгы да хөкем сөреп, торган җиребез бик суык иде. Ләкин өй хуҗасы өчен моның әллә ни әһәмияте юк, чөнки ул сөргеннән алып кайткан, йоны тыш тарафка каратып бүре тиресеннән тегелгән толыбын бөркәнеп, караватында ятар, тормас иде. Тик ютәле бер дә кимеми, бигрәк тә мәхәллә халкыннан берәр хәл белергә килүче булса, бу ютәлнең темплары тагын да артып китә. Монда, табигый, бераз "сәясәт" тә бар иде. Иртәләрен бүлмәбез шул кадәр суына, имамыбыз, суык су белән битен юудан куркып, бармакларының очларын гына чылатып, күзләрендәге эренне сөртеп ала иде...

**Яшәсен ат ите!** Безнең өчен иң бөек бәйрәм көн шулпа пешергән көн була иде. "Бернинди дә кибет эшләмәгәндә, ни шулпасы ул?" диеп сорарсыз. Бу сорауның җавабы болай: шәһәрдә һәм шәһәр тирәсендә ул вакытта шактый күп мөселман бар иде. Боларның кайберләре ит һәм шулпа пешерү өчен берәр гарипләнгән ат сатып алып, яшерен генә суялар һәм итне үз араларында бүлешәләр иде. Кайчак бу сөенечле хәбәрне безгә дә җиткерәләр, бераз ит ала алачагыбызны хәбәр итәләр иде. Мин, чакырылган җир никадәр генә еракта булса да, бар көчемә чабып барып, ул көннәрдә иң кыйммәтле нәрсә булган ит кисәген куеныма саклап, өйгә алып кайта идем. Искиткеч тәмле майлы шулпа пешерер идек. Бу көн безнең өчен уразаны бозып тору, бер бәйрәм була торган иде. Бәлки югарыда язганнарым хәтерегездәдер: Казан өлкә төрмәсендә ятканда да, мин хатынымның төрле юллар белән миңа җибәргән ат ите белән җан асраган идем. Монда да безгә азмы-күпме яшәргә көч биргәне ат ите булды.

**"Ашка йөрүләр".** Заманына күрә хәлле генә булган сәүдәгәр мөселманнар имамны кайчак өйлә һәм кичке ашка чакыргалыйлар иде. Мондый хәлләрдә Лотфи әфәнде чакырган кешегә: "Яхшы, әмма мин бер үзем генә түгел, минем кунагым да бар, нишлим?" дигәч, теге кеше: "Зарар юк, ул да килсен!" дия иде. Китәр идек, кеше төсле тамагыбызны туйдырыр идек. Казан якларыннан килеп, "вакытлыча" монда яшәгән һәм яшерен рәвештә сату-алу белән шөгыльләнгән (бүгенгечә әйткәндә, спекуляция белән) бер М.Й. бар иде, ул табынына заманы өчен кыйммәтле, дефицит нигъмәтләр чыгара торган иде. Чит кешеләр өчен

мин бары Лотфи әфәнденең кунагы идем. Минем кем булуым андагы мөселманнардан бары ике-өч кешегә генә билгеле, артык ачылудан файда юк иде.

**Капкынга төштек.** Шул рәвешле, мәгънәсез һәм оят булса да, тормышыбызны ару гына күреп ятканда, һич көтмәгәндә күнелсез бер хәлгә очрадык. Бу болай булды. Беркөнне кич өйгә кайтуымда өйдә тик студент егет кенә иде. Лотфи әфәнденең бу вакытта өйдә булмавы нормаль хәл түгел иде. Сорадым. Студент өй хуҗабызның тыкрыкта яшәгән Мөхәммәдшаһ әфәнделәргә китүен һәм тиз кайтачагын сөйләде. Чыннан да, тиз кайтырга тиеш иде, чөнки өстәл өстендә самавыр да кайнап утыра, чәй дә тәмләнгән иде. Шактый озак көткәннән соң, хуҗабызның кайтуына өмет өзеп, теге өйдә дә яхшы чәй табыны корганнардыр дип, имамның өйгә кайтып тормаячагын уйлап, бу "тәмле чәй табынына" һәм чәй янындагы татлы әңгәмәләргә катышырга теләп, мин дә Мөхәммәдшаһ әфәнденең өенә киттем. Звонокка бастым. Ишекне бер егет ачты һәм мине русча "пожалуйста!" дип каршылады. Мин аны өй хуҗасының кунакларыннан берсе дип уйлап, шулай ук русча: "Исхаков мондамы?" дип сорадым. Рус бу сорауга: "Димәк, сез Исхаковны таныйсыз?" соравы белән җавап бирде. Мин дә: "Да", дип җавап бирдем. Рус мине эчкә кертте. Ни күзләрем белән күрим: танышларымнан берничә Петроградлы төрек һәм дә ки безнең имам Лотфи әфәнделәр бер бүлмәдә арестованный хәлдә утыралар. Миңа ишек ачкан рус егетенең бер-ике иптәше дә бар иде. Лотфи әфәнде, мине күргәч:"Ни җәһәннәмемә килдең?" диде. Мине дә "тәмле чәй табынына" утыртасы урынга, тотылган якташларым янына куштылар. Андагы рус егетләре Чека хезмәткәрләре булып, әлеге террор оешмасы тарафыннан бу өйдә тозак корып, теләсә кемне каптырып утыралар иде. Менә бу тозакка имам әфәнде белән мин дә төштек. Теге өстәл өстендә калдырып киткән самавыр кайнап, студентыбыз да көтә-көтә арып беткәндер. Монда исә безнең имам буыла-буыла ютәлләп, үзенең бик авыру икәнлеген әйтеп, аны җибәрүләрен башкалар да сорый иделәр. Мәрхәмәтсез һәм имансыз чекистлар бу юлы һич тә көтелмәгән җирдән мәрхәмәт күрсәтеп, Лотфи әфәнде дустыбызны җибәрделәр, хәтта адресын алырга да уйламадылар. Ул да, ютәлли-ютәлли, чекистларга рәхмәт әйтеп, якындагы өенә юнәлде. Мин исә унлап "спекулянт" якташым арасында калдым.

**Чекага!** Төннең яртысы җиткәндә, әлбәттә, башка килүче булмаячак иде. Бөтен төнне кухняда утырып, йокысыз үткәрдек. Икенче көн иртән безне өйдән алып чыгып, сак астында җәяү алып киттеләр. Сенная базарын үткәндә, халык төркеме арасына кереп качу фикере бер мизгелгә башымнан кичсә дә, үз-үземне бик тиз кулга алдым һәм "сөекле" чекистларым һәм иптәшләрем белән юлымны дәвам иттем. Безне Гороховая урамындагы 2 номерлы өйдә булган Петроград Чекасына китереп яптылар. Бу өйдә мәшһүр сарай әфсүнчесе мужик Распутин яшәве билгеле. Анда тагын башка бер "капкын"да тотылган кайбер якташларыбыз белән очраштык.

Мин "спекулянтларны" кулга төшерү өчен корылган капкынга төшсәм дә, спекулянт түгел идем, бу җәһәттән куркуым юк иде. Ләкин мин Сембер комитетыннан эш белән килгән хезмәткәр дә түгел идем инде. Шуңа күрә көтелмәгән бу арест аркасында асыл барлыгым мәйданга чыгудан курка идем.

Димәк, Казан Чекасыннан соң, Петроград Чекасын күрергә насыйп булды. Ләкин монда сорау алу фәлән булмады. Бераз сонрак безне каплаулы кара машинага төяп, билгесез бер урынга алып киттеләр. Чын булса, безне "Финляндия вокзалына" китергәннәр, имеш. Машинадан төшереп, поездга утырттылар һәм алып киттеләр. "Озерки" дигән станциядә төшереп, элек нәрсә бинасы булгандыр, белмим, төрмәгә әйләндерелгән агач бер бинага яптылар.

**Котылу**. Анда да мине сорау алырга чакырмадылар, бер-ике көн тоткач, җибәрделәр. "Спекулянтларның" башы саналган Мөхәммәдшаһ әфәнде минем бары тик Сембердән эш белән килгән бер хезмәткәр һәм мосафир булуымны, сату-алу эше белән бер төрле дә бәйләнешем булмавын, минем өчен үзенең җавап бирәчәген катгый итеп сөйләгән. Бәлки шул гарантия аркасындадыр, мине һәм пәһлеван гәүдәле мишәр "Имай"ны (Имаметдинне) чыгардылар. Димәк, Бакуда тарихчы Һади Атласи бүлмәсендәге кебек, бу куркынычны да җиңел

кичердем. Югарыда бер урында үземнең бөтенләй үк бәхетсез булмавымны сөйләвем юкка түгелдер...

Бераздан бу "спекулянтларны" хөкем иттеләр. Петроградның карт адвокатларыннан озын аксакаллы Мусин-Пушкин исемле бер кеше боларны яклауны үз өстенә алды. Судның бер-ике утырышына мин дә бардым. Суд барысын да аклау белән тәмамланды. Димәк, ул вакытта әле Петроградта "чын судьялар" бар иде...

**"Мешочник"**. Озерки төрмәсеннән котылганнан соң яңадан Лотфи әфәнде белән сөйләшеп утыруларның да кызыгы калмады. Җитмәсә, ач карынга вакыт уздыра идек. Май чыраен күрмәгәнгә күпме булды, шикәр табу — зур проблема. Ит юк, ипи дә зур кытлык. Әгәр каян нәрсәдер табып, ара-тирә шул заман өчен мул табыннарга безне чакыргаламасалар, ачлыктан аяк та сузар идек...

Русиядә революция чорында мең төрле мәшәкатьләр белән шәһәрдән яки авыллардан шәһәрләргә капчыклар, янчыклар эчендә ризык ташыган бер сыйныф барлыкка килгән иде, күп вакыт товарларын капчыкларда ташыганга, мондый кешеләрне русча капчык мәгънәсенә туры килгән "мешок" сүзеннән алып, "мешочники" диләр иде. Менә мин дә ачлык һәм жан өзгәләнүдән, провинциядән ни дә булса китерү нияте белән, капчыкчылык эше белән шөгыльләнергә карар бирдем. Карар бирдем, ләкин провинциягә ничек китәсе? Документ кирәк, чөнки ул вакытта мәмләкәт эчендә сәяхәт хөррияте юк иде. Сембердә алган документның срогы чыкты...

**... Яңадан Сембергә**. Әйе, "капчыкчылык" белән шөгыльләнмәкче булдым, тик кулымда сәяхәт өчен бер таныклык та юк. Моның да бер чарасы табылды. Якташларым миңа бер тимер юл оешмасыннан кирәкле кәгазьләр табып бирердәй бер кешене таптылар. Ул кеше аркылы миңа таныш булган Сембергә барып-кайту өчен таныклык ясаттылар. Бу таныклык буенча мин Петроград тимер юллары санитария-дизенфекция инспекторлыгы агенты идем. Кәгаземдә инспекторлык эшчеләре һәм хезмәткәрләре өчен савым кәҗә сатып алу вазифасы белән җибәрелә дип язылган иде. Һәрхәлдә, бик оста уйланылган уйдырма иде бу.

**"Савым кәҗә"** һәм кайту мәсьәләләре. Мин Сембергә савым кәҗә эзләргә түгел, азмы-күпме азык-төлек алып кайтырга килдем. Тик кире кайту өчен һәрхәлдә шәһәр советына барып, савым кәҗәләр сорап һәм кайту визасы алу зарур иде. Шәһәр советының ишегеннән кергәндә, эчемнән "иншаллаһ, кәҗәләр юктыр", диеп кердем. Чөнки сатыла торган савым кәҗәнең табылуы минем өчен харап бер хәл булачак иде. Советта исә мин эзләгән нәрсә кәҗә дә, сарык та булмыйча, фәкать бер печать суктыру иде. Аллага шөкер ки, советта миңа: "Сезгә бирер өчен түгел, үз хезмәткәрләребезгә дә савым кәҗә таба алмыйбыз әле!" дип җавап бирделәр. Мин: "Ул вакытта моны кәгаземә языгыз һәм печать сугыгыз", — дидем. Минне тизрәк җибәрү максатыннан бу эшләрне шунда ук эшләделәр. Миңа исә башка берни дә кирәк түгел иде.

Сембердә дә ул вакыттагы "социализм дәверенә" хас бер "бет базары" бар иде. Анда итәк астыннан кайбер ашау әйберләре сатыла иде. Базарда йөрдем: май, тоз, шикәр һәм он кебек нәрсәләр алдым. Кайту визасын да алу куанычыннан чәй эчеп чыгарга карар бирдем. "Бет базарында" итәк астыннан алган зур гына бер пакет эчендәге шикәр комын кабып карый башладым. Ни күрим: пакетның бары авызы турысында шикәр комы булып, аннан аста гел вак тоз тутырылган булып чыкты. Югыйсә, мин бу пакетка тоз бәясен түгел, шикәр комы бәясен түләгән идем...

Бөек Русиянең шул хәленә күз салыгыз! Элек хайван буларак, иң фәкыйрь кешеләр генә асраган кәҗәне, сөтен савар өчен Петроград хәтле мәркәздәге бер дәүләт оешмасының эзләтүе табигый хәлгә әйләнгән. Мәмләкәттә бер чәй эчәрлек шикәр комы табу да алтын эзләү белән бер дәрәҗәдә авыр була башлаган!..

**... Урын алыштыру.** Башка исем, ялган документ белән сәяси җинаятьченең гел бер урында озак вакыт торуы ярамаса да, мин зарурият аркасында бөтен бер кышны Петроградта Серпуховская урамында имам Лотфи әфәнде янында үткәрдем. 1921 ел. Яз килде, һавалар җылынды. Ялган булса да, кулда бер документ булган тәкъдирдә, мәмләкәтнең һәр тарафына китәргә мөмкин иде. Петроградта кояш

күрмәс, даими ярым-караңгы бүлмәдә утырып тәмам туйган идем инде. Җир, мохит һәм һава алыштырырга кирәк. Ниһаять, бер "документ" ясатып, Мәскәүгә киттем...

Мәскәүдә кемгә, кайда тукталачакмын? Бу, чыннан да, бер "мәсьәлә" иде. Чөнки хөррият һәм тигезлек дәверендә киң Русия бик тарайган иде: торак проблемасы туды, отельдә яшәү авырайды, урын да юк, урын тапсаң да, бәясе бик кыйммәт. Чарасыздан хосуси квартирага тукталырга мәҗбүр булдым. Лотфи әфәндедән алган киңәшне тотып, Ар. Бур. исемле элекке бер сәүдәгәрнең өенә киттем, моңа кадәр бер дә күрешмәгән кешегә үземне таныттым, каян килүемне һәм нилектән аларны мәшәкатьләргә җөрьәт итүемне аңлаттым. Берсүзсез кабул иттеләр.

**Көньякка сәяхәт.** Бу өйдә берничә көн калганнан соң, "капчыкчылык" максаты белән көньякка сәяхәт ясарга карар бирдем һәм Киевка киттем. Киев көньякта, Днепр елгасы ярында, Мәскәүдән шактый еракларда булса да, китми булмады, чөнки Мәскәүдә мөһим эшем түгел, кунарга урыным да юк иде. Бу сәяхәт дәвамында берничә көнемне юлда һәм Киевта уздырачакмын, ягъни вакыт отачак идем. Көньяктан теге яки бу төрле "товар" китереп, бераз акча да эшләү мөмкин кебек күренә иде. Хуш, бу эшләрдә бик хәзерлексез һәм уңмаган булсам да, шартлары бер дә кулай булмаса да, бу көньяк сәяхәте мине үзенә тарта иде. Бу уңайдан, без төрекләргә бер дә элек чит булмаган тарихи Киев шәһәрен дә зиярәт итәчәк идем. Дөньялар тыныч, төзек вакытта ул якларны барып күрергә насыйп булмаган иде, инде шушы "капчыкчылык" сылтавы белән булса да, барып күрим, дидем...

**... Режим алышынганны көтимме?** Киевтан кайткач, бер якташымның ярдәме белән бер рус гаиләсендә бүлмә табып яши башладым. Бу өйдә, нишләптер, бер ир-ат юк, өч-дүрт хатын гына яшиләр иде. Мин, үз хәлемне уйлап, бу хатыннар белән танышырга базмадым. Билгеле булганча, хатын-кыз күп сөйләшә, сораштырырга, "кешедән сорау алырга" ярата. Бер дә карт булмаган бу хатыннар белән еш-еш сөйләшкәләп утырсам, минем кем, кайдан, элек ни эшләвемне һәм хәзер Мәскәүдә ни эзләвемне, ни белән кызыксынуымны, монда кемнәр белән танышуымны һ.б. һ.б. ларны сораштырачаклар. Ул вакытта мин дә бу сорауларның барысына да җавап биреп бетерә алмаячакмын. Авыр хәлгә төшмәс өчен, иң яхшысы ул хатын-кызлар белән бик бәйләнмәскә кирәк иде. Соңыннан аңлавымча, әлеге хатыннар минем мондый үз-үземне тотышыма, "хатын сөймәслегемә" хәйран калганнар һәм миңа бу өйне тапкан якташыма "мондый ир-ат буламыни", дип шаккатып сөйләгәннәр, имеш. Нишлисең бит. Аңа калса, мин үзем бу читләшүемә һич тә үкенмәдем!..

Мәскәүдә калуның минем өчен аерым файдалары да булачак иде. Мәскәү хәзер хөкүмәт башкаласы. Бу шәһәрдә миңа теге яки бу төрле ярдәме тиярдәй якташларым да артыгы белән иде. Икенче яктан, мондый максатсыз һәм мәгънәсез тормышны да гел дәвам итеп булмый иде. Хәятыма нинди дә булса да яңа бер юнәлеш бирергә, яңа бер адым атларга кирәк. Русиядәге режимның үзгәргәнен көтеп ятмам бит инде?! Җитмәсә, советларның гражданнар сугышында җиңеп чыгуыннан соң режимның алышыначагын күрсәткән бер генә билге дә юк иде. Дәүләт режимнарының гомерен бәндәләр гомере белән үлчәү бик дөрес булмас...

**... Иске бер хафиз.** Мәскәүдә булган вакытымда, элек Троицкида шәкертлек һәм Казанда газетчылык иткән көннәрдә дустым булган берәү белән очраштым. Мин беренче тапкыр Русияне ташлап китәр алдыннан, Троицк дәверендә ул әфәнде хафиз иде, рамазанда "хәтем" индерә торган иде. 1905 елгы революциядән соң, Коръән белән хушлашып, рус теле һәм дөньяви гыйлемнәр укытырга керешә. Үзлегеннән өйрәнеп, лицей бетергәнлеккә имтиханга хәзерләнә, бу эш белән бик озак маташып та, уңышка ирешә алмый. Мин аның белән 1913 елның җәендә, аның "дөньявилашу" дәверендә Казанда күрешкән идем. Атасы казанлы, анасы кыргыз булган бу егет җанга якын, игелекле, һәркемгә хәерле, яхшы күңелле, саф бер төрек тибы иде. Революциянең беренче айларында аның белән һичбер җирдә очраша алмадым. Аның соңрак коммунист партиясенә керүен, күп кенә җаваплы вазифалар башкаруын, 1920 — 21 елларда Мәскәүдә мөһим бер мәктәпнең мөдире булып эшләвен, тыштан коммунист булса да, эчтән милләтче булып калып, кайбер милләтче төрек зыялылары, хәтта Муса Җаруллаһ һәм Лотфи Исхакый кебек прогрессив голамә белән дә мөнәсәбәтләрен дәвам иттерүен ишеткән идем. Шуңа

күрә, иске дусты буларак, минем дә аны күрәсем килде. Бу әфәнде мина, иске дусларымнан язучы коммунист Галимҗан Ибраһимов кебек, "сине һаман асмаганнар икән әле!" дип түгел, булдыра алганча нәзакәтле һәм дусларча каршылады, кулыннан килгән кадәр ярдәм итәчәген сөйләде. Аның белән бернечә тапкыр күрештем һәм бер кич өендә кунып та калдым. Минем ул вакыттагы хәлем белән аның эшен, вазифасын чагыштырганда, бу мөгамәлә аның тарафыннан зур илтифат һәм егетлек саналырга хаклы. Аның белән чор мәсьәләләре хакында бәхәсләр дә куерта идек. Тар фикерле, тәкълидче, фанатик кеше булмавы күренеп тора иде. Яңа әсәрләр укып, белемнәрен арттырган. Ул вакыт аңламында бу иске хафиз дустым заманга яраклашкан, алдынгы гына фикерле, ислам мәгънәсендә монафикъ бер кеше иде...

**Чыгар юл кайсысы?** Кулыннан килгәнчә ярдәм итәргә сүз биргән иске хафиз дустым белән берлектә минем өчен бер "чыгар юл" эзли идек. Беркөн шул турыда сөйләшеп утырганда, ул мина: "Беләсеңме, Сталин, Әмин Рәсүлзадәне үз контроле астына алып, Бакудан Мәскәүгә китертте. Ташкентлы Гобәйдулла Хуҗаев, казанлы Ильяс Алкин һәм башкалар да аның химаясе астында. Әйдә сине дә Сталинга илтик, мәсьәләне ничек булса, шулай аңлатыйк та, ул сине гафу итәр һәм үз контроле астына алыр!" — диде. Ул вакытта әле Ленин исән иде. Сталин бары Милләтләр халык комиссары булу белән бергә, яңа большевик өлкәләренең халык житәкчесе иде. Иске дустымның бу тәкъдиме мине башта бик уйландырды. Башка танышларыма да моны сөйләп күрсәттем. Алар һәм хәтта иске хафиз дустым үзе дә: "Бу хосуста берәр тапкыр И. А. белән дә сөйләшеп кара", — диделәр. Бу И. А. электән танылган бер төрек адвокаты иде. Казан төрекләре арасыннан чыккан, чып-чын социаль-демократ (меньшевик) иде. Ул дәвердәге большевик Олимпында да бернечә иске дусты бар иде, шул дуслары аркасында гына ул һаман Чека кулына төшмичә, һичбер төрле сәяси бәлаләргә тап булмыйча, тик үзе дә бер сәяси эш кылмыйча яши иде. Мин аны электән бер дә күрмәсәм дә, аның шулай ук адвокат һәм социалист булган кардәшен яхшы белә идем. Менә шул И. А. ларга танышырга киттек. Таныштык, проблеманы аңлаттык. Минем проблема хакында ул безгә болай дип сөйләде: "Әйе, дөрес, бәлки Сталин сезне гафу итәр, үз химаясе астына да алыр һәм бәлки берәр эш тә бирер, ләкин сез, бик күп башка шикле кешеләр кебек, күзәтү астына алынырсыз, теләсә нинди Совет хөкүмәтенә каршы ялгыш яки чын хәрәкәтегез булган очракта, сезне шунда ук кулга алып, төрмәгә атарлар. Минемчә, бу имин бер чыгу юлы түгел, әгәр Русиядә калырга дигән фикердә түгел икәнсез, сезнең өчен иң кулай чыгу юлы — эмигрант хәленә күчүдер", — диде.

Бу фикер минем күңелемә ятты. Ул көн бүлмәгә кайтып, бикләнеп, тагын бик озак уйлагач, бу фикер тагын да куәтләнде. Мәскәүдәге дусларымның да күбесе моны кире какмадылар. Ләкин бу хосуста каттый бер карарга килер өчен гаиләмнең дә фикерен белергә кирәк. Хатыным белән берәр жирдә күрешеп, әлеге проблеманы яхшылап уйлыйсы бар иде.

Ул вакытларда Мәскәүдә якын танышларым арасында "кара көн дуслары" дип әйтә алырлык бер-ике НЭП дәвере сәүдәгәре дә бар иде, болардан А. Ш.не зур рәхмәтләр белән искә алуны үземнең бурычым саныйм. 1927 елның җәендә Русиядән Төркиягә эш белән килгән вакытында мине Анкарада да эзләп тапкан иде. Аннан соң бер-ике тапкыр Истанбулда да күрештек. А. Ш. —унган һәм эшлекле кеше булып, Русиядә сугыш, революция һәм НЭП чорларында шактый гына акча да туплый алды. Соңрак Русиядән китеп, Германиягә урнаша һәм сәүдә эшләре белән шөгыльләнә. Соңгы сугыш вакытында Берлинда иде. Сугыш беткәннән соң, балаларына милли тәрбия һәм белем бирү теләге белән 1945 елда Төркиягә килде. Тик бераздан авырып, 1954 елда бу дөньядан китеп барды. Аның исемен яшереп торуның кирәген тапмыйм. Мәрхүм дустым — Габдрахман Шәфи Алмаз, Казан аксакалларыннан Габделхәмид Казакның кияве иде. Ул үлгәч, хатыны Әминә өч кызы белән ялгыз калды...

**... Хәзерләнү**. Югарыда бер урында Мәскәүнең Казанга якын булуы аркасында гаиләм белән хәбәрләшү өчен аның Петроградка карый шактый уңайлы булуын сөйләгән идем. Чыннан да, аннан гаиләм белән хат алыша ала идем. Бу хәбәрләшү, табигый, почта аркылы булмыйча, кулдан-кулга җибәрелгән һәм алынган хатлар иде. Бу эштә безгә кайбер "ялганчы коммунист" милләттәшләребез дә ярдәм иткәләде.

Русиядән китәргә карар биргәч, хатыным белән киңәшергә кирәк булды. Моның өчен исә Казаннан читтә бер урында күрешеп сөйләшергә кирәк иде. Хатыным белән кечкенә улым, гадәттә, һәр җәй рөхсәт алып, Кама елгасы буендагы Сарапул шәһәренә ял итү өчен каенана (хатынның үз әнисе) янына китәләр иде. Яшерен генә хәбәрләшеп, шунда күрешергә карар кылдык. Петроградта бер совет оешмасыннан ялган документ сатып алып, гүя ул оешманың эшчеләре һәм хезмәткәрләре өчен "савымлык кәҗә эзләү" максаты белән мин Пермь шәһәренә китәргә һәм аннан шул ук "эш" белән Сарапул шәһәренә дә барачак идем. Көннәрнең берсендә кесәмдә "рәсми документ" белән мин Петроградта Октябрьский — иске Николаевский вокзалыннан поездга утырып, Пермьгә таба юлга чыктым. Мин бу сәфәр вакытында "рәсми" вазифа белән йөрүче бер "совет хезмәткәре" идем, миңа кем кырын карый алсын?

Пермьдә озак тормыйча, бер пароходка утырып, түбән таба, ягъни төп максатым булган урынга таба киттем. Пароходның гомуми пассажирлар утырган залында искедән танылган сарапуллы бер мөселман белән очраштым. Бик яхшы очраклык иде бу. Сарапулга килүемне хәбәр итәчәк, кая урнашып, кайда калачагым турында шаять, хатыным белән танышып, берлектә хәл итә алачаклар иде. Никадәр генә кулымда дөрес "рәсми кәгазь" булмасын, туп-туры каенана өенә килү хата булачак иде, әлбәттә... Ул әфәнде аларга барып килде һәм каенанам белән хатынымның улымны алып, авылга китүләрен хәбәр итте. Алар кайтканчы торып торырга миңа мәчет каравылчысы янында урын табылды.

Дүрт күз белән көткән кичәләрем, ниһаять, авылдан кайттылар. Чыгышлары белән башка булган гаиләдә кунып, Сарапулда 3-5 көн калдым.

Казанда 1921 елның кыш башларында, бәлки дә 192О ел азакларында аерылышканнан соң 7 — 8 ай үткәч, гаиләм белән беренче күрешүем. Теге вакытта Казанда сөекле хатыным һәм улым белән үз өебездә күрешмәгән кебек, бу юлы да Сарапулда, үз өебез булырдай каенанам өендә күрешә алмадык. Шуңа да карамастан, хатынымның ризалыгын, фатихасын алдым. Бу очрашудан соң инде "сәяси моһаҗәрәт", ягъни Кызыл Дөньяны ташлап, чит бер мәмләкәткә сыенырга дигән карар соң һәм кискен шәкелгә керде.

Каенанам, хатыным һәм кечкенә улым белән хушлашып, аерылыштык. Бу — революция көннәрендә гаиләм белән дүртенче аерылышуым иде. Сарапул аерылышуы соңгы аерылышу да булырга бик мөмкин. Ни өчен? Гаиләм "совет җәннәте"ндә кала, мин исә, булдыра алсам, бу "җәннәт"нең тышына китәчәк идем...

Кайту юлына чыктым һәм килгән юл белән кире кайттым.

**Петроградка кайту.** Петроградка кайттым. Инде яшерен рәвештә Финляндиягә китү уе белән йөри башладым. Асылы белән Европа Русиясенең Нижгород губернасы Сергач өязеннән мишәр дигән төрек ыруына мәнсүп булган, хәзер Петроградта яшәп ятучы, ләкин авылдашлары белән элемтәсен бервакытта да өзмәгән, хәтта бер өлешенең бала-чагасы да авылларында калган кайбер төрекләрнең ул вакытта мөстәкыйль җөмһүрият Финляндиядә туган-тумачалары бар иде. Болар һәрвакыт ул өлкәдән яшерен рәвештә килеп-китеп йөргән бер төркем кешеләр ярдәме белән Финляндия белән бәйләнештә торалар иде. Күрше җөмһүрияттән яшерен килгән кешеләр Петроградтагы кайбер төрекләргә Финляндиядәге кардәшләреннән ул вакытта Русиядә дефицит булган яки бөтенләй булмаган "товарлар" да алып киләләр һәм моннан Финляндиядә яхшы үтә торган әйберләрне алып китәләр икән. Бу "качаклар" арасында намуслы, дөрес кешеләр дә юк түгел иде. Аларның кайберләре әйбер, товар түгел, бәлки кеше качыра булып чыкты. Минем өчен дә мондый "качаклар" ярдәменә мөрәҗәгать итүдән башка чара калмады. Бу кешеләр миңа якташ булачаклар иде. 1921 елның сентябрь урталары. Суыклар башланырга тора. Беркөн безне алып китәчәк кешеләрнең Финляндиядән килүен хәбәр иттеләр. Хәзерләндек. Без өч кеше качасы идек: мин, ата-анасы Финляндиядә булган 15-16 яшьлек бер бала һәм урта яшьләрдәге бер мишәр.

**Финляндиягә ничек киттек?** Финляндиядән килгән адәмнәр диңгездән көймәгә утырып килгәннәр һәм безне дә шул юлдан алып китәчәкләр иде. Качасы көн көпә-көндез бер пригородный поездга утырып, гүя гизү өчен, Ориенбаум тирәләрендәге бер ял итү урынына киттек һәм кичкә кадәр шунда булдык. Тирә-як агачлык. Аннан Фин култыгының каршы ягы, фин туфраклары күренеп, безне

чакырган, өметләндергән кебек тоела. Әйтерсең лә, ул төшләр бер "җәннәт бакчасы" иде дә, ана ирешү Фин култыгы диелгән Сират күпереп бер бәла-казага очрамыйча гына кичү кирәк. Култыкның бу ягыннан караганда хыял гына булып тоелган Финляндия дигән хөррият һәм мәдәният диярына хөрмәтем, мәхәббәтем торган саен арта, берничә сәгатьтән ташлап китәчәк бу золым-зөлмәт, кайгы, хәсрәт, изү, җәза дөньясына нәфрәтем кабарганнан-кабара бара иде. Минем өчен бөтен гомерем шушы иллә яшәгән хәлемдә дә, бу аерылу, читкә китү күнелемдә әллә ни хәсрәт уятмый иде. Кем белә, бәлки бу аерылу башка бер кавышуның башлангычы гына булыр. (Һәм шулай булды да.)

Су өсте караңгылангач, безне аулак бер урындагы өйгә алып килеп, юлга чыгу сәгатен анда көтәргә куштылар. Карангылык ныгытып төшеп бетте. Тирә-як тыныч, тавыш-тын юк. Тик безнең күңелебез генә тыныч түгел, курку белән өмет арасында яна идек. Язмышыбызны ике фин "качагына" тәслим итәчәкбез. Тагын бер куркыныч ихтимал бар: көймәгә утырмас борын, бу ызбада ук Чека агентлары яки чик сакчылары кулына эләгүебез дә бик мөмкин. Тотылсак, безне ни көткәне билгеле. Ниһаять, сәгать 21 белән 22 арасында финнардан берсе килде һәм "әйдә" дип, безне көймә яшерелгән урынга алып килде. Көймә агачлар арасына яшерелгән иде. Алда караңгылык эчендә Кронштадт крепостенын утлары җемелди. Көймәгә утырдык һәм ярдан аерылдык. Димәк, коры җирдә тотылмадык. 10 метрлап киткәннән соң ишкәк көрәкләренең берсе ярда калуы беленмәсенме! Хәзер аны алу өчен кире ярга кайту кирәк. Бер тапкыр коры җирдән аерылып киткәннән соң кире кайту бер дә юньле хәл түгел иде. Мона кадәр гафил булып торган чик сакчыларының бу юлы безнең каршыбызга чыгулары бик мөмкин. Бәла! Фәкать безнең финнар мона һич тә исләре китмичә, калган ишкәк көрәген алу өчен кирегә борылдылар. Аллага шөкер, көрәкне тиз генә табып, яңадан юлга кузгалдык. Әкрен-әкрен генә Ориенбаум буйларыннан ераклаша барабыз. Култык тыныч: бары ишкәкләр чыгарган җинелчә тавыш кына ишетелә. Ишкәк тавышлары ерак һәм билгесез язмышка таба баручы безләргә күнел юатучы бер музыка кебек иде. Совет "җәннәте" артта кала. Эчебездә сөенеч һәм кечкенә генә сагыш хисләре бар. Кронштадт тирәләреннән үтәсе булганга, бу крепостьтан килә торган прожектор яктысына туры килү ихтималы тагын безне куркыта башлады. Аллага шөкер, бу куркынычны да җиңел генә кичеп, диңгез киңлекләренә чыгарга мөмкин булды. Тизрәк һәм җиңелрәк бару өчен җилкәннәрне күтәрдек.

**Фин култыгында.** Кичтән тып-тыныч торган су, таңга таба гелдән-гел кабара-күперә барып, соңга таба котыра ук башлады. Бер-берсен куалаган, биек тауларга охшаган усал дулкыннарның китереп-китереп бәрүе безнең башка кайгыларыбызны оныттыра башлады. Көймәдә биш юлчы бар: ике качак фин, 3 качак төрек. Бу чайкалулар нәтиҗәсендә көймәбез батса, "җәннәт бакчасына" ирешмичә, балыкларга җим булачакбыз. Бер-берсен куалап, кайгыбызны әле бик югарыларга, әле бик түбәнгә ата торган бу биек һәм азгын дулкыннар, гомеребездә беренче тапкыр көймә белән диңгез сәфәренә чыккан безләрнең күпләребезне куркыта, йөрәкләребезне каты-каты кысылып куярга мәҗбүр итә. Бу куркытучы манзараны күрсәтмәс өчен, көймәчеләребез безне көймәнең төбенә яткырып, өстебезне брезент тент белән каплап куйдылар. Инде таң атып, көн яктыра башлады. Без дә тент астыннан чыгып, фин чикләренә якынлашуыбызны күрдек. Ниһаять, бер комлыкка якынлаштык, тик ни күрик: ярда каршыбызга мылтыкларын сугышка әзер кыяфәттә тоткан ике фин чик сакчысы килеп чыкмасынмы! Финча әллә ниләр сөйләгән әлеге чик сакчыларына, качаклар кебек, без дә кулларыбызны югары күтәреп, бирелдек. Хәлбуки, көтелмәгән хәл иде. Бу тотылу, бездән дә бигрәк, фин качаклары өчен зур мәсьәлә: Петроградтан качырып килгән товарлары алыначак, үзләре качаклык эшендә гаепләнеп, хөкем ителеп, төрмәгә ябылачаклар иде... Безнең өчебезне аерып алып, карантинга ябу өчен поезд белән пляж урыны булган, ә хәзер инде Русиягә аннексияләнгән Тирйокига җибәрделәр...

Менә бу хикәя шулай бетте.

*Тәмам.*

*Мөхәммәт ага Садрига — 85 яшь*

## БӘХЕТ ТУРЫНДА ҖЫР



Төрки әдәбиятлар һәм шигъриятенең нигезендә ятучы мәгълүм бер әсәр бар: ул — урта гасырлар шагыйре Йосыф Баласагунинын "Котадгу белек" әсәре. "Котадгу белек" — ягъни бәхет-кот турында белем. Бәхет турындагы шигъри әсәрләрдән без белгән беренчесе дә шулдыр, мөгаен. Димәк, дөньяны танып белү, гамь, моң, яшәү мәгънәсе турында уйлану — шигъриятнең асыл максатын билгеләгән бу төшенчәләр безнең татар шигыренең дә чишмә башында — бөтен тарихында. Ул — Кол Галиләрнең безгә килеп җиткән кайнар сулышында; ул — Тукаебызның: халыкка хезмәттә — бөтен ямь, бәхет-сәгадәт, дип раславында... Һәм, ниһаять, бүгенге шагыйрьләребездә дәвам итә бу хактагы фәлсәфә-уйлар, зур традицияләре булган мәңгелек Бәхет темасы... Аксакал шагыйребезгә 85 яшь тулган көннәрдә аның мәгълүм поэмасын ("Бәхет турында җыр") һәм барлык язганнарын күздән, хәтердән кичергәч, менә шушы уйлар биләде безне... Чыннан да ни ул бүгенге шагыйрь һәм егерменче гасырның каршылыклы, үтә дә тотрыксыз дәверләрен кичкән кеше бәхете? Бәхетле дип санаган гомеренең башы ук җинелдән түгел ләбаса: булачак шагыйрь бик яшьли (Мөхәммәт Хәбибулла улы Садретдинов 1913 елның 20 маенда Казанда эшче гаиләсендә туа) ятим кала, балалар колониясендә тәрбияләнә; ФЗУ мәктәбен тәмамлап, үзе дә эшчеләр сафына килә — М. Вахитов исемендәге Казан химкомбинатында слесарь була... Бәлки, шундадыр бәхеткә юлының, гомерлек җырының башы?

Слесарьлар корыч кисәкләрен
Ин кирәкле деталь итәләр.
Сизелеп тора: корыч белән бергә
Үзләре дә чыныгып үсәләр. —

ди ул "Слесарьлар" исемле шигырендә. Алдынгы эшче — "ударник шагыйрь" чоры бу! Аңа Һ. Такташ, К. Нәҗми, Х. Туфан, Г. Гали, М. Җәлил кебек әдип-шагыйрьләр игътибар итәләр, ярдәм кулы сузалар (бәлки, иң бәхетле мизгелләр шул вакытта булгандыр?!) — нәтиҗәдә, 1932 елда "Җыр башлана" исемле беренче шигырьләр китабы басылып чыга... Аннары — башкалар... Үз буыны шагыйрьләре С. Хәким, Н. Дәүли, Н. Арсланов һ. б. белән бергә сугышны ул яңа ил-ватан бәхетен җырлаучы оптимист ир булып каршылый.

1941 — 1946 елларда Мөхәммәт ага Совет Армиясе сафларында: төрле фронтларда артиллерия, танк, автотранспорт частьларында хезмәт итә; аннары татар телендә чыгучы "Ватан намусы өчен" исемле фронт газетасында эшли. Польша, Чехословакия, Румыния, Венгрияне азат итүдә, Берлинны алуда катнаша ул — бәлки бәхетле дип ихлас ышанган еллары шулдыр шагыйрьнең? "Мин Берлинны алдым" дип атала бит мәгълүм шигырьләр бәйләме һәм китап исеме...

Ике йөз миллион штык ударында
Бу хәнҗәр дә сизелер дошманга! —

дип горурлана ул. Шуңа да һәр яз, май ае аңа яңа шигырьләр китерә, яңа сурәтләр тудыра:

Алтын Прага, Злата Прага!
Килеп яз таңнарыннан,
Дошманнарны себереп түктек
Влтава ярларыннан.

Әйе, "бөтен дөньяны бәхетле итү, азатлык китерү" турындагы татар шагыйренең садә уйлары бу. Ә үз илендә, үз халкында — ниләр? Чыннан да, "Бәхет турында җыр"дагычамы?

— На! — диде Конев солдаты,
Мыекларын бөтергәч.
Сафадан ул ут сорады,
Тәмәке салып төргәч...

Ә гомер дәвам итә. Китаплар, калын сайланмалар, томнар. Алар да "бәхетле булу"ның, халкына кирәкле шагыйрь булуның этаплары, бәлки? Яшьлегендә үк фольклор экспедицияләрендә булып, халык иҗатын, борынгы җырларын җыеп, үзе дә өйрәнгән шагыйрь җыр өлкәсендә дә популярлык казана. Аның шигырьләренә С. Сәйдәшев, М. Мозаффаров, А. Ключарев һ. б. композиторлар көй язды.

Сандугачым сайрый чут-чут, дип,
Безнең илдән матур ил юк! — дип...

— кебек җырны кайсыбыз гына ишетмәгән? Р. Гамзатовның: "Сандугач гел бер җыр җырлый, әмма ул ялкытмый — чөнки ул җыр ил-Ватан турындадыр" дигән хәтерлик. Бу фикерне татар шагыйре күптән әйткән, җырда яңгыраткан икән!

... Менә шундый уйлар, шул ышаныч, бәхетле булуга инану, көләчлек, тормышка чиксез мәхәббәт белән яшәлгән бу озын гомер... Ә 85 яшь яшәү — үзе үк бәхет, үзе үк җыр-дастан түгелмени? Әлбәттә, соңгы еллардагы ил-дөнья үзгәрешләре аның да җанын аз телгәләмидер. Күпме кордашларын-дусларын югалтулар, фани дөньяның мәшәкать-авырлыклары... Үкенечләр дә күптер, мөгаен... Ә бәхет? Бармы соң ул? Бәлки, ул — аны армый-талмый эзләүдәдер, мең мәртәбә заман-чордан алданып та, һаман чал башны, орденнар-медальләр тулы киң күкрәкне чын татарча горур тотудадыр? Ни булса да, бөтен гомер буе язганнарында — шигъри юлларында, мөгаен, шагыйрьнең үзгәрмәс бәхете? Инде санаулы, исән аксакаллар юлы шуны сөйли... Без дә бәхетлеләр булыйк!

Рәдиф ГАТАШ.

## Мөхәммәт Садри

### ӨЧ ШИГЫРЬ

### Моң чишмәсе

*Башкорт шагыйре Нажар Нәжминен Казанда басылып чыккан "Сина барам" дигән китабын укыгач.*

Йотлыгып-йотлыгып эчтем моң чишмәсен,
Ул шифалы — анты күңелнең.
Утта янмый, кайтып, яшәүләрен —
"Юкка түгел, юкка түгелләр".

Мин Мәскәүдән үттем Берлингача,
Син дә аны сугышып алгансың.
Рейхстагта бергә булганбыз без,
Тик син мине танымый калгансың.

Бер чәченә карыйм, бер йөзенә,
Чәчендә нур — илһам нурлары.
Битең шадра. Ә азмыни илнең
Синең кебек шадра уллары?!

"Шадра пәри" икән — була бирсен.
Шадра, диләр, йөрәк яндыра.
Дошман янсын, ә дусларны — синең
Моңлы чишмәң таңга калдыра.

Синең китап белән баеттым мин
Илһам биргән китап киштәсен.
Рәхмәт, шагыйрь, бүләк иткән өчен
Йөрәгеңнең моңлы чишмәсен!

*1988*

## Яшь дустыма

Дөрләр чакта син дөрләп кал,
Гөрләр чакта гөрләп кал,
Биек, текә, ташлы тауга
Үрләр чакта үрләп кал!

Гизәр чакта ил гизеп кал;
Дәрья кич син, йөзеп кал,
Карурманга ак юл салып,
Кояш нурын сибеп кал!

Бакча үстер, өй салып кал,
Илдән рәхмәт алып кал;
Янар чакта Данко булып,
Халкың өчен янып кал!

*1985*

## Идел буенда моңлану

Иделдә көмеш дулкыннар,
Ярларда яшел томан,
Ал кояш чыга, нур сибеп
Илнең бөтен җирләренә,
Саумы сез? — дигән сыман.

Кызара көмеш дулкыннар,
Куера яшел томан:
Каеннар яфрак яралар...
Яшь киленнәр иңнәренә
Ефәк шәл япкан сыман.

Күзәтәм Идел буеның
Моңлы бер матур таңын.
Дулкыннар түгел, яныма
Кайткан кебек була тагын
Яшь чагым, көчле чагым,
Берлинны алган чагым.

*1988*

*Хатип Госманның тууына 90 ел*

# ХАТИП АГА ЯДКАРЕ

Остазыбыз Хатип ага Госман турында сүз чыктымы, Тел, әдәбият һәм тарих институты аспиранты булып йөргәндә булган бер вакыйга искә төшә. 1970 елларда булды ул хәл. Институтның утырышлар залында татар әдәбияты проблемаларына багышланган зур конференция бара иде. Залда илебезнең төрле төбәкләреннән килгән зур галимнәр. Профессор Х. Госман төрки халыкларның шигырь төзелеше турында доклад укый. Куелган проблема җитди. Моңарчы төрки шигырен, шул нисбәттән татар шигырь төзелешен аңлатуда берьяклырак караш яшәп килде. Күп галимнәр төрки шигырь төзелешен гарәп кануннарына нигезләнеп тикшерәләр, бу исә төрки халыкларда борын-борыннан үз шигъри системасы формалашмаган, ә гарәпләрдән алынган дигән ялгыш фикергә этәрде иде.

Төрки шигырьнең үз юлы бар, шигъри система башка халыклардан кермәгән, ул үз телебезнең чараларына нигезләнеп барлыкка килгән, үскән һәм камилләшкән. Залдагылар профессорның бу нәтиҗәләрен хуплап каршы алды. Профессорга төрле яклап сораулар яуды, язма рәвештә дә бирделәр. Ул һәммәсенә җавап бирә барып, бер кәгазьдә тукталып калды. "Әллә күзләрем ялгыш күрәме" дигәндәй язуны әйләндергәләп карады. Аннан, бер фикергә килеп, әчтәлеген залга игълан итте:

— Иптәш Усманов, бу тәфсилләп тикшерүнең нигә кирәге бар? Шагыйрьләребез шигырь төзелешен белмәсәләр дә, язалар ич әле.

Залдагылар аптырашта калды. Аларның күбесе Хатип аганың шәкертләре, тегеләйме-болаймы профессорның катнашы белән фәнгә яисә әдәбиятка аяк баскан кешеләр, һич югында, аның лекцияләрен тыңлаган, хезмәтләренең кыйммәтен яхшы белгән һәм аларга нигезләнеп эш итүчеләр иде. Хөрмәтле профессорга бирелгән бу мәгънәсез сорауны ишетеп тору аларга бик кыен тоелды, күрәсең, уңайсызланып башларын иделәр. Профессорның да бу "галим"гә ачуы чыкты, йөрәген әрнетте бугай, күзләреннән нәфрәт чаткылары сибелеп киткәндәй булды. Ләкин ул үзен тотып калыр өчен көч тапты, тыныч кына тавыш белән:

— Минем иң яратмаган нәрсәм — фәндә өстән-өстән йөрү... Фәнгә менә шундый галимнәрнең борын тыгуы бик аянычлы, — дип сүзен тәмамлады.

Шул конференциядә әйткән "иң яратмаганым — фәндә өстән-өстән йөзү" дигән сүзе Хатип Госманның һәр мәкаләсен, һәр китабын караган саен искә төшә торган булып китте. Чөнки тикшерелә торган объектның төбенә-тамырына төшү, төп хасиятен белергә тырышу аның барлык гыйльми хезмәтләренә дә хас әйбер. Бу аның иманы иде.

Х. Госман фәнгә әдәбият дөньясыннан килде. Ул 30-40 нчы елларда шагыйрь һәм прозаик буларак танылды. "Кырлар лирикасы" (1931), "Кан тавышы" (1934), "Йосыф", "Мин күккә күтәреләм" (1937), "Ялкынлы йөрәк" (1943), "Ут сызыгында" (1945) кебек әсәрләре укучылар тарафыннан җылы каршы алындылар.

Аның әдәбияттан килүе фән эшендә дә зур ярдәм итте, шагыйрьләрнең иҗат лабораториясенә үтеп керергә, аларның иҗат үзенчәлекләрен тирәнрәк ачып салырга мөмкинлек бирде. Моннан тыш ул яшьтән үк рус һәм Көнбатыш әдәбиятларын җентекләп өйрәнеп, Алабуга укытучылар әзерләү һәм Казан педагогия институтларында Көнбатыш әдәбияты буенча лекцияләр укырга да өлгергән иде.


Х. Госман беренче фәнни хезмәтен Һ. Такташ поэзиясенә багышлый. Әмма Такташ поэзиясе гаять катлаулы. Беренче чорда ул романтик шагыйрь булып күзалланса, соңга таба реализмга таба юл тота. Аның эчке иҗади үсеш-үзгәрешен ничек, кай тарафтан ачарга, аның иҗат лабораториясенә ничек ачкыч табарга? Шул вакыт аның Көнбатыш әдәбиятларын яхшы белүе ярдәмгә килә. Көнбатышта исә мондый шагыйрьләр булган. Х. Госман Такташ иҗатын Гете, Шиллер, Байрон кебек даһилар белән янәшә куеп, чагыштырып карый һәм шунда Такташның бөеклеге, аның шигъри эволюциясе ачылып китә. Бу фән дөньясына яңа гына килеп кергән яшь галимнең беренче уңышы була. 1951

елда ул Казан университетында шушы темага кандидатлык диссертациясе яклый.

Шул ук елда аңа Казан университетының татар әдәбияты кафедрасы белән җитәкчелек итүне тапшыралар. Татар әдәбиятын чын-чыннан фәнни нигезгә салып укыту эше яңа гына җайга салынып килгән еллар. Студентлар өчен дәреслекләр юк дәрәҗәсендә, укыту планнары, методик күрсәтмәләр юк. Әдәбиятның борынгыдан алып хәзерге көнгәчә үткән юлында тикшерелмәгән "ак таплар" бихисап. Нидән башларга? Кафедра җитәкчесен шул нәрсә борчый. Ул көн тәртибенә әдәбият тарихындагы "ак таплар"ны бетерү, иҗатлары моңарчы җитәрлек өйрәнелмәгән, исемнәре тарих томаннары артында югалып калган язучы һәм шагыйрьләрне яңадан халык арасына кайтару бурычын куя. Ләкин моның өчен кадрлар тупларга, фән мәктәбе булдырырга, фәнни тикшеренүләрнең юнәлешен билгеләргә кирәк иде. Фидакарь хезмәт белән айлар, еллар үтә торды. Татар әдәбияты кафедрасы акрынлап кирәкле кадрлар белән тулыланды, фәнни хезмәтләр, программалар, методик кулланмалар, дәреслекләр басылды. Кафедра эше җайга салынып китте. Монда, әлбәттә, кафедра җитәкчесенең роле бигрәк тә зур булды.

Университетта эшләү чорында Х. Госман "Социалистик революция һәм татар поэзиясе" дигән темага күләмле монография яза (Бу хезмәт аның 1962 елда яклаган докторлык диссертациясенең нигезен тәшкил итте). Галим әлеге монографиясендә революция алды елларыннан алып 1930 нчы елларга кадәрге поэзиябезне тикшерә. Әдәби процессны иҗтимагый тормыш белән ныклы бәйләнештә ача, поэзиядә әдәби осталык үсеше мәсьәләләренә киң тукталa. Бу монография 20 нче еллар татар поэзиясен тикшерү буенча хәзер дә бердәнбер күренекле хезмәт булып кала.

Гомумән, Х. Госман зур фәнни кыйммәткә ия хезмәтләр язды һәм китаплар



Рәсемдә: Хатип Госман Казан дәүләт университеты доценты, язучы Альберт Яхин белән, 1976 ел.

чыгарды. Аның "Такташ поэзиясе" (1953 ел), "Бөек Октябрь революциясе һәм татар поэзиясе" (1960 ел) һәм "Егерменче елларда татар поэзиясе (1964), "Татар шигыре" (1964), "Шигырь төзелеше" (1975 ел), "Шигърият гомере" (1978 ел), "Олы юлга чыкканда" (1982 ел), "Тюркский стих в средине века" (1987 ел) һ. б. китаплары поэзиябезне тикшерүдә күренекле урын алып торалар. Моннан тыш Г. Кандалый, Мөхәммәдьяр кебек шагыйрьләрнең җыентыклары, "Татар поэзиясе антологиясе", Һ. Такташ, М. Гафури, Ш. Бабич әсәрләренең укучыларга тәкъдим ителүендә һәм "Татар халык иҗаты" дигән күләмле китап чыгаруда да өлкән галимнең өлеше гаять зур. Шуның өстенә урта мәктәпләр өчен дәреслекләр төзүгә кертелгән хезмәтен дә искә алыйк. Аның газет һәм журнал сәхифәләрендә дә әдәбиятның төрле проблемаларына бәйләнешле мәкаләләре еш басыла килде. Галим борынгы татар әдәбияты чыганакларын өйрәнүдә зур хезмәтләр куйды.

Күренекле галим фәндә алмаш әзерләүгә дә зур әһәмият бирде. Аның җитәкчелегендә дистәдән артык диссертация язылды һәм якланды. Кайчандыр Х. Госманның шәкертләре булган М. Хәсәнов, М. Мәхмүтов, Х. Мәхмүтов, Х. Миңнегулов һ.

б. хәзер югары абруйга лаек фән эшлекләләре. Ул дистәләгән кандидатлык һәм докторлык диссертацияләрен яклауда оппонент булды. Югары Аттестация комиссиясе әгъзасы буларак, фәнни хезмәтләргә рецензияләр язып, күпме яшьләргә фатиха бирде ул, фән юлына чыгарга ярдәм итте...

Университет галимнәренең фәнни эше педагогик хезмәт белән бергә алып барыла. Х. Госман бу өлкәдә дә күп тырышлык куйды. Без дә шул университетта укып Хатип аганың "Әдәбият белеме" буенча лекцияләрен тыңлау бәхетенә ирешкән кеше. "Бәхетенә ирешкән" дим. Чөнки ул укыган лекцияләрне тыңлау чыннан да бәхет иде. Аның илһамланып, оста һәм әчтәлекле итеп укыган лекцияләре әле дә хәтердә.

Университетка керү имтиханнары тапшыргандагы бер вакыйга истә калган. Әдәбият буенча сорауларга җавап биреп бетергәч, бер кырыйдарак утырган мәһабәт гәүдәле абый миңа сәер генә сорау бирде:

— Энем, тәрәзәгә кара әле, ни күрәсең, шуны сөйлә, — диде.

Башта аптырап калдым... Коридорга чыккач, бер-беребездән сорашабыз. Теге профессор абый шактый кешегә "Әниең турында сөйлә", "Туган авылың турында"... кебек сораулар биреп утырган икән. Без ул серле сорауларның ни өчен бирелгәнлеген ул вакытта төшенә алмадык, әлбәттә. Соңыннан гына аңлашылды, ул Хатип аганың укырга дип килгән яшьләрнең фантазиясен, эмоциональлеген, кыскасы, иҗади сәләт дәрәҗәсен чамалап утыруы булган икән.

50 нче еллардан соң әдәбиятка килгән язучы һәм шагыйрьләрне күз алдыннан кичерсәң, аларның күпчелеге университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укыган кешеләр. Бу бер дә очраклы хәл түгел. Чөнки кафедра һәм аның җитәкчесе Хатип ага әдәбиятыбызның киләчәге өчен өзлексез кайгыртучанлык күрсәтеп килделәр.

Бәхәссез, Х. Госманның милли кадрлар әзерләүдәге хезмәтләре гаять зур. Ул безнең республикада гына түгел төрки илләр күләмендә дә билгеле. Галим фидакарь хезмәте өчен югары хөкүмәт бүләкләренә лаек булды. Ул "Почет билгесе" ордены кавалеры, шулай ук "Фидакарь хезмәте өчен" һәм башка медальләр белән бүләкләнде.

Хатип ага Бөек Ватан сугышы ветераны иде. Ул авыр сугыш елларын башыннан ахырына кадәр кичеп чыкты. Башта Төньяк-Көнбатыш фронтның "Ватан өчен" газетасында аннан сугышчан офицер булып фашизмның оясына кадәр барып җитте. Сугышта күрсәткән батырлыклары билгесе булып аның күкрәген "Кызыл Йолдыз" ордены һәм күп санлы медальләр бизи иде.

Болар бары да күзгә бәрелеп торган хезмәтләр генә. Авылдашлары Хатип абыйны зур галим булудан тыш, 20-30 нчы елларда үзенең ялкынлы сүзе һәм эше белән аларга ярдәм итүче активист буларак та беләләр.

Хатип ага Пермь өлкәсе Сулмаш авылында затлы гаиләдә, Госман мулла гаиләсендә туган. Бу гаилә безгә 1920-30 елларда шактый билгеле язучы Таһир Госман-Сулмашны, рәссам Шәмит Госмановны да биргән бит әле. 20 нче елларда, әтиләре мулла булу аркасында, бу ишле гаиләгә күп җәбер-золым күрергә туры килгән.

Шул ачы язмышларны уздырган кешегә тоталитар чорда халкына хезмәт итү хакына "кызыл төскә" кермичә дә мөмкин булмагандыр. Минем уемча, тоталитар чорда репрессияләргә эләкмәс, адәм типкесендә йөрмәс өчен, "кызыл төскә" кереп, хәйләкәрләнеп булса да, татар зыялыларының күркәм традицияләрен дәвам иттереп, татар филологиясе фәнен үстерүгә зур хезмәт куйган кешеләребезне хөрмәт итәргә кирәк безгә. Бу да фидакарьлек, бу да халыкка хезмәт итү бит.

Сиксәненче еллар башы иде бугай, ул сиксән яшенә якынлашып барганда Хатип ага бер сәер гамәлгә тотынды. Үзенең дачасында юан бүрәнәләрдән олы бер авыл йорты төзү эшенә кереште. "Нигә кирәк инде бу газап сезгә!" — дигәч Хатип ага: "Шушы урмандагы йортта тынычлап биш-алты ел гына булса да ниятләгән хезмәтләремне язып, эшләремә нәтиҗә ясап калдырасым килә", — диде. Чыннан да, хөрмәтле галим җәйләрен шул йортта яшәп, бик күп язды, фәнгә багышланган гомеренә нәтиҗә ясап, биш-алты елдан соң безнең арадан китеп тә барды.

Аның 1979 елда, Казан дәүләт университетында 70 еллык юбилее вакытында, әйткән сүзе истә калган. "Мин тәңредән озын гомер теләмим, дөньяви гомерем белән генә димим, бөтен эшләгән хезмәтләрем белән 100 ел яши алсам, разый булыр идем", — дигән иде ул. Минем уемча, аның халкыбыз яшәешендәге гомере алай гына булмас. Татар халкы һәм аның әдәбияты, әдәбият белеме булганда, Хатип ага да яшәр.

Рәшит ЯГЪФӘРОВ.

*Шагыйрь Булат Сөләймановның тууына 60 ел*

# КАҺАРМАННАР ЗАТЫННАН ИДЕ УЛ



*Кеше кеше күңелендә гадәттә нинди дер истәлекле вакыйгага яисә данлыклы эше белән истә кала. Булат Сөләйманов дип әйттеләрме, минем күз алдымда иң элек бер искиткеч манзара пәйда була: Казан, май ае, эссе-кояшлы көн; асфальт юлдан читтәрәк җәйрәп яткан өчпочмаклы яшел кишәрлек уртасында, тезләреннән диярлек күперер үскән хуш исле сарут-билчәннәргә батып, буй-буй кара сызыклы ак күлмәкчән мәһабәт гәүдәле берегет кәнҗәләдәй кабарынкы чәчләрен юантык бармаклары белән тараштырып басып тора, ә тыңлаусыз көрәнсу-кара эре дулкыннар, түгәрәк калын иңбашларына кагылып узалар да, талгын җилгә буйсынып, аның саен текә маңгаен сыйпауны дәвам итәләр. "Себер татарларыннан чыккан бердәнбер шагыйрь Булат Сөләйман шушы була инде", — дип таныштырдылар безне. Минем исемне ишеткәч ул:*

*— Пик шәп, тус пулырпыз, Алла пирсә! — диде, тулы йөзен мул яктыртып.*

*Театр рәссамы Әхәт Закиров үз йортында яшәүче бер кардәшенә кунакка алган иде безне ул көнне — Себер татарының буаз портфеленнән бушатылган нигъмәтләр белән сыйланып утырдык: балыкның мин татымаган нинди генә төре өстәлгә тезелмәде анда! Соңрак белдем: Булат Сөләйманов шул иртәдә генә туган якларыннан, Төмән төбәгеннән, килеп төшкән булган икән. Тагын күпмедер вакыттан бөтенләй ачыкланды: ул шулай Себер күчтәнәчләре төяп килеп төшә дә, каршына юлыккан бер танышын авыз иттерә-иттерә, кунакханәгә-мазарга урнашырга соңаргач кына ялгызы торып кала һәм шунда гына төнне кайда куну хакында уйланырга тотына — кесәләре дә саеккан, "туслары та" әллә кая "пулганнар"... Ярый ла кесәсендә Рөстәм Мингалимнең адресы бар икән. Төмәненә әйләнеп кайтып җитүне дә шул оештырачак...*

*Казан шагыйрьләре әнә шулай ел тәүлегенә берничә мәртәбә затлы балыкка тиенеп калалар иде. Сюжет бер үк. Финал да. Кемнәрдер, эчләреннән генә көлемсерәп, "пезнең Сепер Пулат" һаман акылга утыра алмый, дип уйлый торган булганнардыр, чөнки Булат Сөләймановның беркайчан да "Себер күчтәнәчләрен" нинди дер әдәбият түрәләренә ачкыч яратыр өчен төяп килгәне булмады: гомумән каядыр күчтәнәчсез барып төшү табигатенә сыймый иде аның. Еллар үтә торгач, моның яшерен ягы да әкренләп бераз ачылды: бер дә "бакча җимешләре" булмаган икән аның сыйлары, акча җимеше булган... Ә безгә, Себер дигәч, анда затлы балыклар үзләре "тәгәрмәч орчыкларына сикереп урала" кебек тоела иде! Корней Чуковскийның Чехов турында гаять тә тирән мәгънәле бер сүзе бар: "ул магнит шикелле кунакчыл иде." Булат Сөләймановка карата да шул ук фикерне кулланып була, минемчә. Тик аерма шунда: Чеховның мөмкинлекләре чиксез булган шул.*

*Булат Сөләйманов миңа тагын икенче бер шәхесне хәтерләтә: ул — Василий Шукшин. Себердән чыкканлыгы өчен генә түгел. Иҗатларын да чагыштырмыйм. Алар — икесе ике масштабтагы һәм икесе ике дөнья кешеләре. Ә шулай да бу ике шәхестә бер уртаклык күрәм. Яхшырак аңлашылсын өчен, Шукшинның бер генә хикәясен исегезгә төшереп китим: "Ораторский прием" дип атала ул. Шунда Борис Куликов дигән бер каһарман бар. Әдәби каһарман турында бара сүз. Автор сүзләре белән әйткәндә, "славный своим бесстрашием... Причем его не интересовало,сколько перед ним человек: один или семеро." Кешелек хисләрен кимсетергә теләсәләр, шулай, алдын-артын уйламыйча, ташлана ул Борис Куликов. Василий Шукшинның күп каһарманнары шундыйлар. Авторның үз табигатеннән килә бу. Шагыйрь Булат Сөләйманов та минем хәтердә нәкъ шундыйрак шәхес булып саклана: табигать аңа гаделлек хисен ун шәхескә җитәрлек итеп биргән иде. Гаделлекне үзе өчен даулауда чагылмый иде ул, бүтәннәр өчен, газиз халкы өчен көрәшкәндә күренә иде.*

*Халык каһарманнары әнә шундый затлардан туа. Хәтердә ич, Булат Сөләйманов*

*бервакыт хәтта башкаласы Төмән булган "Себер татарлары республикасы" төзергә дә хыялланып йөрде. Һәм, ни кызганыч, чоры ваклыклардан торса, андый шәхесләр озын гомерле була алмыйлар шул...*

***Ризван ХӘМИД**, драматург.*

**РЕДАКЦИЯДӘН.**

Булат Сөләймановның иҗади мирасы күләм ягыннан әллә ни зур түгел. Үз гомерендә ул нибары ике шигырьләр җыентыгы чыгарып кала алды. Ләкин аның Себер рухы белән сугарылган, эчкерсез шигырьләре татар әдәбияты фондында үзләренең лаеклы урыннарын алдылар.

Шагыйрьнең дуслары һәм каләмдәшләре өчен тагын бер сөенечле хәбәр килеп ирешге: якташлары ярдәме белән Булат Сөләйманов турында истәлекләр китабы бастырылып чыгарылачак икән. Кем әйтмешли, бирсен Ходай!

Түбәндә журнал укучыларыбызга шагыйрьнең иҗади мирасыннан берничә шигырь тәкъдим итәбез.

# Булат Сөләйман

## Аучы өенә кире кайтмады

**Аучымы,**
**Аучынымы нидер аулады...**
**Кара урман шомлы шаулады.**

**"Озак йөрмәм", — дигән иде бит.**
**Авылдашлар тирги давылны,**
**Күмеп киткән өчен авылны.**

**У-у-у...**
**Йокламады авыл төн буе.**
**Һәркемнең дә иде бер уе:**
**"Менә-менә кайтып керер ул".**

**Төн үтте...**
**Төн артыннан тагын көн үтте.**
**Аучы өенә кире кайтмады...**
**Авыл өстен болыт каплады.**

## Козыклыкта*

**Йөрим тайга ханлыгында**
**Кояш белән бергәләп.**
**Йөри яз да**
**безнең белән**
**Агачларны иркәләп.**
**Маҗаралар иле бит бу,**
**Балачак**
**һаман исән.**
**Аю булып акырып күк**
**Ешлыктан Аю Хәсән.**

* Козык - эрбет чикләвеге.

Керпе сырты кебек шыткан
Җир сыртында үләннәр.
Алар шундый йомшак,
Атлыйм
Гүя яшел келәмнән.
Агачларда яз бүләге,
Киемнәрнең яңасы.
Чүлдә суга сусагандай,
Эчәм урман һавасын.
Монда дөнья оҗмахыдыр,
Мең төрле ямь
каршымда.
Фәрештәләр сыман кошлар,
Исерә җаным моңга.

Шаулый урман,
мәңге шаула,
Күз карашын иркәләп.
Козыкларны барлап йөрим
Кояш белән бергәләп.

## Учак яктым

Учак яктым
Тайга аланында,
Йөрәгемнән алып бер чаткы.
Күзлене дә
Сукыр иткән төннәр,
Канат җилпеп
Дөрли учак,
кайнар ул,
Якты.
Киң күңелле икән
Аланы да,
Каршыларга җәйгән кочагын.
Якты булсын
Килгән юлчыларга,
Төн дөньясын
Теле белән ялый учагым.
Адашканмы,
Юлдан язганмы ул, —
Әгәр күреп минем учакны,
Дуслык белән килсә
җылынырга,
“Дустым”, — диеп
Эндәшермен аңа
Ул чакны.

Учак яктым
Тайга аланында, —
Үзәгенә үтсен җылысы.
Кешеләргә булган сөюемнең
Учагымда түгел,
Йөрәгемдә яна олысы.

## Әйтмәгез Себерем хакында

Бүлмәмдә саф нарат исләре,
Гомергә иснәп тә туймамын.
Үзләре артыннан ияртеп,
Бүлмәдән чыгара уйларым.

Уйларым артыннан чабам мин,
Тышаудан ычкынган ат сыман.
Тоболга сугылмый үтелсә,
Үземә мин үзем ят сыман.
Әйтәсез:
"Үткәнгә кагылма,
Кыен ул халыкны аңлавы".
Баш куеп тыңлагыз,
Бу җирдән
Ишетелер богаулар чыңлавы.
Йөрәгем аркылы кичерәм
Дәверләр,
гасырлар тавышын.
Бөртекләп җыйган күк
Җыям мин Халкымның шатлыгын,
сагышын.

Әйтмәгез Себерем хакында:
"Үткәндә каргалган җир булган".
Каргалса каргалсын, аңлагыз,
Ул минем туган җир,
И туган як!

* * *

Казанда яз.
Яңгыр ява урамнарда.
Кай җирләрнең суы икән
Шушы яңгырларда?..
И туган як!

*Мәшһүр җырчы Рәшит Ваһаповның тууына 90 ел*

# УМЫРЗАЯ КЕБЕК...



***Рәшит Ваһапов гомеренең соңгы елларында репертуарына "Умырзая" (Ә. Фәйзи шигыре) дигән үтә дә сагышлы, үтә дә моңлы җыр кертә. Бу җырда Рәшит Ваһаповның бөтен язмышы чагылыш таба кебек:***

Умырзая бик тиз үсеп чыга,
Бик аз гына яши тураеп,
Умырзая бик тиз
Башын аска ия,
Умырзая сула, монаеп.

***Әйе, ул бик тиз кабына, татарның иң яраткан җырчысына әверелә, популярлыкның иң югары үрләренә менә һәм, балкып янган ялкын тиз сүнгән кебек, 54 яшендә (1962 елда) бу якты дөньядан китеп тә бара.***

***Еллар үтү белән татар халкының рухи дөньясында Рәшит Ваһапов тоткан урынның зурлыгы, тарихи әһәмияте ачыграк, калкурак чагыла. "Рәшит Ваһапов бөтен татар дөньясын таң калдырган легендар, бөек җырчы иде, — ди аның турында Илһам Шакиров. — Халык җырларын һәм композиторларыбыз әсәрләрен башкаруда ул үзенә бер чор тәшкил итте. Ул башкарган җырларның берсе генә дә халыкка таралмый калмады. Аның югары художестволы, катлаулы һәм музыкаль яктан югары, мелодик яктан мөкәммәл җырлары классик үрнәктәге сәнгать әсәрләре булып калдылар". Кем кем, ә бөек Илһам татар җыр сәнгатендә кайсы җырчының нинди урын тотканын яхшы белә инде.***

***Кабатланмас моң, кабатланмас тавыш иясе Рәшит Ваһапов 40 — 50 елларда иҗат итте. Бу — халкыбыз язмышында бик тә авыр еллар иде. Милли сәясәттәге сталинизм хөкем сөргән, халыкларны юк иту, бетерү сәясәте куәт алган чор бит бу. Бигрәк тә республикадан читтәге татарларга яшәү авыр. Менә шул елларда, элекке СССРның шәһәрләрендә-авылларында булып, Рәшит Ваһапов татар җырының илчесе хезмәтен үтәде. Шул чакта Р. Ваһапов моңнары халкыбыз өчен рухи таяныч булдылар. Шулай итеп, Р. Ваһапов татарны татар итеп саклап калдыруда искиткеч зур роль уйнады. Җырчы буларак, бу аның иң изге, иң саваплы миссиясе иде.***

***Ул сәхнәгә яшьтән үк ишетеп, җырлап үскән халык моңнары белән чыкты. Рәшит Ваһапов иҗаты татар халык җырларын башкаруда тарихи борылыш, югары үрләргә, зур профессионализмга борылыш булды. Халкыбызның бик күп моң җәүһәрләрен профессиональ югарылыкта беренче булып нәкъ менә Рәшит Ваһапов яңгыратты.***

***Р. Ваһапов — Татар дәүләт филармониясенә генә түгел, ә гомумән татар***

*жыр сәнгатенә, профессиональ концерт эшчәнлегенә, татар эстрадасына нигез салучыларның берсе.*

*Ул гомере буе армый-талмый халык иҗатын өйрәнде, аннан яңа җәүһәрләр эзләп тапты. "Урман", "Яшьлек", "Әлфия", "Нурия", "Фирдәвескәй" һәм башка бик күп көйләр халык күңеленә нәкъ менә Рәшит Ваһапов моңнары булып кереп калды.*

*Ә "Яшьлек" җырын исә музыка белгечләре татар җыр сәнгатендә вальс ритмындагы беренче әсәр дип атыйлар. Халык иҗатының бик матур үрнәген — дуэт булып, кара-каршы җырлау алымын да Р. Ваһапов сәхнәгә алып чыкты. Аның Җ. Сәләхова белән бергәләп башкарган "Мәрфуга", "Галиябану" һәм, әлбәттә инде, "Зөләйха" көйләре тыңлаучыны бүген дә таң калдыра.*

*Рәшит Ваһапов — бәхетле җырчы. Әмма аның бөтен гомере сагыш-фаҗига белән тулы. Бәлкем йөрәгендәге ут, эчендәге ялкын әнә шулай сагышлы моң булып тышка бәреп чыккандыр!.. Ул 1908 елның 7 маенда Түбән Новгород өлкәсенең Кызыл Октябрь районы Актук авылында 7 балалы гаиләдә туган. Әтисе — мәшһүр Ваһап мулла. Бу хәл җырчының язмышында фаҗигале роль уйный. 1925 елда Түбән Новгород педагогия техникумына укырга кергәч тә, аннан соң күрше авылларда укытучы булып йөргәндә дә Р. Ваһаповны "мулла малае" дип эзәрлекли башлыйлар. Һәм ул Мәскәүгә юл ала. Биредә "Метростройның" эшчеләр мәктәбендә укытып йөри, үзешчән сәнгатьтә катнаша. Талант иясен күреп алалар, ул Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясенә кабул ителә. Биредә ул сәнгать серләрен үзләштерергә керешә, осталыгын арттыра. Әмма 1937 елны әтисе "халык дошманы" дип кулга алынгач, Рәшит өстендә тагын кара болытлар куера, юллар ябыла.*

*Язмышның бер бәхетле мизгеледер инде: 1941 елда Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында катнашу өчен Р. Ваһаповны Казанга, Татар дәүләт филармониясенә эшкә алалар.*

*Әмма эзәрлекләүләр монда да тукталмый. Бигрәк тә партия оешмасы Р. Ваһаповка нык каныга. Һәр җыелышта диярлек җырчыны чеметеп, аңа тибеп үтәләр. 1949 елны филармониядә "О репертуаре Вагапова в свете доклада т. Жданова" дигән мәсьәлә карала. Ә бу докладның ул чактагы совет сәнгате өчен нинди җимергеч удар булуы яхшы мәгълүм. Р. Ваһаповны репертуарын дөрес сайламауда гаепliләр. Янәсе, "аның җырлары халык күңелендә авыр хисләр, пессимизм уята, тиешле идея рухында тәрбияләми". "Сәяси яктан надан", "партия документларын өйрәнми" һәм башка шундый "гаепләр" җырчы өстенә әледән-әле өелә тора.*

*Ә 1953 елда Хәлиуллин дигән берәү: "Есть элементы национального ограничения — почему заслуженный артист Вагапов не поет русских вещей", — дип тә белдерә.*

*Әлбәттә, боларның барысын да шул заманга хас бер күренеш дип тә бәяләп булыр иде. Әмма ни генә булмасын, алар җырчы күңелен рәнҗеталәр, йөрәген телгәлиләр. Р. Ваһаповның Казанны ташлап китәргә җыенуы уйландырырлык нәрсә. "Тагын бер-ике ел эшлим дә, пенсиягә чыгам, аннары квартирамны Мәскәүгә алмаштырам", — дип яза ул 1960 елда Мәскәүдәге туганнарына.*

*"Рәшит Ваһаповны бөек таланты һәм халыкның аңа булган бөек мәхәббәте саклап калды", — филармониянең ул чактагы директоры М. Ф. Боголюбовның бу сүзләре белән килешми мөмкин түгел.*

*Әйе, Р. Ваһапов халкыбызның гаҗәеп олы мәхәббәтен казанды. Беркемне дә кимсетмичә, ышанып әйтергә мөмкин: Р. Ваһапов — үз заманында татар халкының иң яраткан җырчысы, легендар шәхес иде.*

*Вакыт — иң кырыс хөкемдер ул. Ә Рәшит Ваһаповның якты исеме, аның гүзәл моңнары — бүген дә халык күңелендә. Шагыйрь Ш. Маннапов сүзләре белән әйтсәк, "Киләчәккә халкы белән үзе булып җыры бара".*

Рифат ФӘТТАХОВ

# ИСТӘЛЕКЛӘР

**Илһам ШАКИРОВ,** *Татарстанның халык артисты, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты:*

Без кечкенә чакта өйләрендә радио булган кешеләрне бәхетлеләргә саный идек. Чөнки алар Рәшит Ваһапов, Гөлсем Сөләйманова кебек мәшһүр җырчыларны тыңлый алалар. Ә мин исә сирәк-мирәк очраган патефон тәлинкәләрен әйләндереп хозурланам. Бигрәк тә Рәшит Ваһаповның "Фирдәвескәй", "Яшьлек", "Нурия", "Яңа кара урман", "Әлфия", "Галиябану", "Урман" һәм башка көйләрен кат-кат "әйләндерәм". Соңыннан аңа охшатырга тырышып үзем дә җырлап маташам. Ул чакта әлеге җырлар хыял ирешмәслек бер могҗиза сыман тоела иде.

Урта мәктәптә укыган чагымда район үзәгендә Рәшит Ваһаповның концертлары булачагы мәгълүм булды. Концерт көнен зур түземсезлек белән көтеп алдым.

... Менә сәхнәгә озын буйлы, көләч йөзле, мәһабәт гәүдәле кеше чыгып басты — әле җыр башламас борын ук ул үзенә ихтирам уятып өлгерде. Җыр башланды. Җырлаганда ул хәрәкәтләр бөтенләй ясамый диярлек, көйне-моңны бөтен барлыгында тыңлаучыга җиткерергә тырыша. Тамашачылар асылда радиодан яңгыраган, грампластинкага язылган көйләрне тыңларга теләделәр. Бу аңлашыла да иде: халыкның сәхнәдән җырлаучы җырчының чыннан да Рәшит Ваһапов икәнлегенә ышанасы килә. Җырчы халык сораган һәр җырны авырсынмыйча башкарды. Ә мин аның кыяфәтен күреп, җырларын үз авызыннан ишетеп калгач, озак вакытлар аңа охшатып, "ул булып" җырлап йөрдем.

Казанга килеп музыка училищесында укый башлагач, мине радиодан җырлата башладылар. Бер көнне пианистка Екатерина Соколова белән чираттагы чыгышыбызга хәзерләнгән вакытта студиягә Рәшит ага Ваһапов килеп керде. Башта ул игътибар белән тыңлап утырды да, репетиция тәмам булгач, аркамнан килеп сөйде һәм русчалатып: "Да, душа есть", — дип куйды. Бу зур бәя иде. Әлбәттә, Рәшит абыйның аңа чаклы да мине тыңлаганы булган. Бу очракта аркамнан сыйпап китүен яшь җырчыга фатиха бирү, "канат кую" дип аңларга кирәктер. Аның игътибарлы карашын миңа киләчәктә дә тоеп-сизеп яшәргә туры килде. Репертуарга нинди җырлар сайларга кирәклеге турында дисеңме, тормышта һәм сәхнәдә артист ничек булырга тиешлеге турында дисеңме — ул һәрвакыт үзенең тәҗрибәсе белән уртаклашырга әзер иде.

Консерваторияне тәмамлагач, мине Рәшит Ваһапов эшли торган филармониягә эшкә җибәрделәр. Безгә күп кенә концертларда күп мәртәбәләр бергә чыгыш ясарга насыйп булды. Башта ук шуңа игътибар иттем: Рәшит Ваһапов бервакытта да тавышын күтәреп, тупас сөйләшмәс иде. Ул юмор, мәзәк ярата, анда да кычкырып көлми, елмаеп кына тора. Күз төпләрендә вак кына җыерчыклар беленә башлаган, ә җырларга тотынса, аларның эзе дә калмый; чәчләренә дә чал куна башлаган, җыр башлау белән алар да эреп, юкка чыгалар кебек.

Рәшит Ваһаповның татар халык җырларын башкару үзенчәлеге турында бер-ике сүз әйтәсем килә. Башта ул аларны эзләп таба, репетициядә йөзләгән мәртәбәләр җырлап карап шомарта һәм нәтиҗәдә ул көйләр бары тик Рәшит аганыкы гына булып калалар. Дөрес, ул җырлаган җырларны башка җырчылар да үз репертуарларына алып карадылар, ләкин Рәшит агадан соң аларны йөрәк тә, колак та кабул итә алмады. Ни өчен шулай? Беренчедән, Рәшит Ваһапов җырларның үзенә, башкару манерасына килешеп торганнарын гына сайлап ала белә; икенчедән, кабатланмаслык башкаруы белән аны бары тик үзенеке генә итә ала. Халкыбызның "Урман" җырын гына алыйк. Рәшит Ваһапов бу җырны халык арасыннан табып алды һәм беренче булып башкарды. Аннан соң бу җырны кемнәр генә җырлап карамадылар, юк шул — Рәшит Ваһапов тавышы колакта яңгырый да тора. Бу ни хакында сөйли? Бу — Рәшит Ваһаповның җыр сәнгатендә үзенең ярылып яткан иҗади индивидуальлеге, йөзе булуы, зур шәхес булып калуы турында сөйли.

**Мөхәммәт МӘҺДИЕВ**, *Татарстанның халык язучысы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты:*

Рәшит Ваһаповны мин беренче мәртәбә район сәхнәсендә 1954 елда күргән идем. Мин ул вакытта хәрби хезмәттә идем, чираттагы ялга кайткач ишетәм, Яңа Чүриле дигән район үзәгендә Рәшит Ваһапов, Җәвәһирә Сәлахова концерты була икән. Хәрби хезмәттән шулай ук чираттагы ялга кайткан иптәшем Мансур белән җәйге кичтә ун чакрым араны үтеп клубка килдек. Ләкин бер генә дә буш урын калмаган иде, безгә, хәрбиләр икәнебезне искә алып, урынсыз гына керергә һәм артка барып басарга рөхсәт иттеләр. Сәхнә бик начар яктыртылган иде, шуңа күрә без җырчыларның йөзләрен күрә алмадык. Ләкин бер нәрсә сизелде: кечкенә сәхнәгә ни мәһабәт гәүдәсе, ни куәтле-киң диапазонлы тавышы сыеп бетә алмый иде Ваһаповның. Хәтердә калганы "Эшче" операсыннан Нигъмәт ариясе булды. Рәшит Ваһаповның моң тулы бай тавышы ахырдан кырыс хезмәт шартларында да күңелдә яңгырап торды, иптәш булды.

Берничә ел үткәч, мин аны инде якыннан тыңлау бәхетенә ирештем: бу юлы авыл клубының беренче рәтенә үк билет ала алдым, ә ул рәт теләсә кемгә эләкми, анда колхоз, авыл Советы председательләре, мәктәп директорлары, колхоз партоешма секретарьлары гына утыра. Шулар арасына мин дә эләктем. Ваһаповны якыннан күрү теләгем бик көчле иде. Теге вакытта караңгы клубта минем сиземләвем хак булган: Ваһапов чыннан да бер үзе сәхнәне тутырып тора иде. Баянчысы Фәйзи Садыйков иде. Рәшит Ваһапов ул концертта "Фирдәвескәй", "Нигъмәт" ариясен җырлады. Халыкка иң нык тәэсир иткәне шулай да "Кара урман" булды, ахрысы. Мин бу җырның ничек башкарылуын сөйли алмыйм, аны сөйләр өчен музыка сәнгате терминнарын белергә кирәктер. Шунысын гына әйтә алам: Ваһапов бу җырны бик акрын, басынкы тавыш белән башлады, әйтерсең ерак тарихтан борынгы бабалар безгә эндәште; сәхнәдә мәһабәт гәүдәле, затлы кырыс костюмнан, идәнгә ышанычлы баскан артист тора иде — менә тавыш көчәя, көчәя, халык әсәрләнә, сәхнә белән зал бер тын ала башлады.

Кара да гынай урман уртасында
Төлке уйный торган орлар бар...
Типсен лә генә йөрәк, сүнмәсен дәрт, —
Дәртлеләргә якты юллар бар.

Сәхнәдән шулай җитди, саллы тарихи моң, аһәң агылды. Ул җыр шул көннән башлап минем йөрәгемдә яши, минем күңелемә фәкыйрьләнергә юл бирми. Ләкин минем күңелемдә ул җыр гына түгел, аны халыкка җиткергән талант иясе Рәшит Ваһапов та яши. Бик күп вакыт концертларга җибәрми ул мине, телевизорны да кайвакыт сүндерергә мәҗбүр итә: Ваһапов сәхнәдә кыланмый, шамакайланмый, тамашачы белән сөйләшми, сүзләрне, басымнарны бозмый — ул бары тик җырлый гына иде. Әйе, сәхнәдә җырчы бары тик җырларга гына тиеш. Җырлаганда сүзләрне бозмый дигәнемә бер чыгарма да бар: Ваһапов "Яшь гумер" дип әйтә иде. Ләкин бу кимчелек аның мәһабәт гәүдәсенә кара урман шавы кебек тигез, саллы мәһабәт тавышына ятышлы тоела иде, мондый ир "гомер" дип әйтсә, сәхнә өчен ул азрак, ят булыр сыман иде.

Рәшит Ваһаповның тамашачы белән, зал белән халык моңы, тарихы аркылы контактка керү традициясен соңрак Илһам Шакиров, Хәйдәр Бигичевлар дәвам иттерделәр, үстерделәр. Димәк, Рәшит Ваһапов мәктәбе бүген дә яши. Бу инде сәнгать кешесе өчен үлемсезлек дип атала.

**Динә СИРАҖЕТДИНОВА**, *Татарстанның атказанган артисты:*

1951 елның язы. Казан консерваториясен әле генә бетергән чак, мине Г. Тукай исемендәге Татар Дәүләт филармониясенә эшкә чакырдылар. Моңа кадәр мин, консерваториядә укуымны дәвам иткән хәлдә, опера һәм балет театрында солист булып та эшләдем. Филармония оештырган концертларда да еш катнаша идем. Шуңа күрә, концерт оешмасында эшләү тәкъдимен рәхәтләнеп кабул

иттем, чөнки миңа иҗат эшчәнлегемә киң мөмкинлек ачылган кебек тоелды. Һәм мин ялгышмадым. Иҗат юлымда шактый күренекле кешеләр очрады һәм аларның берсе татар халык җырын эстрадага алып чыгучы, мәшһүр Рәшит Ваһапов иде.

Р. Ваһапов белән беренче сәяхәтебез Башкортстан буенча булды. Ваһапов озын буйлы, матур гәүдәле, чибәр һәм бик мөлаем кеше иде. Зур эчке культуралы, затлы икәнлеге әллә каян күренеп тора, бу, мөгаен, ата-бабаларыннан, "кан"нан килгәндер.

Беренче мәртәбә Рәшитнең җырлавын ишеткәч, мин аның тышкы кыяфәте белән тавышының тулы гармониядә булуына хәйран калдым: тавышы көчле, аңа гына хас булган киң диапазонлы лирик-драматик тенор. Безнең гастрольләр кайда гына булмасын — шәһәрләрдәме, авыл җирендәме — зур уңыш белән үттеләр.

Алга таба гастрольләребезнең маршрутлары бик төрле булды. Мәскәү, Ленинград, Балтик буе, Себер, Урта Азия, Казакъстан, Үзбәкстан... Һәм тагын әллә кайларда концертлар бирдек.



*Рәшит Ваһапов иҗатташ дуслары белән. Беренче рәттә (сулдан уңга) К. Басыйров, Ә. Яһудин, Р. Ваһапов, Ж. Сәлахова, Ф. Биккинин. Икенче рәттә — С. Алеев, Ф. Садыйков.*

Шулай да Мәскәүдә, Ленинградта аеруча еш була идек. Аны яхшы беләләр иде. Радио аша җырлаулары, пластинкалары җырчыны нык популярлаштырдылар: Себергә, Ерак Көнчыгышка кадәр барулар — онытылмаслык очрашулар... Декабристлар сөргендә булган тарихи урыннар белән танышу, дулкынландыргыч тәэсирләр...

Хәтта шушы ерак төбәкләрдә дә Ваһаповның исеме билгеле иде.

Рәшит ага мәрхәмәтле, тыйнак һәм акыллы кеше иде, ялгызы ул бик сирәк кала, аның тирәсендә һәрвакыт кешеләр күп була, ул алар белән тиз танышып китә һәм сәгатьләр буе сөйләшеп утыра ала. Кайчак без аңа: "Рәшит, тавышыңны кичкә калдыр, сиңа бит әле җырларга да кирәк", — ди торган идек. Мона

каршы ул көлемсерәп: “Минем тавыш көндезгә дә, кичкә дә житәр. Мин сөйләшми тора алмыйм”, — дип жавап бирә иде.

Ул — яхшы гаиләчел кеше иде. Анын ике баласы үсә, хатыны — балерина, опера һәм балет театрында эшләде, тагын хатынының әнисе һәм кыз туганы — аларның барын да ул үз канаты астына сыйдырды.

Безнең гастрольләр һәрвакыт озакка сузыла: юлдан, еш күчеп йөрүләрдән, кунакханәләр тормышыннан туйган, арган чакларда ул үзенең юморы белән киеренкелекне киметә, күңелне күтәрә иде. Мәсәлән, берчак шундый хәл булды: Свердловск шәһәре вокзалында поезд көтәбез. Кинәт көтүчеләр арасында ыгы-зыгы башланды: бер кызның чемоданын урлап алып киткәннәр икән, ә шул вакыт радиодан поездга утырту башлануын хәбәр иттеләр. Барлык халык платформага чыкты. Безнең артистлар әлеге чемодан югалуы тәэсирендә состав янында тын гына торалар. Р. Ваһапов кинәт куркынган тавыш белән: “Фәйзи, әнә, баяныңны вагон астына алып кереп киттеләр!” — дип кычкырып куймасынмы... Фәйзи Садыйков вагон астына ташланды, ләкин беркадәр арлы-бирле йөгергәннән соң, беркемне дә тапмыйча, кире әйләнеп кайтты, ә баян үз урынында тора. Ваһаповның шаяртуын аңлап, чын күңелдән көлештек.

Җәйләрен без районнарга чыга идек. Нигездә Татарстан буенча йөрдек. Анда башка дөнья ачыла: киң күңелле авыл кешеләре, бары да тыныч, хәтта тормышыбызның темпы да үзгәрә. Безнең табигать бик шәп: бер Идел генә дә ни тора! Ә урманнар, күлләр... Бу чор безнең өчен чын-чынлап ял була иде.

Ваһапов сәхнәгә чыкканда, аның башы түшәмгә тия яза. Әмма аның мона исе китми һәм ул, гомумән, пошына белмәде. “Мин әле авылларыбызда менә дигән культура сарайлары төзегәннәрен, ә гастрольләргә шәхси вертолетларда йөргән чакларны көтәчәкмен”, — ди торган иде ул шаяртып. Ләкин, кызганыч, күп үзгәрешләрне күрергә насыйп булмаган аңа. Шул артык гади залларда җырлаган чакта, Рәшит югары ноталар алса, аның көчле тавышыннан пыялалар зеңгелдәп куя иде.

Кайчак халык күп җыелып, клубка сыймаганда, безгә урамда чыгышлар ясарга туры килгәләде. Гадәттә сәхнәне ике автомашина өстендә оештырып, саф һавада җырлыйбыз, микрофон булмаса да тавыш яхшы чыга. Халык канәгать, ярты төннән соң гына таралалар.

Бу уникаль кеше турында тагын күп сөйләп булыр иде: ул эчкечелекне куралмады, үзе эчмәде дә, тартмады да, сүгенүне дә яратмады. Бригадада һәрвакыт дуслык атмосферасы хөкем сөрде. Башкача булса, ул сугыштан соңгы авыр елларда уңышлы эшләп тә булмас иде. Ач атларга утырып, авылдан авылга йөрдек бит.

Бары да булды, бары да...

Авылга килү белән клуб мөдире безне фатирларга урнаштыра һәм концертка килә алмый торган өлкән яшьтәге кешеләрнең Ваһаповны үз өйләрендә көтүләрен әйтә. Ул, күчтәнәч алып, көндез алар янына ашыга, озаклап әңгәмә кора, азактан алар өчен җырлый.

Еллар үтте, истәлек кенә калды...

Ваһапов безнең арадан бик иртә китте — аңа бит 54 яшь тә тулмаган иде әле. Аның белән бергә булган авылларга янадан килгәндә, күпләр аны күз яшьләре һәм рәхмәт хисләре белән искә төшерәләр иде.

Р. Ваһапов үзенең чибәрлеге, ягымлылыгы һәм менә дигән тавышы белән халыкта һәрвакыт зур уңыш казанды һәм аңа гашыйк булучылар да шактый булды. Бервакыт Себердә шундый хәл булды: Новосибирскида концерт бара, филармония залы тулы. Концерт вакытында Ваһапов мине һәм биюче Любаны концерттан соң бинадан бергә чыгабыз дип кисәтеп куйды һәм аның янында булуыбызны үтенде. Кулында гашыйк булучылардан кичке ашка чакырган берничә язу бар иде.

Залдан чыкканда без Ваһаповны ике яктан култыклап алдык, ә аны “гашыйклар” көтеп торалар иде инде, һәм, безгә гаҗәпләнеп карый-карый, аның белән сөйләшә, кунакка чакыра башладылар. Мин сорауларга җавап бирер өчен беркадәр вакыт бирдем дә, түземсезлек белән: “Рәшит, тоткарланма инде,

әйдә тизрәк, безнең бала җылыйдыр, мөгаен", — дим. Шуннан соң гына без машиналарга үтеп, утырып китә алдык. Менә шул рәвешле "спектакль" уйнап, без аны еш кына табынучыларыннан коткара идек.

Ваһапов татар халык җырларын искиткеч яхшы башкаручы булды. Аның җырлары үзенчәлекле мелизмнар, һәр әсәрне үзенә бер төрле башкаруы белән аерылып торды. Композиторлар әсәрләрен, мәсәлән, "Менәргә иде Урал тауларына" яки башкорт халык җыры "Азаматны" бик оста җырлады. Аның репертуарында башка җырчыларның "теше үтмәгән" "Әлфия", "Зәйтүнәкәй", "Нурия", "Рәйхан" кебек һ. б. әсәрләр дә бар иде. Бу әсәрләр югары регистрда, артист үз тавышына тулы ирек биргәндә бигрәк тә яхшы яңгырадылар. Менә аның күркәм тавышының киң диапазоны мөмкинлек бирә иде.

Ваһапов белән "бик яхшы" таныш булулары белән мактанып, файдаланучылар да табылып торды. Шундый очрак истә: поездда Себер якларына барабыз: станцияләрнең берсендә безнең купегә бер урта яшьләрдәге татар керде һәм, безгә таба караштырып алгач, сүз башлап: "Миңа биредә артистлар бара дигәннәр иде!" — диде. Без: "Әйе", — дибез. Ул алга таба дәвам итә: "Мин артистларны бик хөрмәт итәм, танышларым да бар. Сез Ваһаповны беләсезме?" Без: "Әйе, беләбез", — дибез. Рәшит шунда безгә күз кысты, сиздегезме, янәсе. Без: "Ә Сез аны яхшы беләсезме?" — дип сорыйбыз. "Әйе, — ди ул. — Миңа аның белән Әстерханда очрашырга туры килде." "Ничек?" — дип сорауга ул: "Без аның белән ресторанда очраштык та төне буе типтердек, һәм икенче көнне дә, администраторлары килеп алып киткәнче, "бәйрәмне" дәвам иттердек", — ди. Без Рәшит белән карашып алдык, ниһаять, ул түзмәде һәм: "Рәшит Ваһапов — мин булам, әмма минем һичкайчан да Сезнең белән таныш булганым юк, һичкайчан да Сезнең белән эчмәдем, һәм мин, гомумән, алкогольдән ерак йөрим. Ничек Сезгә оят түгел алдарга, бер мәртәбә дә күрмәгән кешегә пычрак атарга?!" — диде

Күрсәгез иде ул кеше белән ни булганын: башта ул кызарынды, аннан урыныннан сикереп торды да күз ачып йомганчы, чыгып югалды. Без аны бүтән күрмәдек. Менә шундый хәлләр дә булгалады!

Рәшит Ваһапов белән соңгы гастрольләребез 1962 елда булды. Без җәй буе Татарстан авылларында эшләдек. Бу юлы Ваһапов үзе белән гаиләсен дә алган иде, өч айга якын һәркөн концертлар барды.

Авылларда аңа яшьләр тавышларын тыңлап каравын үтенеп, алга таба укырга бару мөмкинлеге турында киңәш бирүен сорап мөрәҗәгать итәләр. Ул аларны игътибар белән тыңлап, киңәшләрен бирә.

Хәтерлим әле: Сарманда без кунакханәдә яшибез, ә концертларга аерым сәгатьләрдә барып киләбез. Анда бик көчле үзешчән коллектив бар иде. Без Рәшит белән аларга булдыра алганча ярдәм иттек. Гастроль азагында, безне райкомга чакырып, ярдәм өчен рәхмәт йөзеннән Мактау кәгазьләре бирделәр.

Соңгы концертларыбыз Актаныш районында булды. Казанга пароходта кайттык. Рәшит сиздермәскә тырышса да, авырый башлаган иде инде...

Казанга кайткач, без айлык ялга китеп бардык. Аннан соң Украинага барырга тиеш идек, ләкин язмыш башкача хәл итте. Без эшкә чыкканда, Рәшит хастаханәдә иде, ә декабрьдә инде ул вафат булды. Безгә вакытлыча гастрольгә чыгарга туры килде. Көннәрнең берендә көчле буранда клубка концерт куярга килсәк, безне аның вафаты турында телеграмма көтә иде.

Җыелган халыкка бу турыда концерттан соң гына хәбәр иттек. Бөтен зал аякка басып елады — халыкның Рәшит Ваһаповка мәхәббәте шундый көчле иде.

Кыскасы, ул гаҗәеп күркәм кеше, талантлы артист, чын мәгънәсендә халык җырчысы иде.

Китап күзәту

# ОЛЫ ӘДИП "КИЧҮ"Е

Соңгы елларда укучыга барып ирешкән "Кичү" исемле романында Нурихан Фәттах сугыштан соңгы еллар тормышы белән бәйләнешле бик житди мәсьәләләрне күтәрә. Әсәрдә тоталитар системага корылган гаделсез җәмгыятьтә чәчәк аткан әхлаксызлык, икейөзлелек, караклык, хаерчелек күренешләре ачып салына, ачы тәнкыйть ителә. Әдипнең балалык, яшьлек елларының да нәкъ шушы чорга туры килүе һәм аның әсәрне үз күргәннәренә, шәхси кичерешләренә таянып язуы эпизодларның тормышчан дөреслеген тагын да көчәйтә.

"Кичү" романының дөньяга килү тарихы да катлаулы. Әсәрнең язылу еллары 1956 — 1962 һәм 1988 — 1990 дип куелган. Китапка "Сүз башы"нда автор болай ди: "...роман-эпопея кимендә дүрт кисәктән торырга һәм сугыштан соңгы еллардагы татар тормышын чагылдырырга тиеш иде. Мин тормышны үз генә бозмыйча, бизәмичә күрсәтергә, һәр нәрсәдә, аеруча халык тормышын һәм милли мөнәсәбәтләрне тасвирлаганда дөреслекне ярып салырга тиеш идем.

Роман баштарак "Таяныч" дип, соңга таба беркадәр китапчарак "Хыял вә хаят" дип аталды. Әлеге исемнәрдән күренеп торганча, өстебезгә бик авыр йөк алмакчы идек без. Ләкин нихәл итмәк кирәк, чынбарлык хәтта хыялдан да көчлерәк булып чыкты. "Хыял вә хаят"не 1963 елга кадәр яздым да, ары дәвам итәргә куәтем житмичә тукталып калдым. Ул елларда бар нәрсәне буып торган милли террор һәм рәхимсез мохтажлык әсәремне тиешенчә очлап чыгарга ирек бирмәде дисәм, мондый сүзләр хәзер аклану булып аңлашылмас дип уйлыйм. Чөнки дөресе шулай".

Илленче еллар уртасында ук языла башлаган әсәр фәкать туксанынчы елларга кергәч кенә үзенең укучысын эзләп тапты, әмма укучыга да, язучыга да җәмәгатьчелекнең бу әсәр турындагы фикерен ишетергә насыйп булганы юк әле. Бәлки безнең менә бу тәҗрибәбез әлеге бушлыкны тутыру теләгеннән бер аваз булыр.

Романдагы вакыйгалар Башкортстанның Янавыл дигән җирендә барса да, аларны күп татар авылларында сугыш беткән елларда булып үткән вакыйгалар рәвешендә кабул итәсең. Әле генә урта мәктәпне тәмамлаган яшүсмер егет Габделхәй белән без аның киләчәккә зур өметләр баглап йөргән чорларында очрашабыз. Аның әйләнә-тирәсендә мәктәпне тәмамлап чыккан бер төркем яшьләр, мәктәпнең укытучылары коллективы... Галиләр, әчкерсезләр, дәрәҗә саклап йөрүчеләр, хәйләкәрләр, икейөзлеләр, туклар һәм ачлар... Болар бөтенесе, романдагы вакыйгалар тормышка сабыйларча беркатлырак карый торган, саф, намуслы, чиста күңелле Габделхәй күзәтүләре, бәяләмәләре рәвешендә әсәрнең сюжетына үреп барыла.

Әсәр бер төркем яшүсмер егет-кызларның шау-гөр килеп, чыгарылыш кичәсенә әзерләнеп йөрүләре күренеше белән ачылып китә. Бу яшьләрне алда куанычлы хәбәрләр, шатлыклы көннәр көтә. Шатлыкларның беренчесе — урта белем турында өлгергәнлек аттестаты алу, икенчесе — классташлар, укытучылар белән җыйналып, чыгарылыш кичәсендә утыру, ә өченчесе — югары уку йортына керү. Яшьләрнең куанычына аларның үзләре кебек үк саф, чиста язгы табигать тә кушыла.

Ләкин олы тормыш юлы, яшьләр көткәнчә, алай ук ал да гөл түгел икән. Әйләнә-тирәдәге дәрәҗәле абзыйларның исәпләре гел яхшыдан гына булып чыкмый. Шундыйларның берсе — хәрби эшкә катнашы булмаса да, һәрвакыт погонсыз китель белән хәрби фуражка киеп йөрүче мәктәп директоры Василий Михайлович (Вәсби Алдынский). Башыннан алып аягына кадәр формалист бу кеше, укытучы буларак әллә ни мактарлык эш кырмаса да, ни сәбәптәндер, директор буларак, бөтен районда, республикада яхшы исәптә йөри. Чөнки ул өстән төшерелгән күрсәтмәләрне берниндн каршылыксыз үтәп, район житәкчеләренең күңелләрен күрә, ә үзенә буйсынучыларны кулында кысып тота белә. Мәктәп эшләрен дә ул бик оста оештыра. Әнә чыгарылыш кичәсен нинди мул итеп үткәрә: таныш-белеш, дус-ишләре — берсе дә гади кеше түгел. Кайсы склад мөдире, кайсы колхоз рәисе, кайсы ит комбинатында бухгалтер.

Вәсби Алдынский — тоталитар режимга каршылыксыз яраклашкан кеше. Кайчандыр Габделхәйләр кебек ул да шигырьләр язгалаштырган, ләкин шигырьләре тәнкыйть ителгәч, бу эшне ташлаган һәм шуның аркасында үзенә янаган төрмә куркынычыннан котылып исәнимин калган. Тора-бара укытучылыгын да ташлаган ул: тимер юлга эшкә кереп, Янавыл халкы черек бәрәңге ашаганда, ул "пух" итеп яшәгән. Дус-ишләр аркасындамы, авыру-сырхауга салышып йөргәнгәме — сугышка барудан да котылып калган. Ә хәзер аның төп максаты — бөтен ил күләмендә уздырыла торган "интернациональ

процессны" — "национальный мәктәптән урысчага күчү"не оештыру: "...вапшем безне татар мәктәбе харап итә..., безнен өчен ин дөрес юл — әкренләп татар мәктәпләрен урысчага күчерә бару... Нигә безгә артта калырга? Так вот, башка жирләрдә татар мәктәпләре бетә. Без кемнән ким?»

Вәсби Алдынский — Василий Михайлович — үзе куптәннән инде "урыс". Халык анын чын татарча исемен дә оныткан, сөйләшүе дә урыслашкан. "Бөек милләт вәкиле" — рус теле укытучысы Антонина Семеновна анын портреттагы дәрәжәле кешенеке кебек итеп үстерергә тырышкан мыегын "бу мыегыгыз белән сез татар-монгол игосы заманнарындагы кысык күзле варварларны хәтерләтәсез", — дигәч, (28 бит) анысын да кырып ташлый, шулай итеп үзенен "татарлыгыннан" тулысынча котыла.

Әсәрдә аеруча кискен куелган мәсьәләләрнен берсе — тел һәм милләт язмышы. Хөкүмәтнен яна "реформасы"н әсәрдәге геройлар куркү катыш шомлану белән көтәләр. Чөнки бу реформа куп кешеләрне эшсез калдыра: татар бакчалары, мәктәпләре ябылу куркынычы астында. Габделхәй, Сәкинә кебек талантлы яшьләрнен үзләре теләгән һөнәрләре буенча югары уку йортларына керү юллары бикләнә. Әсәрдә урта мәктәпне бик яхшы билгеләренә генә тәмамлаган Габделхәйне, ул фәкать татар милләтеннән булганы өчен генә, алтын медальдән мәхрүм итүләре үзе бик куп нәрсә хакында сөйли түгелме сон?

Романда сугыштан сон авыл игенчеләре тормышын сурәтләүгә зур урын бирелгән.

Инде сугыш беткәнгә байтак вакытлар үзса да, бу жирләр сугыш уты астында калмаган булса да, татар авылы "фашист гаскәрләре ватып-жимереп киткән украин, белорус авылларын" хәтерләтә: "Кое сиртмәсе янындагы яртылаш жимерелгән мич калдыгы, очы сынган ялгыз чыршы — барысы да, барысы да сугыш елы киноларындагы, фотоларындагы кебек. Тик менә күккә күтәрелгән төтен баганалары күренми дә, жир өстендә аунап яткан мәетләр генә юк... Кайчандыр бай, купшы булган, хәзер инде тәрәзәләре аркылы-торкылы такталар белән калакланган, чолан такталары каерып алынган бу нык, таза, ләкин үле йорт яныннан узганда Габделхәйнен күнелендә чиксез кызыксыну да, курку-шомлану да уяна торган иде. Бу турыдан ул тиз-тиз генә узып китмәкче булды һәм жансызөнсез, әмма каберлек сыман серле истәлекләр белән тулы тәрәзәләргә, кәрнизләргә озаклап карамаска тырышты" (176 бит).

Гади игенче өенә керсән, анда шыксыз хәерчелек. Габделхәйнен картәтәләре ачлыктан тилмерә, ә бит бу өйдә көн-төн колхоз кырында эшләүче таза-сау өч кеше бар. Бала-чагасы да хезмәттә. Гаиләгә азрак файда булмасмы дип чабата тукучы картәтәгә "чабата" налогы салу белән янайлар. Башта "кансамул", аннан "фартия", аннан "ата каманист" булып киткән, сугыштан яраланып кайткан яшь бабай көн-төн колхозда эшли, ләкин анын да көнлек хезмәт хакы 300 грамм оннан артмый. Үз халкын, игенчене әнә шулай алдап, талап, колларча бил бөктереп яшәргә мәжбүр иткән тоталитар система әсәрдә бөтен ялангачлыгы белән күз алдына килеп баса. Авыл халкы мондый тормыштан канәгать түгел, ләкин ул бу коллыктан чыгу юлларын таба алмый.

Габделхәй кебек яшүсмерләр, килеп туктаган поездларда таза-тук чырайлы, тишексез, ямаусыз, матур киемле кешеләрне күрәләр күрүен, ләкин бу кешеләр кебек булу өчен читкә китәргә, ә читкә китәр өчен паспорт кирәк. Тоталитар хакимият ач, ялангач крестьянны жиргә мәжбүри бәйләп тору юлын тапкан — крестьянга паспорт бирелми.

Кабалалан чыгасын килә икән, "дус-иш" тап. Ә дус-иш, кода-кодагый кулында бөтен нәрсә, хәтта закон үзе дә. Тыныч кына, матур гына жайлаша белсән. Дәүләтгәрәй абыйлар кебек мул тормышта яшәрсен, ә бәлки иптәш Сафин Мунир Мунировичлар кебек үсеп "Кеше" дә булып китәрсен... Яшь егет кайсы юлны сайлар? Дөрес, ана "милләте башкорт" дигән паспортны ясап бирәләр бирүен... Ләкин Габделхәй үзе татар булгач, анын мондый документны аласы килми. Аннан сон "бу билгесезлектән, хәерчелектән ничек котылырга инде?" дип йөргәндә кемнәрдер "хәрби училищега китәсен" дип егетнен киләчәген хәл итеп куялар. Мондый "шатлыклы" көннәрдә биек трибунадан иптәш Сталин да "бәхетле" Габделхәйгә аталарча кул болгаган сыман тоела. Язмыш кемнәр тарафыннандыр хәл ителгән, киләчәген матур — тик син милләтеннән, иманыннан, теленнән баш тарт; менләгән хәерчеләрне, ачялангачларны гына күрмә. Шулай итеп, Габделхәйгә дә милләтнен бик куп талантларын йоткан зур машинанын бер шөребе генә буласы кала.

Әлбәттә, рухи яктан азатлыкка чыгарга омтылган яшь егет үзенчә тартыша, каршылык күрсәтә, курка-курка гына булса да, "зур абыйлар"га үз фикеренен дөреслеген расламакчы була. Явызлык, галелсезлек дөньясында якты нур булып торган Габделхәй, Сәкинә, Былбылларнын самими саф хисләре, уйлары, кылган гамәлләре укучы күнелендә киләчәккә өмет чаткысы да уята.

Зур әдип, фикер иясе Нурихан Фәттах бу әсәре белән үзе яшәгән чорда хакимлек иткән тоталитар системанын чын йөзен ачып, анын милләт иреген, шәхес иреген буып торуын, гади халыкны, аерым милләтләрне коллыкта яшәтү яисә бөтенләй юкка чыгару өчен бөтенесен эшләвен күрсәтә алды. Әдәбиятта социалистик реализм өстенлек иткән бер чорда Нурихан Фәттахнын "Кичү" романын язып бик купләрне борчыган кискен проблемаларны күтәрүе һәм аларны хәл итүнен үзенчәлекле юлларын эзләве ижади каһарманлык булып кабул ителә.

Әлфинур НӘЖИПОВА

# IMEŞ–MIMEŞ TYGEL

## Səngət qorbannar sorьj

Oşbu xikmətlər Kamal teatrь artistlarь Şərif Xəsəjenefneŋ "Əni kilde" piesasьn səxnəgə qujgan çitmeşence jьllarda başlana.

Bu tamaşada məşһyr artist Şəwkət Biktimeref awьru ənisen tərbiə qьlьrga teləməwce, çəmgiəttən majlь qalçanь kybrək qajьrьp, yze aŋa jynləp birergə teləməyce Islam digən bəndəne ujnьj.

Premjeranьŋ ikence kənendə yk ber əzməwer Şəwkət Biktimerefne uramda ocratьp, izyennən eləkterep ala:

– Əһə, eləkteŋme! Mine taɡьn ber mьsqьl itsəŋ, yzeŋə ypkələ, agajne! Beterəm min sine!.. – di ul, awьzьnnan svizi araqь ise aŋqьtьp.

Artist qauşap–aptьrap qala:

– Tuqtale, iptəş, tuqta. Minem qajcan sine mьsqьl itkənem bar? Minem sine əlegəcə kyrgənem də juq labasa, – di ul.

– Kyrgəneŋ juq, ə yzeŋ səxnədə ut belən ujnьjsьŋ. Matri, peləş baş! – dip əzməwer, janьj-janьj kitep bara.

Şəwkət Biktimeref şuşь ocraşu turьnda "Əni kilde" piesasьnьŋ avtorь Şərif Xəsəjenefkə səjləgəc, tegese kələ genə:

– Ə–ə, alajsa tege... miŋa tugan tieşle agajne inde ul. Min Islam obrazьn şuŋa qarap jazdьm bit, – di. – Qurьqma, şulaj ətəclənsə də, qujan jərəkle ul, – dip, artistnь tьnьclandьra.

* * *

"Əni kilde" spektaklendəge jynsez Islamnь ujnagan əcen Şəwkət Biktimerefkə ikence "һəçym" Baulь rajonьnьŋ Aqbua bistəsendə gastrol'də waqьtta bula.

Ujьn barьşьnda kyrə Şəwkət Biktimeref-Islam: zalnьŋ berence rətendə utьrucь aq jawlьqlь ber əbekəj aŋa əledən-əle nəfrəten belderep, jodrьq kyrsətə. Ikence pərdədə Islam-Şəwkət abьjnьŋ: "Min gəmerem bujь şaxtada eşləp birtelep bettem, inde qajtьp keşecə rəxətlənep jəşərgə çьjьngdanda gьna, miŋa awьru ənine qararga quşasьz!" – dip əjtye bula, tege aq jaulьqlь əbineŋ kizənep torьp, moŋa taş tondьrub bula!

Spektakl' təmamlangac, teatrnьŋ baş rizissjorь Marsil' Səlimçanof səxnəgə kytərelep, Şəwkət Biktimerefneŋ qulьn qьsa:

– Molodis! Bygen səxnəgə ьrgьtьlgan taş – sineŋ ujьnьŋa iŋ zur bəjə! – di ul.

– Bəjəsen bəjə də bit, ul taş cyt kenə minem başьma eləkmi qaldь! – di artist.

Səlimçanof gəreldəp kələ:

– Eləksə də bernişləp bulmьj, tugan. Səngət qorbannar sorьj, – di ul.

* * *

Şəwkət Biktimerefnen, əlege kirebetkən Islam obrazь arqasьnda kyrgən mixnətlәre əle bolar belən genə betmi. Uljan şəhərenə gastrol'gə barqac, Şəwkət abьjnьn səxnədəge partnjorь, unaj geroj — Insafnь ujnawcь Irek Baнmanof sьrxaulьj. Nişlərgə? Rezissjor belən kinəşkənnən son, bu rolgə teatrnьn administratorь Kamal Nizamnь qodalarqa bulalar.

— Belmim şul... — di Kamal Nizam, — buldьra alьrmьnmь ikən? Min bit anda ni səjlərgə ikənen də jynləp belmim...

— Anda əlləni səjləp torasьn da juq sinen, — dip ygetli Şəwkət abьj. — Min yzem sina bulьşьrmьn. "Sin suqьşta bulьp, ike ajaqsьz qalsan da, pinsəne minnən az alasьn. Min şaxtaqa təşep qaramasam da, şaxtjor sanalьp, uc tutьrьp alam aqcanь! Fələn-təgən..." — dip, min sinen acuьnnь cьgarьrmьn. Sin şul waqьt: "Aн, qəbəxət! Bədbəxet!" — dip, mina berne tamьzьrsьn. Barь şul qьna...

— Nu anьsьn qьna buldьram min! — di Kamal Nizam, rizalaşьp.

Həm nicek buldьruьn spektakl' barьşьnda kyrsətə bu. Bala başь qədər jodrьqь belən Biktimeref-Islamnьn jəzenə şundьj itterep tamьza ki, Şəwkət abьj calqan əjlənep təşə. "Şul kirək ul bədbəxetkə!" — digən awazlar janqьrьj.

Spektakl' təmamlanqannan son, Şəwkət Biktimeref sorьj partnjorьnnan:

— Sin nişləp qotьrьp kitten? Cyt kenə tege dənjaqa olaqtьrmadьn mine! — di.

— He, — di Kamal Nizam əstən asqa qarap. — Yzen suq! — diden bit. Əle dəp itep tibərgə də ujlaqan idem, bəxeten: jodrьq belən genə cəpədem!

* * *

Şul uq, "Əni kilde" spektaklendə unaj gerojnь, ike ajaqsьz frontoviknь — Ananьn insaflь ulь Insaf rolen başqarqan kyrenekle artistьbьz Irek Baнmanofqa mənəsəbət başqacaraq bula. Spektakl' təmamlanqac, artistlar tamaşacьqa baş iərgə bergələp səxnəgə cьqalar. Şul waqьt urta rətlərnen bersennən başьna kələpyş kigən ber abzьj kytərelə. Tajaqqa tajanqan. Hər adьmь sajьn protizь şьqьr-şьqьr kilə. Zal monь işetep-kyrep, tьnьp qala. Abzьj keşe awьrlьq belən genə səxnəgə kytərelə, tup-turь Irek Baнmanof janьna kilə, anь jaqьn tuqanьn ocratqandaj, nьq itep qocaqlьj da başьn artistnьn inenə qujьp tьnьp qala. Annarь kyz jəşləren qul arqasь belən sərtep, ləm-mim ber syz əjtmicə, səxnədən təşep kitə. Zal uşьna kilep, alqьşlarqa kymelə.

— Səxnədə kypme ujnap, əlege frontovik abzьj innəremnən kilep qocqandaqь kebek dulqьnlanqanьm bulmaqandьr, — di Irek Baнmanof. — Minem əcen in qəderle bylək şikelle bulьp xəteremdə qaldь ul abzьjnьn syzsez rəxməte.

* * *

Anьn qarawь, urьscadan tərçemə itelgən ber spektakl'də əlkəş ferma mədire bulьp ujnaqannan son qatь eləgə Irek Baнmanofqa. Dəresrəge, anьn xatьnь Rəşidə apaqa eləgə. Kicen əlege tamaşanь qarap qajtqan kyrşe jorttaqь əbi ikence kənne Rəşidə apanь kibet ciratьnda ocrata:

— Sin tege... Irek Baнman digən nəməstənen qatьnь bit, imə?

— Əje, əbi, şunьn xatьnь min, — di Rəşidə apa.

— I-i, balam, i balaqajьm. Sin ul adəm təqənəse belən niceklər jəşisen? Bigrəklər də ecə ikən bit ul. Kicə tiəterdə kyrep isem-aqьlьm kitte... — di əbi, cirattaqь keşelər aldьnda Rəşidə apanь şaqtьj unajsьz xəlgə qujьp.

Nişlisen bit, baş rezissjor Marsil' Səlimçanof əjtmeşli, səngət qorbannar sorьj şul inde...

**Şamil MANNAPOF**

## *Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан*

*РӘСМИ ХӘБӘРЛӘР*

### СВЕРДЛОВСК ӨЛКӘСЕНДӘ — ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ КӨННӘРЕ

Свердловск өлкәсендә татар әдәбияты көннәре булып үтте. Әлеге чара Җөмһүриятебез Премьер-министры Ф. Мөхәммәтшинның Екатеринбург каласына визиты вакытында Татарстан һәм Свердловск өлкәсе арасында килешенгән мәдәни программалар кысасында үткәрелде.

Әдәбият көннәрендә язучылардан Мөсәгыйт Хәбибуллин, Җәүдәт Дәрзаман, Галимҗан Гыйльманов, Газинур Морат катнашты. Алар өлкәнең ике районында булып, халык белән очраштылар.

Сәнгатебез осталарыннан Клара Хәйретдинова, Искәндәр Биктаһиров, яшь җырчы Лилия Муллагалиева, Харис Нигъмәтҗанов җитәкчелегендәге татар халык уен кораллары оркестры чыгышларын да тамашачылар яратып кабул иттеләр.

### ЧИЛӘБЕДӘ — I ТАТАР КОНГРЕССЫ

Чиләбе шәһәрендә өлкәнең I Татар конгрессы булып үтте. Бу тәбәктә җәмгысе 250 меңгә якын милләттәшебез яши.

Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев конгресста катнашучыларга котлау җибәрде. Монда ТР Мәгълүмат һәм матбугат Министры И. Әхмәтҗанов җитәкчелегендәге Татарстан делегациясе дә кунак булып барды. Делегатларга Татарстанның дәүләт җыр һәм бию ансамбле зур концерт күрсәтте.

### ТАТАРСТАНДА — МОҢ ТАНТАНАСЫ

27 — 31 март көннәрендә республикабызның Казан һәм Әлмәт шәһәрләрендә "Европа — Азия" III халыкара музыка фестивале булып узды. Анда, Япония, Америка, Бөекбритания һ. б. илләрдән килүче музыкантларның әсәрләре белән бергә, Татарстан композиторларының көйләре дә яңгырады. Кунаклар танылган композиторлардан Рәшит Калимуллин, Фасил Әхмәтов, яшьләрдән Резедә Ахиярова, Рөстәм Зарипов, Илфат Дәүләтшин көйләрен яратып тыңладылар. Р. Калимуллинның көйләре чит ил музыкантлары башкаруында да яңгырады.

### ТУКАЙГА БАГЫШЛАП

Күренекле әдипләрнең персональ энциклопедияләрен (энциклопедик характердагы сүзлек-белешмәләрен) әзерләп чыгару эше XX гасырның икенче яртысында шактый җанланып китте. Данте, Шекспир, Шиллер, Бернс, Диккенс, Лермонтов, Шевченко, Абайга багышланганнары инде басылып та чыкты. Үзбәкстанда Нәваи, Әзербайҗанда Низами энциклопедияләрен төзү дә тәгәлләнеп килә... Ниһаять, бездә — Татарстанда да — Г. Тукайның тормышы һәм иҗатына багышланган шундый уникаль басманы хәзерләргә нык-лап тотындылар. 1993 елда Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы Нил Юзиев җитәкчелегендә башланган бу мөһим эшне иҗади төркемгә керүче галимнәрдән Азат Әхмәдуллин, Резедә Ганиева, Марсель Әхмәтҗанов, Флүн Мусин, Флорид Әгъзамов, Зөфәр Рәмиев, Гали Арсланов, Фәрит Яхин, Фоат Галимуллин, Нәҗип Нәккаш, Гөлнур Гобәйдуллина, Заһир Шәйхелисламов һ. б. уңышлы дәвам иттерделәр. 1988 ел башында Г. Тукайга багышланган энциклопедик сүзлек-белешмә нәшер ителеп, бөек шагыйребезнең туган көнендә укучыларыбызга барып иреште.

### ДИССЕРТАЦИЯЛӘР ҮЗЕБЕЗДӘ ЯКЛАНА

Быел Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында, Россия Федерациясенең югары аттестация комитеты карары нигезендә, Диссертация Советы эшли башлады. Әлеге Советка Россия халыклары теле, әдәбияты һәм фольклористика белгечлекләре буенча "филология фәннәре кандидаты", "филология фәннәре докторы" дигән фәнни дәрәҗәләр алуга диссертацияләр яклату хокукы бирелде.

Диссертация Советының рәисе — академик Мирфатих Зәкиев, рәис урынбасары — профессор Фатих Урманчеев, гыйльми сәркатибе — филология фәннәре кандидаты Зөфәр Рәмиев.

## ЕРАК АРАЛАРНЫ ЯКЫН ИТЕП

Татар халкының киләчәге хакына җан атып йөрүче милләттәшебез, бүгенге көндә Алманиядәге Мюнхен шәһәрендә яшәүче Гали ага Акыш, хатыны Зарифа ханым белән бергә, Татарстанга кунакка килде. Алар 19 — 21 март көннәрендә Чаллыда булып, Г. Акыш исемен йөрткән мәктәп-лицей, шулай ук педагогия колледжы укучылары белән очраштылар, бүгенге татар яшьләре тормышы белән таныштылар.

## К. НАСЫЙРИ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ

Татарстан Мәгариф министрлыгы коллегиясенең чираттагы утырышында күренекле мәгърифәтче-галим Каюм Насыйри исемендәге еллык премиянең яңа лауреатлары билгеле булды. Беренче бүләк, яшь буынны тәрбияләүдәге уңышлары өчен, Балтач районының Карадуган ясле-бакчасы коллективына, икенче бүләк татар теле һәм әдәбияты буенча үзенчәлекле дәреслекләрнең авторлары — Казан дәүләт педагогия университеты проректоры Фираз Харисов белән галимә Чулпан Харисовага һәм язучы-галим Альберт Яхинга бирелде.

## МУЗЕЙДА ОЧРАШУЛАР

Күренекле рәссам-график Эрот Зариповның шагыйрь Равил Фәйзуллинга, аның якыннарына, якташларына багышлап, мәркәзебезнең Тукай музеенда ачылган яңа күргәзмәсе тамашачыларда зур кызыксыну тудырды. Ике ай дәвамында биредә меңләгән кеше булды. Алар арасында башкалабыз кунаклары, белемнәрен күтәрү өчен күрше республикалардан-өлкәләрдән килгән мөгаллимнәр, табиблар, эшче-хезмәткәрләр, югары уку йортлары студентлары, педколледж укучылары да бар иде. Күргәзмәгә килүчеләр алдында рәссам Э. Зарипов үзе һәм Р. Фәйзуллин чыгышлар ясап, тыңлаучыларны яңа иҗат иткән әсәрләре белән таныштырдылар, рәссамнарның һәм язучыларның иҗатлары, шулай ук "Казан утлары" журналының эшчәнлеге турында сөйләделәр.

### *ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНДӘ*

## ЮБИЛЯРНЫ КОТЛАУ

5 мартта Мәскәүдә, Советлар йортының Колонналы залында атаклы язучы — Социалистик Хезмәт Герое Сергей Михалковның тууына 85 яшь тулуга багышланган тантаналы кичә уздырылды. Төрле республикалардан килгән вәкилләр белән бергә, юбилярны Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев та кайнар котлады, аңа истәлекле бүләк тапшырды.

### *ТУГАНДАШ БАШКОРТСТАН ҖИРЕНДӘ*

## ЯҢАВЫЛДА — ӘДӘБИЯТ-СӘНГАТЬ КӨННӘРЕ

Башкортстанның Яңавыл шәһәре һәм районы хакимияте (җитәкчесе — Нәзир Зыязов) чакыруы буенча, яңавыллыларның Казандагы "Якташлык җәмгыяте" президенты — Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеев, туган ягында булып, күпсанлы укучылары белән якыннан аралашты. Район үзәгендә һәм авылларда — предприятие-учреждениеләрдә, мәдәният йортларында һәм мәктәпләрдә үткән очрашулар барышында күренекле әдип үзенең яңа әсәрләре белән таныштырды. Башкортстанның һәм Татарстанның атказанган артисты Фән Вәлиәхмәтов җитәкчелегендәге җырчылар һәм музыкантлар исә И. Юзеев шигырьләренә язылган җырларны башкарып, тамашачыларга тылсымлы моң бүләк иттеләр.

""Казан утлары" һәм аның дуслары" дигән исем астында үткән әлеге кичәләрне-очрашуларны, журналыбыз эшчәнлегенә бәйләп, язучы-мөхәррир Шаһинур Мостафин алып барды.

### *Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** Шәмаил. Рәссам Ф. Гыйрфанов эшеннән фотокүчермә.

# ЯҢА КИТАПЛАР

Рәдиф ГАТАШ. **Бу — Сиңа кылган догам.** *Шигырьләр, газәлләр, робагыйлар.* — Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. — 240 б., тиражы —3000 данә.




Танылган шагыйрь Рәдиф Гаташның бу китабына аның 1990 —95 елларда язылган яңа әсәрләре тупланган. Китап — алты лирик циклны эченә ала. Аларның һәркайсы бүгенге заман кешесенең үзенчәлекле мәхәббәт монологы булып яңгырый. Газәл, робагый, бәет, мәхәббәт хат-хитаблары кебек борынгы формаларда да авторның кызыклы табышлары бар. Алар, шагыйрьнең үзе билгеләп үткәнчә, "иске касәдәге яңа шәраб" шикелле...

Кайтыгыз, минем сөенең
Былтыргы бураннары!
Киңәйде, бигрәк киңәйде
Күңелнең урамнары...

Китапның редакторы — Г. Гыйльманов, рәссамы — Ф. Кадыйров.

* * *

Шамил МАННАПОВ. **Өндәге төшләр.** *Шигырьләр.* — Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. — 256 б., тиражы — 2000 данә.




Бу китапка шагыйрьнең төрле елларда язылган иң уңышлы лирик-фәлсәфи һәм юмористик шигырьләре, җырлары, риваять, әкият жанрында иҗат ителгән әсәрләре тупланган. Аларда замандашыбызның яхшы сүзгә, сөю-назга сусаган күңел тибрәнешләре, җәмгыятебездәге үзгәрешләрнең, бәйсезлек өчен көрәшнең, асылыбызга-иманыбызга кайту юлындагы каршылыкларның кеше җанында чагылышы тасвир ителә.

Китап Мансур Вәлинең "Шигырьне ни яшәтә?" дигән мәкаләсе белән ачыла. "Укучы инде игътибар иткәндер, — дип яза тәнкыйтьче: Шамил Маннапов гади итеп, йөрәккә ятышлы итеп яза. Аның шигъри тойгысы, кичерешс безнең күңелгә җай гына, ипле генә үтеп керә. Җиләс җил кебек кенә, сусаганда яратып эчелә торган чишмә суы кебек кенә... Менә шундый чакларда тагын бер мәртәбә уйлап куясың: шигъриятнең һәм гомумән әдәбият белән сәнгать әсәренең төп хасияте түгел микән мондый үзенчәлек?.."

Китапның редакторы — Ф. Зыятдинова, рәссамы — Д. Нәүрүзова.

Индекс 73210



Язучы Җәүдәт Дәрзаман

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARЬ
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)